

# КАЗАН УТЛАРЫ

6
ИЮНЬ
1982

Журналыбызның бу саны Чаллы төбәгендә яшәүче язучылар иҗатына багышлана.



Х. ЯКУПОВ. Чаллы сылулары.

Н. Курамшин фоторепродукциясе

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ

1922 елның май аеннан башлап чыга

6

1982

ИЮНЬ


## *Бу санда*


СССРның ТӨЗЕЛҮЕНӘ 60 ЕЛ

**Г. РӘХИМ.** Ил җырына кушыл, республикам! Шигырь . . . 3

**Р. К. БЕЛЯЕВ.** Батырлык һәм матурлык тантанасы . . . 4
**К. СИБГАТУЛЛИН.** Хыялыбыз башкаласы . . . 11
**Р. ВӘЛИЕВ.** Иске сәгать дөрес йөри. Повесть . . . 17
**Н. МАДЬЯРОВ.** Чаллы. Шигырьләр . . . 78
**Х. ХӨСНУЛЛИН.** Тукайның яңа ватаны. Шигырь . . . 79
**А. ЧУРБАНОВ.** Беренче җәй. Хикәя . . . 81
**Я. ИГӘНӘЙ.** Утлы корыч кебек... Шигырьләр . . . 87
**М. ГАЗИЗОВ.** Субайлар. Шигырьләр . . . 88

«ЛӘЙСӘН» ӘДӘБИ БЕРЛӘШМӘСЕ (ЧАЛЛЫ)

**А. САФИН.** Хыял. Хикәя . . . 90
**Р. СӘЛИМҖАНОВ.** Кичке аваз. Парчалар . . . 94
**М. САФИН.** Чаллы этюдлары . . . 98

«ОРФЕЙ» ӘДӘБИ БЕРЛӘШМӘСЕ (ЧАЛЛЫ)

**И. ЛИМОНОВА, Е. КУВАЙЦЕВ, Ю. МАЛКОВ, Н. АЛЕШКОВ, Р. АСЫЛБАЕВА, П. ЮЛАЕВ.** Шигырьләр . . . 101

«ДАНКО» ӘДӘБИ БЕРЛӘШМӘСЕ (ТҮБӘН КАМА)

**М. ФЕДОСЕНКО, Л. ВОЗДВИЖЕНСКИЙ.** Шигырьләр . . . 104

«КАМА ТАҢНАРЫ» ӘДӘБИ БЕРЛӘШМӘСЕ (ТҮБӘН КАМА)

**М. ШӘЙХИ, М. ХӘБИБУЛЛИН, А. МОРТАЗИНА, К. ЗИННӘТ, Р. ИМАЕВ, Р. РАХМАН.** Шигырьләр . . . 105
**Р. ХИСМӘТУЛЛИН.** Сусау. Хикәя . . . 109

ДУСЛАР ИҖАТЫ

**А. ХӘЛИМ.** Беренчеләр. Поэмадан өзекләр . . . 118
**Н. ШӘМСЕТДИНОВ.** АН-2. Шигырьләр . . . 121



КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ

ОЧЕРК ҺӘМ ПУБЛИЦИСТИКА

Г. КАШАПОВ. Ашкын йөрәк . . . 123
Р. ВӘЛИЕВ. Сиреньнәр . . . 130
Ф. АБДУЛЛИН. Көмеш тәңкәле нигез . . . 134
Ф. ДУНАЙ. Дәү апа . . . 137

С. РАДЗИЕВСКАЯГА 90 ЯШЬ

Л. ИХСАНОВА. Олы бәхет иясе . . . 143
С. РАДЗИЕВСКАЯ. Мең еллык төн. Романнан өзек 146

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Т. ГАЛИУЛЛИН. Еллар чакырдылар еракка . . . 150
Н. ЛАИСОВ. Шигърият — табигать сагында . . . 160
М. ВӘЛИЕВ. Авылыбыз моңын югалтсак . . . 167

КИТАП КҮЗӘТҮ

Ф. ЗӨЛКАРНӘЕВ. Соклану сәләте . . . 176
Р. МОСТАФИН. Беренче заттан . . . 179

Кечкенә рецензияләр . . . 182

СӘНГАТЬ

Г. ВӘЛИЕВА. Тереклек агачы . . . 186

НӘНИЛӘР ДӨНЬЯСЫ

Р. БӘШӘР. Кызык булыр иде. Шигырьләр . . . 190

Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары . . . 191

Баш редактор: ЗӘКИ НУРИ

Редколлегия: ШАМИЛ БИКЧУРИН, РАЗИЛ ВӘЛИЕВ, АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ, МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ, ЗӨЛФӘТ, ФӘРВАЗ МИҢНУЛЛИН, ТУФАН МИҢНУЛЛИН, РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ *(баш редактор урынбасары)*, РӘФЫЙК НӘФИКОВ, АТИЛЛА РАСИХ, СИБГАТ ХӘКИМ, ФАИЛ ШӘФИГУЛЛИН, НИЛ ЮЗИЕВ

Техник редакторы *Р. Сөләйманова*
Корректорлары *Ф. Кадыйрова, Г. Салихҗанова*

Редакциянең адресы: Казань, 420066, ул. Декабристов, 2.

**Телефоннар:** баш редактор — 3-07-60, баш редактор урынбасары — 3-07-09, җаваплы секретарь — 3-07-09, проза бүлеге — 3-07-61, поэзия бүлеге — 3-07-61, тәнкыйть бүлеге — 3-07-63, сәнгать бүлеге — 3-07-63, очерклар бүлеге — 3-07-61, хатлар бүлеге — 3-07-63, корректорлар — 3-07-65, техник редактор — 3-07-65, машинисткалар — 3-07-60.

Производствога бирелде 19/II-1982 ел. Басарга кул куелды 18/V-1982 ел. ПФ 09024. Кәгазь форматы $70 \times 108^{1}/_{16}$. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 65 049 экз. Заказ Ю-74. Бәясе 90 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1982 ел.

# СССРның төзелүенә 60 ел

## Гәрәй Рәхим

### Ил җырына кушыл, республикам!

Татарстан белән Сахалинны
Бәйли алмый кышлар һәм язлар.
Мондый озын, ерак араларны
Тоташтыра бары «КамАЗ»лар,
Без ясаган җитез «КамАЗ»лар.

Татарстан, кыйтга араларын
Үталмассың мең ат җигеп тә —
Ил җегәре булган моторларга
Көч бармаса әгәр нефтьтән,
Без бораулап тапкан нефтьтән.

Татарстан, синең чын йөзеңне
Танымаслар иде күп илләр —
Тудырмасаң әгәр алтын куллы
Хатын-кызлар, батыр ул-ирләр...
Тудырдың син илгә Җәлилләр!

Татарстан, сине бөек Ленин
Мәңгелек бәхеткә бәйләде.
Ил җырына кушыл, республикам:
СССРның бу зур бәйрәме,
Алтмыш еллык олы бәйрәме!

Р. К. Беляев,
КПССның Чаллы шәһәр комитеты
беренче секретаре,
РСФСР Верховный Советы депутаты

# БАТЫРЛЫК ҺӘМ МАТУРЛЫК ТАНТАНАСЫ



1969 елның 13 декабрендә иске Чаллы шәһәре читендә Михаил Носков экскаватор чүмече белән туң җирне умырып алды да машина әрҗәсенә китереп салды. Гасырлар буе тын яткан Чаллы ягы нәкъ менә шушы көнне, яңа туган сабый кебек, үзенең дөньяга килүе турында хәбәр итеп, бар тирәгә аваз салды. «Яр Чаллы», «КамАЗ» дигән сүзләр телләрдән телләргә күчеп сөйләнә башлады. Нәкъ менә шушы көнне Чаллы каласының яңа тарихы башланды.

«Яр Чаллы. Халкы 720 ир-ат һәм хатын-кыздан гыйбарәт. 136 йорты, чиркәве, училищесы, су тегермәне, 18 кибете, җомга көнне җыела торган базары, өч ярминкәсе бар. Кама елгасы буенда — пристань. Халкы, иген игүдән тыш, бурлак булып хезмәт итә, пристаньда эшли». 1888 нче елны басылган бер географик сүзлектә Чаллы шәһәре турында менә шундый сүзләр язылган.

Иске Чаллы башка провинция шәһәрләреннән бер ни белән дә аерылмыйча, гасырлар буе шулай үз көенә яшәп яткан. Бөек Октябрьның давыллы җилләре әлегә кадәр дөньяга билгесез бу төбәкне дә йокысыннан уята. Комдив Азинның атаклы «тимер дивизиясе» революциягә каршы чыккан дошманнар белән сугыша, Колчак яулары белән көрәшкә меңләгән ярлы-ябагай күтәрелә.

Революция җиңеп чыккач, социалистик төзелеш бишьеллыклары башлана. Чаллы яклары әле озак еллар буе Татарстанның ерак почмакларыннан берсе булып кала бирә. Җәй көне монда бары тик пароход белән генә килеп була, ә кышын 180 чакрымдагы Бөгелмә тимер юл вокзалына йөриләр. Озакламый күршедә генә нефть башкаласы Әлмәт төзелә башлый, нефтехимиклар шәһәре Түбән Кама салына, Алабуга, Зәй, Лениногорск калалары үсә.

Кама буенда зур йөк автомобильләре комплексы төзү турында карар чыккач, Чаллы каласы, әкият баһадирлары сыман, ел үсәсен көн үсә башлап, бөтен дөньяга танылa. Әгәр 1970 елны шәһәрдә 30 мең кеше яшәгән булса, бүген инде бездә 400 мең чамасы кеше исәпләнә. Дөньядагы бер шәһәр дә тиз үсеш ягыннан Чаллы белән тиңләшә алмый.

Ә ни өчен зур йөк автомобильләре комплексын нәкъ менә Чаллыда салырга булдылар соң?

Илебез картасына игътибар белән күз салыгыз әле. Совет власте елларында гына күпме яңа шәһәр калкып чыккан: Магнитогорск, Комсомольск-на-Амуре, Братск, Түбән Кама, Тольятти... Алар берсе дә гади шәһәрләр генә түгел, алар — гигант төзелеш үзәкләре, илебезнең социалистик үсеш тарихын, энергетик куәтен билгели торган факторлар, алар — бөек Ленин идеяләренең тормышка ашуын күрсәткән ышандыргыч мисаллар. Яр Чаллы шәһәре һәм Кама автомобиль гиганты да нәкъ менә партиябез һәм хөкүмәтебезнең ил-халык мәнфәгатьләрен кайгырту юлында башкарган тагын бер бөек казанышы булып дөньяга килде.

Ә чыннан да, КамАЗны ни өчен Чаллыда салырга булдылар соң әле?

Зур йөк автомобильләре комплексы салу турындагы мәсьәлә кузгалгач, СССР Госпланы дистәләгән вариантны тикшереп карады. Электрон-хисаплау машиналары әлеге вариантларны һәрьяклап чагыштырды, һәм бу ярышта моңа кадәр бөтенләй диярлек билгеле булмаган гап-гади Чаллы шәһәрчеге җиңеп чыкты. Баксаң, Татарстандагы Чаллы шәһәре илебезнең үзәк өлешендә, энергетик комплекслар уртасында урнашкан икән. Чимал ташу һәм әзер продукцияне озату өчен янәшәдә генә иң арзан транспорт юлы — Кама, Агыйдел, Вятка, Идел елгалары агып ята. Якында гына Горький, Ульяновск, Ижевск, Тольятти кебек «автомобиль шәһәрләре» булу да бик мөһим роль уйный. Бу регионда нефть һәм газ чыга, Зәй ГРЭСы, Түбән Кама ГЭСы, төзелә, монда СССР промышленность төзелеше министрлыгының «Татэнергострой», «Камгэсэнергострой» кебек куәтле оешмалары бар. һәм, ниһаять, Татарстанның үзендә һәм янәшә өлкәләрдә шәһәр төзелешләре өчен җитәрлек эшче көчләр тупларга була. Менә шуларның барысын исәпләп-чагыштырып караганнан соң, Чаллы варианты иң кулай дип табылды.

1970—1971 елларда КамАЗ төзелешенә килгән кешеләрне Чаллы җирендә зур сабантуе кунаклары кебек каршы алдылар. Автобуслар җитмәгәндә аларны йөк машиналарына утыргычлар куеп ташыдылар, тулай тораклар, йортлар тапшырылганчы, төзүчеләр якын-тирә авылларда торып эшләделәр. Ул көннәрдә кадрлар бүлеге умарта оясы сыман кайнап торды. Татарстан районнарыннан һәм күрше-тирә республикалардан, Казагыстаннан һәм Камчаткадан, Балтик буеннан һәм Кавказ якларыннан — гомумән, илебезнең барча якларыннан җыелган романтик йөрәкле кешеләр өчен КамАЗ төзелеше ил күләмендәге Сабан туе мәйданына әверелде.

КамАЗны төзи башлауга дистә елдан артык вакыт узды. Шул вакыт эчендә зур йөк автомобильләре чыгаручы автомобиль гиганты сафка басты, һәм ул көннән-көн куәтләнә, ныгый бара. КамАЗ төзүне КПСС Үзәк Комитеты Генеральный секретаре, СССР Верховный Советы Президиумы Председателе Л. И. Брежнев «Кама буендагы батырлык» дип атады. Төзелешнең беренче көненнән үк КПСС Үзәк Комитеты, партиянең Татарстан өлкә комитеты безнең һәр уңышыбызны хуплап, көндәлек эшебездә юнәлеш биреп, практик ярдәм күрсәтеп тордылар.

КамАЗ төзүчеләре беренче казык каккан көннән үк үзләренең никадәр зур эшкә алынганнарын аңлап, янып, илһамланып эшләделәр һәм яшәделәр. Коммунистлар һәм комсомоллар һәр хезмәт батыр-

лыгының үзәгендә булдылар, һәр яңа башлангычны хуплап, рухландырып тордылар. Бары тик шундый оештыручылар, коммунистлар, фидакарь төзүчеләр, эшчеләр булганда гына партиябез һәм хөкүмәтебез куйган гигант бурычларны тормышка ашырырга мөмкин иде.

Чаллы шәһәре илебез шәһәрләренең берсенә дә охшамаган. Чөнки ул үзенең проектында ук бүгенге көн шәһәре дип кенә түгел, ә киләчәк шәһәре итеп планлаштырылган иде. Әгәр дә бүтән зур төзелешләр палаткалардан башланган булса, Чаллы кешеләре беренче көннәрдән ук диярлек менә дигән йортларга кереп урнаштылар. Әле моңа кадәр күрелмәгән комплекслы төзелеш — шәһәр белән автогигантны бер үк вакытта салу — безнең эшне тагын да ныграк катлауландырды, партия һәм совет органнарына, хуҗалык оешмаларына тагын да зуррак җаваплылык өстәде. Киләчәк шәһәрләрен корганда Чаллы каласын салу тәҗрибәсе әле кат-кат өйрәнелер. Ләкин шуны да онытмаска кирәк: Чаллы үзе дә буш җирдә калкып чыкмады, ул моңа кадәр төзелгән шәһәрләр тәҗрибәсеннән чыгып салынды. Автогигант һәм шәһәр салучыларның хезмәт батырлыгы турында сөйләгәндә без Магнитка һәм Днепрогэс төзү, чирәм җир күтәрү, Татарстан нефтен үзләштерү, Түбән Кама нефтехимия каласын кору елларында туган күркәм традицияләр, фидакарьлек үрнәкләре турында уйлыйбыз, Кама буендагы каһарманлык шул традицияләргә барып тоташа дип саныйбыз. Чаллы җирендә СССР халыкларының какшамас дуслыгы, аларның бер-берсенә ярдәм кулы сузарга әзер торулары тагын бер тапкыр исбат ителде, партиябез алып барган милли политиканың дөреслеге тагын бер тапкыр расланды. Илебезнең төрле якларыннан: барлык республикалардан, өлкәләрдән Кама буендагы бөек төзелешкә җитмешкә якын милләт вәкиле килде. Аларның күпчелеге монда бөтенләйгә берегеп калды, гаилә корды. Автогигантны тизрәк сафка бастыру өчен илебезнең бар ягыннан Чаллыга төрле материаллар, җиһазлар һәм техника агылды. КамАЗны, чын мәгънәсендә, бөтен ил төзеде.

КамАЗ ул — заводлар комплексы гына түгел, ә кешеләр өчен зур тормыш мәктәбе, язмышлар яңарган төбәк тә. Монда комсомоллар белән яшьләр, шәһәр һәм автогигант кору белән бергә, рухи чыныгу да алдылар, киләчәк язмышларының ныклы нигезен салдылар. Чаллыда югары сыйфатлы эшче кадрлар, партия, совет, хуҗалык җитәкчеләре үсеп чыкты, бердәм коллективлар оешты. Моннан дистә ел элек комсомол әйдәүчеләре, төзелештә башлап йөрүчеләр булып эш башлаган Ю. И. Петрушин, Ф. З. Бакеев, М. Ш. Бибишев, Т. Н. Зәйнуллов, Н. И. Ашимова кебек коммунистлар бүген инде автогигант производствосы, шәһәр төзелеше җитәкчеләре булып үсеп җиттеләр.

Инде хәзер, КамАЗның икенче чираты сафка басып, 400 мең кешелек шәһәр салынгач, узган юлга борылып карап, эшләнгән эшләргә кайбер нәтиҗәләр ясарга да мөмкиндер. Ә ул нәтиҗәләрнең иң зурысын, һичшиксез, сафка баскан куәтле автомобиль комплексы һәм бүгенге көндә халык хуҗалыгында эшләүче 300 меңгә якын йөк автомобиле тәшкил итә. Хәзер инде илебезнең йөк ташучы автомобильләр паркын КамАЗдан башка күз алдына да китереп булмый. Узган 1981 елда барлыгы 85120 автомобиль, 100 мең двигатель җитештерелде. КамАЗның баш конвейерыннан һәр көнне 300 гә якын машина чыгып торды.

КамАЗ өчен соңгы еллар заманның иң камил технологиясен үзләштерү, фән-техника казанышларын производствога кертү, тармакташ предприятиеләр белән бәйләнешне ныгыту, эшнең сыйфаты һәм нәтиҗәлелеге өчен көрәш, хезмәт шартларын яхшырту, производство белән идарә итүне камилләштерү еллары булды.

Автогигант белән янәшә яңа шәһәр аякка басты, кешеләрнең яшәү шартлары көннән-көн яхшыра барды. Әле моннан берничә ел элек

кенә безнең хәтта ашханәләребез, кинотеатрларыбыз, культура сарайларыбыз да юк иде. Чаллы төзүчеләре авырлыклардан зарланып, сукранып утырмадылар, җиң сызганып эшкә тотындылар. Шуны да әйтергә кирәк, бу объектларның күбесе яшьләр инициативасы белән шефлык тәртибендә эштән соң салынды. Һәм менә хәзер безнең шәһәрдә биш миллион квадрат метр чамасы торак мәйданы, йөздән артык балалар учреждениесе, 39 мәктәп, берничә стадион, больницалар, йөзләгән кибет, политехника институты, училищелар, техникумнар, культура сарайлары, кинотеатрлар бар.

Моңа кадәр күрелмәгән тизлек белән әлегедәй зур эшләр башкарып чыгу өчен, шулай ук шәһәр яны авыл хуҗалыгы зонасын да үстерергә кирәк иде.

Теплица комбинаты, кош фабрикасы, бройлер фабрикасы, терлекчелек комплекслары кебек объектлар КамАЗ тизлеге белән корылды, авыллар арасына асфальт юллар салынды, өр-яңа поселоклар төзелде. КамАЗ төзелә башлаган елны Чаллы (хәзерге—Тукай) авыл хуҗалыгы районы 12 мең тонна сөт, 3 мең тонна чамасы ит, 1644 тонна бәрәңге һәм ярты миллионга якын йомырка җитештергән иде. Шәһәрне азыктөлек белән тәэмин итү өчен берничә ел эчендә авыл хуҗалыгы продуктлары җитештерүне 10—12 мәртәбә арттыру бурычы куелды. КПССның Татарстан өлкә комитеты, ТАССР Министрлар Советы, КПССның Чаллы шәһәр комитеты авыл хуҗалыгын үстерүгә иң мөһим бурычларның берсе итеп карадылар, аны һәрчак игътибар үзәгендә тоттылар.

КамАЗ корылган елларда авыл җирендә 80 мең квадрат метр чамасы торак йорт, 4080 урынлы гомуми урта белем бирү мәктәпләре, 1500 урынлы мәктәпкәчә яшьтәге балалар учреждениеләре, 10 культура йорты, 4 сәламәтлек саклау объекты җиткерелде, капиталь төзелеш күләме, 1965 ел белән чагыштырганда, 25 мәртәбәгә артты. Дистә ел эчендә Чаллы шәһәрендәге халык саны 11 тапкырга үссә, шул чорда Тукай районы җитештергән авыл хуҗалыгы продуктлары 12 мәртәбә артты.

Җырларда җырланган, канатлы кош сыман илләр чикләрен үтеп бар дөньяга таралган «КамАЗ» дигән кыска гына сүзгә партия һәм хөкүмәтебезнең кайгыртучанлыгы, урындагы оешмаларның бер йодрык булып тупланып үз-үзләрен аямыйча көн-төн эшләүләре, йокысыз төннәр һәм борчулы көннәр, көндәлек кыенлыклар һәм җиңү шатлыклары сыйган. Шәһәребезнең 20 мең коммунисты, 60 меңгә якын комсомолы КПССның XXVI съезды карарларын тормышка ашыру өчен барган көрәшнең һәрчак алгы сызыгында булдылар. Партиянең Комсомол, Автозавод, Тукай район комитетлары, 213 башлангыч партия оешмасы эшчеләрне туплау, аларның һөнәр осталыгын арттыру, бердәм коллективлар оештыру, производствоның җитештерүчәнлеген арттыру, идея-эстетик тәрбия бирү өлкәләрендә гаять мөһим чаралар үткәрде.

Җитмешенче еллар башында, КамАЗ әле яңа төзелә башлаган чакта, күпләр өчен ул хыялга сыймас фантастик корылма булып тоелган иде. Без партиябез һәм хөкүмәтебез каршында биргән вәгъдәбезне үтәдек. Бу титаник эштә башлангыч партия оешмаларының, КПСС район комитетларының өлеше гаять зур булды. Төзелеш чорында партия эшенең яңадан-яңа формалары уйлап табылды, коммунистлар һәрчак иң кыен урыннарда булдылар, хезмәт батырлыгы үрнәге күрсәттеләр. Комсомол чакыруы белән КамАЗга килгән, әле тормыш тәҗрибәсе дә тупларга өлгермәгән яшьләр дистә ел эчендә ил-җир язмышын үз кулларында тотардай булып җитештеләр, хезмәт батырларына әйләнделәр, коммунистлар рухы белән коралландылар. Р. Га-

ниев, В. Филимонов, Г. Баштанюк, А. Вәлиева, Е. Вдовина, Р. Сәләхов, У. Наурбиев, А. Мальнев, В. Мәүликов, Л. Белоусова, Ш. Хөснетдинов кебек батырлар КамАЗ белән бергә үстеләр, аларның исеме КамАЗ даны белән бергә бөтен илгә таралды. Язучыларның, сәнгать осталарының бүгенге совет чынбарлыгын тасвирлаган әсәрләре үзәгенә нәкъ менә шундый геройлар алынырга тиеш. Алар поэма яисә пьеса, повесть яки роман герое булырга лаеклы.

Кама автомобиль гиганты һәм ул чыгарган продукция турында инде күп язылды. Әйе, эшләнгән эшләр бик күп, әмма алда торган бурычлар да зур, киң колачлы. Киләчәктә без шәһәр төзелешенә аерата зур игътибар бирәчәкбез. Чаллы каласы илебез шәһәрләре төзелешендәге бөтен казанышларны истә тотып салынды дидек. Ләкин Чаллы бербөтен шәһәргә әверелеп җитсен өчен әле безгә бик күп көч түгәргә кирәк булачак. Әлегә исә безнең шәһәребез ике өлешкә — иске һәм яңа шәһәргә бүленгән. Алар арасындагы иске йортларны сүтеп, чокырларны һәм ерганакларны күмеп, иркен юллар, киң проспектлар саласы, агачлар утыртасы бар. Без Чаллыны киләчәктә яшеллеккә күмелеп утырган урман-шәһәр итеп күз алдына китерәбез. Ә хәзергә әле ул, үзәк өлешен һәм аерым микрорайоннарын санамаганда, гаҗәеп зур төзелеш мәйданын хәтерләтә.

Монда һәркем үзен кирәк саный,
Йолдыз сыман шул уй кабынган.
Паролебез — Чаллы, КамАЗ безнең,
Илләр таный безне адымнан.

Чаллы шәһәренең киләчәге турында уйлаганда күңелгә ирексездән шулай шигъри образлар килә... 10—15 елдан соң җәйге аяз бер көнне Кама елгасы буйлап килгән кеше яр буенда биек җилкәннәрен күтәргән галәмәт зур ак кораб күреп таң калыр. Ләкин бу күз алдында чагылган сихри мираж да, әкиятләрдәге тылсымлы кораб та булмас, ә безнең ак калабыз яңа Чаллы ерактан шулай мәһабәт һәм соклandыргыч матур булып күренер.

Яр буйлап тезелеп киткән егерме бишәр катлы күркәм йортлар, күккә ашкан кунак йортлары, тимер юл вокзалы, елга порты салынгач, Чаллы каласы, тәгәлләнгән бербөтен ансамбль кыяфәте алып, кешеләрне ерактан ук кызыктырып, үзенә чакырып торыр. Хәзерге Мәләкәс инеше җәелеп, зур елгага әверелер. Аның ярында турист комплекслары, яхт-клуб, йөз мең урынлы стадион, өч заллы йөзү бассейны һәм дистәләгән спорт заллары корылачак. Кама аша салынган күпердән автомобильләр, поездлар йөри башлагач, Чаллы белән Казан, Мәскәү һәм башка шәһәрләр арасы бик күпкә якынаячак.

«Чаллы-2» елга вокзалыннан җәяүләп кенә иске шәһәрнең мемориаль комплексына килеп булачак. Мондагы борынгы йортларның иң матурлары реставрацияләнәчәк, тузганнары сүтелеп, алар урынына Татарстан районнарындагы милли архитектура үрнәкләре саналган йортлар һәм каралтылар күчереп салыначак. Иске Чаллы, шулай итеп, тәэсирле зур милли-этнографик музейга әвереләчәк. Аның территориясендә шәһәр музее, күргәзмә залы, рәссамнар һәм скульпторлар өчен остаханәләр, чәйханәләр, милли бүләкләр сата торган кибетләр урнашыр.

«Чаллы-2»дән су трамваена утырып, «Чаллы-1» вокзалына төшкәч, туп-туры шәһәрнең административ үзәгенә килеп керербез. Үзәк мәйданны шәһәр оешмалары бинаалары, 1 миллион томга исәпләнгән китапханә, Кияү һәм Кәләш сарае, 24 катлы түгәрәк кунак йорты, бербер артлы тезелеп киткән фонтаннар, бөек юлбашчыбыз В. И. Ленин һәйкәле бизәр.

Административ үзәкне узгач, сәүдә урамы аша Театр мәйданына

килеп чыгасың. Бу мәйданда өч заллы кинотеатр, 2500 урынлы концерт залы, музыкаль комедия театры һәм Культура сарае төзеләчәк...

Чаллының киләчәге турында сәгатьләр, көннәр буе сөйләп булыр иде. Шәһәребез проектын төзегән инженерлар һәм галимнәр хәтта үзләре дә аның үсеш күләмен күреп шаккаталар. Чаллы проекты башта 400 мең кешегә исәпләнгән иде, ә без инде бүген үк ул чикне узып барабыз. Хәзер шәһәребезнең 800 мең кешегә исәпләнгән генераль проектын төзү башланды. Күп тә үтмәс, бу кысалар да тараер, Чаллы миллион кешеле шәһәргә әверелер.

Шәһәр һәм автогигант белән бергә Чаллыда коммунистик җәмгыять төзүче яңа буын кешеләр дә үсә. Аларның рухи ихтыяҗларын канәгатьләндерү, бөтен яктан камил, гармонияле совет гражданины тәрбияләүне без үзебезнең иң зур бурычыбыз дип саныйбыз.

Яшь буынны тәрбияләүнең иң нәтиҗәле ысулы — хезмәт тәрбиясе. Бу яктан караганда Чаллы җире үзенең нинди зур тормыш мәктәбе икәнен исбат итте инде. Тугызынчы һәм унынчы бишьеллыклар чорында хөкүмәт бүләкләренә лаек булган ун меңгә якын кешене әлеге хезмәт һәм тормыш мәктәбенең отличниклары дип тулы ышаныч белән әйтеп була. КамАЗның икенче чиратын тапшыру чорында күрсәткән хезмәт батырлыклары өчен биш меңгә якын кеше орден һәм медальләр белән бүләкләнде, биш кеше Социалистик Хезмәт Герое исемен алды.

КамАЗ һәм шәһәр төзү чорында кичергән кыенлыкларыбыз һәм яулаган җиңүләребез турында сөйләгәндә, язучыларга, рәссамнарга, композиторларга, артистларга иң олы рәхмәт хисләребезне җиткерәсем килә. Алар беренче нигез ташы салынганнан алып, бүгенге көнгә кадәр безнең иң якын ярдәмчеләребез булдылар, үзләренең әсәрләре һәм ялкынлы сүзләре белән эшчеләрне һәм төзүчеләрне, инженер-техник работникларны һәм җитәкчеләрне яңадан-яңа җиңүләргә рухландырып тордылар. Мәскәү, Ленинград, Казан шәһәрләренең әдәбият-сәнгать осталары булышлыгы белән безнең үз шәһәребездә дә озаклаплый профессиональ иҗат оешмалары, йөзләгән үзешчән сәнгать коллективлары барлыкка килде.

Шулай бервакыт КПСС шәһәр комитеты киңәшмәсенә төзүчеләр һәм эшчеләр белән бергә без үзешчән сәнгать осталарын, клуб җитәкчеләрен, музыкантларны, яшь язучыларны да чакырдык. Кайбер хуҗалык җитәкчеләре башта моңа гаҗәпләнеп калганнар иде. Ә инде КамАЗ төзергә килгән йөз меңләгән яшь буын вәкилен идея-эстетик, рухи тәрбияләү зарурлыгы турында зурдан кубып сөйли башлагач һәм әдәбият-сәнгать осталарының бу өлкәдә нинди эш башкара алулары турында басым ясап әйткәч, киңәшмә эше тагын да җанланыбрак китте.

Шәһәрдә яңа үзешчән театрлар, вокаль-инструменталь ансамбльләр, хореография коллективлары, халык уен кораллары оркестры барлыкка килде, үзешчән композиторлар, яшь рәссамнар, музыкантлар, җырчылар, язучылар һәм шагыйрьләр үсеп чыкты. «Ләйсән» һәм «Орфей» әдәби берләшмәләренә йөрүче яшь язучыларның әсәрләре район һәм республика газет-журналларында гына басылып калмыйча, үзәк матбугатта да бик еш дөнья күрә башлады, бер-бер артлы аларның коллектив җыентыклары, соңрак үз китаплары чыкты. 1980 елның башында РСФСР Язучылар союзы идарәсе карары белән Чаллы язучылар оешмасы ачылгач, тәҗрибәле каләм осталары һәм яшь талантлар өчен зур әдәби проблемалар турында бергә-бергә фикер алышу, берберсенең әсәрләрен уртага салып сөйләшү, профессиональ осталыкларын арттыру, тормыш белән әдәбият арасындагы бәйләнешләрне тагын да ныграк ныгыту мөмкинлекләре күбәйде.

Хәзер Чаллы язучылар оешмасында СССР Язучылар союзының 9 члены, 200 дән артык яшь һәм башлап язучы исәпләнә. Филология

фәннәре докторы тәнкыйтьче Тәлгат Галиуллин, язучылар Эдуард Касыймов, Кадыйр Сибгатуллин, Нәҗип Мадьяров, Мәхмүт Газизов, Равил Вәлиев, Рахмай Хисмәтуллин һәм алар белән янәшә торып иҗат итүче Ямаш Игәнәй, Газиз Кашапов, Наип Лаисов, Хәниф Хөснуллин, Александр Чурбанов, Инна Лимонова, Евгений Кувайцев, Николай Алешков, Рафис Сәлимҗанов, Альберт Сафин кебек яшь талант ияләре КамАЗ елъязмасына үзләренең лаеклы өлешләрен керттеләр. Аларның күбесе хаклы рәвештә күкрәкләрендә «КамАЗ төзелеше ударнигы» значогын йөртә. Шагыйрь һәм прозаик Разил Вәлиев оешмага җитәкче булып килде. Язучылар оешмасы көннән-көн ныгый бара, хәзер инде ул шәһәр күләмендә үткәрелгән бер генә зур чарадан да, бер генә олы вакыйгадан да читтә калмый. Язучылар һәм үзешчән сәнгать осталары кешеләрнең рухи ихтыяҗларын канәгатьләндерү, аларга идея-эстетик тәрбия бирүнең никадәр кирәкле, зур һәм катлаулы эш икәнен аңлап, аны образлы телдә «КамАЗның өченче чиратын төзү» дип атыйлар.

Моңа кадәр эшләгән эшләренә югары бәя биргән хәлдә, без язучылардан һәм культура фронты хезмәткәрләреннән әле КамАЗ киңлегенә тиң әсәрләр, КамАЗ төзүчеләре һәм эшчеләре хезмәтенә тәңгәл килерлек ялкынлану, илһамлану көтәбез, киләчәктә дә алар халыкның, партия һәм совет органнарының ышанычлы ярдәмчеләре булырлар дип уйлыйбыз.

Безнең алда торган бурычлар гаять зур. Унберенче бишьеллыкның иң хәлиткеч елларыннан берсе булган 1982 елда, СССРның 60 еллыгын бәйрәм иткән юбилей елында, халык хуҗалыгы өчен 90 мең КамАЗ автомобиле чыгару, яңа модификацияләрне серияле эшләүне үзләштерү, машиналарның сыйфатын яхшырту шәһәр партия оешмасының игътибар үзәгендә булачак.

Төзү һәм монтаж оешмалары да моңа кадәр алган темпны киметмичә эшләргә йөкләмә алдылар. Быел алар 300 миллион сумнан артык төзү-монтаж эшләре башкарырга, КамАЗ объектларында һәм транспорт электро-җиһазлары заводында яңа производство куәтләрен сафка кертергә, Татарстан атом электростанциясе төзү эшен башларга тиешләр. Шулай ук Түбән Кама ГЭСында дүрт агрегатны файдалануга тапшырырга, Кама аша күпер салуны төгәлләргә, катыргы-кәгазь комбинатын кора башларга кирәк. Шәһәр төзелешендә йөз миллион сумлык төзү-монтаж эшләре башкарып, 425 мең квадрат метр торак мәйданы, ике мәктәп, ун балалар комбинаты, берничә культура һәм халыкка хезмәт күрсәтү объекты тапшырасыбыз бар. Шәһәр халкын яшелчә, бәрәңге, ит-сөт продуктлары белән тәэмин итү өчен Тукай районы хезмәтчәннәренә дә җиң сызганып эшләргә туры киләчәк.

Йөз меңләгән эшчеләрне, төзүчеләрне, инженер-техник хезмәткәрләрне берләштергән автозавод коллективлары, төзелеш оешмалары, шәһәр яны зонасы хуҗалыклары бу җаваплы планнарны үтәү өчен үзләренең көч-куәтләрен, иҗат дәртләрен кызганмаслар дип ышанабыз.

Күргәнегезчә, безнең яулаган җиңүләр һәм уңышлар, ирешелгән батырлыклар белән юанып утырырга вакытыбыз юк. Чаллы төзүчеләрен, КамАЗ эшчеләрен алда яңа җиңүләр, яңа батырлыклар көтә!

Совет кешеләренең хезмәт батырлыгы һәм күңел матурлыгы тантанасы булачак Яңа Чаллы каласы салу һәм дөньяда тиңе булмаган автомобиль гиганты — КамАЗның яңа куәтләрен сафка бастыру эше дәвам итә. Без аны киләчәк буыннарга тапшырасы иң кадерле мирасыбыз, В. И. Ленин идеяләренең дөреслегенә мәһабәт бер һәйкәл булырлык итеп төзибез.

Кадыйр Сибгатуллин

# ХЫЯЛЫБЫЗ БАШКАЛАСЫ

## Баш урам

Хәбәрләр күп.
Хәбәрләр тиз килә.
Соңга калмый хәзер соңгы хәбәр.
Җимерелгән дип килә. Килми әле
төзелгән дип берәр яңа шәһәр.
Кемнең генә йорты тетрәнсә дә
үзәкләрне ала өзеп-өзеп.
Шәһәрләрнең төне тыныч түгел,
җир сулышы һаман өзек-өзек.
Шәһәрләр күп. Кемгә нинди зыян
кайбереннән калса зират кына?!
Бетончыга эш бар... утрауларда...
Бетончыга эш бар: җир астында...
Төзүчегә
якты дөнья кирәк, тирән һава.

... Күп шәһәрләр карый шуңа күрә
Көнчыгышка,
Көнчыгышка таба!

Җир астына түгел,
җир өстенә.
Көмеш сулар аккан ярлар буйлап.
Үткәннәрне белә, күрә торып,
бүгенгене, киләчәкне уйлап.
Биек ярлар буйлап, калку җиргә
салабыз без аның һәрбер йортын:
безгә дә бар дөнья күренеп торсын,
һәм безне дә дөнья күреп торсын!

Су буена, ярга, калку җиргә!
Кояш, һава кирәк тәрәзәгә!
Күрсен дөнья: киләчәккә безнең
бу ышаныч нинди дәрәҗәдә!
Табылмаслык булып югалганын...
Үләр хәлдән терелә алганнарын —
беләбез без кайбер шәһәрләрнең
сызымнарда гына калганнарын.
Бик беләбез: кешенеке кебек
шәһәр язмышы да каһәрләнгән.

Шуңа, дибез — безнең кешелеклелек
күренеп торсын безнең шәһәрләрдән!

Яңа Чаллы үзәгеннән үтә.
Юк, башлана Чаллы шул урамнан.
Без Тынычлык проспекты дибез,
зур ул аннан, проспектлардан.
Кайда аның иң беренче йорты? —
шәһәребез саен бар ул урам.
Шул бер урам — барыннан да зуррак —
дәүләтебез буйлап уза урап.

Һава тирән. Ярлар җиләс тора.
Иркен сулый монда Җирнең җаны.
Үзәк урамына — дәвамына
ташлар тезә бүген Яңа Чаллы.
Без Тынычлык проспекты дибез.
Аңа тоташ һәр урамның башы.
Һәр шәһәрдә,
тыныч ятсын диеп,
иплән сала кеше һәрбер ташын.
Планетаның чиксез бу урамын
күптән төзи инде безнең халык:
һәрбер ташын йөрәгеннән алып,
һәрбер ташын йөрәгенә салып!
Яңа Чаллы үзәгеннән үтә
ераккарак, һаман ераккарак.
Төзүченең йөрәк тибешендә:
«Өзелмәсен — дөнья тора карап!»
Ышанабыз: ялгышалар күпләр.
Ышанмыйбыз дөнья ялгышына
Ышанабыз — кешеләрнең, Җирнең,
шәһәрләрнең якты язмышына!
Төзүче без!
Димәк, көрәшчеләр.
Күкрәк сугып алай димәсәк тә.
Төзелә монда Җирнең баш урамы,
дәвам итә моннан киләчәккә!

## Тарту көче

Тик ятмыйлар юллар.
Юллар һәрчак
замананың даим тарту көче.
Юлы булгач йөкләре дә була,
төяүчесе була, тартучысы.
Ике туктап ике ял иткәннәр
Чаллы үрен менеп җитәр-җитмәс.
Аты булса кеше кая бармас,
юлы булса кеше кая китмәс.
Атлар тарткан, үгез, сыер тарткан,
алар арса кеше үзе тарткан.
Өметләре алдан чакырып торса,
заманасы әйдәп торган арттан.
Без бүген дә йөкче һәм тартучы.
Йөкләр авыр, әмма атлар әйбәт.

Без һәрвакыт төяп бушатучы,
замана ул һәрчак тора әйдәп.
Йөк тә арта, тартучы да кирәк.
Бушый алмый бүген йөкче кулы.
Йөкче Казан кебек, Чаллы-йөкче.
Тарту көче — яңа Чаллы юлы.

Озатабыз. Яңа машиналар...
һәм башкалар китә, һәм башкалар...
Йөкче КамАЗларның тормышлары
Чаллы юлы белән башланалар.
Без озаткан яңа йөк атларын
кайсы якта каршы алсагыз да,
сез, егетләр, тизрәк бушатыгыз,
бүген инде гаҗәп арсагыз да.
Буш димәгез. Йөктә кырлар шавы
(дулкынлана әнә карабодай).
Соңгы кабат бездә сайрый-сайрый
кошларыбыз китеп бара бугай.
Сак булыгыз. Зинһар сак булыгыз
бушатканда безнең КамАЗларны.
Күлләрен дә алып үзләренә
утырып китә безнең кыр казлары.
Озатабыз. Менә бер болынның
чык тамчысы, соңгы бер чәчәге.
Борчылмагыз! Барыбер бездә кала
яңа бакчаларда — киләчәге.
Югалтулар белән барабыз без.
Шәһәр кадәр шәһәр сал да, имеш,
югалмасын икән бер буразна,
үзгәрмәсен икән берәр инеш...
Елга-сулар исән, кыр-басулар,
җәйләре дә исән, кышлары да...
Елгаларны диңгез итә алабыз,
күкләр биек очар кошларына.
Күгебезнең тирәнлекләрен дә
төягәннәр безнең машиналар.
Халкыбызның зирәклекләрен дә
җиткерергә сезгә ашыгалар.
Буш димәгез: яңа КамАЗларның
әрҗәләре шыплап-шыплап тулган.
Җиребезнең җан җылысын төяп
озатабыз сезгә яңа юлдан.
Буш димәгез: яңа КамАЗларның
әрҗәләре тулы асыл маллар.
Бушатыгыз! Анда безнең гомер:
безнең көннәр,
төннәр,
кичләр,
таңнар!
Тик ятмыйлар юллар. Еллар һаман
каршы ала яки озата тора.
Олы юллар һәрчак ике яклы,
нидер китә, нидер кайта тора.
Нәрсә тарта аны? Нәрсә көтә?
Суык яктан килә,
җылы яктан...

Татарстан туфрагына баскач
кардәш булып китә җиде яттан.
Алып килә безгә хис-тойгысын
үз халкының,
ихлас кардәшлекнең
Чикләре юк мәллә халыкларның,
чикләре юк мәллә бу яшьлекнең?
Чаллы юлы бүген илебезнең
Кан тамыры. Шулай исәпләнә.
Кая гына барып ялганса да
без бүлмибез аны кисәкләргә.
Бер. Тоташ ул.
Сукмак-сукмак булып
еракган ук илне иңләп ята.
Бер. Тоташ ул.
Чаллы юлы буйлап
йөри вакыт бары ике якка!
Машиналар — китә.
Кеше — килә!
Кошлар кебек кайта җан-туган да.
Сигнал микән КамАЗ гудоклары
сусаганга безнең җир-суларга?
Җаны-тәне тарта.
Килә, кайта —
монда, димәк, аңа сулар һава.
Чаллы юлы — илнең тарту көче.
Машиналар китә — юллар кала.
Машиналар китә. Килә — кеше.
Кемнәр кайдан тагын юлга чыга?
Чаллы юлы иркен. Киңрәк ягы
килүчегә һәрчак, кайтучыга!

## Хыял

Рухы таза булса, беркайчан да
ашкынуын кеше тыя алмаган.
Китәме ул читкә, я кайтамы —
башланалар юллар хыяллардан.
Күңеле саф икән, кешедән дә,
алладан да кеше оялмаган.
Күккә ашарлык олы мәхәббәтләр
башланалар җирдә хыяллардан.

Дөньясы киң. Шуңа гомере буе
җиргә генә кеше сыя алмаган.
Бер-бер артлы купме йолдыз-җиһан
кабына тора кайнар хыяллардан.
Ул чаклар да булган — башны башка,
ташны ташка куеп җыя алмаган.
Үсә торсын диган,
яңа йортка
нигез салган башта —
хыяллардан.
Мең кат лаек, юкса, шуңа кадәр
үзенә-үзе һәйкәл коя алмаган.

Шәһәр салган, шәһәр булып һаман
һәйкәл килеп чыккан хыяллардан!

Кешеләрнең таныклыкларына
мин бер махсус билге уяр идем:
әгәр булса,
«Хыял-талант бар» дип,
баш хәрефтән язып куяр идем.
Булә торган булса аны кеше
йөзенчегә берне, меңенчегә...
мин бирдерер идем — кемгә кемгә —
шагыйрь белән башта
төзүчегә!
Кагылмасын иде бер казык та,
Яңа йортка нигез салынмасын...
Шәһәр түгел, мунча салырга да
хыялсызлар берүк алынмасын!
Алынганнар!
Шәһәр булыр дигән,
утырткан да бер таш,
замандашым.
Ялан кырдан искән җилләр генә
тузгытканнар аның ялан башын.
Алынганнар! Тездән сазга батып,
шушы кырга кергән минем чордаш.
Күз алдында ап-ак шәһәр торган,
ә янында торган бары бер таш!
Бары бер таш.
Ләкин хыялый таш.
Ышанмас та кайбер акыллылар.
Шунда да шул хикмәт: без кичергән
хыялларның тирән акылы бар.
Алынганнар! Бары ун ел гына...
Бу — хыялның, юкса, сабый чагы.
Зирәк бала кебек, үзебезне
һәм хыялны узып бара Чаллы!
Алындылар! Ун ел элек монда
алып килде бер таш
Минем чордаш.
Бөтендөнья картасында тора
шәһәр булып хәзер шул горур таш!
Иң яраткан төпчек балабыз күк
аңа карап, күреп туя алмыйбыз.
И көләч тә үзе, и матур да —
шушы иде безнең хыялыбыз.

Шушы иде безнең хыялыбыз.
Нинди булыр үсеп җиткәч бала?
Карыйбыз да алга...
Карыйбыз да
хыялларны тагын борчу ала.
Күпме кеше,
ничә кибете бар —
гаме инде анда гына түгел.
Җаны нинди, рухы нинди булыр,
нинди булыр моның йөрәк, күңел?!

Вагоннарда күбрәк,
шәһәрләрдә
сирәк яши шәһәр салучылар.
Алар китәр,
тагын йөз елдан соң
нәрсә әйтер монда калучылар?
Чакырамы хыял йөз ел алга,
маяклары шуннан дәшә микән?
Син салырсың бер йорт: йөз ел анда
ун йорт булып ул йорт яшәр микән?
Йөз елларга таба безнең уйлар
чәчәк ата-ата барырлыкмы?
Хыялларны безнең бу шәһәрдән
йөз елдан да күреп танырлыкмы?
Шул турыда бүген безнең хыял.
Шәһәр бала әле, хыял-бала.
Оныкларга сөенечкә дигән
нигезендә асыл хыял кала.
Яши кеше. Бөек хыялларның
белеп булмый кайда башланасын.
Үсә Чаллы, кем өчендер ул бит
хыялының бүген башкаласы.
Белә кеше, кайгыртуны еллар
йөзе-меңе белән кайтарасын.
Безнең юл — яшьлеккә, яшәешкә...
Тик хыяллар гына,
тик хыяллар гына картаймасын!



Яңа Чаллы

Н. Курамшин фотосы.

Разил Вәлиев

# ИСКЕ СӘГАТЬ ДӨРЕС ЙӨРИ

ПОВЕСТЬ

## Юл азагы — юл башы



Стенадагы иске сәгать, ютәленнән буылган карт сыман озак гыжылдап, иртәнге алтыны сукты. «Вакыт галиҗанәбләренә суык тигән,— дип уйлады Искәндәр.— Суык тигән».

Шул чак аның тәне буйлап салкын тәпиле кырмыскалар көтүе йөгереп узгандай булды. Ул юрганын башына ук тартып китерде, җылы эзләп, аякларын арлы-бирле йөртте. Аннары шактый вакыт, кымшанмыйча, күзләрен түшәмгә төбәп ятты. Нәрсә турындадыр уйлыйсы, хыялланасы — шулай итеп иртәнге авыр хисләрдән котыласы килә иде аның. Ләкин, үч иткәндәй, башына бер уй да килми. Әйтерсең, ул белгән-күргән нәрсәләр барысы да кара төн пәрдәсе артында бүленеп калган, әйтерсең, ул үткәнгә җилкәсе белән борылып утырган да киләчәкнең буп-буш чиксезлегенә күзләрен төбәп, онытылган иде.

Тәрәзәдән кергән сүрән яктылык ишәйгәннән-ишәя барып, озакламый бөтен бүлмәне тутырды. Караңгылык әкренләп почмакларга күчте, пәрдә артларына үрмәләде, анда да сыенып урын таба алмагач, идән ярыкларына сеңеп юкка чыкты. Идәндә, төн диңгезе ярга чыгарып ыргыткан ватык кораб калдыкларына охшап, бер пар чүәк, уч төбе хәтле келәм, урындык башыннан шуып төшкән чуар сөлге генә ятып калды.

Искәндәр кинәт кенә юрганын тибеп очырды да тезләрен кочаклап караватка торып утырды. Бармаклары белән чәчен артка сыпырып куйды, күзләрен уды. Инде тагын нишлим, дигәндәй, як-ягына карангач, стенада асылынып торган җепне тартты, брадагы лампочка иртәнге яктылыкка куәт өсти алмады,— җепне янә тартып сүндерде. Аннары иплап кенә караваттан шуышып төште дә аякларына чүәк элеп, бүлмә буйлап лаштыр-лоштыр атлап китте. Кухняга керде. Өстәлдә инде атна буе юылмаган тәлинкәләр өелеп ята. Иренеп кенә кранны борды,— тагын җылы су юк икән. Савыт-саба юмаска сәбәп чыгуына сөенгәндәй, теләр-теләмәс кенә сукранып, кранны ябып куйды.

«Элек тә җылы су сирәк килә иде. Ә савыт-саба гел чиста тора иде. Ничек юды икән ул аларны? Салкын су беләнме?»

Өйдә аның юньләп ашаганы да юк иде. Иртән бер чынаяк чәй эчә дә чыгып йөгерә, көндез кайда туры килсә, шунда ашый, ә кич... кич кайтканда күп чагында алар йоклаган була...

Кофе банкасы эзләп шкафта актарынганда, аның күзе стенадагы календарьга төште. Күкрәктән суга кергән озын кара чәчле ялангач кыз артка каерылып караган да, үзенә төбәлгән чит карашны күреп, бер мәлгә югалып калган. Менә ул, исенә килеп, алга ташланыр да тар бүлмәне яңгыратып көлә-көлә диңгез эченә йөзеп кереп китәр... «Ерак китә алмассың,— дип елмайды Искәндәр.— Гомерең аз калган». Ул, су кызының кызыктыргыч шәрәлегеннән котылырга теләгәндәй, календарьның соңгы битен әйләндереп куйды. Куйды да, арткы яктагы «Котлы булсын Яңа ел!» дигән сүзләрне күргәч, сәерсенеп озак карап торды. Бүген — утыз беренче декабрь, елның соңгы көне иде. Ә ул бер нәрсә дә әзерләмәгән, аның бер нәрсәсе дә юк. Өе ташландык абзар сыман, тәм-том, аракы-шәраб та алмаган, чыршы хәстәре дә күрелмәгән. Өе генә түгел, аның уйлары, хисләре, хыяллары — гомумән, ул үзе Яңа елга керергә әзер түгел.

Шулчак стенадагы иске сәгать, гыжылдап, озак итеп бер тапкыр ютәлләп куйды. «Вакытка суык тигән» — дип, ачу белән иреннәрен тешләп кабатлады ул. Инде ничә тапкыр шул сәгатьне антиквар кибетенә илтергә җыенды. Вакыт тими. Бабайдан калган истәлек, дип тота. Бабасы күптән дөнья куйды инде. Ә сәгать һаман йөри. Гүя ул әле һаман бабасы вакытын санап йөри, гүя ул әле һаман бабасы өчен ютәлли... «Вакытка суык тигән...»

...Ул көннән аның өчен дөньядагы бар нәрсәнең мәгънәсе үзгәргән кебек булды, җансыз әйберләргә җан керде, бүлмәсе көннән-көн зурая барган сыман тоелды, ә тирә-юньдәге түгәрәк дөнья күзгә күренеп кечерәйде. Искәндәр көннәр буе шәһәр ыгы-зыгысына ияреп ихтыярсыз йөри-йөри дә, тын гаваньга кайтып сыенган нәни каек сыман, аптырап-сәерсенеп бик озак бүлмәсе уртасында басып тора. Гасырлар артыннан килгән күкрәү авазына охшатып иске сәгать суга башлагач кына, яңадан аңына килгәндәй була. Ул инде ничә еллар буе шушы сәгать белән сөйләшеп, бәхәсләшеп яши. Кайвакытта, бигрәк тә ялгыз калган чакта, борынгы сәгать янында ул үзенең бик кечкенә, уйларының да бик вак икәненә төшенеп, гарьләнеп тә куя. Тора-бара сәгатькә ул җанлы әйбергә караган сыман карарга гадәтләнде. Иртәнге алтыда радиодан гимн яңгырый башлагач, иң беренче эш итеп, әле кулындагы бүләк сәгатькә, әле стенадагы борынгы сәгатькә карый. Үз кулындагы сәгатьнең дөрес йөргәнен күргәч, бала кебек сөенә. Иреннәрен кыйшайтып, стенадагы сәгатьне үчекли, ярый инде, миннән булсын яхшылык дигәндәй, диванга басып телләрен күчерә.

Искәндәр тәрәзә төбендә яткан сәгатен әйләндереп карый-карый кулына такты. Аннары кабалана-кабалана киенде дә идән себеркесе эзли башлады. Ләкин — гөнаһ шомлыгы — өйдә себерке юк иде. Соң моңа кадәр булгандыр бит инде ул. Хатыны себеркене дә үзе белән алып китмәгәндер... Искәндәр аның идән себергән чагын хәтерләргә тырышты, ләкин исенә төшерә алмады. Зәңгәр джинсы чалбар киеп, тузгыган коңгырт чәчләренә башы белән чума-чума иелеп идән юганын хәтерли, ә менә идән себергән чагын — юк. Әллә идәнне ул бер чакта да себермәде микән? Көн саен югач, себереп торуның кирәге дә калмый. Мүкәли-мүкәли килеп, башы белән пианинога бәрелгәч кенә, үзенең гел кирәксез нәрсәләр турында уйлаганын аңлап, башын түбән иде. Тезләрен юешли-юешли күпме тырышса да, идән чистармады, киресенчә, пычрагы буй-буй булып җәелеп кенә калды. Кул селтәп, юлбарыс тиресенә охшап калган идәнгә караңгы бүлмәдәге иске паласны чыгарып каплады.. Шул арада кухняда кофе ташый башлады. Йөгереп барып газны сүндерде дә, кофега ике шакмак шикәр салгач, озак итеп аның ак күбекләре сүнгәнне карап торды.

Каядыр ашыккан, кабаланган кебек, тиз генә юынып алгач, янадан кухняга чыгып, авызын пешерә-пешерә кофе эчте. Эчеп бетергәч, бөтен эше тәмам булган кебек, тагын туктап калды.

«Нишләргә? Бүген нишләргә? Нинди эшләр бар бүген?— дип үз-үзенә сорау бирде ул.— Беренчедән, өйне тәртипкә китерергә. Аннары, кибеттән кирәк-ярак ташып, бәйрәм өстәле әзерләргә. Чыршы табарга. Уенчык элмәсәң дә ярый, бала-чага юк...— Ул, чыннан да бала-чага юклыгына ышанырга теләгәндәй, як-ягына каранды.— Чыршы кыяфәте булгач, исе аңкып торгач, шул җиткән. Тагын нишләргә? Ә-ә-ә!? Ә, кунаклар!? Күптән дәшеп куйган кунаклары бар бит аның. Бүген тагын бер тапкыр исләренә төшерергә кирәк булыр. Инде күптән күргәне дә, аралашканы да юк. Телефоны булганнарына шалтыратыр, Ислам белән Шәукәтләрнең өйләренә кереп чыксаң да була».

Искәндәр почмактагы тумбочка өстендә торучы телефонга күз ташлады. Куе кызыл төстәге телефон иртәнге эңгердә менә-менә сүнеп килүче олы бер утлы күмергә охшап тора. Соңгы арада нигәдер берәү дә шалтыратмый әле аңа. Баштарак, алар киткән көннәрдә, берничә көн телефон тынып тормады. Аны сорап шалтыраттылар, кызының классташлары шалтыратты. Ул, нигә аны миннән сорыйсыз, дигән сыман, өзек-өзек кенә җаваплар кайтарды: «Китте ул, китте. Белмим, белмим. Бөтенләйгә китте, белмим, белмим... Кайтмаска китте... Нишләп шаяртыйм, ди инде... Шулай килеп чыкты инде... Бер-беребезне аңламаганбыздыр. Үткән үткән инде, нишлисең. Ун елны түгел, бөтен гомерен суга салган кешеләр дә бар бит. Хәерлегә булсын... Юк, юк, үкенмим... Үкенмәм. Сөенмим дә... Күптән шулай булырга тиеш иде. Шулай кирәк иде... Җае чыкмый торды. Менә, ниһаять, җепне өзәргә булдык... Ана яхшы...»

Искәндәр телефон трубкасын кулга алып бераз әйләндергәләп торды да беренче булып хәтергә килгән номерны җыя башлады. Озак җавап бирми тордылар. Искәндәрнең трубка тоткан кулы тирләп чыкты. Ниһаять, колакны кытыклап торган озын гүләү авазын бүлеп, телефоннан таныш тавыш ишетелде.

— Тыңлыйм сезне...

Искәндәр шатлыгыннан кычкырып җибәргәнен дә сизми калды.

— Ә-әй! Хәмит дус! Йоклап ятасың мәллә? Шалтыратам, шалтыратам — җавап бирмисең. Бәйрәм көнне йоклап яту килешми.

— Т-с-с! Кычкырма шулкадәр. Балаларны уятасың. Сәгать ничә икәнне беләсеңме соң син?

Искәндәр, аптырап, әле кулындагы сәгатькә, әле стенадагы сәгатькә карады:

— Бе-ләм...

— Бу вакытта авылдагы карт әтәчләр белән шәһәрдәге карт буйдаклар гына тора...

— Бәйрәм бит.

— Бәйрәм нәрсә өчен? Бәйрәм ул, туган, халык йокласын өчен. Рәхәтләнеп, бөтен кайгыларыңны онытып йоклар өчен ул бәйрәм...

Искәндәр, Хәмитнең шулай акыл өйрәткән тон белән сөйләвенә сәерсенеп, телсез калды. «Нәрсә булган моңа? Иртәнге җиденче яртыда түгел, төн урталарында шалтыратканы булды — алай кырт кисеп сүз кайтармый иде».

— Йокыңны бүлгән булсам, гафу ит. Кичкә безгә киләсеңне тагын бер тапкыр исеңә төшермәкче генә идем...

Телефон тынып калды, бераздан кыштыр-кыштыр килде. Ерактан тонык кына булып хатын-кыз тавышы ишетелде: «Бармыйбыз да, килмибез дә». Телефон тагын шытырдап алды. Хәмит аны уалырдай итеп учына кыса иде, ахрысы. Ниһаять, ул телгә килде. Тавышы, әле генә бозлы судан чыккан сыман, салкын һәм калтыраулы иде:

— Искәндәр... малай, безнең планнар үзгәреп тора бит әле. Хатын бит... Яңа ел ул гаилә бәйрәме, аны һәркем үз өендә я туганнарында үткәрергә тиеш, ди. Үзең беләсең, хатын-кызга аңлатып буламыни? Үпкәләмә, малай, без әтиләргә барырга булган идек. Нигә эндәшмисең? Иртәгә үзең безгә килеп чык. Барыбер бер ялгызың. Күңелсез дә булыр үзеңә. Сөйләшеп утырырбыз. Хатын пәрәмәч пешерер...

Телефон трубкасы Искәндәрнең кулын пешерә башлагандай тоелды. Ул аны шапылдатып куйды да тәрәзә тупсасына килеп таянды. «Әйе! — Тәрәзә пәрдәләрен җәһәт кенә ике якка каерып ташлады.— Әйе! Димәк, бәжра чыннан да кысыла башлады. Исемлектән бер кешене сызып ыргыттык. Дуслар исемлегеннән. Хәмит, Хәмит... Без синең белән биш ел буе бергәләп юкка гына студент шулпасы эчтек микәнни? Биш ел буе бер бүлмәдә яшәп, болай да кыска гына гомернең биш елын уртак кайгылар, уртак шатлыклар белән уздырдык...»

Сөмбелнең бер кечне әйткән сүзләре кылт итеп аның исенә төште.. «Әллә син үзеңне берәр кешегә кирәкмен, дип уйлыйсыңмы? Чыгарып ташла башыңнан ул беркатлы уйларыңны. Кеше үз өен яратса, шул бик җиткән. Әллә син үзеңне берәр кеше үлә-бетә ярата, синең өчен җанын бирергә әзер тора, дип беләсеңме? Шулай булмый торсын. Әгәр дә берәрсе сиңа якты йөз күрсәтә икән, белеп тор, димәк, аңа синнән нидер кирәк, яисә, һич югында, аңа шулай яхшы, аның синең белән уйнап аласы, үзенең шатлыгын сиңа күрсәтеп бер ялтырыйсы килә. Шулай итмәсәң, шатлык шатлык булмый бит, җир астына күмелгән хәзинә була».

Искәндәр, гадәтенчә, аны бүлдермичә генә тыңлап утырды, кайтарып сүз әйтмәде. Шулай итсәң, сүзен тизрәк очлыйсын яхшы белә иде ул. Бу сүзгә Хәмит оеткы салып чыгып китте. Төнге сәгать унберләрдә котмәгәндә килеп кергән иде ул. Йөзе әле генә мунча чыккан төсле алсуланып киткән, бүреге гадәттәгедән арткарак шуышып тәбәнәк маңгаен биегәйтеп җибәргән. Түргә узып тормадылар, кухняга кереп утырдылар. Сүзне Хәмит башлады.

— Малай, хәлләр хөрти бит әле минем,— диде ул еламсырак тавыш белән.— Хөрти, малай, эшләр...

— Нәрсә булды тагын? Милиция-мазарга эләкмәгәнсеңдер бит? Шуннан да зур трагедия юк бүгенге көндә.— Сүзне уенга борырга, Хәмитнең көн аралаш табылып торган борчуларын бүгенге сүз үзәгенә алмаска иде аның исәбе.

— Анысы юк ла... баш ике түгел... Хатын әллә нишләде... Кичә бөтенләй өйгә дә кайтмады. Кайдадыр кунып калган. Кайтуына бугазына ябыштым. Күзгә караган да тик тора. Исерек кеше шикелле елмая. Бер кул белән якасыннан тотып, икенче йодрыкны йомарлап тордым-тордым да, үзем дә сизмәстән, елап җибәрдем. Суга алмадым. Балалар куркыр, дидем. Ә ул, берни булмагандай, чишенде дә малай белән кыз арасына кереп ятты. Шуннан соң гына теле ачылды.

— Кайда йөрдең, эттән туган нәрсә,— мин әйтәм.— Балаларын төне буе тәрәзә төбен саклап чыкты.

— Син төннәр буе кайтмыйсың бит әле,— ди.— Син кайда йөрсәң, шунда.

— И-их, шунда күлмәген күтәреп каеш белән ярасы килде! И-их! Соң мин... Минем белән чагыштыра бит үзен. Мин нәрсә, калсам, шул дуслар белән сөйләшеп калам. Әллә кайда эт типкәсендә йөрмим бит. Дуслар очрый. Әйдә, сөйләшеп утырыйк, күрешмәгәнгә биш былтыр, диләр. Шунда аларга: «Хәзер мин йөгереп кенә хатыннан рөхсәт сорап киләм. Җибәрсә, утырырбыз»,— дип әйтә алмыйм бит инде. Үзең күреп торасың, Искәндәр, шулай каткан күңелне җебетеп, җанны бушатып утыра торгач, таң атканнары сизелми дә кала. Бер сөйләшүгә бер гомер бит ул андый чакларны. Ә өйдә нишлим мин? Фатирын алып биргән,

мебелен тезеп куйган, зарплатасын тиенен тиенгә кайтарып җиткергән. Тагын ни кирәк аларга? Дуслар белән әллә нигә бер рәхәтләнеп күңел бушатып утырырга гына хакым бардыр бит инде минем, ә?

— Үзенә шулай дип әйттеңме соң?

— Әйттем, әйтмәгән кая?

— Нәрсә ди?

— Мин дә нәкъ синең сыман эшлим. Квартираны сиңа гына түгел, семьяга бирделәр, мебельгә минем дә өлешем керде. Телисең икән, претензиясез генә шушында яшә, теләмәсәң, дүрт ягың — кыйбла, ди.

— Ә күңел турында, күңел турында аңлатып әйттеңме соң?

— Күңел нәрсә? Күңел ул миндә дә бар, ди.

— Дуслардан башка, кешеләрдән башка, җәмгыятьтән башка яшәп булмаганын, кешенең кешесез тормыш итә алмаганын төшендерергә иде аңа.

— Һәй, малай, бар сүзеңә дә җавабы әзер бит аның. Нәрсә, хатын сиңа дус түгелмени? Хатын сиңа дошманмыни, ди? Сиңа бәгыреннән өзеп балалар тапкан, егерме ел җыеп килгән иң яшерен хисләрен бүләк иткән хатының сиңа ятмыни? Син дә иң элек аны аңларга тиеш. Бер хатыныңны да аңламагач, аны юата, аның күңелен күрә белмәгәч, нинди дуслар, нинди җәмгыять турында авыз ачып сөйләшергә мөмкин, ди. Син башта хатыныңның күңелен күр, шуннан соң башкалар турында уйла, ди.

— Ә нигә, моңа кадәр әйбәт кенә тора идегез бит әле. Минем Сөмбел сезне гел мактап сөйли иде. Хәмит тырыш, Хәмит йорт җанлы, Хәмит юк-бар белән баш катырмый. Ә мин ялкау, мин булдыксыз, мин өй турында кайгыртмыйм, мин бушкуык, мин юк нәрсә турында хыялланып гомеремне уздырам...

Искәндәр, кызып китеп, тавышын чамасыз күтәрә төште бугай, сөйләнә-сөйләнә кухняга Сөмбел килеп керде:

— Нәрсә мактанасың, нәрсә этәчләнәсең тагын?

— Хәмит белән менә бар дөньяны сүгеп утыра идек әле.

— Дөньяны сүкмәгез сез, шул дөньяда яши белмәгән өчен, үзегезне сүгегез. Дөнья нәрсә? Дөньяның гаебе юк. Ул мең ел элек тә шулай булган, мең елдан соң да шулай булачак. Ә менә кеше үзгәрә, кешеләр үзгәрә, халык үзгәрә.

— Кеше белән бергә дөнья да үзгәрә инде...— Хәмит коңгырт күзләрен челт-челт йомып куйды, уртадан кырт бөгелеп төшкән мул кашлары турайды.

— О-о! Пәри башка, җен башка. Бутамагыз әле сез, егетләр. Табигатьнең үз законы, кешенең — үз законы. Табигатькә кеше кирәк түгел, ә кеше табигатьсез яши алмый. Җәнлек-җанварларны гына карагыз сез: алар табигать законнары буенча яши, алардан табигатькә бер зыян да юк. Ә кеше? Кеше кыра, җимерә, елгаларны туктата, урманнарны кисә, һавага тонналап агу очыра... Табигатьнең үз баласы булса, үзен тудырган дөньяга шулай карамас иде ул. Димәк, кеше — табигатьнең үги баласы....

Искәндәр, Сөмбелнең сүзне бөтенләй бүтән якка борып җибәрүенә уңайсызланып, Хәмиткә карап куйды. Хәмит тырпаеп торган тыңлаусыз кара чәчләрен бармаклары белән аралаган да идән ярыгына карап уйга чумган. Искәндәрнең нидер әйтергә җыенганын күреп, Сөмбел тамчыга охшаган озынча йөзен күтәрә төште. Юка иреннәренең сул почмагына мыскыллы елмаю саркып җыелды.

— Космологик теорияләрең белән Хәмитнең башын катырма әле. Менә сезнең аркада, хатын-кыз аркасында җирнең үги улы булып беттек тә инде... Җәнлекне ник үтерә кеше — хатын-кызга тун кирәккә. Диңгез төбен нигә айкый кеше — хатын-кызга энҗе-мәрҗән кирәккә.

Урманны нигә кисә кеше — хатын-кызлар бер-берсен уздырып мебель даулаганга. Сугышлар нигә чыга — хатын-кыз аркасында... Безне менә шушылай начар итеп кем тәрбияли — хатын-кыз тәрбияли...— Боларның барысы өчен дә син гаепле дигән сыман, Искәндәр Сөмбелгә карап алды.— Бүген нинди тузга язмаган мәкалә укыдың тагын? Үзең җир, җир, дисең, үзең һаман күктә йөзәсең...

Сөмбел, тыела алмыйча, көлеп җибәрде. Аның тавышы, йолдыз чыңына охшап, бик тирәннән, еракган килә иде.

— Мин күккә синең янга менәм бит,— дип башлады ул, көлүеннән тыела алмыйча.— Эштән соң сәгать буе чиратта торып, сетка тутырып азык-төлек төяп кайтам.— Аның тавышы торган саен кырыслана барып, шырпы кабына ябылган кигәвен быжылдавына охшый башлады.— Барын-югын әтмәлләп ашарга әзерлим, табак-савыт юам, өйне җыештырам. Аннары сине эзлим. Син өйдә бар да кебек, юк та кебек. Гәүдәң бар, үзең юк. Аягың — җирдә, башың — күктә. Каяле, мин әйтәм, бу илаһи затны — сөекле иремне — күреп төшим әле, дим дә күккә менәм. Ни әйтсәң дә, безнең гаилә члены, кызыбызның атасы бит ул.

— Ярый, Сөмбел, җитте, арттырыбрак җибәрәсең. Хәмитнең үз борчуы үзенә җиткән.

Хәмит ашыкмыйча гына тураеп басты да ишеккә таба атлады.

— Гафу итегез. Мин болай гына, үтеп барышлый гына кергән идем, гаепләп калмагыз.

Искәндәр, киенеп, аны озата чыкты. Урамда ишеп-ишеп кар ява. Кар иреннәргә төшеп эри, муеннарга тула, керфекләргә куна.

— Күптән урамга чыгасы калган,— дип үзалдына гына әйтеп куйды Искәндәр.— Юк белән баш катырып утырабыз шунда. Без күк белән җир турында фәлсәфә сатып утырабыз, ә монда дөньяның асты-өскә килгән, күк белән җир тоташкан. Я, әйтеп кара, кайда җир дә кайда күк монда хәзер?

— Әйе,— дип көрсенде Хәмит. Ул әле һаман үз уйларыннан арына алмый иде, ахрысы.

— Җир, күк, табигать, кеше турында фәлсәфә кору — бөтенләй кирәксез нәрсә. Аңа карап үзгәрми ул, агайне. Аристотельләр, Гегельләр, Платоннар безгә караганда күп акыллырак булган. Алар дөньяны аңларга һәм аңлатырга тырышканнар. Ну, аңлаттылар да ди. Шуннан дөнья үзгәрәме? Юк, юк! Кояш мең ел элек тә көнчыгыштан чыккан, хәзер дә шуннан чыга. Агачларның яфрагы элек тә яшел булган, хәзер дә яшел. Элек тә җирдә яхшы-яман булган, хәзер дә бар.

— Коперниклар булмаса, син мескен әле һаман да Кояш Җир тирәли әйләнә, дип йөрер идең...

Искәндәр Хәмитне җиңеннән тартып туктатты.

— Әйләнсен! Миңа димәгәе кояш гел синең заводың тирәли әйләнсен. Аңа карап дөнья үзгәрми бит. Безнең ничек уйлаганга карап дөнья үзгәрми. Кояшның ничек әйләнү-әйләнмәве мине тамчы да кызыксындырмый. Кеше акылында кояш — Кояш булып урын алган. Минем өчен аның яктыртуы, җирне җылытуы, көнчыгыштан чыгып көнбатышта баюы кыйммәт.

— Син, Искәндәр, авыл мулласы шикеллерәк фикер йөртәсең. Табигать законнарын белми торып, бүгенге фән казанышларына ирешеп булмаганын, менә бу багана башындагы лампочка да янмаганын аңлыйсыңдыр инде, шәт. Галәмгә очу, айга менү турында әйткән дә юк...

— Ә миңа синең галәмеңнең кирәге шул кадәр генә бит, Хәмит. Миңа шушы бәләкәй генә җир шары да җиткән. Нәрсә калган анда миңа?

Искәндәр озак итеп күккә карап торды.

— Җирнең ресурслары чикләнгән.

— Чикләнсә... Булганы җитәр безгә. Чамалап тотарга кирәк. Ерак юлга чыгам, дип, өйдәге бөтен ризыкны биштәргә тутырмыйлар бит ин-

де. Юлга чыксаң, юлда тап дигәннәр борынгылар. Ә без менә күп нәрсәнең кадерен белмибез. Кая ашыгабыз, белмим. Ашыккан ашка пешкән, ди иде безнең бабай.

— Син, Искәндәр, җир дә җир, дисең, ә үзең бер дә җир кешесенә охшамагансың. Менә җир өчен, табигать өчен нәрсә эшләдең син? Берәр агач утырттыңмы?

— Һәр елны Кызыл шимбәдә урам себерәм.

— Синең ул урам себерүең шимбәгә әзерләнгән күрәк бәясен дә капламый бит.

— Анысы минем эш түгел. Кушсалар, зуррак эшне дә эшләрбез.

— Ә нигә кушканны көтеп ятарга?

Искәндәр аңа җавап биреп тормады, иелеп кулына кар алды да йомарлап күккә ыргытты. Кар йомарламы аларның каршына ук төшеп, чәлпәрәмә килде.

— Күрдеңме?— Ул Хәмиткә күтәрелеп карады.— Җир җибәрми безне, малай. Җирдә туган җан иясе җирдә яшәргә тиеш. Күккә хыял белән генә менәргә кирәк, күңел белән, җан белән генә. Шекспирлар, Бетховеннар кебек. Галәмгә синең гәүдәң түгел, рухың кирәк. Тимербетон йортларга караганда, җан җылысы күбрәк кирәк кешеләргә. Кеше барыбер урамда яшәми ул, бер алачык булса да салып керә. Ә менә күңелне тәртипкә китерү кыенрак. Кеше иң элек үз күңеленең ап-ак өен салырга тиеш.

— Телиме-теләмиме, кешенең хыялы ахыр чиктә материаль төс ала, чынга аша бит.

— Бу өлкәдә безнең Сөмбел специалист инде. Аның белән килешер идегез сез. Аныңча, без барыбыз да чит планетадан җиргә эксперимент ясар өчен китереп ташланган җан ияләре бит. Шуңа күрә җирнең кадерен белмибез, аның байлыкларын сандыкларга төяп үз йортыбызга алып китәргә җыенгандай яшибез. Кешеләр арасындагы дошманлык, җир бүлү, канкойгыч сугышлар да шул чит планетадан килүебезнең сәбәбе, дип аңлата ул. Аныңча, без — җирнең үги баласы.

— Кем ничектер, минем әле җирдә бер явызлык та, бер зыян эш тә кылганым юк. Күпме алсам, шулкадәр бирәм. Димәк, бурычым да юк.

— Җиргәме, хатыныңамы? Хатыныңа зарплата кайтарып бирү белән Җиргә әҗәт түләүне бутама син, Хәмит. Җиргә без һәрберебез бурычлы. Менә кеше шул бурычны түләргә өйрәнгәч, Җирдә гармония булачак.

— Хатынга күпме бирсәң дә, аз, ди ул.— Хәмит сүзне уенга борырга уйлады, ахрысы.— Ә безгә үзебезгә дә яшәргә кирәк. Син әйтмешли, күңелнең ак өен корырга кирәк. Аннары, күңел белән генә яшәп булмый бит әле. Кешеләр үзләре күккә очканда, син хыялыңда гына күккә ашып утырсаң, ерак китә алмассың. Сөмбел дөрес әйтә ул, без җирнең үги баласы. Инстинкт буенча омтылабыз без күккә.

— Берәр тапкыр әнинең янына кайтканың бармы соң?

— Нигә? Монысы ни дигән сүз тагын? Әни үткән ел гына өч ай бездә торып китте бит...

— Ә үзеңнең кайтканың бармы? Әллә кайдагы планетаны туган йортыбыз, дип, шунда кан тарта, дип шапырынабыз, акыллы сүзләр сөйлибез, ә үзебезнең ындыр артындагы әниләребез янына кайту турында исебезгә дә кереп карамый.

Хәмит бармак калынлыгы булып өелгән карны сыпырып төшерде дә якасын күтәреп куйды. Искәндәр, аңа карамыйча гына, сүзен дәвам итте:

— Беләсеңме, Хәмит, соңгы арада бик сәер төшләр күрәм әле мин. Йокыга китүгә, колагыма бик сәер музыка ишетелә башлый. Ул якынайганнан-якыная бара... Карасам, алдымда — фаэтонга җигелгән ка-

натлы ак ат. Үзе күзләрен тутырып миңа карый, карашы шундый ягымлы, шундый таныш. Фаэтонга менеп утырам да һавага күтәрелеп китәм. Очам, очам, музыка мине һаман озата бара. Бу бит — минем музыка, мин гомерем буе язарга хыялланган музыка. Ул көчәйгәннән-көчәя бара, мин, фаэтонга басып, барабан таяклары белән әле бер йолдызга, әле икенчесенә сугам, йолдызлардан музыка яңгырап түгел, агылып чыга. Мин сабый бала кебек бар галәмне яңгыратып көләм... Минем тагын да югарырак менәсем, яңа йолдызларга кагыласым, тагын да серлерәк музыка авазлары ишетәсем килә. Канатлы атны куаларга теләп, бар көчемә аңа сыдырам. Камчы эзе ак атның сыртында кып-кызыл булып сызылып кала, миңа ул эздән кан тамчылары чәчрәп чыга, канатлы ат әкрен-әкрен генә алсу төскә керә, минем күзләрне кызыл элпә каплап ала. Музыка тына, һәм мин бар көчемә кычкырып җибәрәм. Уянып китсәм, бүлмә тып-тын, тәрәзә пәрдәләре генә иртәнге кояш нурларыннан алсу төскә кереп, шомлы төшне искә төшереп тора. Ул канатлы ат турында да озак уйладым мин. Әле беркөнне альбом актарып утырганда әнкәйнең күзләрен күреп шаккаттым. Төштәге ак ат күзләренә шундый охшаган икән аның күзләре. Нәрсәгә юрарга икән бу төшне?

— Сөмбелгә сөйләгәнең бармы соң?

— Аңа сөйләдең ни дә сөйләмәдең ни. Аннары, сирәк күрешәбез бит без. Сөйләшергә вакыт та юк. Ул — көндез эштә, ә мин — кич... Минем хыялый дөньяма бигүк керәсе дә килми бугай аның. Мине бөтенләй буш куыкка саный кебек ул. Кайчан бер җиргә төшәрсең инде, дип күрсенә дә тагын үз дөньясына кереп чума.

— Соң үзе дә чит планеталар, оча торган тәлинкәләр белән җенләнә түгелме соң?

— Соңгы арада бөтен укыганы — гел шул турыда. Синең янга күккә менәсем килә, шуңа укыйм ди. Үзең ишетеп тордың бит.

— Җирдә күрешә алмасагыз, күктә бер очрашып сөйләшер, аңлашыр идегез.

— Аның оча торган тәлинкәсе минем хыялый ак йортны күрми, минем хыял аның тәлинкәсенә керә алмый, ахрысы. Йөрибез шулай тегендә-монда очып. Ә гомер уза, заяга уза.

— Миңа кайтып та җиттек,— диде Хәмит.

Искәндәр, сүзеннән бүленеп, капыл туктап калды.

Кар туктаган. Күк йөзе күтәрелеп, биегәеп киткән. Җир соры болытлар фонында илаһи бер төскә кереп калган. Әйтерсең, җир белән күкнең урынын алмаштырып куйганнар. Күк шундый да гадәти, ә җир — саф, җир ак әкияткә төренгән, җиргә аяк белән басарга түгел, кул белән кагылырга да кыймассың.

Искәндәр, шушы матурлыкны гомерендә беренче тапкыр күргәндәй, сак кына басып подъездга керде. Җиңен кайтарып, сәгатенә күз салды.

— Кара син, икенче киткән бит, малай. Тагын эләгә инде сиңа хатыныңнан. Кереп аңлатыйммы? Икәү булгач, бәлки сүз әйтмәс.

— Кирәк түгел. Күп аңлаштык инде аның белән. Мин сиңа аһ-зарымны сөйләрмен, дип килгән идем, үзегезнең исәбегез үзегездән артып ашкан икән. Бер уйлаганда, минем хәл җиңелрәк тә әле. Мин — җир кешесе. Хатын да миннән ерак китмәгән. Җирдәге хәлләрне ничек тә ерып чыгарга тырышырбыз. Ә менә сезнең хәлләр катлаулырак. Сез икегез дә — күктә. Күктәгеләргә аңлашу авыррак. Аллалар сөйләшми бит, ым кагып кына аңлаша. И-их, сезне! Бер-берегезгә юл куярга кирәк иде азрак. Ярый, сезгә акыл җыярга дип барып, үзем акыл өйрәтә башладым бугай. Әле үзегездә кунып калмакчы да булган идем. Хатынга үч итеп.

— Хатының да сиңа үч итеп берәр иптәш кызы янында кунып кайткандыр әле. Йөрисез шунда качышлы уйнап, кеше башы катырып.—

Искәндәрнең чын-чынлап ачуы чыга башлаган иде. Ул подъезд ишеген шапылдатып япты.— Керсәң, кер, кермәсәң, әйдә безгә!..

— Сезнең йолдызлы өйдә урын булмас миңа. Үзебездә, ни әйтсәң дә, җылырак икән. Хуш, тәмле йокы!

— Сәлам әйт. Вакыт бик соң. Тавыш-фәлән чыгара күрмә тагын.

— Әбиеңне өйрәт.

Хәмит авыз тутырып елмайды да, кырт борылып, баскычтан менеп китте.

Искәндәр сәгать суккан тавышка сискәнеп башын чайкап куйды. Иртән иртүк әллә нинди уйлар килә әле бүген. Вакыт та гадәттәгедән акрынрак уза. Хәзер нишләргә инде? Ул бүлмәгә күз йөртеп чыкты да бер баштан икенче башка арлы-бирле йөренергә тотынды. Юл уңайлый гына урын-җирне җыеп куйды, урындыкларын стена кырыена тезеп чыкты, шифоньер астында күзенә нидер чалынган иде, тезләнде дә кулы белән үрелеп шуны тартып чыгарды. Кызына былтыр алып кайткан сары толымлы курчак икән. Бер кулы юк. Курчакны алга-артка аударып карады, ыгы-ыгы килеп елый, тик күзләре генә элеккечә йомылмый, гел ачык тора. Ул курчакны кая куярга белмичә бер мәл уйланып торды, тәрәзә төбенә утырткан иде, авып төште, өстәлгә дә, урындыкка да, шифоньер башына да куеп карады, ләкин бер кулсыз курчак кызы кайда да ятышмый сыман иде. Йомылмый торган зәңгәр күзләрен тутырган да гел аңа карап тора. Аптырагач, курчакны шифоньер тартмасына салды да өстенә чүпрәк каплап куйды.

Инде нишләргә? Берничә мәртәбә телефон янына да килеп карады. Трубкага тотынырга кыймады. Хәмит белән сөйләшкәннән соң, телефон аппараты кызыл тәнле салкын бака төсле тоела башлады аңа. Трубканы алсаң, бак-бак, дип кычкырыр сыман. Пианиноның буявы куба башлаган капкачын күтәреп, озак кына аклы-каралы клавишаларга карап торды. Бүлмә эче шулкадәр тын, шул тынлыкны бозып көй уйнарга җөрьәт итмәде. Я күршеләр килеп җитәр, дип уйлады. Моңа кадәр болай ук кыюсыз түгел иде бит ул. Кызы иртүк пианино «дыңгырдата» башлауга, күршеләре йөгереп керсә дә, сүзне уенга борып кына җибәрә иде. Шушы микәнни инде аның ун ел буе көрәшеп алган җан тынычлыгы, шушы микәнни аның күңел хөрлеге, уй бөтенлеге, шушы микәнни аның иҗат иреге?! Алар киткәнгә иртәгә бер ай тула, шул арада нәрсә кырды ул? Әйе, сырты сызлый башлаганчы урында ауный, теләгән вакытта тора, теләгән вакытта ашый, кая теләсә — шунда бара. Ләкин болар гына аз бит. Аның тормышында нидер тамырдан үзгәрергә, ул бөтенләй яңача яши башларга тиеш иде бит. Кайда ул үзгәреш? Элек аның бар уңышсызлыкларына ул, бары ул гына гаепле кебек тоела иде. Костюмы үтүкләнмәгән булса да, эштә кәефен кырсалар да — нишләсә дә — ул гаепле. Музыка яза алмыйча газаплануына да бары ул, бары тик ул гына гаепле, ул гына сәбәпче.

Искәндәр, нәрсәдер исенә төшкәндәй, кабаланып, пианино янына килде дә клавишаларга ачу белән суга-суга уйный башлады. Куәтле аккордлардан бүлмә сискәнеп уянгандай булды, стеналар бөтен тәне белән калтыранып куйды. Ул музыка язачак! Аңа үч итеп, бөтен дөньяга үч итеп язачак! Ул ансыз яши ала, ә музыкадан башка яши алмый, ул бары тик музыка өчен генә яши. Хәзер аның үз ирекe булачак. Аннан хәзер «ресторан даһие» дип көлмәячәкләр. Аның хәзер иң якын дуслардан гына торган даирәсе булачак. Ул кич белән ресторанга барып берничә сәгать кенә уйнап кайтачак та көннәр буе өйдә бикләнеп музыка язачак. Заяга узган ун ел вакыты турында уйлый-уйлый шашып язачак. Аннары язганнарын тыңларга дусларын чакырачак. Житте, житте, ресторан сандугачы булып йөрү житте. Ул үзенең кем икәнен күрсәтергә

тиеш. Юкка гына пединститутның музыка факультетын тәмамламады бит. Югары белемле музыкантның ресторанга нигә керәге бар? Ресторан белән араны өзәргә! Мәктәптә укытуын укыта алмас. Дүрт мәктәптән китәргә туры килде инде, директорлар белән килешә алмады. Аның музыка иҗат итәсе килә, балаларга да музыканың ничек дөньяга килүе, иҗат газаплары турында сөйли. Ә мәктәпкә программа кирәк. Аптырагач, ресторанга барып керде. Мәктәптә аның көйләрен тыңлаган кеше дә юк иде. Григка, Равельга нярәсең, шулар йогынтысыннан чыга алмыйсың, дип теңкәсенә тиделәр. Монда рәхәт. Монда сүз дә әйтмиләр, кемгәдер нярүдә дә гаепләмиләр. Уйна да уйна гына. Бииләр, җырлыйлар, кул чабалар. Монда Григ та, Равель да, «Бони М» да, «АББА» да, Искәндәр дә бар. Барысына да урын җитә, барысын да тыңлыйлар, барысына да бииләр — уйна да уйна гына. Искәндәргә бу тигезлек ышерен бер эчке ләззәт бирә, үз музыкасының бөтен дөньяга танылган композиторлар әсәре белән янәшә яңгыравы, ресторан халкының аны шул бөекләр белән тиң күрүе күңелендә татлы ышаныч уята иде.

Пианинодагы музыка авазына телефон чылтыравы кушылды. Ул, теләмичә генә куптарылып, трубканы алды.

— Әл-лү... Кем анда?

— Интизар бу, Интизар абыең.

— Абый сиңа тагын...

— Нәрсә, кәефең юкмы әллә? Кая, мин әйтәм, таң сандугачы чыгып киткәнче шалтыратып алыйм әле, дим. Ни эш кырып ята идең?

— Болай гына, буш күңелне музыка белән тутырып утыра идем.

— Синең эшләр хутта хәзер. Хөррият! Без генә монда бала-чага чүпрәге арасында әвәрә киләбез. Әле хатын белән чүт әйткәләшеп китмәдек. Салатка бәрәңге әрче ди. Кичә кич буе кишер туратты, дөге чүпләтте, бүген тагын — бәрәңге...

Искәндәрнең киһәт кенә кухня өстәле артына утырып кишер кырасы килеп китте. Йөзенә, кетер-кетер кишер кимергәндәге сыман, рәхәт бер ваемсызлык төсмере чыкты. Ул арада телефонның тавышы кырысланды:

— Әллә берәрсе бармы анда?

— Юк ла, Робинзон кебек япа-ялгызым... Кая әзерләнәсез ул кадәр? Кишерне әйтәм, күп турыйсыз. Туй булмыйдыр лабаса?

— Туй, дип, безнең туган-тумача Чыңгыз хан чирүе кебек бит. Җыелып килсәләр, мирең белән корытырлар...

Искәндәрнең трубкалы кулы салынып төште, болай да базык гәүдәсе тагын да бөкрәебрәк, бәләкәйләнебрәк киткәндәй булды, диңгез төсендәге күзләре сүрәнләнә төште, соргылт кашлары бер-берсенә якынаеп, кушыла язды. Трубкадан Интизарның туктамыйча сөйләшкәне ишетелә. Искәндәр аскы иренен тешләп бераз торды да телефонга эндәште:

— Безгә килмәскә булдыгызмыни?

— Нәрсә? Ничек сезгә? Сөмбел китте түгелме соң?

— Октябрь бәйрәмендә үк килешкән идек бит... Яңа елны быел бездә каршы алырбыз, дип.

— Соң, туган, килешүче якларның сан һәм сыйфат ягыннан үзгәрүе сәбәпле, килешү шартларын үтәү дә һәр якның үз ирегендә кала. Чынлап әйтим, сиңа — ялгыз кешегә ничек итеп семья белән барып керәсең инде? Теге чакта, сөйләшкән чакта, Сөмбел дә бар иде бит.

— Ә мин?..

— Син — минем дус. Ләкин дус дип, семьяны ташлап китә алмыйм бит инде.

— Нигә ташлап китәргә? Парлап чакырдык... чакырдым... бит мин сезне.

— Булмый инде, Искәндәр, ачуланма.

— Һич югында, берәр генә сәгать утырырсыз да китәрсез.

— Булмас инде, гаеп итмә. Елга бер килгән олы бәйрәмне өйдә генә

уткәрик инде. Ә син миңа үпкәләмә, аңла. Кешеләрне аңламасаң, ничек музыка язарсың син... Ярый, хуш иттек.

Интизарның тавышы өзелүгә, телефоннан, колакны үртәп, өзек-өзек авазлар ишетелә башлады: «Көт-көт, кит-кит, көт-көт, кит-кит»,— дип кабатлый сыман иде телефон.

«Монысы читләп-сипләп тормады, кибетче малае икәне әллә каян күренеп тора, счет төймәсе тарткан кебек, сүзләрне чалт-чолт кына тарткалап куйды да — вәссәләм!— дип уйлады Искәндәр.— Димәк, бүгенге базарда минем бәя шактый төшкән икән. Ярый, бераз гына вакыт бирегез, кемнең күпме торганын күрсәтермен әле мин сезгә...»

Ул, шифоньерны ачып, утүкләнгән күлмәк эзләргә тотынды. Актарына торгач, күлмәкләр арасыннан сары чәчле курчак кызы килеп чыкты. Зәңгәр күзләрен чекерәйткән дә туп-туры аңа карап тик ята. Искәндәр, нигәдер, бу карашны күтәрә алмады, күзләрен читкә борды. Курчак өстенә чүпрәк каплады да күлмәк якасын төймәле-төймәле көзге каршына килеп басты. Картаелган. Борын яфраклары яныннан ирен читләренә таба сузылып киткән ике сызык тагын да тирәнәя төшкән, элек алсуланып торган иреннәренә тутык кунган сыман, чигә чәчләренә тагын берничә ак төк өстәлгән, болай да биек маңгае башның яртысын диярлек яулап ала язган... Картаела...

Өскә мул якалы кышкы пальто киеп, башны бүрек белән каплагач, гомер-рәссам утыз биш ел буе тырыша-тырыша ясаган рәсем-сурәтләр юкка чыккандай булды. Бары тик йөзендәге ике тирән буразна гына, беркая да яшерә алмассың дигәндәй, астыртын бер көлү белән көлә.

Почта әрҗәсе шыгрым тулы иде. Гәзитләрне карап тормады, хатларны учлап кесәгә тыкты да иң элек открыткаларны укырга булды. Кинәт кенә аңа рәхәт булып китте. Күңел түрендә посып яткан, инде онытылып килгән горурлык хисе баш калкытып куйды. «Әле дөньяда мин дә бар, мин әле кемгәдер кирәк, минем турыда уйлыйлар, кайгырталар»,— дия иде кебек ул хис.

Әнисе бәйрәм белән котлаган. Открытканы алдым, онытмавың өчен рәхмәт, дигән. Ерак җир түгел бит, бәйрәм арасында ник бер әйләнеп китмисез, дигән. Иң аска, хәрефләрне балаларча бөтерә-бөтерә, тигез юллар белән бер куплет шигырь язып куйган.

Кайтсаң иде кеше улы кебек,
Япсаң иде лапас түбәсен.
Өйләндең дә, көйләндең дә, ахры...
Минем һаман килә күрәсем.

«Их, әнкәй, әнкәй, нигә шулкадәр беркатлы син,— дип уйлады Искәндәр.— Лапас кайгыларымнн соң минем башта? Акчасын җибәрермен, менә дигән итеп ябып куярлар». Әйе, кайтып әни кешенең күңелен күрергә кирәк, бик кирәк анысы. Ә вакытны каян алыйм? Һәр көн эштә. Бәйрәмдә... дус-иш белән... җыелып утырасың.— Искәндәр авыр итеп көрсенде. Әнисенең йөзен күрергә теләгәндәй, күз карашы белән буш стеналар буйлап йөгереп узды. Һәм өендәге сырлап-бизәкләп эшләнгән борынгы сәгатьне уйлап, тагын онытылды. Шушы борынгы сәгать аны үткәннәр белән: үзенең нәсел-нәсәбе, туганнары, туган җире, буыннан-буынга килгән гореф-гадәтләре, алай гына да түгел, бөтен дөнья белән тоташтырып торучы бердәнбер тылсым булып тоелды. Борынгы сәгать вакытны гына күрсәтми, ә кешеләрнең кайгы-шатлыгын, халыклар һәм илләр язмышын, тарих агышын күрсәтә, шулар хисабын да алып бара иде. Шулчак Искәндәрнең кулындагы сәгать каешы авырттырып бeләзеген кисә башлады. Сәгатен салып аңа бераз карап торды да колагына

якын китерде. Ул текелди, ул бары тик аның вакытын гына саный иде. Әйтерсең, Искәндәрнең алдына: «Менә синең бөтен гомерең, аның белән теләсә нишли аласың», дип бер өем алтынсу бөртек куйганнар. Ә ул бүгенге көнгә кадәр шул бөртекләрнең әле берсен дә авыз итеп карамаган, тик шулай да көшел шактый кимегән. Алтын бөртекләрне тек-тек итеп көне-төне бер нәни генә карак кошчык — аның сәгате чүпли дә чүпли, чүпли дә чүпли...

— Бәйрәм, дуслар...— дип сузып-сузып кабатлады ул.— Шунсыз булмый, алар белән гомер итәсе, яшисе бар бит әле миңа. Арбадан бер төшеп калсаң, әйдә, утыр, дип, кулыңнан тартып менгерүче юк монда. Авыл түгел бу. Егылганны торгызучы, абынганны юатучы юк. Их, әнкәй, әнкәй! Әйе, хәлеңне аңлыйм. Бер ялгызыңа рәхәт түгеллеген аңлыйм. Чакырдым бит, монда яшәргә кил, дидем, риза булмадың, ата-баба нигезен ташлап китә алмыйм, дидең. Ә мин анда ике-өч көнгә кайтып нишли алам инде? Синең тәмле-томлыңны ашап, йөрәгеңдәге оны тылып торган яраңа тоз салып кына китәм. Бер уйласаң, күрешмичә тору яхшырактыр да әле. Ни әйтсәң дә, син анда үз нигезеңдә: күршекүлән, туган-тумача бар. Ә минем монда кемем бар? Авыр чакта кемгә барып башымны салыйм мин? Шушы диңгез хәтле олы шәһәрдә бер йомычка шикелле бәргәләнеп йөрисең... Берәүнең абыйсы министр, икенчесенең туганы профессор, өченчесе әти-әнисе белән яши — тумыштан шәһәр егете. Ә мин бу шәһәрдә үги бала кебек.— Искәндәрнең күз алдыннан яшен тизлеге белән таныш елмаю чагылып узды. Сөмбелнең бераз мыскыл катыш кинаяле елмаюы иде бу.— Менә бүгенге дәрәҗәгә житәр өчен генә дә күпме көч түгәргә туры килде миңа. Авылдан иске чемодан күтәреп килеп төшкән малай бит мин. Шәһәргә килгән беренче көнемне әле бүгенгедәй хәтерлим: урам уртасында калдым да, кая барырга белми, тик басып торам. Кузгалсам, як-якка агылучы машиналар изеп-сытып узар кебек. Ярты сәгатьләп тормаганмындыр, ниһаять, бер милиционер житәкләп тротуарга чыгарып куйды. Машиналар бер хәл, аларына тиз ияләштем, тик менә кешеләргә ияләшү генә авырга туры килде. Чөнки минем беркемем дә, бер нәрсәм дә юк иде бит, әнкәй. Минем һәр адымым, һәр уңышым крепость яулап алуга тиң иде. Институтка керү, тулай торакта мең бәла белән урын алу, имтиханнар тапшыру, үтүкли торгач көзге кебек ялтырый башлаган бердәнбер костюмны киеп кичәләргә йөрү, шунда Сөмбел белән танышу, өйләнү, туй ясау, диплом яклау, эшкә урнашу, фатир алу... Менә шуларны эшләү өчен генә дә күпме көч киткән, күпме җан кыйналган. Ә берәүләр тормышның бу өлешен, бу чорын бөтенләй үтеп тә тормый бит. Алар мин бүген басып торган урыннан, шушы биеклектән старт ала. Ә синең улың ошбу нәрсәләргә ирешкәнче ярты картайды.

Сөмбелне дә гаепләмим мин. Аның үз фәлсәфәсе, минем — үземнеке. Бары шул гына. Ул — шәһәр кызы. Ул дөньяга аек акыл, якты күз белән карый. Институт тәмамлагансың икән, бик яхшы, аны азмы-күпме акылы булган һәркем тәмамларга тиеш, ди. Ә миңа институт тәмамлау илаһи бер нәрсә булып күренә иде. Дөрес, хәзер алай ук түгел инде. Ләкин барыбер аның битараф горурлыгына житү өчен миңа күп кирәк әле. Бала туу да, фатир алу да аның өчен гадәти бер нәрсә. Чөнки ул — бөтен кеше дә эшли торган һәм эшләргә тиешле эшләр. Ә миннән һаман авыл чыгып бетмәгән, бала — минем өчен — шәҗәрә агачының бер ботагы, нәсел дәвамы, Бикмурзиннар нәселен дәвам итүче, киләчәккә алып баручы. Ә фатир алу — йорт салып керүгә бәрабәр. Үзең беләсең, авылда йорт салу — егет кеше өчен иң зур, иң мәртәбәле эш. Егете нинди булса, йорты да шундый була. Сине яшәгән йортыңа карап бәялиләр. Ә монда нәрсә?.. Мең газаплар белән фатирга ирешеп, кош тоткандай, ордер күтәреп кайткач та, исе китмәде Сөмбелнең. «Кешеләр, әнә, өчәрдүртәр бүлмәлене дә алалар, исләре дә китми»,— дип кенә куйды. Менә

шул көнне беренче тапкыр аптырап, сәерсенеп озак карап тордым мин аңа. Инде фани дөнья мәшәкатьләреннән бераз котылдым, хәзер үз уйларым, үз хыялларым белән иркендә яшәрмен, эшли башлаган эшләремне төгәлләрмен, рәхәтләнеп иҗат итәрмен, күңелдә талпынып яткан көйләрне язармын дип кенә йөргәндә, канатларым янә салынып төште. Кайгыны ничек тә эчкә йотарга, авыздагы канны төкермичә түзәргә була. Ә менә синең сөенечең белән сөенүче, синең уңышларыңны күреп куанучы кешең булмавы бик авыр, гаҗәп авыр, әнкәй...

Хәзер мин дә нәкъ синең кебек ялгыз. Кайчагында, әллә авылга кайтып, клуб мөдире булып эшкә керимме, дип тә уйлап куям. Авылдашлар аңламас, институтларда укып йөреп тә бер нәрсә майтара алмады, дип әйтер кебек. Авыл халкы үзенә кирәк чагында бик зәһәр телле дә бит ул. Аннары, минем үз хыялларым бар бит, әнкәй. Гомеремнең мәгънәсе, бөтен максатым шул хыялга бәйле. Мин бу шәһәргә өйләнер-көйләнер өчен генә килмәдем. Мин музыка язарга тиеш. Авылның беренче баянчысы гына булып каласым килми минем. Нигә сиңа сөйлим әле боларны? Үз кайгың үзеңә җиткәнне дә беләм, югыйсә, бүтән сөйләр кешем булмаганга сөйлим. Шулай булмаса, борчып торыр идеммени? Аңласаң, мине бары син генә аңлыйсың. Сөмбел аңламады. Аңларга да теләмәде. Ул минем төннәр буе нота кәгазьләре белән утыруымнан, яңа көй яздым дип, төн урталарында аны уятып акрын гына пианинода уйнауларымнан көлде генә. «Ташла, җүләр, маташма юк белән, Бетховеннар, Чайковскийлар, Сәйдәшевләрдән соң нәрсәдер язарга, иҗат итәргә маташу — мәгънәсез эш. Әнә, берәр музыка мәктәбенә урнаш та балалар укыт. Җитәкчеләр белән телгә килмәсәң, юк-бар белән балаларның башын катырмасаң, ярыйсы гына укытучы чыгачак синнән. Үзеңә дә, кешегә дә файдаң тияр. Семьяң да тыныч яшәр. Күңелең утырса, бәлки безне дә күрә башларсың. Юкса, хатыныңны да айга берничә мәртәбә генә күрәсең бит син. Кызыңның ничәнче класста укыганын да чамалап, яшен санап кына беләсең. Балага әти кирәк, хатынга ир кирәк, шуны аңлыйсыңмы син? Хыялый Камыр батыр түгел, авыр чакта таянырлык, эч сереңне уртаклашырлык чын ир кирәк миңа...»

Шулай, әнкәй, синең анда ялгыз башыңа — ялгыз кайгы. Бүгенге көнең ул кадәр куанырлык булмаса да, искә төшерерлек юанырлык үткәнең бар әле синең. Карт кешеләргә шунысы җиңел, киләчәк турында уйлап баш катырмый алар... Ә минем нәрсә? Сабантуй алдыннан икеөч атна ял биреп, ат чабышына алып чыккан яшь айгыр кебек, нәселле юртаклар артыннан калмыйм, дип, тыным буылганчы чаптым-чаптым да, хәлдән таеп, туктап калдым. Миңа хәзер ял кирәк, миңа башымнан сыйпап сөюче, җылы сүз әйтеп юатучы кирәк. Кайда ул кеше? Сөмбел дә китте. Ул барда бөтен уңышсызлыкларны аңа сылтый, бар кайгыхәсрәтемнең сәбәбен аннан күрә идем. Аның китүенә бер ай вакыт узды, дөньям үзгәрмәде, күңелем баемады. Киресенчә, бушап кына калды. Хәтерлисеңме, син миңа бер әкият сөйләгән идең?.. Бер патша, дөнья тыныч вакытта да тик тормасыннар дип, сугыш атларын тегермән әйләндерергә куя. Атлар, бер-бер артлы тезелешеп, айлар-еллар буе түгәрәк буйлап аркан тарталар. Шулай берзаман сугыш башланган хәбәр килә. Сугышчылар атларга менеп атланалар да дошманга каршы ташланмак булалар. Ләкин, ни гаҗәп, атлар алга чапмый, түгәрәк буйлап тик әйләнеп йөри икән. Билгеле, дошман боларны күз ачып йомганчы кырып кына салган инде...

Менә мин дә, әнкәй, үземне шундыйрак хәлдә итеп сизәм. Гомер буе өй — кибет — эш, өй — кибет — эш арасында йөгереп йөреп, шул тегермән атына охшап беткәнмен сыман. Әле Сөмбел киткәч тә, шул түгәрәктән чыга алганым юк. Кирәксә дә, кирәкмәсә дә өйгә кайтам, эшкә йөрим, кибеткә барам...»

Искәндәр, милиция сыбызгысы чырылдавына сискәнеп, уянып киткәндәй булды. Караса, бер кулына открытка тоткан килеш, урам уртасында басып тора. Тирә-яктан, яңа сөреп ташланган кара җир өстендәге кортлар сыман, төрле төстәге машиналар чаба. Ничек машина астына кермәгән ул? Болай йөрсәң, коймак ясап куюлары да бар. Милиционер, бәйрәм көн булмаса, штраф чәпи идем, ярый, бу юлга калып торсын, миннән булсын яхшылык дигәндәй, елмаеп бармак янады. Искәндәр дә аңа каршы сүрән генә елмайды.

Вак-төякләр белән сумканы шыплап тутырып, ике шешә әзербәйҗан коньягы да алгач, тагын нәрсә кирәк икән, дип кибет киштәләренә бер кат күз йөгертеп чыкты. «Ә-ә, шампанский! Шампанскийсыз Яңа ел була ди мени?!» Үз-үзенә яңалык ачкандай, ул ашыга-кабалана касса янына килде.

— Ике шешә шампанский сугып бирсәгезче, чибәрем.

— Беренчедән, мин сезнең чибәрегез түгел, икенчедән, шампанскийны әчетеп өлгермәдем. Яңа елның яңа елына бәлки әзер булыр, килерсез.

Кибетче кыз, бик тә үткер сүз әйткән шикелле, калын иреннәрен чәй тәлинкәсе хәтле җәеп елмайды да, алтын тешләрен балкыта-балкыта, бөтен гәүдәсе белән дерелдәп, тиз генә, ашыгыч кына көлеп алды. Озаклап көләргә вакыты юк, чөнки чиратта бүтән кешеләр көтә иде.

— Әнә, алма суы ал...

— Бәйрәм бит, затлырак әйбер кирәк иде.

— Кешедән артык җирең юктыр. Әнә, бар халык шуны эчә, өзелеп төшкән җирләре юк. Әйдә, әйдә, копченый колбаса шикелле сөрәеп торма, юлында бул, чират көтә.

— Кеше алдына моны куеп булмый бит инде. Алар бик нәзберек халык. Яхшырагын... Бер генә шешә булса да...

— Әллә бүген тудыңмы?— Сатучы, шаяруын онытып, чын-чынлап ачуланырга тотынды.— Юньле кеше бәйрәм хәстәрен ярты ел алдан күреп куя. Киләчәккә карап яшәргә кирәк... Үзең белмәсәң, хатының әйтергә тиеш иде. Дөнья хатын-кыз кулында хәзер.

Искәндәр, дәресен әзерләп килмичә, «ике»ле алган малай кебек, башын аска иеп чыгып китте. Чираттагы кешеләр аңа сәерсенеп карап калдылар. «Инде кибетчеләр дә ничек яшәргә кирәген өйрәтә башлады,— дип мыгырданды ул.— Кая барып кагылма, шунда акыл сата башлыйлар». Ныклап уйласаң, аларда да хаклык бар анысы. Көне җиткәч кенә бәйрәмгә әзерләнә башламыйлар бит инде».

Сөмбел киткәч, ай буе үз-үзен кая куярга белмичә, ике тәрәзә арасына эләккән чебен сыман, арлы-бирле бәргәләнеп йөрде ул. Эшкә гадәттәгедән алда килеп, сәгатьләр буе оркестрантларны көтеп утыра, ә алар, киресенчә, гадәттәгедән соңрак килә. Кирә-керешкә үк чишенеп аталар да, ваемсыз гына кулга инструмент алып, эстрадага чыгып утыралар. Йөзләре чытык, әйтерсең, музыка белән кеше күңелен күтәрергә түгел, ә суган әрчергә утырганнар. Тора-бара йөзләре ачыла үзләренең. Башта программа буенча, «Ай, былбылым»ны уйныйлар. Кайсы-берсе, туктап торган арада, якындагы өстәл янына барып, кояшлы Грузия исәнлегенә чәкештереп тә килә.

Шуннан соң, башлана «лезгинкалар», башлана юмарт табигатьле Кавказ ритмнары. Колагың гына чыдасын. Барабанчы Альфред соңгы чиккә җитеп шаша, Искәндәрнең пианино авазы, тау елгасына килеп кушылган кечкенә чишмә кебек, югалып кала. Альфред аның саен котырынып, эреле-ваклы барабаннарын кыйный, әйтерсең, шулай итеп, гомер буе җыелып килгән бар үч-ачуларын чыгара, шуның белән ләззәтләнә иде. Барабанчы булса да, нигәдер, башкаларга караганда күңеле йомшаграк сыман аның. Искәндәр ансамбльдә бары тик аның белән генә уртак тел таба. Ә ул, Искәндәрнең үзен якын иткәнен сизепме, әллә

чын күңелдәнме, программадагы көйләрне уйнап бетергәч, юмартланып киткән кунакларның заказларын да башкаргач, аңа баш кага. «Әйдә, Искәндәр, синең көйне уйныйбыз!»— дигән сүз инде монысы. Альфредның ансамбль егетләре сүзсез аңларга өйрәнгән, алар көйне тиз генә күтәреп алалар. Искәндәр боларын уйламый, ул залдагы ярым исерек кунакларны да, рюмкалар чәкәшкән, кычкырып-кычкырып сөйләшкән тавышларны да ишетми, аның өчен хәзер галәмәт зур базарга охшаган шәһәр дә, адым саен ачы сүз кыстырып сөйләшә торган дус-ишләр дә, фатир да, Сөмбел дә — берсе-бер юк. Коңгырт чәчләре тузгып як-якка таралган, кашлары, очарга җыенган кош канаты сыман, өскә талпынган, күзләре — чиксез моң һәм дәрт тулы күзләре — кешеләргә түгел, ә эчкә, үзенең эчке илаһи дөньясына төбәлгән кебек. Ул беркемне дә күрми, бер нәрсә дә ишетми. Ул гомере буе шушы мизгелне көткән, ул гомере буе шушы мизгел өчен генә яшәгән диярсең.

Көй тәмамлангач, ул башын кисәк кенә артка таба селкеп куя да, беренче тапкыр күргәндәй, залга карый. Башта бер ара аңышмыйча тора. Ул үзенең ресторанда икәнен онытып, ул гүя сәхнәдә, меңләгән тамашачылар алдында. Искәндәрнең күз алдыннан бер-бер артлы нигъмәт тулы өстәлләр йөзеп китә, арадан сирәк-мирәк кенә кул чапкан тавышлар ишетелә. Ул ихтыярсыз торып баса да, гаепле кеше сыман, озак итеп баш иеп тора.

Урамга чыккач, Альфред белән озак кына сүзсез атлыйлар. Сүзне гадәттә Альфред башлап җибәрә.

— Туйдым...— була аның беренче сүзе.— Туйдым бу бака туеннан. Туйдым бу кабак җырчысы булып йөрүдән. Китәм. Иртәгә үк китәм!

Искәндәр аны тыңламый, чөнки көн саен кабатланган бу сүзләрнең төн үтүгә истән чыгасын, иртәгә кичке җиделә Альфредның барабан артына чыгып басасын, дүрт сәгать онытылып торганнан соң, кайткан да тагын шул ук сүзләрне кабатлыйсын яхшы белә иде ул.

— Китеп кая барасың? Бәлки, монда яхшырактыр да әле. Тикшерган, бәйләнгән кеше юк, тамашачы күңелле халык — нәрсә уйнасаң да ярый.

— Чын тамашачы алдында уйныйсым килә минем, Искәндәр. Гомеремдә бер генә тапкыр гына булса да. Батам, бетәм бит мин бу сазлыкта. Шушы ресторанга килеп эләкмәгән булсам, күптән консерватория бетергән идем бит. Мин хәзер кем? Сазлык бакасы. Кит син моннан, Искәндәр, яхшы чакта кит.

— Китеп кая барасың? Үз-үзеңнән качып булмый.

— Син талантлы бит. Менә дигән көйләр язасың. Һич югында, өйдә ят, эшләмә. Музыка яз, иҗат ит. Бер заман таныррлар, аңларлар.

— Дворян нәселеннән түгел шул мин. Бабайдан калган мирас та бик зур түгел — иске чабата белән бер кәкре шөшле генә. Эшләми яшәп булмый хәзерге заманда.

— Ә иҗат эш түгелмени?

— Эшен эш тә, аның белән тамак туймый шул.

— Моцартлар, Шубертлар, Глинкалар беркайда да эшләмәгән, шулай да менә дигән итеп яшәгәннәр, иҗат иткәннәр.

— Таптың чагыштырыр нәрсә...

— Дөрес, безнең чорны алар заманы белән чагыштырып булмый, бездә — иҗат иреге, бездә — хөррият.

— Салулама, егет, читкә каерма. Аңлыйм, тел төбеңне бик яхшы аңлыйм. Ботинкаң тар булганга, дөнья тар дип зарланма, ди торган иде безнең бабай. Башта эш күрсәт, аннан аяк терәп сөйләш, таләп ит. Һәрбер чебешкә каз оясы ясап булмый бит инде. Әй, каз оясының нәрсә икәнен дә аңламыйсыңдыр әле син. Шәһәр малае... Мин шәһәрдә туып үскән булсам, синең шикелле мәми авызланып йөрмәс идем. Үзе безнең авылда булсаммы? Билләһи дип әйтәм, бу консерва орнияләр,

театрлар, концерт заллары безнең авылда булса, мин шуларда, ыштан балагы белән инештә маймыч тоткан кебек, үз малай булып үссәм, кем чыгар иде миннән! И-их! Камыры йомшак шәһәр кешеләренең, оеткысы төче. Авылда без кермәгән кыяр түтәле, без тузгытмаган карга оясы, без төшмәгән кар базы юк иде! Менә синең, Альфред, берәр тапкыр шәһәрдәге иң биек агач башына яисә иң биек өй түбәсенә менгәнең бармы? Юк шул, юк. Хәчтерүшләр сез.

— Нигә авылда гына яшәмисең соң? Кайт та культура йорты директоры булып урнаш. Оркестр оештыр, хор оештыр, ансамбль оештыр, үзешчәннәрне күтәр.

— Оештыру сәләте юк миндә. Минем бары тик музыка гына язасым килә. Кешенең үзе теләгән эшне эшләргә хакы бардыр бит...

— Ә нигә язмыйсың соң? Тот та яз, кеше башы катырып йөрмә.

— Ничек дип аңлатырга? Күңел тынычлыгы юк. Эштә, үзең беләсең... Өйдә — хатын-кыз. Аннары, Альфред дус, бу дөньяда мине аңлаган бер генә кеше дә юк. Аңларга теләүче дә күренми.

— Ә синең үзеңнең берәр кешене аңларга теләп караганың бармы соң?

— Белмим...

— Димәк, үтә чыккан эгоист син! Нигә дип бөтен халык сине генә аңларга тиеш әле? Һәркемнең — үз кайгысы, үз борчуы, үз дөньясы.

— Син иҗат кешесе бит. Аңларга тиеш. Нечкә күңелле кеше. Менә хатын мәктәптән укытып кайтты, ди. Алты сәгать укыткан, ничәдер балага «биш»ле, ничәсенәдер «дүрт»ле, «өч»ле, «ике»ле куйган. Юк нәрсәне бар итеп, шуларны сораштырып утырыйммы инде аннан? Сорамыйча да шулай икәнен беләм бит мин аның.

— Ялгышасың, Искәндәр, бик нык ялгышасың. Мин дә элегрәк шулай уйлый идем. Хатын минем өчен йорт җәнлеге шикелле генә иде. Кер юа, ашарга пешерә, теләгән чакта, башыннан сыйпап куясың, теләмәсәң, җилкәң белән борылып ятасың...

— Урта гасырда яшәгәнсең бугай. Хәзерге хатыннар...

— Бүлдермә әле. Хатыннар кайчан да бер үк хатыннар алар. Матриархат чорында да үзләренең нәфислекләрен саклап кала алганнар. Менә син хатыныңа юри генә бер җылы сүз әйтеп кара әле. Юри генә башыннан сыйпа, юри генә иркәлә, назла.

— Юри генә булдыра алмыйм мин.

— Соң, агач түгелдерсең лә...

— Ул мине аңламый, минем тормышымның, минем хыялымның мәгънәсен аңламый. Минем нәрсәдер иҗат итә алуыма ышанмый.

— Ышанмый икән, ышандыр. Ышандыра алмасаң, син, димәк, иҗат кешесе түгел. Ә ничек итеп залдагы меңләгән тамашачыны әсир итә алырсың син? Тормыш, яшәү — үзе иҗат ул. Музыка язу гына иҗат түгел... Берәр көеңне уйнап караганың бармы соң аңа?

— Язган берсен уйныйм, ичмасам, ник бер чәч бөртеге кыймылдап карасын!

— Тагын яз, тагын уйна.

— Булмас, ахрысы. Без аның белән аерылышырбыз кебек.

— Юләр син, Искәндәр. Мин дә аерылыштым. Гомерем буе хыялланган хөрриятькә ия булдым. Бер читлектә яшәргә өйрәнгән арысланга ирек зыянлы гына ул. Яши алмый ул иректә — һәлак була. Читлеккә кергәнсең икән, үзеңне шул читлектә иреклe хис итәргә өйрән. Синең фантазияң җитәрлек бит...

— Һе-һе...

— Аерылышсаң, бетәсең, малай. Бетәсең! Буының сыек синең. Үзеннән дә кеше чыкмый, иҗатың да...

— Ә ул миңа барыбер иҗат кешесе дип карамый.

— Ә син аңа иҗат кешесе дип карыйсыңмы соң? — диде Альфред.—

Ул бит гади укытучы гына, дисеңме әллә? Һәр эш — иҗат ул, Искәндәр. Ә дөнья — базар. Сату-алу, алыш-биреш... син нинди товар бирсәң, шул ук бәяне кайтаралар. Дөньяның алыш-биреше бик гадел аның. Беркемне дә алдый алмыйсың. Син аңа бер яхшылык кылсаң, ул да сиңа шуның белән җавап бирә, син аңа бер җылы сүз әйтсәң, ул да җылы сүз таба, күңел төбеннән актарып, кырып-себереп булса да таба, бурычлы калмый. Менә шул нәрсәне колагыңа киртләп куй, Искәндәр.

Ул төнне алар таңга кадәр шәһәр урамы буйлап онытылып сөйләшеп йөрделәр. Бу вакытта борчып тормыйм дип, Искәндәр өенә кайтмады, Альфредта йоклап калды.

Йокыдан уянганда көндезге өч тулып килә иде. Торып берәр чынаяк кофе эчтеләр дә, ул өенә кайтып китте. Кызы бу вакытта мәктәптән кайткан булырга тиеш иде. Гаепле кыяфәт белән, ишекне сак кына ачып өйгә керде. Коридорда ук ул өйдә ниндидер үзгәреш булганын сизгән иде. Чишенмичә генә түргә узды.

Шифоньер ишеге шар ачык, элгечтә аның берничә күлмәгеннән башка кием-салым күренми, икесе бергә төшкән портрет урыны стенада аксылланып калган, келәме алынган урындагы обой чәчәкләре, куптарылып ташланган таш астындагы сыек яшел үләннәр сыман, яктырып тора. Бүлмә уртасындагы өстәлдә, шакмаклы дәфтәр битендә эре-эре хәрефләр ярылып ята. Җинаять өстендә тотылудан курыккан кеше сыман, ашыгып язган.

«Искәндәр!

Сау бул! Рәхәт яшә. Без монда һәрчак артык булдык. Бездән башка иркенләп тормыш ит. Бәлки, кайчан да булса акылыңа килерсең әле. Без сиңа беркайчан да начарлык теләмәдек. Синең ордым-бәрдем сүзләреңә, җен алыштырган кеше кебек, иләс-миләс йөрүләреңә күп түздек, күрмәмешкә салыштык. Ә син һаман безне гаепләдең, безнең һәр хәрәкәтебез сине чыгырдан чыгара иде. Имеш, без сиңа иҗат итәргә шартлар тудырмыйбыз, сиңа гел комачау гына итәбез. Әйдә, рәхәтләнеп иҗат ит әле бер. Атаклы композитор булгач, концертыңа чакырырга онытма. Иске дус итеп тыңларга, синең уңышларыңа сөенергә килербез. Хуш. Без поездга киттек... Безне эзләмә, безнең өчен борчылма, югалмабыз. Хәер, синең борчылганың да булмады инде. Ярый, хәерлегә булсын...»

Сөмбел, Ләйсән».

Паровоз пошылдаулары чыгарып, бар бүлмәне гөрселдәтеп иске сәгать сугуга, Искәндәрнең күз аллары караңгыланып китте. Ул күзләрен чытырдатып йомды. Паровоз тагын, тагын уһылдады, кузгалырга рөхсәт биреп, ачы итеп сыбызгы чырылдады. Искәндәр, бөтен гәүдәсе белән суырылып, поездга омтылды. Менә гаҗәп, яшел вагоннар урынына рәт-рәт парталар тезелгән, һәр партада аның Сөмбеленә охшаган балалар, ә иң алда, паровоз урынында — аларның борынгы сәгате. Сөмбел паровоз-сәгать тәрәзәсеннән кул болгады да, поезд тавышсыз гына кузгалып китте. Ул, алга сөрлегеп, чак кына егылмыйча калды.

Милиция сыбызгысы чырылдауга, Искәндәр сискәнеп китте. Караса, тагын юл уртасында, тагын шул ук урында басып тора, тагын шул ук милиционер аңа бармак яный. «Болай булса, машина астында калам бит мин,— дип уйлады Искәндәр.— Саграк йөрергә кирәк, саграк. Алны-артны карап».

Ул ачуыннан каты итеп баса-баса баскычтан менде, ишекне киереп ачты. Аның күңеле кителгән, ул кемгәдер үпкәләгән иде. Кемгә булсын, аның хәзер үпкәләр кешесе дә юк. Ул үзенә үпкәләгән иде.

Пианино капкачы ачык калган икән, аны шапылдатып ябып куйды. Пианино, мин назлы зат, минем эчем тулы моң-зар, шатлык-сөенеч, миңа тупас кагылырга ярамый дигәндәй, шактый вакыт иңрәп торды.

Азык-төлекне бушатып, кисеп-турап өстәлгә тезә башлагач, табынның бик ярлы икәне күренде. Бу табынга кеше чакырырлык түгел иде. Нәрсәдер уйларга, хәстәрен табарга кирәк. Искәндәр, маңгаен җыерып, күзләрен йомып, үзенең таныш-белешләрен хәтердән үткәреп чыкты. Монысы музыка училищесында укыта, тегесе — мәктәптә... Танышлар арасында аңа ярдәм итә алырдай кеше күренми. Туктале, Фиданны кафега склад мөдире булып урнашты дигәннәр иде. Шуңа барып карасам? Әйе, шунда барырга кирәк, ул борып җибәрмәс.

Кулына сумка тотты да ике-өч баскыч аша сикерә-сикерә урамга чыкты. Фидан искә төшүгә үк күңеле үсеп киткәндәй булды аның. Фидан егет кеше, ул институтта укыганда ук арада бөтенесеннән аерылып тора иде. Артыгын сөйләшмәс, кирәкмәгән җиргә тыгылмас, ә үз эшен барыбер эшләр. Дөрес, музыкага бер кәсеп итеп кенә карый иде ул. «Музыка — бәйрәм ул, ә бәйрәм көн саен килми. Көн саен аның кирәге дә юк! Кеше бу дөньяга бәйрәм итәргә килми, яшәргә килә!» Музыка турында сүз чыкса, шушы бердәнбер фәлсәфәсен ярып сала да, миннән көлмиләрме икән дигәндәй, мәче елгырлыгы белән, астан гына һәркемне карашы белән сөзеп чыга.

— Сәлам, Искәндәр!

Башын күтәреп караса, каршында Рүдәл тора. Бүрек колакчынын төшереп куйган, күзлек пыялалары тирләп, йөзенә сукыр кеше кыяфәте керткән, бит очлары, кершән яккан кызларныкы кебек, уч төбе хәтле генә җирдә алсуланып чыккан.

— Кая юл тоту болай?

— Бәйрәм хәстәрен күреп йөрү иде әле... Берни табып булмый.

— Шаяртма. Беләбез сине. Ресторанга барып бер сызгырсаң, хәзер төяп китерәләр сиңа.

— Мин анда беркемне дә белмим бит. Музыкантларны гына...

— Шаяртма. Эшнең кәттәсенә эләктең инде. Безнең шикелле, тугыздан — алтыга тигез була йөз дә егерме тәңкә мәсьәләсен чишеп ятмыйсың.

— Ә мин туксан сум алам...

— Шаяртма. Таммаса да, агуын ага инде анда. «Маэстро! «Лезгинка»ны җибәр әле! Шәмәхә кәгазь — бездән, музыка — сездән!»

Рүдәл, аяк очларына басып, кулларын кош канаты сыман җәеп, бер урында тыпырдап алды.

— Ташла шул кешедән көлүеңне.

— Туры әйткән туганына ярамаган, диләр. Мин бит гаеп итеп әйтмим. Нишлисең, тормышта һәркемнең үз юлы. Талант булса, мин дә музыка факультетына керер идем. Колагыңа сыер типкән булгач, кая барасың — тарих факультетына. Сез бүгенге белән яшисез, ә без — үткәндә. Теге патша теге патша белән ни өчен сугышкан, бу патшаның күпме байлыгы булган, ырулык чорында безнең бабаларыбыз нинди ыштан киеп йөргән, урта гасырда сөңге белән сугышканнармы, кылыч беләнме? Без менә шулар белән яшибез. Ә сезнең — көн дә бәйрәм, көн дә туй. Музыка, бис, браво, афәрин! Тормыш түгел, тоташ фейерверк!

Искәндәр, теләмичә генә, аның сүзләренең дөреслеген шик астына алу өчен генә тырышып көлгәндәй итте. Тамак төбенә төер тыгылып, буыла-буыла ютәлләргә тотынды. Рүдәл шап-шоп итеп аның җилкәсенә сукты. Ул, ничектер, кызганмыйча, үч алырга теләгәндәй, авырттырып суга иде.

— Дөрес сүзгә җавап юк! Бөтенегез җылы җирләргә урнашып беттегез инде, мин генә калдым бер кырыйда аксак чәүкә сыман. Хәмит — заводта цех башлыгы, Интизар — этисенең җылы кочагында. Күр дә тор, кибет директоры булып урнашачак ул. Әле генә Фиданны күрдем, юньләп сәлам дә бирми. Нәрсә булган соң, мин әйтәм. Карасам, егетебез склад мөдире булып урнашкан икән. Кереп чык дип тә әйтмәде.

«Сине чакырсаң, бәладән башаяк,— дип уйлады Искәндәр.— Юкны бар итеп бөтен шәһәрне сасытыр идең».

— Ярый, мин ашыгам. Төш җитеп килә инде. Ә минем бер нәрсә әзер түгел.

— Син дә эреләндең, кунакка да чакырмыйсың.

— Соң, син өйләнмәгән кеше, ә без... парлы кунаклар гына чакырган идек.

— Соң үзең дә буйдак түгелме соң хәзер? Әллә Сөмбел кайттымы?

— Кунакларны без инде әллә кайчан, аның белән бергә чакырып куйган идек.

— Хәзер ул юк бит инде. Аның китүен, бәхетле, бәйсез көннәрең башлануын бәйрәм итмәкче буласыңмы?

— Яңа ел барыбер килә бит ул, Сөмбел китте дип вакыт туктамый.— Искәндәр, җиңен кайтарып, сәгатенә күз ташлады. Секунд теле, тегермән әйләндерүче миңгерәүләнгән ат кебек, түгәрәк буйлап җан-фәрманга чаба иде. Ул, Рүдәл каршында сәгатькә карап торуына уңайсызланып, көлемсерәде дә сүзен дәвам итте.— Вакыт поезд кебек бит ул, пассажирлар һәрберсе үз станциясендә төшеп кала,— ул бара да бара.

— Ә ул кая китте соң?

— Белмим, поезд белән киткән...

Рүдәлнең күзләре, кысылып кара сызыкка әйләнде.

— Сөмбел төшеп калды, ә мин алга киттем димәкче буласыңмы?

— Киресенчә...

— Шаяртма. Ашыкмый тор. Бәлки ул чыннан да алга киткәндер, ә син төшеп калгансыңдыр.

— Калсам, калырмын, синең эшең түгел.

Рүдәл бүреген тагы да батырыбрак киде дә, кырт борылып, китеп барды. Искәндәр шулчак, нидер сизеп, ихтыярсыз бүреген салды. Бүреге өстендә бәләкәй генә ак өем агарып тора. Күгәрчен башына «пәп» итеп киткән. Аяк астында буталып йөрүче кызыл томшыклы, түгәрәк бүксәле ваемсыз күгәрченнәр бөтен кыяфәте белән Рүдәлгә охшап күренделәр аңа.

Искәндәрнең Рүдәлгә артык исе китми иде, тик менә Сөмбел генә... Алар һәрчак бер-берсен яклыйлар, бер-берсенә сүз әйттермиләр иде. Бу нәрсә Искәндәрнең җанын борчый, ул моңа чыгырыннан чыгардай булып үртәлә.

Әле бүген дә аның авызыннан Сөмбел турында ишеткәч, йөрәге өзелеп төшеп киткәндәй булды. Ул Сөмбелнең киткәненә, аны ташлап киткәненә сөенеп бетә алмый кебек иде. «Әгәр дә ул Сөмбелне эзләп барса?» — дип уйлады Искәндәр кинәт кенә. Искәндәр Сөмбелнең аныкы булуын күтәрә алмаячак. Теләсә кая китсен, теләсә кем белән яшәсен, бары тик аныкы гына булмасын. Бу аның бәгырен өзәчәк, горурлыгын аяк астына салып таптаячак. Ун ел элек аның кулыннан тартып ал да: «Мин аңа лаек түгел, ул синеке булырга тиеш»,— дип, кире кайтар имеш. Юк, болай булмас. Нигә дип аның поезд белән китүен әйттем соң әле? Хәзер ул аның бөтен туган-тумачасын белешәчәк, эт шикелле иснәнеп эзләп табачак. Аның каршына махсус чыгып торган ул, кая киткәнен белер өчен махсус сөйләштергән. Ә мин беркатлы...»

Кафе бөтенләй буш диярлек иде. Искәндәр касса янына килеп басты. Касса артындагы әби — пенсионерка булса кирәк — аңа йокылыуяулы караш ташлады.

— Сездә Фидан дигән егет эшлиме? — Искәндәр моны теләр-теләмәс кенә, икеләнеп кенә әйтте. Мондый шып-шыр кафеның складь һәм шул

складның мөдире дә булуын ул берничек күз алдына китерә алмый башлаган иде.

— Юк, белмим, андый кешене белмим. Кыяфәте ниндирәк?

— Тазарак кына, озын буйлы, түгәрәк йөзле, чәчен артка тарап йөри. Боксерга охшаган.

— Кем булып эшли соң ул?

— Склад мөдире...

— Ә-әй, Федяны әйтәсеңме? Күптән шулай диләр аны. Әллә нинди Фиданнарың белән баш катырасың. Эшли, эшли, нишләп эшләмәсен ди. Алтын егет ул безнең.

Кассир әби шул арада балкып китте.

— Ә син аның кеме буласың соң?

— Бергә укыган идек... Дусты... Иптәше...

— Нигә аны баштук шулай димисең? Кадерсез кунак сыман... Әйдәле, алып керим әле янына.

Искәндәр кассир әби артыннан иярде. Стена кырыена тау-тау өелгән әрҗәләр арасыннан боргалана-боргалана шактый бардылар. Кассир әби әрҗәләр өеме арасындагы сейфка охшаган ак калай тышлы ишекне сак кына, яратып кына шакыды.

— Кем бар анда?— дигән калын тавыш ишетелде эчтән. Искәндәр Фиданның бәрхет бас тавышын шундук таныды.

— Мин бу, Федя. Сине сорыйлар, дустың диме шунда...

Эчтә пыяла чылтыраган, акча коелган авазлар ишетелде, пышылдашып алдылар да тагын тындылар.

— Хәзер, безнең бераз эш чыкты әле монда, көтегез.

Искәндәр шушы буш һәм салкын бинада җылы сүзләр ишетүенә ышанырга да, ышанмаска да белмичә, беркавымга югалып калды. Ул арада кассир әби аякларын чаж-чож сөйрәп китеп тә барды. Әрҗә таулары арасындагы лабиринтның әле бер почмагыннан, әле икенче чатыннан кемдер килеп чыга да, өскә күтәрелеп карамыйча гына, култык астындагы төенчеген чытырдатып кыскан килеш, аның яныннан үтеп китә. Кеше узган саен ул тимер ишеккә елыша, ә эчтә нидер пышылдашып алалар да, тагы әлеге кыймmәтле бәрхет аваз ишетелә:

— Чак кына көтегез инде, хәзер...

Ниһаять, ишек шалтырап ачылды. Искәндәрнең борын төбеннән генә мәче елгырлыгы белән ике кеше чагылып узды. Ул аларның ирме-хатынмы икәнен дә абайлый алмады, бары тик кулларындагы буаз сумкаларын гына күреп калды.

— О-о-о! Кемне күрәм мин? Искәндәр галиҗәнаблары түгелме соң бу?

Искәндәр, ни әйтергә дә белмичә, каккан казык кебек бер урында тик басып торды.

— Уз, әйдә, түрдән уз. Мондый кунак киләсен белгән булсам, юлга келәмнәр җәеп куйган булыр идем.

Искәндәрнең боеккан күңеленә шушы мизгелдә ясалма кунакчыллык та хуш килде. Күптәннән җылы сүз ишеткәне булмагангадырмы, аңа монда гаҗәп рәхәт булып китте. Түшәмгә кадәр өелгән әрҗәләр, капчыклар, почмактагы мичкәләр, баш очындагы шәрә лампочка, кулдан ясалган гади өстәл, артсыз урындык та шулкадәр якын, үз тоелды.

— Минем монда икәнне каян белдең? Ничек таптың?

— Бөтен шәһәр синең турыда гына сөйли хәзер. Фидан тегеләй дә, Фидан болай, диләр.

— Анысын арттырасың инде. Шәһәр читендәге бер алла каргаган урынга урнашкан булдым.— Ул, үзең күрәсең дигәндәй, башы белән әрҗәләргә ымлап күрсәтте.— Шушы инде безнең тормыш. Кая, нишләп сүз белән сыйлыйм әле сине? Һәй, Шамка, башыңны тык әле монда!

Ишектән күзләрен челт-челт йома-йома кызгылт-зәңгәр йөзле, искергән борынлы берәү күренде. Ул авыз ачып сүз әйтмәде, кая кушсаң — шунда чабам дигән күндәм кыяфәт белән тик кенә тора бирде. Фидан ялт итеп ике бармагын өскә күтәрде:

— Ике персонага! Беренче класс!..

Тегесе, була ул дигәнне аңлатып, рәттән тиз-тиз генә биш-алты мәртәбә күзләрен межелдәтеп куйды да җир астына төшеп киткәндәй юкка чыкты. Фидан, җитди кыяфәт алып, Искәндәргә таба борылды.

— Я, сөйләп җибәр әле, маэстро, ниләр бар синең дөньяда? Сөмбел киткән дип ишеттек. Анысына бетеренмә. Табылыр, яхшырагы табылыр, орлыклары Мәккәдә түгел. Тартылып киткәнсең дип әйтимме? Аптырама юкка, кеше китә — көшел кала, дип җырлый иде безнең бер күрше. Үз көенне үзең көйлә, үз җаеңа яшә.

Искәндәр Фидан янында сабый бала кебек югалып калды. Ул Фиданның арбадан төшеп кала торган егетләрдән түгел икәнлеген моңа кадәр дә белә, ләкин аның бу кадәр үк үз-үзенә ышаныч белән сөйләгәнен күргәне юк иде.

— Мин кайгырмыйм да. Әле иңләшеп җитеп кенә булмый. Бүлмә дә, күңел дә бушап калган кебек. Нидер җитми. Элек артык сыман иде, хәзер җитми.

— Синдә буш булса, миндә шыгрым тулы. Аз гына кәефең булмадымы, монда кил. Сөйләшербез, күңел бушатырбыз. Телисеңме, кафега музыкант итеп урнаштырам үзеңне.

— Мин эшлим бит инде. Ресторанда. Анда да син урнаштырган идең.

— Монда да эшләрсең. Эчеңне төртеп тишмәс.

— Монда сезнең... бөтенләй кеше йөрми бугай бит. Тамак ялгап алмакчы булган идем. Бер кабым әйбер таба алмадылар. Нәрсә белән сату итәсез соң сез? Ничек тоталар сезне монда?

— Синең баш җитәрлек нәрсә түгел ул. Стакатто методы белән эшлибез без.

— Анысы ничек була тагын?

— Минһаҗев дигән композиторны хәтерлисеңме? Бездә гармонияне укытып йөргән иде. Менә шул композиторның биш симфониясе, өчмедүртме концерты, әллә ничә балеты бар диләр. Ә берәрсен ишеткәнең бармы? Шиш, фуга! Ә беләсең килсә, барысы да радиога, телевидениегә, театрларга сатылган, акчасы алынган. Композитор дигән вывеска бармы? Бар. Партитура бармы? — Фидан өстәлдә яткан кәгазь өемен күтәреп бераз селкеп торды да шапылдатып яңадан өстәлгә ташлады.— Бар! Дебит, кредит һәм дә — фуга! Композитор бар, әле ничек кенә бар! Синең белән миңа караганда мең мәртәбә яхшырак яши. Ә музыка? Музыка бар да, юк та. Исәпкә бар, сангa юк. Без дә менә шушы музыкаль метод белән эш итәбез. Безнең монда үз гармониябез бар. Ярый, монысы безнең өлкәгә нәни генә экскурс булды. Хәзер, хәзер...— Ул, коридордагы аяк тавышларын ишетеп, сүзен бүлде.— Хәзер төп эшкә тотынабыз.

Тимер ишекне аягы белән этеп ачып, бүлмәгә поднос күтәргән кеше килеп керде. Подноска тезелгән шешәләр, азык-төлек, нигъмәт артыннан аның шәлперәйгән иске борыны гына күренеп тора. Ул сүзсез генә подносны өстәлгә куйды да кулларын чалбар балагына ышкый-ышкый китеп барды.

— Менә шушылар белән эшлибез инде.

— Нигә тотасың соң андыйларны? Бу бәндә нинди эш майтара алсын?

— Шул ук музыкаль метод. Ул кеше бар да, юк та монда. Күр дисәң — күрә, күрмә дисәң — күрми, ишет дисәң — ишетә, ишетмә дисәң — чукракка әйләнә.

— Нинди музыкаль метод булсын? Кешеләрне роботка әйләндереп бетерәсез бит сез монда.

— Ул бит үзе теләп шуңа бара. Кусаң да китми ул моннан. Аның өенә кереп кара син. Башың әйләнер. Аныкы төсле мебельне төшеңдә дә күрә алмыйсың. Каян таба — бер алла гына белә. Һәр кибеттә, һәр кафеда-ресторанда аның ишләре бар. Алар бер-берсе белән элемтәдә торалар. Теге кибеттә шушы минутта нәрсә бар, теге кафега иртәгә нәрсә китерәчәкләр — барысын да энәсеннән-җебенә кадәр белеп тора алар. Шулардан башка эш тә алып барып булмый. Хәзер төшеп каласың.

— Болай яшәгәнче, яшәмәвең мең артык.

— Туктале, тыпырчынма. Менә, әйтик, бүген синең бәйрәм өстәлеңдә ни була?— Фидан аның эчендәге бар уйларын белеп-күреп тора кебек иде. Искәндәр үзен урам уртасында анадан тума ялангач калган кебек хис итте. Фидан кыза барды. Аның алдына кара һәм кызыл уылдыклы ике консерв банкасы ачып куйды, калын-калын телемнәр белән кызыл балык кисәргә тотынды. Искәндәр алдына әфлисун, мандарин, лимон өелде. Өстәл уртасына әрмән коньягы белән шампанский шартлап килеп утырды.— Син төннәр буе йокламыйча, алар өчен музыка язасың, аларның рухи ихтыяжларын канәгатьләндерү турында уйлыйсың.

— Мин алар өчен язмыйм.

— Кем өчен язасың соң?

— Үзем өчен.

— Хе-хе-хе... Болай булсаң, ерак китә алмассың син, Искәндәр. Теге мескен, йомран шикелле, кул астына эләккән бар нәрсәне өенә ташый, монысы, үз мәнфәгатен кайгыртып, склад мөдире булып урнашкан. Ә миңа нигә үзем өчен язмаска, дисең инде. Мин дә кеше бит! Шулаймы?

— Шулай да булсын ди. Ә мин йомран шикелле үз өемә ташымыйм, үз күңелемдә, үз хәзинәмдә булган белән үземне юатам. Бары шул гына.

— Натураль хуҗалык була инде бу. Артта калгансың син, егет, дөньядан шактый артта калгансың. Безгә хәзер мәми авызлар түгел, токтан җиреннән өзә торган егетләр кирәк.

— Син бу айсбергың белән бер бик каты бәреләсең әле, Фидан.

— Нинди айсберг ул?

— Һич югы, шушы кафең белән. Музыкаль метод түгел бу, айсберг теориясе белән эш итәсез сез монда. Кафеның кеше күрә торган алгы ягында бер төсле, ә аста — айсберг. Пешекчеләр пешереп тормый, товарны шул килеш кенә уңга-сулга җибәрә. Эш бара, план тула, үзең әйтмешли, партитура языла, ә музыка юк.

— Бик тирәнгә керә башладың, алай-болай ОБХССтан түгелсеңдер бит? Әйдә, юк белән баш катырганчы, яшь чакларны искә төшереп, күңелне җылытып куйыйк әле бер.

Фидан хрусталь рюмканы яңгыратып чәкештерде дә бер сулыштан йотып куйды. Искәндәр, эчәргәме-эчмәскәме дигәндәй, рюмкага карап калды.

— Әйдә, күрешү хөрмәтенә! Яңа ел бит бүген, бәйрәм!

— Шуңа икеләнеп торам әле. Кунаклар килергә тиеш.

— Һә-әй, кунак килер алдыннан йөз граммны кабыпмы-кабып куярга кирәк тә инде ул.— Фидан профессиональ осталык белән әфлисунны кабыгыннан чишендереп куйды. Бу минутта ул теләсә кемне шулай тиз генә чишендереп ташлый алыр кебек иде.— Кунак килгәндә хуҗаның күңеле хуш, авызы ерык булырга тиеш.

Искәндәр, ни булса шул булыр дип, коньякны төбенә кадәр эчеп куйды.

— Менә син безне эт итеп сүктең. Белмичә сүктең. Бүген син төн буе уйнап-җырлап бәйрәм итәчәксең, ә мин дежурда булам. Теләсәм

дә, сиңа бара алмыйм. Бүген төнлә безгә вагон килергә тиеш, шунсыз план тулмый. Ул вагонны быелгы елга кертеп калдырырга кирәк. Вакыт төшенчәсен без сезгә караганда яхшырак аңлыйбыз, димәк ки, безнең эш сезнекенә караганда фәлсәфирәк, мәгънәлерәк. Иске ел поезды финишка вакытында килеп өлгерәме — юкмы, безнең язмыш шуңа бәйләнгән. Ә син күктә, болытлар өстендә яшисең, ул поездларга төкермисең дә.

— Поезд, поезд,— дип кабатлады Искәндәр.— Мин үзем поезд кебек...

— Әйдә, безнең рестораннар трестына эшкә кер алайса дим бит.

— Син һаман шаяртасың, Фидан. Ә минем эшләр шаярудан узган.

— Ул хәтле нәрсә булды соң әле сиңа? Кителеп төшкән җирең күренми. Сөмбел киткәч, иҗади фантазиягә куәт керә башласа гына...

— Шаярмыйм мин, Фидан. Инде менә бер ай буе һәр төнне төшемә поезд керә. Шпаллар арасыннан чәчәк җыеп йөргәндә әллә каян гына килеп чыга да ажгырып өскә килә. Мин чабам, чабам, поезд аның саен якыная, менә-менә сытып-изеп узар сыман. Мин һаман алга йөгерәм, ә рельстан читкә чыгарга башыма да килми. Инде поезд җилкәмә килеп терәлде генә дигәндә, кычкырып уянып китәм. Төш юрый беләсеңме син?

— Әби-сәби шикелле төшкә ышана башладыңмы әллә инде?

— Төш — кешенең еллар буе уйлап-хыялланып йөргән хисләренең соң чиккә җитеп кысылган бер йомарламы ул. Юк нәрсә төшкә керми. Кеше дөньяда булмаган нәрсә турында уйлый да, хыяллана да алмый. Бу поезд да юктан гына түгел. Минем язмыш — поезд язмышы кебек. Туу белән мине бер рельска кертеп җибәргәннәр дә, әле менә һаман шуннан чыга алганым юк. Кешеләр җил-давыллы, кайгы-хәсрәтле станцияләрне читләтеп үтә. Ә мин — юк, мин турыга барам, мин рельстан чыга алмыйм. Сөмбел киткәч, рельссыз тормыш башланыр дигән идем, баксаң, бүтәнчә яши белмим икән.

— Син, Искәндәр, тормышыңны юкка катлауландырасың. Тормыш син уйлаганча ук катлаулы түгел бит ул. Һәркем үзенең бәхете турында үзе кайгыртырга тиеш. Һәр кеше бәхетле булса, бар халык бәхетле була, дөнья түгәрәк була. Бары шул гына, бик гади бит югыйсә. Син инде үзеңне зур максатлар өчен дөньяга килгән дип саныйсың. Сана, әйдә, саный бир. Институтта укыган чакта ук йолдыз чире белән чирли идең. Һаман терелеп җитмәгәнсең икән. Әллә мине... музыканы үземә караганда кимрәк ярата дип уйлыйсыңмы? Һо-о, юк! Арып-талып эштән кайткач, пианино янына килеп утыруга, бу дөньяның бар әрҗәләре, капчыклары эреп әллә кая юкка чыга. Менә шул чакта мин дә канатланам, мин дә яши башлыйм, шул чакта гына үземне бәхетле хис итәм мин. Ә болар,— Фидан бүлмәгә, өстәлдәге нигъмәтләргә битараф караш ташлады,— болар бер юаныч кына. Миннән барыбер композитор да, зур музыкант та чыкмый. Ә яшәргә кирәк. Типтереп, сиптереп, кешеләрнең күзләрен яндырырлык итеп яшәргә кирәк. Музыкант Фиданны тыңларга теләмәгән идегезме, ярый, менә хәзер склад мөдире Фидан янына килерсез. Бил бөгә-бөгә керерсез, рәхмәт укый-укый чыгып китәрсез. Ә ул сезнең арттан мыскыллы көлеп калыр.

— Ярый, мин китим әле, Фидан.

— Кая ашыгасың? Үпкәләдеңме әллә? Буш өйгә кайтып нәрсә эшләмәк буласың? Кем көтә анда сине?

— Кунаклар киләсе. Өстәл әзерләргә кирәк. Кибетләргә йөрисем бар.

— Нинди кибет ди ул тагын? Нәрсә кирәк, бөтенесен төяп җибәрәм хәзер. Әй, Шамка!

— Нинди Шамка ул тагын? Кирәк түгел.

— Шамил аның чын исеме. Нәрсә кирәк сиңа?

— Бер нәрсә дә кирәк түгел.

— Ә нигә генә кердең соң монда? Минем янга йомышсыз кермиләр...
Фидан аның буш сумкасына карап куйды.
— Хәлеңне белергә.
— Әйдә, алай булгач, юл аягына берне күтәреп куйыйк. Яңа елны каршы алу да шул булыр.
— Ярый, мин китим инде.
Искәндәр, буш сумкасын селки-селки, әрҗәләр артындагы лабиринт буйлап әкрен генә чыгып китте. Фидан, башын артка ташлап, сүзсез генә сейф-бүлмә эчендә басып калды. Саубуллашып та тормадылар, бер-берсенә хәтерләре калган иде аларның.

Урамга түшәлгән ап-ак кар һәм кояш яктылыгыннан Искәндәрнең башы әйләнеп китте. Ул, баскыч култыксасына таянып, күзләрен йомган килеш шактый ара басып торды. Җиргә сибелгән миллион йолдызлар күзне авырттырып җемелди. Искәндәр буш сумкасы белән аяк балтырына шапылдатып сукты да йолдызларны шыгырдата-шыгырдата атлап китте. Шәһәр чите булгангадырмы, урам буш, бары тик сары чәчле малайга охшаган кояш кына биек йортлар артыннан башын күтәргән дә якты күзләрен олы итеп ачып үреләүреләү шәһәргә карый. Шулчак Искәндәргә дөньяда кояш белән үзеннән башка беркем дә юктыр сыман тоелды. Хәмитләр, Интизар, Альфред, Рүдәл, Фиданнар — барысы да үз өннәренә кереп качкан йомраннар. Алар тышта кар эреп, дөнья җылынмыйча, гөлләр чәчәк атмыйча, шул өннәреннән чыкмаслар, җыйган ризыкларын эшкәртеп ятарлар кебек. Ә ул аларның өенендә яши алмый, аның йомран өенә керәсе килми, анда аны кабул итәргә атлыгып торучы да юк...
Искәндәрнең борын төбеннән генә гөрселдәп буш трамвай узып китте. Ул тукталышка кадәр йөгереп барды да трамвайның иң арткы утыргычына кереп утырды. Трамвайда беркем дә юк иде, шуңадырмы, ул бөтен көченә чаба, озын гәүдәсе белән як-якка атына. Шулай атынып бара торгач, Искәндәр үзенең йокыга киткәнен сизми дә калды.

Трамвай ап-ак каен урманын урталай ярып чаба да чаба. Туй күлмәге кигән сылу каеннар сискәнеп юл читенә тайпылалар. Каен урманын чыгуга яшькелт киемле солдат егетләргә охшаган усаклар арасына ажгырып килеп керделәр. Аннары алда колач җитмәс гәүдәле имән баһадирлар күренде. Трамвай ачы тавыш белән сызгыра, бөтен гәүдәсе белән калтырый, коточкыч авазлар чыгара. Аның кыяфәтен күргә йөз яшьлек имәннәр тамырлары белән куптарылалар да җан-фәрманга чаба башлыйлар.
— Туктатыгыз! Туктатыгыз!— дип кычкыра Искәндәр.
Ә трамвай һаман чаба да чаба.
— Туктатыгыз! Мин төшеп калам!
Аның сүзенә колак салучы, аны ишетүче, аңа җавап бирүче юк. Ул урыныннан сикереп тора да буш вагон буйлап чабып китә. Трамвай йөртүче кыз утырган кабина ишеген йодрыклары белән төяргә тотына, буш сумкасы белән шап-шоп суга.
— Туктатыгыз! Без кая барабыз? Мин төшеп калам!— дип инәлеп кабатлый ул.
Ә трамвай һаман күз иярмәс тизлек белән алга ыргыла, барган саен урман куера, караңгылана. Ишекне төя-төя Искәндәрнең куллары арый, башы стенага бәрелә. Ә дию арбасы һаман чаба. Менә арба ут булып кыза, аны ялкын чорный, Искәндәр бер баштан икенче башка чаба, тирләп-пешеп чыга, чәчләреннән бу күтәрелә. Һәм ул, аптырап, хәлдән таеп, утыргычка утыра да, үзенең көчсезлегеннән гасабиланып, тавышсыз

үксеп җибәрә. Шулчак дию арбасы туктый, алда ялтырып, миллионлаган рубин йолдызлары белән күзләрне чагылдырып әкият сарае балкып күренә. Түрдәге пыяла ишек ачыла, аннан... кинаяле елмаеп алды капкара, арткы ягы ап-ак күлмәк кигән... Сөмбел килеп чыга. Килеп чыга да аяклары җиргә тияр-тимәс атлап... юк, атлап түгел, йөзеп аңа каршы килә... Килеп җитә дә сак кына аның җилкәсенә кагыла.

— Әйдә, төшәбез!— ди ул боерган аваз белән.— Килеп җиттек.

Шулчак колак төбендә меңләгән йолдызлар чыңлап куя да сүнә. Искәндәр күзләрен ача. Кырыйга шуып төшкән бүреген рәтләп куя, сәерсенеп күтәрелеп карый.

— Төшәргә вакыт, гражданин. Инде өченче тапкыр әйләнәсез. Билет та алмадыгыз. Әллә йокы планы тулмаганмы?— дип трамвай йөртүче кыз дәшә икән.

Табак-савытларны юып, тузаннарны сөртеп, урын-җирне тагын бер кат пөхтәләп чыккач, ул хәлдән таеп креслога утырды. Бер эшсез кеше кебек, түшәмдәге ярыкларга, җөйләргә, почмактагы обой җыерчыкларына, шкаф җекләренә, идән ярыкларына кадәр күздән кичерде. Шулчак бүлмәсе искиткеч зур булып тоелды аңа. Ипи-тоз күтәреп, беренче тапкыр ишекне ачып кергәч тә шулай күренгән иде. Аякларын төрек солтанына охшатып бөкләп, идән уртасында шактый озак онытылып утырган иде ул чакта. Стеналар шып-шыр, кызгылт-соры идән көзге болын кебек зур да, буш та...

Искәндәр идәндә гаҗәпләнеп утырган арада, Сөмбел кухняга кереп чыкты, туалет, ванна ишекләрен ачып карады, бүлмәне аркылыга-буйга адымлап үлчәп чыкты. Үзе йөри, үзе бертуктаусыз сөйләнә:

— Менә монда диван куябыз, монда — өстәл, бу почмакка — телевизор, бу якка — сервант, ишек катында — шифоньер.

Искәндәргә аның сүзләре стена аша сөйләшкән кебек тонык кына ишетелә. Ул, күзләрен йомып, Сөмбел сөйләгән әйберләрне күрергә тырышып карый, ләкин алар үч иткәндәй күз алдына килми дә килми. Ул тагын күзләрен йома, шулчак стеналар музыкаль штукатулка сыман зеңгелдәп куя да буш бүлмәгә бөтен җирдән: тәрәзәләрдән, ишекләрдән, вентиляция торбаларыннан, идән ярыкларыннан музыка агыла башлый. Музыка авазларыннан аның колаклары авырттырып чыңлый, гәүдәсе кош сыман җиңеләеп кала. Ә музыка агыла да агыла. Музыка, аллыгөлле төсләргә кереп, аның күзләрендә чагыла, музыка, чишмә чылтыравына охшаган көлү авазы булып, идәнгә чылтырап коела.

— Тахта белән сервант арасына пианино алып куярсың. Бигрәк тар инде... Бер бүлмә — бер бүлмә инде... Алгач-алгач, зуррагы кирәк иде... Әнә, кешеләр...

Искәндәрнең күз алдында ап-ак пианино калкып чыга. Аның капкачы үзеннән-үзе ачылып китә дә икегә аерылып ике канат сыман як-якка җәелә.

— Кеше шикелле бер урында гына төпләнеп эшләсәң, күптән әллә кем булыр идең инде. Йөрисең бит шунда әнәк эте сыман ары тулганып, бире болганып. Аңа гына ярамый, ул гына талант, имеш. Талантны үлчи торган прибор табылмаган әле, кешене хәзергә эше буенча бәяләр. Эшләгән ашый, эшләмәгән... баш кашый...

Ак пианино өстенә көл коелган төсле булды, аннары ул күзгә күренеп карала башлады. Бары тик ак клавишалары гына ап-ак тешләргә охшап, елмаеп, балкып тора.

— Моннан ары болай яшәп булмый. Зарплатаңны тиенен тиенгә миңа биреп барасың. Җүнлерәк мебельгә җыярга кирәк. Шушы мәктәбеңдә кешечә генә эшлисең. Музыка язам дисең икән, яз, сине беркем дә

тыймый. Юк нәрсә белән маташуыңны аңлагач, үзең белеп туктарсың әле.

Кара пианино сәерсенеп тыңлап торды-торды да, ак тешләрен ялтыратып шаркылдап көлеп җибәрде.

— Нәрсәдән көләсең? Әллә бер бүлмәле квартир алдым дип, акылдан яза башладыңмы?

— Сөенә белмисең син, Сөмбел. Гаҗәпләнә, шакката белмисең.

— Нәрсәсенә шаккатасың моның?

— Юк кына нәрсәгә дә гаҗәпләнә белергә тиеш кеше. Шунсыз дөньяның бер кызыгы да юк бит. Һәр нәрсәгә гадәти әйбер дип карасаң, туып торуыңнан ни мәгънә?

— Һәр очраган нәрсәгә шаккатып карап тора башласаң, урам чатына да чыгып җитә алмассың. Олы юлга, ерак сәфәргә чыккан кеше һәр әремгә сокланып, һәр чәчәкнең таҗ яфрагын санап тора алмый.

Искәндәр ярым шаярып, ярым җитди кыяфәт белән җыр сузып җибәрде:

> Олы юлның тузаны ла, күрми калдым тузганын,
> Күрми калдым, сизми калдым яшь гомеремнең узганын.

— Менә, менә, нәкъ өстенә бастың. Гомер кыска, юл озын, аргы башына барып җиткәнче...

— Әйбәт кеше син, Сөмбел. Синең һәр сүзең үзең өчен шулкадәр дөрес, ә минем өчен дөрес түгел. Мин шушы бәләкәй генә фатирны да зур итеп күрәм, шуңа сөенәм. Ә синең аңа исең дә китми...

— Кеше алга карап яшәргә, зур хыяллар белән хыялланырга тиеш.

— Зур хыяллар...— Искәндәр, сүзен бүлеп, бармагы белән тәрәзә пыяласына тиз-тиз генә ике сызык сызды, аннары алар өстенә аркылы таяклар тезеп чыкты, шлагбаум ясап куйды.— Мин бу шәһәргә поезд белән килдем. Поезд ерак, бик ерак бара иде. Җир читенә хәтле. Ә миңа анда барырга кирәк түгел, мин шушы шәһәрдә төшеп калырга тиеш. Миңа башта шушы беренче тукталышны өйрәнергә, шунда яшәргә, гаҗәпләнеп, сокланып яшәргә кирәк иде. Әгәр дә, син әйтмешли, зур хыяллар белән хыялланып, бер тукталышта да туктамыйча гел алга барсам, ерак, бик ерак китәр идем мин. Ләкин ерак китүдән ни файда? Мин бит тирә-юньдәге матурлыкны күрмәс, дөньяның мәгънәсен аңламас идем. Буш вагоннар таккан поезд кебек мәгънәсезгә чабар да чабар идем. Юк, миңа андый тукталышсыз ерак сәфәр кирәк түгел. Һәр тукталыш — минем өчен соңгы тукталыш кебек. Шул тукталышны ачып, өйрәнеп бетермичә алга бара алмыйм мин.

— Син, гомумән, кая барганыңны белмисең, Искәндәр.— Арлы-бирле йөри торгач, Сөмбелнең аяклары арыды булса кирәк, ул идәнгә, аның каршына килеп чүгәләде.— Шуңа күрә дөньяны беркайчан да аңлый алмаячаксың. Мине дә аңламыйсың. Менә син поезд, дисең. Уйлаганың бармы соң, без шул поездда урыннары очраклы гына янәшә туры килгән пассажирлар кебек бит. Соңгы станциягә кадәр бергә барып җитеп булырмы?

— Соңгы станция...— Искәндәрнең күз алдына аермачык булып кара пианино килеп басты.— Син ераграк китәрсең, Сөмбел. Мин шушында гына калырмын инде. Гаҗәпләнеп, шаккатып, сокланып бетмәдем әле мин.

— Кемең бар соң синең монда?

Искәндәр аның бу соравын җавапсыз калдырды. Сүзне уенга борып җибәрмәк булды.

— Син чынлап та вокзалдагы сыман сөйләшә башладың. Әйдә, шундый көнне дә ямьсезләнеп утырмыйк әле. Чыгар термосны, ал азык-төлекне. Вокзалда икән вокзалдагыча булсын, юлда туктап тамак ялгап алу зыян итмәс.

Аннан ул кинәт кенә туктап калды да: «Кемең бар?— дип кабатлады.— Кемең бар монда?»

Искәндәр термосны ачып, капкачына чәй агызды, авызын пешерә-пешерә тиз генә йотып җибәрде. Кайнар чәй бугазын көйдереп узды, утлы шар булып, эченә кереп утырды. Утлы шар әкренләп бөтен тәнен яндырды, тамагына кайнар төер күтәрелде, гәүдәсе, куллары, башы кызышты һәм бөтен бите буйлап, әчеттереп, ирексез ике утлы тамчы тәгәрәп төште. Ул, йөзен яшерергә теләп, башын аска иде.

Шулчак, сискәндереп, нидер чылтыраган аваз ишетелде. Искәндәр беркавым аңына килә алмыйча торды. Кабалана-кабалана күлмәк итәкләрен кыстырды, битләрен учы белән сыпырды. Битенең юеш икәнен сизгәч, аптырап, югалып калды. Йөгереп барып көзгедән карады. Ике як бите буйлап сузылган кызыл эзләр күргәч, ботын чеметте. Юк, ул йокламый, ул үз аңында. Тагын кыңгырау чыңы ишетелде. Ул, йөгереп барып, телефон трубкасын алды. «Кит-кит, кит-кит»,— дип, телефон салкын тавышы белән кабатлап торганда әлеге чыңлау тагын ишетелде. Ул, трубканы ташлап, ишек янына атылды.

— Кем анда? Хәзер, хәзер! Хәзер ачам!

Ачкычын таба алмыйча яңадан бүлмәгә йөгереп керде, аяк астындагы паласка абынып егыла язды. Ишек төбендә, дөньяда иң кирәкле кеше көтеп торадыр, ул китсә бөтен нәрсә чәлпәрәмә килер, аның болай да мәгънәсен югалткан тормышы бөтенләй сүнеп-сүрелеп калыр сыман иде. Ачкычны өстәлгә куйган икән, аны алганда күз өсте-өсте өелгән ризыкларга, тәртипсез тезелгән тәлинкәгә, чәнечке, пычакларга төште. Аларны рәткә китергән арада ишекне дөбердәтә үк башладылар. Бөтен фатирны шау-шуга тутырып, менә-менә бер-бер артлы кешеләр керә башлар. Иң алдан кергән Хәмит тунын салып идәнгә ташлар да шампанский шешәсен шартлатып ачып җибәрер. Аның артыннан кочагы белән чәчәкләр күтәргән Интизар күренер. Тальян гармунын каерып тартып Альфред килеп керер, тирә-якны яхшырак өйрәнү өчен Рүдәл ишек төбендә басып калыр, Фидан кочагындагы төргәкләрен диванга китереп аударыр...

Искәндәр, башына агылып торган хыялый сурәтләрне сыпырып төшерергә теләгәндәй, маңгаен уч төбе белән ышкыды. Ишекне тагын дөбердәттеләр. Ачып җибәрсә, ишек төбендә күрше Хәбир абый басып тора. Искәндәрнең ачылган авызы ябылмыйча калды, ул үзенең каударлыгыннан үзе оялып, песи баласы сыман ишеккә елышты.

— Бик озак юандың. Әллә яшь килен алып кайттыңмы, күрше?

— Өстәл әзерләп йөрим.

— Кунаклар киләсеме?

Искәндәр, әле генә аңына килгәндәй, нәрсә дә әйтергә белмичә, тын калды. Ул тагын да бөрешеп, бәләкәйләнеп китте.

— Бер егет сиңа язу калдыргание.

Хәбир абый пинжәк кесәсеннән дүрткә бөкләнгән кәгазь чыгарды.

— Ишек төбендә басып торгач, чакырып керттем үзен. Бигрәкләр җор телле егет булып чыкты, мәлгунь. Мәзәк сөйләп эчне катырып бетерде.

— Кем ул, кайда ул?

— Китте инде, көтеп тормады. Кадыйр исемлеме шунда. Ну, анекдотларны сибеп кенә тора! Мин дә сынатмадым — бер акбашны чыгарып утырттым. Во Хәбир абыең!

Искәндәр шунда гына күршесенең шактый кызмача икәнен абайлады. Кәгазьне алды да, нидер вәгъдә итеп тә вәгъдәсен үтәмәгәнне күреп үпкәләгән кеше төсле, боек кыяфәт белән бүлмәсенә керде.

Кадыйр аның авылдашы иде. Ул мәктәптән соң тракторчы булып китте. Отпускада көньякка санаторийга барган икән. Кайтышлый аның

янына сугылырга иткән. Ике сәгатьтән артык көтеп утырган. Поездга соңга калам, ашыгам, дигән.

Искәндәрнең кул аркасындагы кан тамырлары күзгә күренеп бүртеп чыкты. Ул ишекле-түрле йөрде, тәрәзәдән урамга карап торды, почмактагы чыршыны күтәреп икенче башка илтеп куйды. Вокзалга шалтыратты, Кадыйрның поезды җиденче унике минутта китәргә тиеш икән. Җиңен кайтарып, кул сәгатен карады: җиде туларга биш минут. Өмет белән стена сәгатенә таба борылды. Иске сәгать алты туларга җиде минут күрсәтә иде. Ул беркавымга икеләнеп калды. «Кайсы дөрес йөри боларның?» Борынгы сәгать аны үртәгәндәй ябалак күзләре белән карап тора. Ул диванга менеп басты да стена сәгате телләрен кул сәгате белән дөресләп куйды.

Кадыйр аңа балачактан, мәңге кире кайтып булмый торган үткән гомердән килгән илче кебек тоелган иде. Кадыйрны күрсә, үзенең балачагы белән очрашыр, бүгенге аһ-зарлардан котылып, яңадан сабый хәленә кайтыр, өр-яңадан яши башлар иде кебек.

Ул үзенең китап тулы портфель күтәреп беренче тапкыр мәктәпкә барганын күз алдына китерде. Тирә-юньдә чәчәк ташкыны агыла, көлү тавышы урамга сыймыйча, капкаларга, йорт стеналарына барып бәрелә. Шулчак йортлар, капкалар сихри бер төскә кереп балкый башлый. Менә Искәндәрне күтәреп алып урындыкка утырталар да кулына гармун тоттыралар. Ул олы гармун артында бөтенләй югалып кала, нәрсә уйнарга да белмичә, бармакларын гармун телләренә куйган килеш, тик тора. «Уйна! Уйна!» — дип хор белән кычкыралар аңа. «Нәрсә уйныйм соң?» — ди ул пышылдап кына. «Совет Армиясе»н уйна, «Каршылау Маршы»н уйна!» Ул гармун күреге өстенә башын кыңгыр сала да уйнап җибәрә. Гармун авазына кушылып бар халык гөр килә. Уйнап бетергәч мәктәп директоры аның башыннан сыйпый. «Каян өйрәндең болай оста уйнарга? Музыкант чыгачак синнән. Юлыңнан тайпылмыйча барсаң, менә дигән композитор чыгачак». Директорның сүзләре күңелне рәхәт кымырҗытып тора башлый. Шул сүз аның төшләренә керә, малайлар таяк атка атланып йөргәндә ул шушы тылсымлы сүз канатында оча, бүтәннәр башын мендәргә төртеп, мыш-мыш йоклаганда шул сүз аны ай сукмагы төшкән урман аланнары буйлап атлата, йолдызларга кадәр алып менә.

Ул, Кадыйр килеп керүен көткәндәй, күзләрен ишектән алмый торды. Ләкин балачак ишеге ачылмады, ул мәңгегә ябылган иде.

Искәндәр пианино янына килеп утырды. Аның куллары кагылуга пианинодан сагышлы музыка агылды. Искәндәр бар дөньясын онытып, алга-артка чайкала-чайкала уйнады да уйнады. Музыка өермәсе аның күзләрендәге утлы күмерне өреп кабызды, күңел җилкәннәрен кабартты. Шулчак ул үзенең әле моңа кадәр ишетелмәгән, ләкин аһәңнәре инде ничә еллар буе җанында яңгырап торган гаҗәеп таныш та, ят та, сәер дә шулай ук искиткеч якын да бер көй уйнаганын аңлады. Бу аның язмышы турындагы көй иде. Искәндәр үзенең бармакларын да, гәүдәсен дә тоймады, ул үзе каядыр эреп юкка чыкты, аның урынында бары шул көй генә торып калды. Гүя аның гәүдәсен кара табутка салганнар да бүлмә уртасына куйганнар. Пианино-табуттан үзеннән-үзе тылсымлы музыка агыла, бу шулай Искәндәрнең җаны елый, өзгәләнеп-өзгәләнеп җаны елый, язмышы турында сөйли.

Табут тышында кемдер көмеш шөлдер чылтыратты. Аны чакыралар, аның музыкасын, аның җан авазын ишеткәннәр дә кешеләр Искәндәрне үз араларына, үз яннарына чакыралар. Ул аларга кирәк...

Искәндәр авырлык белән башын күтәрде, чигәләрдә чыңлаган аваз-

лардан арына алмыйча бер ноктага текәлеп торды. Көмеш шөлдер тагын аваз салды. Ул, ихтыярсыз атлап, телефон янына килде.

— Искәндәр! Искәндәр! Нигә эндәшмисең? Искәндәр, дим! Өф! Өф! Әллә телефон эшләми инде?

— Мин бу, тыңлыйм.

— Нәрсә, йоклый идеңме әллә? Тавышың кабердән килгән шикелле ишетелә.

Искәндәрнең телефонны төбе-тамыры белән йолкып тәрәзәдән урамга ыргытасы килде.

— Ни кирәк сиңа?

— Бик кырт сөйләшәсең. Мин сиңа яңа хәбәр җиткермәкче булам, ә син...

— Ни булды?

— Телеграмма килде. Сөмбелдән...

Искәндәрнең трубка тоткан кулы хәлсезләнеп асылынып төште. Ул ваемсыз кыяфәт белән уттай янып торган кызыл телефонга текәлде. Аннары, аңына килеп, трубканы колагына китерде.

— Сөмбелдән? Ул кайда? Нәрсә дигән?

— Яңа ел белән котлаган...

— Телеграмманы каян суккан?

— Хәзер карыйм, менә монда язылган бугай. Якты юл, дигәнме шунда? Әйе, Якты юл.

— Кайда икән ул?

— Белмим... Колакка чалынган да сымак үзе. Юл булгач, берәр олы юл буендагы шәһәр кисәгедер. Хәзер көн тудымы — яңа шәһәр салалар бит. Якты да булгач, бүгенге яңа шәһәрдер... Үзең нишләп ятасың соң әле? Кунакларың килә башладымы? Безнекеләр белән монда өй тулды инде. Утырыр урын да юк. Чакырмыйча-нитмичә килделәр дә керделәр. Кичкә үзебез дә чакырулы бит. Ничек котылырбыз боларыннан. — Хәмит, шикәр кимергән кебек, кетердәтеп көлеп җибәрде. — Төнге уникедән соң җыелышып үзәк чыршы янына чыгабыз. Әйдә, шунда күрешәбез. Берәрне кыстырып та чыгарбыз. Яңа елда иң беренче күргән кешең мин булыйм әле...

Хәмит сөйли дә сөйли, ул сөйләгән саен, Искәндәрнең колаклары томалана бара, күңеле һаман саен ныграк үртәлә. Әгәр хәзер трубканы ташламаса, аның колаклары чукракланыр күк.

Ул телефон трубкасын шапылдатып куйды да өстәл янына килеп коньяк шешәсен ачты, рюмканы тутырып салды. Кулны күтәреп каршысыннан чәкешергә кеше эзләде, беркем дә юк икәнен аңлагач рюмкасын яңадан куйды. Шулчак аның тыны буыла башлагандай тоелды. Ул форточкаларны ачты, күлмәк якасындагы өске төймәне ычкындырды, әмма сулыш алу җиңеләймәде. Аптырагач, подъездга чыкмакчы булды. Коридордан үтешли чөйгә эленгән пальто кесәсеннән тырпаеп торган гәҗитләрне алды. Аннан берничә хат белән открытка да иярел чыкты. Хатның берсе мәктәптә бергә укыган кыздан, икенчесе курсташы Сәбиләдән иде. Сөмбел киткәч, ялгызлыктан каңгырып, нишләргә дә белмичә утырган көннәрнең берсендә ул бөтен таныш-белешләренә Яңа ел белән котлап открыткалар салды. Шуңа җавап килгән... Хатлар бер-берсенә ике тамчы су кебек охшаган. «Открытканны алдык, рәхмәт. Үзеңне дә якынлашып килүче Яңа ел белән котлыйбыз. Эшеңдә, иҗатыңда яңадан-яңа уңышлар телибез».

«Боларның күңелендә бер генә җылы сүз дә калмадымы икәнни?» — дип уйлады Искәндәр. Салкын кәгазьле хатларны урындыкка ташлады, игътибарсыз гына соңгы открытканы әйләндереп карады. Беренче хәрефләрне күрүгә үк бармаклары буйлап чемердәп җылы йөгерде. Открытка аның кызыннан — Ләйсәннән иде.

«Эткәй!

Без хәзер монда яшибез. Кайда икәнен язсам, әнкәй ачулана. Ул хәзер эштә, мин мәктәптән кайттым. Бездә озакламый Яңа ел житә. Шифоньерда минем Миләүшә исемле курчагым калган. Бер кулы юк аның. Бер кулы безнең әйберләр арасында киткән. Миләүшәгә читендер инде хәзер. Кулы булмагач, берни эшли алмыйча тик кайгырып утырадыр. Чыгарып ташлый күрмә аны. Мин бик-бик яратам аны.

Ләйсән.»

Искәндәр, ниндидер серле мәгънәсен ачарга теләгәндәй, һәр сүзне кат-кат укыды. Хатны кулына тоткан килеш шифоньердагы бер кулсыз курчакны өстәл уртасына китереп утыртты. «Миләүшә, Миләүшә»,— дип кабатлый-кабатлый аның башыннан сыйпады.

Ләйсән хатын укыганнан соң, ул үзенең бу шәһәрдә беркемгә дә кирәге юклыгын тагын да ныграк тойгандай булды. Ул бүген, үзләре яңа йортка күчкәндә иске йорт капкасы төбендә ташлап калдырылган хуҗасыз эт сыман, көне буе шәһәр буйлап кая бәрелергә белмичә йөрде. Һәркемнең үз мәшәкате, үз кайгысы. Хатыны булып хатыны Сөмбел дә аны ташлап китеп барды. Ул чынлап та яши белми, ахрысы. Кеше җылысына өмет итеп яшәмәскә, иң элек үз учагыңны тергезергә кирәк. Учагың сүнә башласа, сине ташлап китәләр. Беркемне дә гаепләп булмый. Әгәр дә син кешеләр арасында яшисең икән, аларның гореф-гадәтләрен, йолаларын хөрмәт итәргә тиеш.

Искәндәр пинжәген киде, ишек катына килеп бераз уйланып торды да, подъездга чыгып, күрше ишекне шакыды. Ишектән Хәбир абыйның тирләп-пешкән канәгать йөзе күренде.

— Әйдүк, күрше, әйдүк! Күрше хакы — алла хакы, диләр. Түрдән уз.

— Юк, Хәбир абый, мин синең үзеңне чакырмакчы идем.

— Әттәгенәсе, минем монда бер батальон кунаклар чакырулы бит. Чакырсак, чакырабыз инде кунакны! Во Хәбир абыең!

Озакка түгел, күз сирпеп кенә чыгарсың. Сүзем бар иде.

— Сүз булса, кирәбез. Сүзне сүз итәргә кирәк. Аллага шөкер, кеше сүзен аяк астына салып таптаган булмады. Во Хәбир абыең!

Искәндәргә нишләптер рәхәт булып китте. Хәбир абыйның мәзәк атлап йөрүләренә, һәр сүз әйткән саен йоткылыкларына хәтле күрсәтеп авыз еруларына, күңеле хуш килгән саен, «Во Хәбир абыең!» дип куюларына хәтле якын, үз тоелды. Ул моңа кадәр аңа бөтенләй игътибар итмичә йөрүе, аның белән аралашмавы өчен үз-үзен битәрләп куйды.

— Басып сөйләшкән сүзнең иманы булмый. Утырыйк әле, Хәбир абый. Мин бер көй язган идем бит әле, Хәбир абый.

— Көй дисеңме? Әйтәм, төннәр буе дыңгыр да дыңгыр килеп, йокы бирмисең.

Хәбир абый пианино ягына кинаяле елмаю белән карап куйды.

— Уйнап күрсәтимме?

— Уйныйммы дип, уйнар өчен язгансыңдыр бит инде. Минем үземнең болай сез яшьләр уйный торган көйләргә колак күнекмәгән.

Хәбир абый күз карашын өстәлгә күчерде.

— Әйдә, салып куйыйк әле башта!— Аның күңелен уятасы, күңелен музыка тыңлар өчен әзерлисе килә иде Искәндәрнең.

Аягүрә басып, рюмкаларны зыңлатып эчеп куйдылар. Хәбир абый озак кына тын алмый торды, нәрсә бу дигәндәй, коньяк шешәсен әйләндереп карады.

— Менә хәзер уйнасаң да була.

Искәндәр, пианино янына барырга кыймыйча, әле тәрәзә төбенә, әле ишек катына килде. Әйтерсең, музыка белгече каршында имтихан тотарга җыена.

— Тизрәк бул, минем кунаклар җыела анда.

Искәндәр, аның сүзләренә буйсынып, капыл гына туктады да пианино каршына килеп утырды.

Ургылып аккан суга чумарга җыенган малай сыман кулларын алга сузып, күңелендә кайнаган музыка ташкынына башы әйләнгәнче өстән карап торды. Хәзер, хәзер ташкын аны бөтерә-бөтерә үз эченә алып керәчәк...

— Хәбир, дим, Хәбир! Кая китеп олактың? Мондамы син?

Елга тынып, туктап калды. Томан эченнән утлы күлмәк кигән газраил күренде.

— Эчеп, күңел ачып утырасызмы? Инде бу дуадак каз янына иярләштеңме? Аңа карама, эчәр дә, печәр дә ул. Хатыны белән баласын куып чыгарып, берүзе квартирда типтереп ята бит, әнә.

Искәндәр бу сүзләрне ишетмәс өчен клавишаларга бар көченә суга-суга марш уйнарга тотынды.

— Әйдә, әйдә, каккан казык сыман басып торма. Тоз суы сипмәгәннәрдер монда. Аракы үзебездә дә мүре.

— Соң, хатын, көй яздым ди бит, җыру яздым ди. Шуны гына тыңламакчы идек. Шуңа гына чакырды, әйдә, син дә тыңла.

— Шушы да булдымы көй? Көйсез кешеләр көе бу. Кухняда пәрәмәчләр көя, көтә-көтә кунакларның күзе күгәрде. Нинди көй ди ул тагын? Радиодан, телевизордан көне-төне шалтыраганнары да житкән. Колаклар тонып бетә. Әйдә, әйдә!

— Көйсез кодагый булма әле, хатын.

— Әйдә дим мин сиңа!

Тәки Хәбир абыйны җилтерәтеп алып чыгып китте. Искәндәр өскә күтәрелеп карарга да кыймады.

Искәндәр уттай кызган маңгаен пианинога терәде. Аның хәзер кемгәдер сыенасы, кемнеңдер кочагына кереп җылынасы, иң өстенә башын куеп иркәләнәсе килә иде. Ләкин кара пианино аны юата алмады, бары тик күңелгә сагыш кына өстәде.

Подъездда кычкырып сөйләшкән, көлешкән авазлар ишетелде. Искәндәр шунда гына бүлмәгә кичке караңгылык иңгәнен күрде. Ут кабызгач, яктылыкка күзләре чагылудан, тәрәзә каршына килеп басты.

Урам буйлап халык агыла. Шулчак ул, нигәдер, авылда урам тутырып сарык көтүе кайткан чакны искә төшерде... Кешеләр елмая, көлә, бер-берсенең колагына иелә-иелә нидер сөйли, каядыр ашыга. Шушы кадәр халык арасында аның хәлен белергә теләгән, үз мәшәкатьләреннән азга булса гына да арынып, аның янына сугылырга уйлаган бер кеше дә юк микәнни соң?

Ул бүген үзе янына беркем дә килмәсен аңлады. Бүген дә, иртәгә дә... беркайчан да... беркем дә... килмәячәк. Аның йөрәге атылып чыгардай булып ярсый-ярсый типте, җаны, ялгызлык исе сеңгән бүлмәдә калырга теләмичә, форточкадан очып чыгарга итте. Искәндәр йөгереп барып форточкаларны япты, телефонны розеткадан тартып чыгарды. Шулай иткәч, шәһәр белән, бөтен дөнья белән алыш-биреше өзелгәндәй тоелды. Диван артындагы иске чемоданны сөйрәп чыгарды да аңа өстәлдәге бар нәрсәне сыпырып төшерде.

Өстәл уртасындагы сыңар куллы курчак кызы, күзләрен тутырып аның һәр хәрәкәтен күзәтеп торды.

Урамга чыккач, читлегеннән качкан арыслан сыман, кая барырга белмичә як-ягына каранды. Яшел утлы такси күренүгә аның каршына йөгерде. Чемоданын арткы утыргычка ыргытып, үзе таксист янәшәсенә утырды да шаккан кеше төсле бар көченә кычкырып җибәрде:

— Вокзалга!

Поезд, кемдер арттан этеп җибәргән кебек, кисәк кенә талпынып куйды, аннары, бераз уйланып торгач, ыңгыраша-ыңгыраша авырлык белән кузгалды.

Ул кергәндә купедагы өч пассажир нәрсә турындадыр бирелеп сөйләшәләр иде, кинәт туктап калдылар. Искәндәр чемоданын илтифатсыз гына утыргыч астына тибеп кертте дә өстәл янындагы буш урынга килеп утырды. Беравык барысы да тын тордылар. Тынлыкны өстәлнең каршы ягында утыручы какча йөзле, маңгайга таба өчпочмакланып төшкән көл төсендәге чәчле агай бүлде:

— Отылдым, ярты — миннән, — диде ул һәм Искәндәргә ачулы караш ташлады.

Аның янәшәсендәге түгәрәк йөзле кеше сүзгә аңлатма бирергә ашыкты:

— Бәхәсләшкән идек без монда. Ир кеше керәме, хатын-кызмы, дип. Безнеке дөрес булып чыкты. Рәхмәт сиңа.

Өстәлгә терсәге белән таянып, тәрәзәдән карап баручы кеше, авызы тулы алтын тешләрен күрсәтеп, көлеп җибәрде, бирчәеп беткән кулы белән өстәлгә сукты.

— Рәхмәт, егет, безнең сүзне сүз иттең.

Искәндәр аның кулында бер бармагы юклыгын искәрде. Килеп керүгә, пенсионерлар арасына эләктем дип көрсенгән иде, берничә минут эчендә күңеле күтәрелеп киткәнен сизде.

Какча йөзле кеше, чемоданында шактый казынгач, теләмичә генә шәраб чыгарып утыртты. Түгәрәк йөзле агай күзләрен кыса-кыса аны дүрт стаканга тигезләп бүлде, өстәл артындагы сумкасыннан каклаган каз боты алып вак телемнәргә кисте. Дүрт бармаклысы ул кискәндә авызларын чәпелдәтә-чәпелдәтә карап торды.

— Алдык, егетләр!

Өчесе дәррәү стаканнарны күтәрделәр. Искәндәр, чыгып китәргә ниятләнеп, торып басты.

— Кая син болай? Ашыкма, егет. Син булмасаң, бу шәрабның гомер чыгасы юк иде. Әйдә әле, тотып җибәр салганын, белеп кайдан алганын...

Түгәрәк йөзле агай, кулга стакан алгач, бәхет кошының койрыгыннан эләктергән сыман, бөтенләй канатланып китте.

— Әйдә, әйдә, егет кеше булуың өчен бер күтәреп куйыйк әле.

Искәндәр тартынып кына стаканга үрелде. Стакан читенә иренен тидергән килеш, астан гына сөзеп агайларның эчкәнен күзәтте.

— Болай ярамый, егет, ярамый. Чит кешеләр дисеңдер инде. Алайса, танышыйк. — Түгәрәк йөзле агай аңа ике кулын сузды. — Миңнеахмәтмотыйгулла. Авылда Мотыйк дип кенә йөриләр. Безнең якларга барып чыксаң, сора, балта остасы Мотыйк кайда тора диген. Йөз чакрым тирә-юньдә белмәгән кеше юк мине.

— Мине алай ук белмиләр, шулай да танышыйк. — Какча йөзле агай озак итеп аның кулын селкеп торды. — Ибраһим атлы булам мин. Ибраһим дип тутырып әйткән кеше юк инде бездә, Бригадир Ибрай дип кенә җибәрәләр.

Тәрәзә буендагы агай танышканда торып ук басты. Сул кулын йөрәге янына куеп, уң кулын алга сузды.

— Монысы Сәгыйдулла абыең булыр инде. Үзеңнең атың ничек соң?

— Искәндәр...

— Һай, һай, пәйгамбәрләр исемен эләктергәнсең үзең. — Сәгыйдулла агай Искәндәргә, олы хөрмәт белән карагандай, баштан аякка ка-

дәр күз йөртеп чыкты. — Әтиең иманлы кеше булгандыр. Хәзерге яшьләрдә иман бетте бит.

Бригадир Ибрай буш стаканны кул аркасы белән этеп куйды да сүзгә кушылды:

— Заманга тел тидермә, агайне. Бәхетле заманда яшибез. Өстеңә киярге бармы — бар, торыр җирең бармы — бар, тамагың тукмы — тук. Хөкүмәткә рәхмәт әйт тә мич башында тик ят.

— Заманга зарланган кеше юк. Аллага шөкер, өс бөтен, ачтан үлгән кеше дә юк. Барысы да житеш, шулар янына иман да булса...

— Нинди иман кирәк сиңа тагын? — Бригадир Ибрайның Сәгыйдулла агайга ачуы чыкты. — Иман да иман. Менә мин — кырык дүртенче елны сугыштан яраланып кайтканнан бирле бригадир, шул елдан бирле — коммунист. Әллә мине дә имансыз дияр идеңме тагын? Нәрсә өчен көрәшәбез без җирдә? Коммунизм өчен. Димәк, иманыбыз — коммунизм безнең.

— Лекция укыма әле син миңа, туган. Син белгәнне мин күптән киптереп элгән. Алтмыш бер яшьлек башың белән житмеш сигезне тутырган чал сакаллы бабаңа акыл өйрәтеп утырасың.

Искәндәр бары шунда гына Сәгыйдулланың түгәрәк пөхтә сакалына, пөхтә мыегына игътибар итте. Аның да бу бәхәскә кушыласы килә башлады.

— Мулла-мазар түгелсеңдер лә, Сәгыйдулла бабай? — Ул стаканга күрсәтеп елмайды.

— Мулла булып булмады шул. Менә сезнең кебек акыллы егетләр бәхетле тормышта яшәсен, дип, кырык биш яшькә чаклы илнең бер башыннан икенче башына дошман куып йөрдек.

Бригадир Ибрай Искәндәргә яратып карады.

— Менәтерә, яшьләр бозыла диссең, янәшәңдә барган бер дигән егетне күрмиссең. Мондый егетләр булганда дошманга махы бирү юк!

Сәгыйдулла бабай, каршы әйтергә сүз таба алмыйча, уң кулындагы дүрт бармагын өстәлдә тыпырдатып алды.

Купе почмагында рәхәт оеп утырган Мотыйгулла, монда мин дә бар дигәндәй, иренеп кенә сүзгә кушылды:

— Ташлагыз шул юк-барны. Иман да иман. Кесәңдә бер тиен акчаң булмаса, коры иманың белән әллә кая китә алмассың. Менә минем кесәдә ошбу минутта мең тәңкә акча бар.— Ул түш кесәсен иркәләп капшады.— Димәк теки, ике-өч айга минем иманым бар. Ул беткәч, шул иманны эзләп тагын чыгып китәм. Йорт килешеп, көнне-төнне белмичә ике-өч ай эшлим. Эшләгәндә авызга тамчы да алмыйм мин. Чып-чын муллага әйләнәм.— Ул Сәгыйдулла бабай ягына карап көлемсерәде.— Намазлыкка утыр да дога укы. Ә миңа дога түгел, акча, ак-ча кирәк. Акчасыз яши алмыйм мин. Кесәмдә акчам булмаса, үземне кешегә санамыйм. Һәм шулай ук бүтәннәр дә кешегә санамый...

— Акча иманыңа әйләнгән, алайса.— Сәгыйдулла агай бу сүзләрне әйткәндә борылып та тормады. Әйтерсең ул аның белән түгел, ә тәрәзә артындагы төпсез төн дингезе белән сөйләшә иде.

— Әйләнсен, аннан кемгә зыян? Үзем эшлим, үзем ашыйм, үзем эчәм.

— Ә кешеләр турында уйлаганың бармы соң?

— Минем турыда беркем дә уйламый бит әле...

— Хатының, балаларың турында димим, туганнарың, дус-ишләрең, авылдашларың турында?..

— Минем беркемем дә юк.

Шулчак Искәндәрнең йөрәге сулкылдап-сулкылдап тибәргә тотынды. Аның тизрәк шушы балта остасы Мотыйк белән ялгыз каласы, аның эч серләрен сөйләтәсе килә башлады. Ул купедан чыгып китәргә сәбәп эзләп як-ягына каранды, өске ятактагы сөлгене иңенә салып коридорга

чыкты. Коридордагы тәрәзә каршында озак басып торды. Мотыйкның чыгуын көтте. Ләкин купе ишеге ачылмады, эчтә кызып-кызып ни турындадыр бәхәсләшәләр иде. Искәндәр, беренче күргәндәй, тәрәзә артындагы агачларга карады. Агачлар юл буйлап бер рәткә тезелгәннәр дә җан-фәрманга аның каршына йөгерәләр. Инде килеп җитеп, кочакка ташланам гына дигәндә, туктый алмыйча, яшен тизлеге белән янәшәдән генә узып китәләр. Агачлар гына түгел, юл кырыена өелгән тау-тау кар көртләре, кар астыннан башын тырпайткан чакрым баганалары, куаклар арасыннан атылып чыккан куяннар, күктәге әллә нинди җәнлек-җанварларга охшаган болытлар да — барысы-барысы аның каршына йөгерәләр, аның кочагына керергә ашыгалар кебек. Ул җирне, табигатьне, дөньяны тәүге кат күргәндәй, сокланып, гаҗәпләнеп, яратып, күзләре талганчы вагон тәрәзәсеннән карап барды.

Юынып купега керсә, агайлар өстәл арасында чөкердәшеп чәй эчеп утыралар.

— Әйдүк, мактап йөрисең,— дип, балта остасы Мотыйк аңа үз яныннан урын күрсәтте.

Авызларын пешерә-пешерә чәй эчкән арада бригадир Ибрай өзелгән сүзне ялгап алып китте:

— Син чыккан арада без монда ярты Европаны әйләнеп кайттык. Бигрәк озак йөрдең, әллә берәр кызның башын әйләндердең инде?

— Безнең арада иң идейный, иң иманлы бәндә Ибраһим абзагыз булып чыкты бит әле. — Сәгыйдулла бабай, хөрмәт күрсәткәнен аңлатып, өстәлдәге конфетларны аның алдына этеп куйды.— Беләсеңме, нишләгән ул? Төн уртасында малаең өйдән куып чыгарган.

— Чыгардым шул. — Бригадир Ибрай гәүдәсен турайтты, иреннәре хәйләкәр елмаюдан юкарып калды.— Кыек юлдан йөрсә, тагын куып чыгарырмын.

— Кәперәймә, үзеңне куып чыгармасын,— дип балта остасы Мотыйк гөргелдәп ләззәт белән көләргә тотынды.— Син срогыңны тутыргансың, нәрсә алып кайтсалар шуңа риза булып тик утыр.

— Мин урын өстенә калган кеше түгел әле.— Ибрай торып ук басты.— Үлем түшәгендә ятканда да рөхсәт итмәм. Күпме яшәп, минем йортыма хәрәм ризык кергәне булмады. Мин исән чакта керәсе дә юк!

— Нинди хәрәм ризык булсын ул сиңа? Малаең җир өстендә калган бәрәңгене чүпләп алып кайткан бит, колхоз амбарыннан урламаган. Ә син, бушаттырмыйча, машинасы белән фермага илтеп аударткансың. Чал чәчле башың белән уйлап кара әле, басуда калса ул бәрәңге барыбер черегән булыр иде бит, әйеме?

Мотыйк белән Ибрай, башкаларны онытып, кулларын җәя-җәя икесе генә сөйләшә башладылар.

— Чересен,— дип үҗәтләнде Ибрай.— Черсә, колхоз җиренә ашлама булыр.

— Ул аны көннәр буе җыйган, хезмәт куйган. Син, һич югында, аның хезмәтен хөрмәт итәргә тиеш идең.

— Кушсаң, эшләмәс иде әле.

— Ну, алып та кайтты ди. Шул бәрәңгене малга ашатсаң, кемгә файда була? Сиңа бит. Ә син колхозныкы. Димәк ки колхозга да файда була. Син аннан печән сорап бармыйсың. Син хөкүмәткә шул бәрәңгене ашаган сыерны сатасың, базарга ит алып чыгасың. Каян карасаң да файда.— Мотыйк, дөрес сүзгә җавап юк дигәндәй, Ибрайның күзләренә карап торды да шопырдатып чәй эчеп куйды. Ләкин тегесе һич тә бирелергә җыенмый иде, аның саен үҗәтләнә генә барды.

— Сиңа нәрсә, сиңа — ике дөнья бер морҗа. Бүген монда син, иртәгә — җәһәннәм читендә. Ә мин шул нигездә туган, шунда үскән, шунда соңгы туй күлмәген киясе. Исән чакта минем яманатым чыгарга тиеш түгел. «Бригадир Ибрай малае машинасы белән колхоз бәрәңгесе

кайтарып аударган»,— дисәләр, оятын кая куям мин аның? Өй саен кереп, ул бәрәңгенең барыбер басуда череячәк икәнен аңлатып йөримме? Аңлатып булмый аны кешегә. Җилгә таралган сүзне җыеп алып булмый. Кермәсен ул хәрәм ризык минем өйгә, поты бер тиен... Безнең иман, Мотыйк туган, менә шул була инде — Ибрай Сәгыйдулла карт ягына күз ташлады.— Сезнеке ничектер, белмим...

— Малаең ни диде соң? Аңладымы?

— Аңлатырсың аларга? Теге еллар булса, иман кертерләр иде дә бит ул мур кыргырларына...

— Тьфү, тьфү, диген, авызыңнан җил алсын.— Сәгыйдулла бабай, кеше тыңламыймы дип, як-ягына каранды.— Җен чакырмыйча да килә ул... Үз малаеңа нәрсә теләп утырганыңны аңлыйсыңмы син?

— Аңлыйм, Сәгыйдулла абый, аңлыйм.— Бригадир Ибрай йомшара төште.— Дошманыңа күрсәтмәсен ул көннәрне. Кызып киткәнгә генә авыздан ычкынды. Юләр сүзгә йөгән юк.

— И-их, күпме яшәп тә аңлап бетереп булмый бу дөньяны.

— Нәрсәсен аңлыйсың инде аның? — дип Мотыйк сүзгә кушылды.— Барысы да ап-ачык. Эшләсәң, умырып акча аласың, акчаң булса, морҗа башына басып йөрисең. Аңладым мин дөньяның кая барганын, биш бармагым кебек беләм мин аны.

— Биш бармагым кебек, дисеңме? — Сәгыйдулла бабай аңа карап кеткелдәде.— Минем дә шулай саламнан тартә каерып йөргән чаклар бар иде. «Дөньяны биш бармагым кебек беләм»,— диюгә, шулай бер мәхлугы көлеп җибәрмәсенме! «Нигә көләсең?» — мин әйтәм. «Арттырасың, Сәгыйдулла туган»,— ди бу. «Ничек арттырыйм, ни сөйлисең?— мин әйтәм.— Шушы яшемә җитеп ялган сөйләгәнем булмады». «Әшулай да менә хәзер арттырасың»,— ди, үзе һаман көлә. Шулчак тез өстендә яткан кулыма карадым да мин дә аңа кушылып көлеп җибәрдем. Бармагым дүртәү генә икән бит минем. Берсен шахтада өздергән идем. Менә сиңа биш бармак! Дөнья турында беләм дип әйткәнче, иң әүвәл үз-үзеңне барлап, бизмәнгә салып кара икән... Шул көннән бирле тәки арттырмый башладым бит. Сүз иярә сүз чыкса, гел дөресен әйтәм: «Дөньяны дүрт бармагым кебек беләм»,— дим.

Искәндәр ике кулы белән ияген учлап, Сәгыйдулла бабай сүзләренә үз уйларын куша-куша онытылып тыңлады, тик шулай да сүзгә кушылырга кыймады. Поезд тәгәрмәчләре, сәгать йөргән тавышка охшатып, бертуктаусыз тыкылдый. Искәндәрнең күз алдына стенадагы борынгы сәгать килеп басты. Менә сәгать әкрен-әкрен Сәгыйдулла бабай кыяфәтенә керде дә ерактан, еллар түреннән килгән тоныкк аваз белән сөйли башлады. Аннары сиздермичә генә бригадир Ибрай тавышы белән сүзгә кушылды, бераз баргач, балта остасы Мотыйкка әйләнде дә ютәлли-ютәлли сугарга тотынды. Искәндәр, күз алдында төрле кыяфәткә әверелеп торган борынгы сәгатькә карый алмыйча, шәмәхә тәрәзәгә текәлде.

Тәрәзә артындагы иксез-чиксез басу-кырлар, урман-болыннар, вакыт артыннан калырга теләмәгәндәй җан-фәрманга чабалар. Юл буендагы агачлар каршыга йөгереп килеп вагон тәрәзәсеннән үреләдә, үзенә кирәкле кешене күрмәгәндәй, ары чабып китә. Кызлар кашы кебек нәзек ай да болыт көртләренә чума-чума поезд артыннан калышмый йөзә. Ай нурына манылган көмеш болытлардан ак басулар өстенә талгын музыка агыла. Искәндәр, соклануын яшерә алмыйча, пышылдады:

— Айлы соната...

— Ай, дисеңме? — Сәгыйдулла бабай да тәрәзә янынарак елышты.— һе-һей, яңа туган ай ласа бу. Тот та хәзер үк мәчет манарасына менгереп куй.

4*

Сәгыйдулла бабай поезд артыннан йөзүче айга карап алды. — Безнең авылда бер кызык адәм бар. Аны тыңласаң, эчең катканчы көләсең, чып-чын театр инде. Шулай бер көнне такта яра торган җиргә килеп кергән бу. Фырт кына киенгән, авызга фильтрлы сигарет капкан. Пиларамның түгәрәк пычкысы янына килгән дә, әйләнә микән дип, кулын куеп карамак булган. Түгәрәк пычкының әйләнгән-әйләнмәгән икәне эңгер-меңгердә күренми дә бит ул. Кулын куюы булган, пычкы биш бармагын тиң өзеп тә чыгарган. «Кулсыз калдың бит!» дип кычкырып җибәргән шунда берсе. «Кул нәрсә, кул әллә кайчангы кул инде ул, менә бияләйне беренче тапкыр гына киеп чыккан идем, бияләй кызганыч»,— ди икән бу тыныч кына. Авыртуы сизелә башлагач, үрле-кырлы сикергән сикерүен, әмма ләкин башта югалып калмаган.

— Җитеп бетми торгандыр аның...

Сәгыйдулла бабай Ибрайга усал итеп карады:

— Җүләрне чәчеп үстермиләр бит. Җүләр ул алабута кебек эрсез, теләсә кайда үсә. Ә акыллы кешегә яхшы туфрак кирәк, аңа тәрбия кирәк. Акыллы адәм бик нәзберек була ул. Вакыты-вакыты белән, басуны чүп үләне каплаган кебек, җүләрләр, эрсезләр күбәеп китә. Аларны утап басуны чистартканчы, шактый ук зыян да ясап өлгерәләр. Җүләрләр күп, ә ил-җир бераү генә. Барысына да ничек җитешсен ул? Болай да рәхмәт инде аңа, яманны яхшыдан аерырга өйрәтә, кешеләр эшләгән хатаны төзәтә. Әнә, борынгы истәлекләргә игътибар җитмәгәне искәртте бит.

Сәгыйдулла бабай, сүз шушының белән тәмамланды дигәндәй, дүрт бармаклы кулы белән өстәлгә таянды да тынып калды. Искәндәргә, алар сөйләгән саен, дөнья киңәйгәннән-киңәя баргандай тоелды. Моңа кадәр ул, чүп савытында казынган урам эте кебек, юк-бар уйлар белән тулы күңелендә казынган, дөньяның бәләкәй генә бер кисәген бәләкәй генә булмәсенә бикләп, шуннан тырыша-тырыша музыка сыгарга тырышып яткан икән. «Менә кайда икән тормыш, менә кайда икән музыка»,— дип уйлады ул. Аның өчен бу агайларның һәр сүзе моңа кадәр белмәгән яңалык ача, ул хәтта кемнең дөрес, кемнең ялгыш сөйләгәнен дә уйлап тормый, аңа һәр сүз кадерле, һәр сүз якын. Искәндәр купедагы картларга тагын бер кат күз йөртеп чыкты. Балта остасы Мотыйк ишек төбенә үк килеп ике кулын ике тезенә куйган килеш башын аска игән дә өнсез калган. Бригадир Ибрай өстәл җыештырып маташа, әйтерсең, өстәлдә тәртип урнашкач, үз күңелендәге болгавыр уйлар да тәртипкә килер дип уйлый. Ә Сәгыйдулла абый элеккечә йотылып-йотылып тәрәзәдән карый...

— Яшьләрнең урын — түрдә, карт-корыныкы — түрдә, диләрме әле? Яшьләр хәзер шәһәрләр сала, космоска, алланың үзе янына менә алар хәзер.— Бригадир Ибрай саллы кулын Искәндәрнең иңенә куйды.— Шулай бит, энекәш?

Ни әйтергә белмичә, Искәндәр тик елмаеп торды. Аның өчен җавапны Сәгыйдулла бабай бирергә булды:

— Галәмгә менү, аңысы безнең акыл җитмәс эш инде. Шулай да кадим заманнарда ук күккә менәргә омтылган безнең халык. «Ай югары, ай югары, айга менәсем килә»,— дип җырлаганмы әле борынгылар? Мәчет манарасы салуы да шул күккә менәсе килүдән эшләнгән эш бит инде аның. Менә, синең бу турыда уйлаганың бармы, энем?

Искәндәр Сәгыйдулла бабай янынарак шуышты. Бу минутта бар сүзләрен аңа гына сөйлисе килә иде, аны ул гына тыңлар, ул гына аңлар иде кебек.

— Журналларда да яздылар бу турыда. Бәлки, укыгансыздыр...

— Журналларда галимнәр күп язалар хәзер галәм-җир турында.

— Галимнәрнең төрлесе төрлечә фараз кыла. Хәзер кешенең килеп чыгуы турында да төрле гипотезалар йөри бит. Берәүләр Дарвин теориясен яклый, без маймылдан яралган, ди. Икенче берәүләр, аларга каршы килеп, бүтәнчәрәк фикер йөртә...

Ибрай, кисәк кенә Искәндәрнең беләгеннән тотып, аның сүзен бүлде:

— Манара турында минә мин дә бүтәнчәрәк уйлыйм. Күкнең монда катнашы юк. Ерактан күренеп, үзенә чакырып торсын өчен шулай биек итеп эшләгәннәр аны. Манара нигә текә, очлы итеп ясалган — янгыр үтмәсен өчен. Аннары килеп... төп авырлыгы аскы өлештә булганлыктан аның ныклыгы арта. Авылда торган кеше белә инде аны. Минем йортның түбәсе дә текә. Текә булган саен түбә озаккарак чыдый,— дип, сүзен очлап куйды Ибрай. Сәгыйдулла бабай аңа кырын күзен генә төшереп алды да, үзалдына сөйләнгәндәй итеп, әйтә куйды:

— Шәһәрдә, энә, йортларны тип-тигез түбәле итеп җиткерәләр. Эш түбәдә генә микән...— дип, сакалын сыпырып куйды. Нәрсәнедер өнәп бетермәве йөз җыерчыкларыннан ук сизелә иде. Искәндәр аның өлкән кеше булуына карамастан, дөнья хәлләре белән кызыксынуын, хыялыйрак фикер йөртүен ошатып өлгергән иде. Ләкин менә шушы минутта сүзгә кушылып китүдән тыелып калды. Галәм, чит планеталар, кешенең килеп чыгуы турында үз яшьтәшләре белән кызып-кызып бәхәсләшә торганнар иде. Ә монда... әллә ничек, ныклап танышып та өлгермәгән юлдашлар.

Мотыйк кинәт күкрәген тотып еш-еш сулый башлады.

— Һава юклыгы үзен сиздерә.— Бераз тотлыгып торгач, кесәсеннән алып бер уч дару йотып җибәрде.— Астма минем, кем әйтмешли, Әсмабикә түтиегез бугаздан ала. Коньяк кирәк. Шуны йотып куйсаң, Әсмабикә апаңның күңеле йомшый. Ресторанга барып килмисеңме, егет? Хәлем начар...

Искәндәр, утыргыч астындагы чемоданын ачып, өстәлгә коньяк шешәсе чыгарып куйды. «Һә-әй, бөтенләй истән чыккан»,— дип сөйләнә-сөйләнә, бәйрәм табыныннан сыпырып төшергән ризыкларын берәм-берәм тезә башлады. Мотыйк абыйның баш күтәрелде, күзләре ачылып йөзенә нур кунгандай булды.

— Ярый, туганнар, минем төшәр чак та житә,— дип башлады Бригадир Ибрай.— Гаепләп калмагыз. Ялгыш сүзләр ычкындырган булсам, күңелегезгә авыр алмагыз.

Балта остасы Мотыйкка бөтенләй дәрт керде, сулышы да күзгә күренеп тигезләнде, тост әйтергә җыенгандай торып басты.

— Минем теләк шул: Яңа елны менә дигән итеп каршы ал, малаеңа бүтән сүз әйтәсе булма. Авызыңа кергәнне төкермә, кеше авызыннан тартып алма.

Бригадир Ибрайның Мотыйк әйткән сүзләргә хәтере калды бугай, ул стаканын этеп үк куйды.

— Иркенләп сөйләшергә вакыт юк. Әйдә, минем белән төш, кунак та булырсың, честный авыл кешесенең ничек яшәгәнен дә күрерсең. Бик атаклы балта остасы да икәнсең үзең. Минем мунча да тузган... Сиңа кайда төшсәң дә барыбер түгелмени?

— Барыбер түгел. Сиңа мунча салганчы, кесәдәге менә бу мең тәңкәне бетерәсе бар әле.

Бригадир Ибрай, синең белән сөйләшеп эш чыкмас дигәндәй кул селкеде дә, Искәндәргә эндәште:

— Ә син кайда төшәсең, егет? Бу станциядә түгелдер бит? Безнең авылга яңа ветврач киләсе дигәннәр иде. Алай-болай шул түгелсеңдер бит?

— Юк, ул түгел.
— Сорамадык та, кая барасың соң син?
— Белмим әле.
— Ничек белмисең? Әйтәсең килмиме?
— Ерак барам, моннан күренми.
Искәндәрнең бәйләнчек сүзләргә җавап бирәсе килми иде.
— Кыркуланма әле. Бу яшьләргә авыз ачып бер сүз әйтеп булмый. Яңа ел алдыннан нинди ерак юл чыгу ди ул? Яңа елны поездда каршы алмассың бит. Әйдә безгә! Йорт станциягә терәлеп кенә тора минем. Бәйрәм итәрбез, теләсәң, иртәнге поезд белән үз юлыңа китәрсең. Билетын үзем алып бирермен. Аңа гына калмаган. Әйдә, чынлап, төшәбезме? Нигәдер якын иттем мин сине. Үз улыма да ул кадәр күңелем ятмый, хәтта... Билетың кая хәтле алынган соң?
— Карамадым. Соңгы станциягә хәтле, дигән идем кассирга...
— Кемең бар соң анда?
— Беркемем дә...
— Мине җүләргә санама.
Балта остасы Мотыйк Бригадир Ибрайның төпченүен ошатмады бугай, авыз читен сыпырып куйды да теш арасыннан сытып кына әйтеп куйды:
— Тинтерәтмә егетне. Төшәсең икән, җыена башла. Һәркемнең үз станцасы...
— Әле ярты сәгать вакыт бар минем.
Алар сөйләшеп калды. Искәндәр буфетка барып килү нияте белән җил-җил атлап купедан чыгып китте.
Күрше вагон ишеген тартты — ачылмады. Ишек бикле иде. Вагоннар тоташкан аралык бик каты чайкала, Искәндәр бер мәлгә үзен ат өстендә җайдак чапкандай хис итте. Җайдак чабу да ардырды, ә ул һаман ишек төбеннән ары китә алмады. Искәндәр, аптырагач, боз каткан ишек пыяласын сулышы белән өреп җылыта башлады. Пыялада түгәрәк күз ясалды, һәм күз алдында дулкынланып төшкән коңгырт чәч пәйда булды. Бу чәч төсе гаҗәп таныш иде аңа. Ул ашыга-ашыга тагын боз тәрәзәгә сулыш өрде: чәч дулкыннары кызның иңнәренә төшеп ятты. Нәкъ аның чәче кебек...

Имтиханнарны тапшырып бетергәч, алар группалары белән җыелышып саубуллашу мәҗлесе үткәрергә булдылар. Мәҗлескә читтән дә дус-ишләр чакырылган иде. Искәндәрнең урыны өстәл артында Фидан белән янәшә туры килде. Фиданны һәрвакыттагыча тамада ясадылар. Ул сөйли дә сөйли, кулларын җәеп мактый-мактый кешеләргә сүз бирә. Ә Искәндәрнең күзләре өстәл түрендә Рүдәл белән янәшә утырган кызда иде. Иңбашларына агып төшкән чәч дулкынында коеныр утыручы кыз исә Фиданның авызына караган да тораташ булып хәрәкәтсез калган. Ул Рүдәлне дә, мәҗлестәге башка кешеләрне дә күрми, берни дә ишетми сыман. Фидан моны сизә, сизгән саен ныграк сүзчәнләнә бара, аңа ошарга тырыша.
Хәмит баш җитмәс физик формулалар кыстыра-кыстыра сөйли башлагач, кыз карашын аңа күчерде. Хәмитнең озын-төз гәүдәсе, җөмлә әйткән саен, тагын бер яңа фикер суырып чыгаргандай, башын капыл гына артка ташлап куюлары, вакыт-вакыт туктап, «шулаймы?» дип сорау бирүләре кызның күңеленә хуш килде, ахрысы, ул Рүдәлнең колагына иелеп нидер пышылдады. Аннары, Рүдәлгә битараф караш ташлаганнан соң, аңа җилкәсе белән борылып утырды.
Интизар торып баскач, аның гәүдәсенә сыланып торган соңгы мода белән тегелгән костюмына, кардай ак күлмәгенә, күлмәк якасына килеп кунган кара күбәләгенә, бармагындагы имән чикләвеге кадәр кашлы йөзегенә карап, мәҗлестәге барча кыз өнсез калды. Ул авызын

ачса, аның авызыннан да алтын сүзләр генә коелыр сыман иде. Дулкын чәчле кыз аңа йотардай булып карап торды, костюмының һәр җөенә кадәр өйрәнеп чыкты.

— Мин сезгә бер кызык хәл сөйлим, — дип башлады Интизар.

Кызык диюгә үк, кызлар дәррәү елмаешып куйдылар.

— Көннәрдән бер көнне бер профессорның «Волга»сын урлаганнар. Милициягә хәбәр итә бу. Көне буе эзлиләр, машинаны таба алмыйлар. Кич гаражына чыгып караса, «Волга»сы елык-елык килеп үз урынында тора. Бер җире имгәнмәгән, сыдырылмаган, көзгеләренә, «дворник»ларына хәтле исән. Машина эчендә дә бар нәрсә исән-сау. Алгы утыргычта театрга ике билет һәм бөкләнгән кәгазь ята. Кәгазьдә мондый сүзләр язылган: «Хөрмәтле профессор, машинагызны алып торган өчен гафу итегез. Безгә ул бүген сезгә караганда кирәгрәк иде. Исән-сау килеш китереп куйдык. Сцеплениесе начар аера иде, төзәттек, тормозыгызны да көйләдек, бензины да — бак тулы. Шулар өстенә, прокат бәясе итеп, театрга ике билет калдырабыз. Театрда премьера бүген, билетлар ике ай алдан сатылып беткән, бармый калмагыз».

Хөрмәтле профессор намуслы каракларга рәхмәт укый-укый хатынын җитәкләп театрга бара. Ә кайтуына — ишеге ачык, бүлмәләре — шып-шыр. Болар театрда утырган арада әлеге караклар квартирны чистартып чыкканнар.

Интизар мәгънәле итеп елмайды да урынына утырды. Кызлар гөрләтеп кул чаптылар. Фиданга бу ошамады. Ул, Интизарның яңа костюмына май тамызырга теләгәндәй, сорау бирде:

— Бу гыйбрәтле вакыйганың мәгънәсе нидән гыйбарәт инде, Интизар әфәнде?

— Мәгънәсеме? Аның мәгънәсе...

—...юк,— дип Интизарның җөмләсен очлап куйды Искәндәр.

Барысы да аңа борылып карадылар. Бу көтелмәгән борылыш Фиданга да ошады, ул, чүп арасыннан алтын тапкан сыман, бөтен карашын Искәндәргә юнәлтте.

— Акыллы кешедән акыллы сүз чыга диләр. Интизар безнең арада бик озын һәм кызыклы итеп гыйбрәтле вакыйга сөйләде. Рәхмәт аңа.— Кызлар, аптырашып, бер-берсенә карап куйдылар. Фидан аскы иренен тешләп бераз тын торды да сүзен дәвам итте.— Ә Искәндәр ике хәрефле бер сүз белән шул гыйбрәтле вакыйганың мәгънәсен аңлатып бирде. Дәвам ит, Искәндәр, тост әйтергә синең чират.

Искәндәр югалып калды, керфек арасыннан күз сирпеп ташкын чәчле кызга карады. Бу юлы кызның бөтен игътибары анда иде. Ул тагын да ныграк каушады, тотлыга ук башлады. Фидан, аның хәлен аңлап, коткарырга уйлады.

— Бөекләр күп сөйләшми,— дип Искәндәргә карап әйтте ул.— Бөекләр безнең кебек фани дөнья мәшәкатьләре белән яшәми. Аларның тормыш күктә, алар илаһи уйлар белән яши, алар поэзия телендә, музыка телендә сөйләшә. Таныш булыгыз, сезнең алда — киләчәкнең бөек композиторы Искәндәр Бикмурзин.

Өстәл астына борчак тәгәрәгән сыман көлү авазлары коелды. Фидан дәвам итте:

— Хәзер ул сезгә минем сүзләремнең дөреслеген исбатлар. Әйдә, Искәндәр!

Ул Искәндәр алдына баян китереп куйды. Искәндәр шунда гына гәүдәсе калтыраудан туктаганны сизде, баян каешларын иңнәренә салды да салмак кына борынгы көй уйнап җибәрде. Аны бетергәч, дәртле заман көйләренә күчте. Шул арада мәҗлестәгеләр торып басты, Искәндәрне урындыгы-ние белән күтәреп коридорга алып чыктылар. Бу минутта ул үзен патша тәхетендә утырган кебек хис итте, оялды, тирләп кызарып чыкты. Искәндәр баян төймәләренә кагылуга, җырлар-

биюләр башланды, мәҗлестәгеләргә күрше бүлмәдәге студентлар да килеп кушылды.

Искәндәр бар дөньясын онытып, бармаклары кызыша башлаганчы уйнады. Вакыт-вакыт башын күтәреп дулкын чәчле кызны эзләде. Ул әле Фидан белән бии, әле аны Интизар бөтереп алып китә. Рүдәл житез биюләргә кушыла алмый, шуңа күрә вальс башланганны гына көтә дә кыз янына карчыга кебек ташлана. Ә ул берсен дә борып җибәрми, кем чакырса да биергә чыга, очынып-очынып бии, коридорны яңгыратып туктаусыз көлә. Аның чәчләре музыка агышына кушылып тирбәлә, дулкынланып йөзенә төшә, ул үзенең чәчләре арасына кереп адаша. Егетләр, бүтән кызларның барлыгын да онытып, аның белән биергә чират көтә, ул моны күреп тагын да ныграк җилбәзәкләнә, музыка ташкынына ияреп, туктый алмый бөтерелә дә бөтерелә.

...Искәндәр тырнакларын авырттыра-авырттыра тәрәзәдәге бозны зурайтырга тырышты. Ишек тоткасын да бар көченә басып карады. Кыз аңа җилкәсе белән борылган да кем беләндер көлә-көлә сөйләшә. Ул көлгәндә, әйтерсең, җир өстенә бәллүр йолдызлар коела. Искәндәр әкрен генә, кыяр-кыймас кына ишек пыяласын шакыды. Теге якта җавап бирүче булмады. Ишекнең теге ягында көлешкән авазлар ишетелде. «Кертмибез! Оҗмах ишеге бикле!» — дип кычкырды аңа ир кеше. Искәндәр өнсез калды. Ишекнең теге ягында Сөмбел белән Ул басып тора иде.

Искәндәр, дулкын чәчле кыздан күз алмый уйный торгач, үзенең туктап калганын да сизмәде. Аның бармаклары хәлсезләнеп, баян төймәсенә баса алмас хәлгә килгән иде. Баянны Фиданга тоттырып, оеган аякларын көчкә яза-яза Рүдәл янына килде. Аның тирәсендә дулкын чәчле кызны күрмәгәч, кабалана-кабалана күзләре белән кызлар арасыннан эзләде. Ләкин ул беркайда да күренмәде, ул, гүя, бии-бии эреп юкка чыккан иде. Искәндәр Рүдәлнең сүзләренә җавап биреп тә тормады, кешеләрне аралый-аралый коридор буйлап китте. Беренче катка төшеп менде, коридорның аргы башыннан урады. Искәндәр тагын Рүдәл янына әйләнеп килде, ул да як-ягына каранып аны эзли иде. Турыдан-туры сорамаска җай чыкканны күреп, ул Рүдәлгә эндәште:

— Кемне эзлисең?

— Сөмбелне.

— Кемне, кемне?

— Минем белән килгән кызны.

— Кайда соң ул?

— Фидан үпкәләтте бугай аны. Елап, икенче катка йөгерде.

— Ә син?

— Кызлар туалетына кермәм бит инде...

Искәндәр беренче катка йөгереп төште дә урамга чыкты, кайсы якка барырга белмичә бераз аптырап торгач, трамвай тукталышына таба китте. Сөмбел кулъяулыгы белән күзләрен сөртеп тора иде. Аны күргәч кырт кына борылды. Искәндәр бер сүз дә әйтмәде, килеп кызның кулыннан җитәкләде дә тулай торакка таба алып китте. Сөмбел каршылык күрсәтмәде, тын гына аның янәшәсендә атлый бирде.

Алар тулай торак янына килеп җиттеләр, сүзсез генә аны да үтеп киттеләр. Ике ягына өрәңге агачлары тезелгән тар сукмакка кергәч кенә Искәндәр сүз башлады:

— Сез бүгенге мәҗлеснең королевасы булдыгыз.

— Зинһар, мәхәббәт турында сөйләмәгез, гашыйк булдым дия күрмәгез.

— Әйтсәм, ни була? Сезгә гашыйк булмаган кеше юк иде бүген.
— Мина түгел, үзләренә гашыйк иде алар. Һәрберсе үзен күрсәтергә тырышты. Мин алар өчен көзге, лакмус кәгазе генә идем.
— Тыйнаклык әйбәт нәрсә...
— Ә чыннан да шулай түгелмени? Бер сүз әйтәләр дә миңа карыйлар, бер сүз әйтәләр дә борылып карыйлар. Шәп әйттемме, янәсе, бу кызның йөзе үзгәрдеме? Реакциясе ничек? Син ул яктан сынатмадың, миңа күтәрелеп тә карамадың, матур сүзләр дә сөйләмәдең.
Искәндәрнең иреннәрен тутырган елмаюны төн караңгылыгы үзенә яшерде, Сөмбел аның керфекләре дымлануны да күрмәде.
— Мин бар сүзләремне музыка белән сөйләдем. Аңламадыгызмыни?
— Музыка барыбыз өчен дә уртак иде бит...
— Мин аны сезнең өчен генә уйнадым.
— Рәхмәт, бик яхшы уйнадыгыз.— Сөмбелнең сүзләре бу юлы ихлас яңгырады.
— Безнең һөнәр шул бит. Уйный белмәгән кеше юк бездә. Фиданның уйнавын ишетмәдегез...
— Бозык кеше ул...
— Нигә алай дисез?
— Анысын үзеннән сорагыз.
— Алайса, мин дә бозыктыр инде...
Алар шәмәхә күк читендәге түгәрәк ай эреп юкка чыкканчы шәһәр урамнары буйлап йөрделәр. Ай белән бергә, аларны бер-берсеннән аерып торган еллар киртәсе дә, шикләнүләр, икеләнүләр томаны да эреп юкка чыкты.
Йокысыннан иртә уятканга үпкәләгән малай сыман, кызарынган йөзен йодрыклары белән уа-уа кояш түшәгеннән торганда гына алар арып-талып Искәндәрләр бүлмәсенә кайтып егылдылар. Бүлмәдәшләр кичә каникулга кайтып киткән иде. Аулак бүлмәне эчтән бикләп куйдылар да, чишенмичә генә караватка барып аудылар.
Искәндәр күзләренә төшкән кояш яктысыннан уянып китте. Караватны шыгырдатмаска тырышып Сөмбелгә таба борылды. Аның чәчләре мендәргә таралып төшкән, күлмәк изүләре ачылган. Искәндәр, үзүзенә исәп бирмичә, Сөмбелнең кояшлы иреннәренә капланды. Сөмбел, татлы төш күргән сыман, күзләрен ачмыйча гына Искәндәрнең башын кочагына алды. Искәндәр аның керфекләрен, яшьле күзләрен үпте, чигәләрен, колакларын, борынын үпте, иреннәре белән муенын иркәләде, күкрәкләренә кагылды. Сөмбелнең йокылы тәне әкрен-әкрен уяна барды, аның тәнендәге калтырау Искәндәргә күчте. Ул бер җилкенүдә күлмәген салып ыргытты. Егерме биш ел буе сусыз чүл кичеп әлсерәгән күңелен сусаудан басарга теләгәндәй Сөмбелгә сарылды, аның башыннан сыйпады, иңнәреннән сыйпады, биленнән сыйпады... Сөмбел башын артка ташлап, күзләрен чытырдатып йомды, аның калтыранган иреннәреннән бары бер сүз генә пышылдап чыкты:
— Ис-кән-дәр...
Алар, гүя диңгез уртасында калган кечкенә көймәдә чайкалалар иде. Дулкын көймәне тибрәтә, дулкын яшь тамчысы булып битләргә сибелә, дулкын: «Яра-там, я-ра-там!» дип берөзлексез пышылдый.
Шулчак диңгезнең астын өскә китереп күк күкри. Искәндәр, ни булганын аңламыйча, чытырдатып көймә кырыена тотына. Күк тагын күкри. Күк күкрәгән саен диңгез тына бара, дулкыннар әкренләп басыла-басыла да дөнья тып-тыныч булып кала. Искәндәр күзләрен ача. Сөмбелнең яшьле күзләрен күргәч, аны ничек юатырга белмичә, үзалдына бер үк сүзләрне кабатлый башлый:
— Син минеке, син ми-не-ке, син ми-не-ке ге-нә... Мин сине беркемгә дә бир-мим!

Тагын күк күкри. Бу юлы күк күкрәвс якында гына, ишек артында гына ишетелә.

— Кем кирәк? — дип җан ачуы белән кычкыра Искәндәр.

— Сөмбел андамы? — Рүдәлнең тавышы күк күкрәүнең зәгыйфь кайтавазы булып ишетелә.

— Ач ишекне, ач, үтерәм, — дип ике кулы белән дөбердәтә ул.— Ач, кертегез!

— Кертмибез! Оҗмах ишеге бикле! — ди аңа Искәндәр.

— Сөмбел! Син андамы?

Сөмбел аңа җавап бирми.

— Ач, Сөмбел, үтенеп, ялварып сорыйм, ач!

— Ачмыйбыз! Оҗмах ишеге бикле! — дип кабатлый Искәндәр.

Сентябрьдә институтка җыелгач, егетләр арасыннан Искәндәр белән исәнләшүче булмады. Ләкин аның моңа исе китмәде, ул әле ялгызлыкның нәрсә икәнен белми, ул әле бәхетле иде. Шул көнне алар Сөмбел белән ЗАГСка гариза илтеп бирделәр.

Искәндәр тамбур ишеген ике куллап төяргә тотынды.

— Ачыгыз! Ачыгыз — дип өзгәләнеп кычкырды ул.

Ишек артындагылар аңа игътибар итмәделәр, көлә-көлә сөйләшүләрендә булдылар.

Ул ачу белән ишеккә тибеп куйды да кире үз вагонына керде. Күзенә ак-кара күренмичә барганда, аңа ачык ишектән эндәштеләр. Искәндәр туктап калды.

— Купеңны үтеп барасың бит, кая ашыгасың? — Авызы колагына җиткән Мотыйк аны җилтерәтеп купега алып керде.— Булдымы, алып кайттыңмы?

— Нәрсә?

— Булуына үзем дә ышанмаган идем, кирәк чагында әйбер табып буламыни? Борчылма син, без монда чарасын күрдек инде. Итәк асты дәүләте яшәсен.

Искәндәр күзләрен бер ачып бер йомды. Ул әле генә тулай торак бүлмәсендә иде, аны Сөмбел кочагыннан каерып алдылар да тып итеп монда төшереп утырттылар.

— Чабыштан кайткан ат шикелле мышныйсың, әллә артыңнан куа килделәрме? — Бригадир Ибрай, утыргыч астындагы чемоданын алаала, үз алдына сөйләнде: — Сөлек кебек егетләр шәһәрдә әрәм булып ята бит. Шәһәрнең холкы кырыс аның, шәһәр синең җелегеңне суырасуыра да, кирәгең беткәч, чыгарып ташлый. Авылда алтын бәясе булыр иде сиңа.

— Һәр тавык үз кетәклеген мактый,— дип бүлдерде аны Мотыйк.— Яшь чагында кеше дөнья гизәргә тиеш. Яшь кешегә туган җир якын түгел, торган җир, йөргән җир яхшы.— Ул башын тыгып купе ишегеннән карады.— Нишләп килеп җитми соң әле бу? Бригадир Ибрай абзасын озатырга өлгерми бит, каһәр.

— Минем өчен булса, борчылмагыз. Мин үз өемә кайтып җиттем. Миңа шуннан ары берни дә кирәк түгел.

Ул, чемоданын куеп, саубуллашырга кул сузганда купега проводница хатын килеп керде. Итәк астыннан алып, сүзсез генә, Мотыйкның кулына коньяк шешәсе тоттырды. Бригадир Ибрай авызын ачкан килеш катып калды, аннары лып итеп утыргычка иңде.

— Ай-яй-яй-яй! — дип бугаздан сызгырып чыккан тавышы белән озак сузып торды ул.— Ай-яй-яй-яй!

Аңа күтәрелеп караучы булмады, һәркем үз уе белән мәшгуль иде. Искәндәр ишек төбендә нишләргә белмичә таптанып тора, Сәгыйдулла бабай тәрәзәгә текәлгән дә бар халәте белән төн караңгылыгына кереп чумган. Мотыйк өстәл тирәсендә эвәрә килә. Ул стаканнарга коньяк салып чыкты да шат аваз белән дәште:

— Рәхим итегез! — Аның башкаларга сүз бирергә исәбе юк иде бугай, туктамый сөйләвен дәвам итте.— Безнең дүрт кешелек җәмгыятьтә ул иң акыллы, иң иманлы, иң тәүфыйклы, иң гадел кеше иде. Әгәр дә һәр җирдә шулай дүрт кешенең берсе әүлия булса, бик җиткән. Артыгы белән җиткән. Бригадир Ибрай абыегыз ул — Җир кешесе, ул үзенең бәхетен шушы Җирдән эзли, шуннан таба да. Ә без нәрсә? Менә Сәгыйдулла картны алыйк инде... Бу алла бәндәсе җәһәннәм читенә китеп оялаган да үткәне белән бүгенгесе арасында килеп сарып йөреп вакыт уздыра, тәне — анда, җаны монда аның. Җаның үзең белән булмагач, бәхет тү-тү инде ул. Ә бу егет кая барганын, нәрсә эшләгәнен дә, димәк ки нәрсә өчен, ни өчен яшәгәнен дә белми. Аның тамыры юк, аны җил очыртып йөртә. Ә монысы,— ул күкрәгенә сугып куйды,— монысы, үз җанына урын таба алмыйча, авыл саен күчеп йөри. Бу авылда туя башласалар, икенчесенә китә, анда да берәр кырын сүз ишетсә, тагын ары китә. Күңеле яралы аның, авыр сүзне күтәрә алмый ул. Әйдәгез, җирдәге иң бәхетле кеше өчен, Бригадир Ибрай өчен, күтәреп куйыйк әле моны!

Балта остасы Мотыйк Ибрайны кочаклап алды, аның күзләреннән ике бөртек яшь сытылып чыкты. Тегесе, аңышмыйча, аптырап карап торды. Алар беравыкка купеда башка кеше барын да онытtылар. Сәгыйдулла бабай стаканга кагылмады, миңа җитте дигәндәй, кулын күкрәгенә куйды да аякларын бөкләп утыргычка утырды. Искәндәр кулларын әле кесәсенә тыкты, әле пинҗәк астына кыстырды.

— Ай-яй-яй-яй! Ай-яй-яй-яй! — дип сөрән салды шулчак Бригадир Ибрай.— Ай-яй-яй-яй! Акыллы кешедә — акыллы акча, юләр кешедә — юләр акча дип юкка әйтмиләр икән. Уңга-сулга чәчә башлады бу миллионер. Ай-яй-яй-яй! Иллелектән сдача алмады! — Ул башын чайкыйчайкый шул сүзләрне берничә мәртәбә кабатлады.— Ай-яй-яй-яй, бер коньякка илле тәңкә бирде! Иллелектән сдача алмады.

Поезд, карурманга кереп адашкан юлаучы сыман, йөрешен акрынайтты да туктап калды. Бригадир Ибрай купедагылар белән тиз-тиз саубуллашты, бары Искәндәрнең кулын гына озак кысып торды.

— Ният итсәң, кил безнең якка. Бөтенләйгә кил. Каңгырып йөрмә болай. Муеның булса, камыты табылыр. Сорамадым да, бер-бер һөнәрең бармы соң синең?

— Музыкант мин.

Бригадир Ибрай, кызганган сыман, аңа моңсу караш ташлады.

— Әйтәм бик моңлы бала күренәсең... Нигә бу кадәр күңелгә якын әле бу егет дип юл буе уйлап килдем. Үзем дә гармунчы бит мин. И-их! Моңлы кешенең кадере бетте хәзер... Һөнәрең катлаулы икән шул. Безнең каз кетәге чаклы авылда оя табылмас шул сиңа.— Ул сөйләнә-сөйләнә коридор буйлап китте, Искәндәр аны озата барды.— Безгә тракторчы, комбайнчы, сыер савучы кирәк. Безнең авылга күңелең ятмас шул синең. Юкка кыстадым төшәргә, безнең станция кулай булмас шул сиңа. Ары барам дисең инде алайса?

Искәндәр, әйе дигәнне аңлатып, башын какты.

Бригадир Ибрайның чыгып киткәнен әле генә аңлап, алпан-тилпән килә-килә коридорга Мотыйк чыкты.

— Сау бул! — дип коридорны тутырып кычкырды ул. Тавышка купе ишегеннән проводница башын чыгарды. Кем икәнен күргәч, ачуланырга әзерләнгән авызы елмаюга күчә алмыйча тотлыгып торды.— Сау бул! Малаеңа сәлам әйт! Брат братның көтү көткәненә рад... Ике бармак

арасына ит үсми... Шушы сүзнең кайсы дәрес икәнен белсә, кеше чыгар аннан. Мотыйк абыең әйтте, диген.— Ул, хәле бетеп, стенага сөялде.— Мунчаңны салдырмый тор, менә бу мунчаны салып бетергәч,— ул кесәсенә төртеп күрсәтте,— килермен. Авылыңның исеме ничек?

— Камышлы Күл. Бригадир Ибрайны сорарсың. «Коммунизм» колхозы бригадирын...

— Курыкма, күп алмам... Мал бетерә башларны...— Балта остасы Мотыйк җырлый-җырлый купега кереп китте.

Бригадир Ибрай сөйләнә-сөйләнә вагон баскычыннан төште:

— Ай-яй-яй-яй! Ай-яй-яй-яй! Иллелектән сдача алмады. Ай-яй-яй-яй! Иллелектән, иллелектән сдача алмады бит!

Поезд кузгалгач кына Искәндәр кинәт уянып киткәндәй булды. Ашыга-ашыга килеп проводница ишегең шакыды.

— Ресторанга бармакчы идем, күрше вагонга узып булмый, ишек бикле.

— Күрше вагон өчен мин җавап бирмим.

— Ачыгыз инде, үтенеп сорыйм, ачкычыгыз ярый бит.

— Минем ачкыч кая ярамас.— Проводница ишекне шыгырдатып ябып куйды.

Искәндәр ишек төбендә бераз аптырап торды да, үз купеларына кереп, Мотыйкны култыклап алып килде. Ул эшнең нәрсәдә икәнен аңламыйча, проводница каршында таптанып торуында булды. Проводница мул авызын тутырып елмайды да ачкычларын шалтырата-шалтырата Искәндәргә эндәште:

— Бара тор, хәзер килермен.

Искәндәр оча-оча килеп тамбурга керде. Ишек пыяласындагы күз томаланган, ул, иреннәрен түгәрәкләп, зәңгәрсу бозга җылы сулышын өрде. Күз ачылды, ләкин тамбурда дулкын чәч күренмәде. Анда кемнәрдер арлы-бирле йөриләр, кычкырып сөйләшәләр, ара-тирә көлешеп алалар. Искәндәр, сагаеп, аларның сүзләренә колак салды.

— Урлап алган малда бәрәкәт юк анда,— диде ир кеше тавышы.

— Керәм дигән бәхет тешеңне сындырып керә ул,— дип җавап бирде аңа икенчесе.

— Кеше өлешенә керергә ярамый. Һәркемнә үзенә дигән бәхете көтеп тора. Эзлә, тап ул бәхетне. Ә кеше бәхетенә кызыгып, көнләшеп йөрмә, аның бәхетен тартып алырга да тырышма. Үзеңнекен тап.

— Кеше бәхете белән бәхетле булып булмый.

Аларның сүзләре аңа нәрсәсе беләндер бик тә таныш сыман иде...

Туйга чакырып та килмәгәч, шактый вакыт узып, онытыласы үпкәләр бераз онытылгач, Искәндәрләр группадагы иң якын кешеләрне генә аерым җыярга булдылар. Сөмбел кунакларны үзе чакырды. Рүдәлдән башкалары барысы да килделәр. Мәҗлес башында сүзне сүзгә ялгый алмыйча шактый озак аптырап утырдылар. Тора-бара телләре ачылды. Бүлмә хуҗасының иске пианиносы да бар икән, бераздан шул якка күчтеләр.

— Мин уйнамыйм, тарих үзе уйный монда,— дип Фидан пианино капкачын ачты да уйный башлады. Искәндәр беренче ноталар яңгырауга ук өнсез калды.

«Сөмбел» дигән көйне уйный иде ул. Искәндәрнең бу көендә Сөмбелнең бар дөньясын онытып очына-очына биюләре дә, трамвай тукталышындагы моңсулык тулы сораулы күзләре дә, тулай торак бүлмәсендә кояшлы иреннәре белән пышылдаган мәхәббәт хисләре дә, түбәләре ай нурына манчылган өрәңге агачларының аларга сөйләгән мәңгелек

серләре дә бар иде. Фидан уйнаганда Искәндәрнең йөрәге, уч төбенә кыскан кош баласы кебек, талпынып-талпынып типте, битләре, колак очлары кызарды. Мәҗлестәге кешеләрнең барысы да аның уй-хисләрен, яшерен теләкләрен, өметләрен беләләрдер кебек тоелды аңа. Әйтерсең, шушы минутта аның йөрәген суырып алганнар да учларына салып әйләндерә-әйләндерә карыйлар иде.

Сөмбел, күбәләк төсле, уртага җилпенеп чыкты да музыка агышына ияреп бөтерелә башлады. Аның белән бергә Искәндәрнең бар хисләре, уйлары, хыяллары да бөтерелде. Туй көнне башын аска иеп, оялчан елмаю артына яшеренеп утырган Сөмбел бүген яңадан үз стихиясенә кайткан, бераз ял итеп алганнан соң, күккә күтәрелгән күбәләк сыман, иреккә чыккан иде. Интизар томырылып карап торды-торды да түзмәде, биек үкчәле туфлиләре белән фырт атлап Сөмбел янына килде. Музыка өермәсе аларны шундук күтәреп алып китте. Интизар берничә тапкыр бөтерелүгә аларны Хәмит килеп аралады... Искәндәр урыныннан кузгалмады, Сөмбелне үзенең күз карашы җылысында коендырып, музыка рәхәтеннән оеган килеш тик басып торды. Тулай торактагы мәҗлестән соң, мондый рәхәтне беренче кичерүе иде әле аның. Ул, Сөмбел белән танышкан кичәне уйлап, елмаеп куйды. Ул кичне дә мәҗлес түрендә Сөмбел бөтерелде, ул кичне дә барчасы аңа гашыйк иде.

Музыка авазлары тынуга, кунаклар кул чаптылар.

— Әй дә, Сөмбел, булдырдың!

— Чып-чын балерина инде.

— Йөзеп кенә йөри, аккошмыни!?

Искәндәрнең йөрәге кинәт кенә талпынып куйды да, хәлсезләнеп, уктай аска таба атылды. Ул бары тик шунда гына аларның үзе янына түгел, Сөмбел янына, Сөмбелне күрергә, Сөмбел белән сөйләшергә килүләрен аңлады. Аңлады да телсез калды. Искәндәрнең музыкасын ишетүче, аңа җылы сүз әйтүче, хәтта сүз катучы кеше дә булмады. Алар өчен гүя ул дөньяда бөтенләй юк иде. Шулай итеп алар Искәндәрдән үч алалармы, әллә Сөмбел күзләрен томалаган, сихерләгән идеме — ул аңлый алмады.

Сөмбел башын артка ташлап көлә-көлә бүлмәдән чыгып китте. Кунаклар, хан кызы тирәсендәге кәнизәкләр кебек аның артыннан иярделәр. Искәндәр, елап җибәрүдән куркып аскы иренен тешләде дә, гасабиланган күңелен басар өчен, пианино өстенә иелде. Музыка аның күңелен әкренләп тәртипкә салды, бераздан ул бөтенләй тынычланды. Бармаклары, үзләре дә сизмичә, аның бердәнбер көен — «Сөмбел»не эзләп тапты. Бу инде Фидан уйнаган шашкын хисле Сөмбел түгел, ә киң күңелле, ачык йөзле, олы йөрәкле, мәрхәмәтле Сөмбел иде. Ул уйнаган саен Сөмбел һаман якыная барды, менә-менә музыка пәрдәсе артыннан елмаеп ул үзе килеп чыгар сыман иде. Ләкин Искәндәр күпме генә уйнаса да аны чакырып дәшүче, аның янына керүче булмады. Ул бу мәҗлестә үзенең хуҗа икәнен дә белә, ләкин күрше бүлмәгә керергә базмый, үзен анда, нигәдер, артык сизә иде.

— Их, син мондамыни әле? Кунакларга кадер-хөрмәт кайда? А-ну, безнең янга! — Фидан аны, сабый бала кебек кулыннан тотып, җилтерәтеп алып керде.— Карагыз әле моны! Ком-по-зи-тор! Музыкадан аерыла алмый...

Фиданның сүзенә кушылучы булмады, мәҗлес соң чиккә җитеп кызган, кунаклар берсен-берсе бүлдерә-бүлдерә бәхәсләшәләр иде.

— Бәхет — материаль төшенчә түгел.

— Аның нигезендә, барыбер, конкрет әйбер, материя ята. Мәсәлән, машина алдыммы, димәк, мин бер көнгә генә булса да бәхетле.

— Машина алу факты бәхет түгел, машина алам дип хыялланып йөргән көннәр бәхет. Машина алгач, син бу хыялыңны үтерәсең. Хыял

белән бергә бәхет тә ул. Бәхет белән хыял кулга-кул тотынышып йөри ул.

— Машина да булдымы бәхет? — монысын Сөмбел әйтте.

— Ә синеңчә нәрсә соң ул бәхет?

— Бәхет ул — мәхәббәт.

Сөмбел, чыпчык көтүенә бер җим ташлаган кебек, сүзен әйтте дә туктап калды. «Чыпчыклар» очына-очына җим өстенә ташландылар.

— Мәхәббәтнең бәхетлесе, бәхетсезе була.

— Өйләнгәнче — бәхетле мәхәббәт, аннары бәхетсезе башлана, шулаймы?

— Берең яратып, икенчең яратмаса, мәхәббәт — мәхәббәт түгел, трагедиягә әйләнә.

— Мин сине яратам, анда синең эшең юк. Теләсәң — ярат, теләмәсәң — дүрт ягың кыйбла. Мин болай да бәхетле, мин яратам — шул җиткән.

— Әтәчләнмә! Чын мәхәббәт турында түгел, идиот мәхәббәте турында сөйлисең син.

— Минме идиот? — Интизар, кызып, торып ук басты. Фидан аны җиңеннән тартып утыртты.

— Мәхәббәт һәм бәхет — икесе ике нәрсә,— диде ул. Фидан, Искәндәрнең сүзгә катнашмыйча утыруын күреп, мәҗлесне тынычландырырга тели иде.— Мәхәббәтнең гомере кыска. Мәхәббәт мизгел генә ул. Һәм аның шулай булуы яхшы да. Әгәр кеше гомере буе мәхәббәт хисләреннән айный алмый яшәсә, аның җәмгыятькә бер тиенлек тә кирәге булмас иде. Таһир белән Зөһрәне, Ромео белән Джульеттаны гына карагыз. Төннәр буе бер-берсенең күзләренә карап утырудан башка нәрсә эшләгән алар? Мондый мәхәббәтнең нигә кирәге бар, аннан кешеләргә ни файда? Яратасың икән, син җыр җырлап, музыка уйнап кына утырма, хисләреңне материаль шартлар белән дә исбат ит. Материаль дөньяда яшисең бит син, күктә түгел.

Искәндәргә бүген барысы да читләтеп кенә аның турында сөйлиләр, теге кичтә Сөмбелне алып киткәне өчен астыртын гына үч алалар кебек тоелды. Аның чигәләре сызлый башлады. Хәмит тавышын ишеткәч кенә, бәлки монысы бүтән нәрсә турында сөйләр дип, аңа ялварып диярлек карады.

— Файдалы-файдасыз дигән сүз — мещаннар теориясе ул. Файдасы юк дип, без, синеңчә, көлмәскә, еламаска, шатланмаска, кайгырмаска тиешме? Күктәге йолдызларның безгә файдасы бармы? Ләкин алар кирәк, күңел өчен кирәк. Дөньяның чиксез икәнен, үзеңнең бик бәләкәй генә бер бөҗәк икәнеңне белү өчен кирәк.

— Бәләкәй кеше икәнемне мин болай да беләм.— Фидан Хәмитне үртәп сөйләшә иде.— Йолдыз сезгә кирәк — зур кешеләргә, озын куллы кешеләргә, безнең кул барыбер йолдызга җитми. Бәлки, шулай бәләкәй булганга да бәләкәй мәхәббәт кирәктер миңа? Бер минутлык, күп дигәндә, бер төнлек мәхәббәт.

Искәндәр, Сөмбелнең теге кичне әйткән сүзләрен искә төшереп, йодрыкларын кысты, аның ягына күз ташлады. Ләкин Сөмбел, берни булмагандай, битараф иде. Фидан сүзен дәвам итте:

— Мин айлар, еллар буе мәхәббәттән исереп йөри алмыйм. Миңа эшләргә, яшәргә кирәк. Ә бәхет, үзегез белгәнчә, эш белән генә табыла. Эш плюс мәхәббәт тигез була бәхет.— Фидан әле генә зур ачыш ясагандай, авыз тутырып елмаеп куйды.— Ә синеңчә ничек, Искәндәр?

Ул сискәнеп китте, нәрсә әйтергә дә белмичә, ярдәм көткәндәй Сөмбелгә карады.

— Минем... бу турыда уйлаганым юк.

— Мин болай да бәхетле диюеңме инде бу?

— Бәхет... Бәхет... бүген булмый бит ул. Бәхет я кичә булган була, я аны иртәгәдән көтәсең...

— Ничек? Ничек?

— Монысы өр-яңа теория түгелме соң?

— Үткәндәге иң кадерле минутны искә төшереп утырганда гына бәхетле сизәм мин үземне. Ә шул бәхетле минут үз вакытында сизелмичә үтеп киткән була. Киләчәк турында уйлаганда да ерактагы ирешелмәс бер максатны күз алдына китерергә тырышып утырасың-утырасың да үзеңне бәхетле итеп сизә башлыйсың. Ә шул хыял тормышка ашкач, бөтенләй бәхет булып чыкмый, бераз шатланасың да — шуның белән бетә.

— Синең теорияңә логика җитми,— дип бүлдерде аны Фидан.— Үткәнне искә төшерәсеңме яисә киләчәк турында хыялланасыңмы — иң мөһиме — син бүген искә төшерәсең, бүген хыялланасың. Димәк, син бүген бәхетле.

— Бәхетнең чыганагы минем янда юк бит, ул — үткәндә яисә киләчәктә... Мең ел элек сүнгән йолдызның яктысы бүген дә безгә нур сибеп, шатлык биреп торган кебек... Йолдыз үзе сүнгән, йолдыз үзе юк бит... Бәхетнең чыганагы юк...

— Ул синең йөрәгеңдә.— Хәмит шуның белән Искәндәрнең сүзләренә йомгак ясады.

Ләкин Фиданның туктарга исәбе юк иде.

— Бәхет турында сөйләшү — бәхетсезләр эше. Кемнең кайсы төше авырта, шул төшен капшый. Һәркемнең бәхете үзенчә. Әнә, Искәндәр асыл кошны тәпиеннән эләктерде, бәхет кошы тотты. Аңа хәзер хыялый бәхет турында теоретик семинарлар үткәрсә дә була. Ә безгә әле җирдәге бәхетне табасы бар. Концерт беткәннән соң, гомеремдә бер генә мәртәбә булса да зал мине аягүрә басып алкышласа, бис, браво, афәрин кычкырса, мин үземне гомергә бәхетле санар идем. Күпне өмет итмим мин, бер генә мәртәбә... Ә инде йөз дә беренче скрипкачы булып, сәхнә почмагында гомер уздырганчы, урам себерүең мең артык.

— Бәхетне көтеп, сагалап торып булмый, бәхет үзе килми, аңа каршы барырга, аны күрәшеп, яулап алырга кирәк.— Искәндәр сүзгә кушылып киткәнен сизми дә калды.

— Минем кебек дип әйтәсең киләме? — Фидан аңа мыскыллы карап ташлады.— Сөмбелне авызыгыздан тартып алдым да бәхетле булдым, ә сез, саламторханнар, авыз ачып карап калдыгыз. Шулаймы? Безгә нәрсә, әнә, Рүдәл кара көеп йөри. Синең эш җиңел, син берәр теория уйлап табып үзеңне акларсың. Материя бардан юк булмый, юктан бар булмый, бер халәттән икенче халәткә генә күчә. Сөмбел элек Рүдәлнеке иде, хәзер — минеке... Ә-ә-әй! Бәхетле кеше акланып тора димени?!

Искәндәрнең кинәт кенә өстәлне әйләндереп җибәрәсе, аларның барысын да өйдән куып чыгарасы килде. Гүя бүген алар барысы да аннан көләр, аны мыскыл итәр өчен генә махсус җыелганнар иде.

— Урлап алган малда бәрәкәт юк анда,— дип, Интизар Искәндәр күңелендә дөрләгән учакка утын ыргытты.

— Керәм дигән бәхет шулай тешеңне сындырып керә ул,— дип, Хәмит учакка бер уч су сипте.

— Кеше өлешенә керергә ярамый. Һәркемне үзенә дигән бәхете көтеп тора. Эзлә, тап шул бәхетне, ә кеше бәхетенә кызыгып, көнләшеп йөрмә, аның бәхетен тартып алырга да тырышма. Үзеңнекен тап...

— Тук-та-ты-гыз бу комедияне! — Искәндәр бар көче белән өстәлгә китереп сукты.

Барысы да аптырап аңа карап калдылар.

— Сөмбел, син чакырдың! Махсус оештырдың бу кәмитне.

Сөмбел бер агарынып, бер кызарынып торды-торды да аның янагы-

на чалтыратып җибәрде. Искәндәр исәр кеше кәлүе белән шаркылдап көлә-көлә урамга чыгып йөгерде.

Сары күлмәкләрен аяк астына салып ташлаган каен кызларына карый-карый бар табигать тавышсыз гына елый иде. Искәндәрнең чәчләре юешләнеп маңгаена ябышты, күлмәге тәненә сыланды. Урамда очраган кешеләр аның җан-фәрманга йөгереп барганын күреп, борылып карыйлар, ләкин бите буйлап яңгырга кушылып аккан күз яшьләрен күрмиләр иде.

Икенче көнне Фидан аңа, берни булмагандай, еракган ук сәлам бирде. Интизар белән Хәмит тә дустанә сөйләштеләр. Искәндәр, бик авыр имтихан тапшырган кебек, җиңеләеп китте. Ләкин Сөмбел генә шул көннән соң басынкыланып калды, аның күңел күгендәге кайсыдыр бер тәрәзәсе Искәндәр өчен инде ябык иде...

— Йокыга китмәгәнсеңдер бит? Нәрсә мәрткә китеп торасың?

Проводницаның гөрелдәп чыккан тавышы аның вагон-вагон булып агылучы уйларын шлагбаум кебек бүлеп куйды. Ишек ачылуга, Искәндәр тамбурга атылып керде. Ләкин анда тәмәке тартып торучы ике кешедән башка беркем дә күренмәде.

— Монда бер кыз бар иде. Зәңгәр күзле, туры борынлы бик чибәр кыз. Чәчләре дулкын булып иңенә төшкән. Күрмәдегезме?

— Үткән станциядә генә бер егет белән төшеп калды. Шуларны әйтәсеңдер инде?

— Исемен белмисезме соң?

— Кем сораган аны.

Искәндәр, сикереп төшеп калырга ниятләгәндәй, вагон тоткасына ябышты.

— Гражданин, ишекне ачарга ярамый.

Проводницаның шлагбаум төсле аклы-каралы кырыс тавышы аны айнытып җибәрде. Тәрәзә артыннан шалтырый-шалтырый буш товар вагоннары уза башлады.

Аның гәүдәсе кинәт кенә авыраеп китте. Ул аякларын көчкә сөйрәп купега керде дә хәлсезләнеп утыргычка елышты. Йөрәге, вагон тәгәрмәчләрен уздырырга теләгәндәй, ашыга-ашыга тибә, вакыт поездын узарга теләп атлыга, алгысына иде.

Әле генә шау-гөр килеп торган купе моңсулык белән тулган. Балта остасы Мотыйк башын өстәлгә салып мәлҗерәгән, Сәгыйдулла бабай, тәрәзә артындагы төпсез караңгылыкның серенә төшенергә теләгән сыман онытылган. Күкнең куе шәмәхә төстәге түшәгенә ятып аларны озата килүче айга карап бара торгач Искәндәрнең күңеле дә тынычланды, уйлары тәртипкә килде. «Алар бөтенесе миңа каршы яшерен заговор оештырганнар, алар Сөмбел белән безнең бергәлекне кичерә алмаганнар. Мин, юләр, шуны да аңламаганмын. Алар һәр бәйрәм саен аның янына түгел, ә Сөмбел янына, Сөмбел белән сөйләшергә, Сөмбелне күрергә килгәннәр. Ә ул аларны һаман дус санап йөргән, алар өчен кичләр буе үзе язган музыканы уйнаган, аларга бар серләрен, күңелен ачкан. Сөмбел шуларның барысын күреп, белеп торган, ләкин эндәшмәгән. Бәлки, шул мәҗлесләрдән яшерен бер ләззәт тә тапкандыр әле ул. Сөмбел Искәндәр белән бергә яшәүдән аргандыр... Шулай үз-үзенә урын таба алмыйча, ике арада бәргәләнеп йөргән. Киләчәк белән бүген арасында таган атынган... һәм, ниһаять, бердәнбер дөрес юлны сайлаган: бөтенесен калдырып, үзе генә китеп барган».

Искәндәрнең кинәт кенә күзләре ачылып киткәндәй булды, ул еллар буе җанын газаплап йөргән сорауларга, ниһаять, җавап табуын аңлап,

аһ итте. Аның анда-санда сибелеп-чәчелеп яткан уйлары кинәт кенә бер җепкә тезелеп, вагоннар кебек бер-бер артлы тәртип белән агыла башлады. Ул үзенең, бар дөньяга кул селтәп, беренче очраган поездга утырып китүенә сөенеп бетә алмады. Әйе, бары поезд, аның йөрәгенә кушылып текелдәгән вагон тәгәрмәчләре, бераз беркатлырак, ләкин авылча хәйләкәр, авылча үҗәт Бригадир Ибрай, күпме яшәп тә җирдә үз урынын тапмаган, күңеле утырмаган сәрхүш Мотыйк, бүген белән үткән арасында йөреп, киләчәге турында кайгыртырга оныткан Сәгыйдулла бабай гына аңа тормыш мәгънәсен аңлата ала иде.

Вакытны белергә теләп, ул стенага күтәрелеп карады. Үзенең вагон купесында барганын белсә дә, ниндидер могҗиза белән, борынгы сәгать тә алар янына килгәндер, бу бәхетле минутларны, үз гомеренең мәгънәсен аңлый башлаган минутларны шул борынгы сәгать санныйдыр кебек тоелды аңа... Ләкин стена буш иде... Шулчак аңа дөнья тагын үзенең мәгънәсен югалткан кебек тоелды.

Сәгыйдулла бабай, тәрәзәдән көч-хәл белән аерылып, аңа таба борылды. Күзләрен хәйләкәр кыскалап куйгач, Мотыйкка төртеп күрсәтте.

— Карале моны, гел сабый бала кебек, дөрт санын онытып эрегән бит. Аракы нишләтә кешене, ә!?

«Аракы» сүзен ишетеп, Мотыйк башын калкытып куйды да тагын иеды.

— Арыгандыр, өч ай эшләп кайтам, ди бит.— Искәндәрнең нишләптер аңа тел тидерттерәсе килми иде.

— Гәүдәсе түгел, җаны арыган аның. Җанына ял бирергә кирәк... Станциясен йоклап уза күрмәсен тагын.— Сәгыйдулла бабай Мотыйкның башын күтәрде. Тегесе күзләрен ача алмыйча торды, бераздан, айнырга карар кылгандай, башын селкеде.

— Син башта шифер белән ябабыз дигән идең, хәзер калай, дисең. Сәгыйдулла бабай бот чабып кеткелдәп көлеп җибәрде.

— Менәтерә, безнең купе түбәсен шифер белән яба башламасын бу. Әй, Мотыйгулла, идән тактасын ышкылаган ягы белән аска җәйгәнсең түгелме?

Мотыйк дерт итеп уянып китте. Үзенең кайда икәнен аңлагач, үпкәләгән кыяфәт белән бераз авызын турсайтып торды да иренеп кенә көлгәндәй итте. Сәгыйдулла бабай сүзне икенчегә борды:

— Станцияңне узып китә күрмә, дим. Шуңа уяттым.

— Сәгать ничә әле?

Искәндәр, ирексездән, тагын стенага күтәрелеп карады. Мотыйк авызын учы белән каплап ютәлләргә тотынды. «Вакытка суык тигән»,— дип пышылдады ул. Аннары, теләмичә генә кулындагы сәгатен аңа якын китереп күрсәтте:

— Унбер тулганда гына барып җитәм әле мин. Аңа хәтле тагын әллә ничә ак алъяпкычлы түтәйнең эч серен бушатырга була.— Ул өстәлдәге яртылаш бушаган коньяк шешәсенә күрсәтте.— Тик... менә... сез генә бүлышмыйсыз. Бергә-бергә күңеллерәк булыр иде. Әллә ошатмадыгыз инде мине? Мә, егет, алып кил әле тагын бер түтәйне.— Мотыйк күкрәк кесәсеннән иллелек суырып чыгарды.— Тарихи очрашу бит бу. Без бүтән беркайчан да менә шушылай өчебез бер поездда, бер вагонда, бер купеда очраша алмаячакбыз. Беләсезме, беркайчан да! Кадерен белергә кирәк...

Сәгыйдулла бабай кинәт кенә уйчанланып китте. Аннары, үз-үзе белән сөйләшкәндәй итеп, тын гына әйтте:

— Шушы көнне, шушы елның соңгы сәгатьләрендә... И-их, үтә гомер, яшисе дә яшисе иде бит әле, юкса... Нигә килә бу яңа еллар? Вакыт үз көенә аксын иде ул, син үзең теләгән вакытта поездан төшеп

калган сыман, аннан төшеп кал идең. Күңелең бимазалый башласа, тагын менеп утыр идең вакыт поездына. И-и-их, үләсе килми... Әле яшь башларга гына исәп итеп тора идем лә...

— Үз-үзеңә ясин чыгып утырма әле,— Мотыйкның тавышы моңа кадәр ишетелмәгәнчә усал чыкты.— Үләргә җыенмыйсыңдыр бит? Авылыңда кара авызын ачып кабер көтеп тормыйдыр? Үзең кунакка кайтам дисең... Сөенергә кирәк. Елга бер туган ягыңа кайтасың... Мине авылда көтеп торучы булсамы?..

— Көтеп торучы... Көтеп торучы... Мине кем көтә дисең? Мин кайтканга иң нык сөенүче кем авылда, беләсезме? Белмисез шул. Чәкүшкә Гыйльмулланың чатан кызы кибетче Әлфинур.

— Кибете-ние белән сатып аласыңмы әллә?

Сәгыйдулла бабай Мотыйкка җавап биреп тормады, өзелгән җөмләсен дәвам итте:

— Бер алдыма, мең артыма төшә инде шул Әлфинур. Бабасы Мәкәрҗәдән бер олау кызыл билле прәннек алып кайткан диярсең. Мин кайткан көнне янымa дус-иш җыела, сабантуе җиткән диярсең. Ә мин, Мәкәрҗә сәүдәгәре кебек, кибет ишеген киереп ачып керәм дә Әлфинурга кычкырам: «Чыгар, үскәнем, булган малыңны!» — дим. Әлфинур башта итәге белән сөртә-сөртә бер ярты чыгарган була, үзе минем күзгә мөлдерәтеп карый. «Чыгар әрҗәсе белән!» — дип кычкырганны көтә ул. Анысын да озак көттермим, чөнки ирләрнең күз карашы үземдә икәнне сизеп торам. «Әйдәгез, туганнар, ир йөрәге тар бүлмәгә сыямыни? Сәйрәнгә чыгыйк!» — дип сөрән салам да кибетче алдына бер уч акча ыргытам. Ул чатанлый-чатанлый бер әрҗә китереп куя. Аны күтәреп урман авызындагы чишмә буена менеп китәбез. Кич буе гүли урман авызы. Мине күтәреп күккә чөяләр. Шуларның сүзләренә оеп, онытылып утырам. Аннары кочаклашып җырлый-җырлый авылга төшәбез.

— Аннары, аннары? — дип кыбырсыды Мотыйк.

— Аннары, үткән елны шундый бер сабантуеннан соң сельсоветка чакыралар үземне. Бардым, кердем. Урын күрсәттеләр, утырдым. Сельсовет председателе: «Сәгыйдулла абый, сезнең өстән жалоба килде бит әле»,— ди. «Нинди жалоба? — мин әйтәм.— Кешегә тигәнем, кешенекен урлаганым юк. Мин монда — кунак кеше. Шул булдымы кунакка хөрмәт? Рәнҗетәсең, кем... Минҗиһан». Ә ул, усал кыяфәт алыйм дипме, әллә болай күзе начар күрүдән генәме, күзлеген киеп куйды. Аннары өстәлдәге кәгазьгә күз төшергәч, жанга үткәрердәй итеп сөйләргә тотынды: «Хатыннар өстеңнән жалоба язганнар, Сәгыйдулла абзый. Ирләрен җыясың да әрҗәсе белән аракы эчертәсең икән. Шуңа семьяда тавыш чыга, колхоз производствосына зыян килә». «Мин аларның авызларына көчләп коймыйм бит. Берсен дә кыстамыйм, эчәсе килгәне эчә, эчәсе килмәгәне — юк. Демократия...» «Син, Сәгыйдулла абый, олы башың белән демократияне аракы янына куеп сөйләмә. Гаиләне, җәмгыятьнең нигезен тәшкил иткән гаиләне, таркатуга китергән демократиянең безгә кирәге юк». «Гөнаһлы булма, Минҗиһан, нахак бәла ташлама кеше өстенә. Елга бер күңел ачар өчен кайтам бит мин авылга. Елга бер. Ел буе авызымнан өзеп акча җыям. Авылыма кешечә кайтыйм, ким-хур булмыйм, дим». Шуларны әйткәч, бераз йомшады тагын үзе, күзлеген дә салып куйды. «Жалоба килгән икән, без аңа җавап бирергә тиеш»,— дип үз өстеннән җавапны алгандай итте. «Синең үз башың бар бит, Минҗиһан»,— дим мин аңа. Шуннан соң бу тагын кызып китә. «Яхшылап әйткәнне аңла, Сәгыйдулла абый. Акчаң күп икән, йорт салып кер, җирен бирербез. Ни әйтсәң дә, син — бу авыл кешесе». «Бер киткән җиргә кире кайтулары ай-һай кыен...»

Сәгыйдулла, күңеле нечкәреп китүдән оялып, туктап калды, күлмәк

якаларын рәтләде, пинжәк төймәләрен каптырды. Әйтерсең, әле ул хәзер дә авыл советы председателе каршында басып тора иде. Аннары Искәндәргә карап әйтеп куйды:

— Авылда Җилпуч Сәгыйдулла дип йөртәләр иде мине элек. Элек чәчүне тырыс белән чәчәләр иде бит. Миңа тырыс бәләкәй тоелгандырмы, әллә таба алмаганмындырмы — хәтерләмим, чәчү вакытында бер көнне муенга әнинең җилпучын асып чыктым. Симәнәмнең яртысы җилгә сибелә, халык бот чабып көлә. Менә шул көннән Җилпуч кушаматы ябышып калды миңа.

Мотыйк, ишек катында басып торган Искәндәрне күреп, аптырап эндәште:

— Һаман китмәдеңмени әле? Бар инде, энем, сиңа ни тора ул. Булмаса, проводницадан сора. Җир тишегеннән табып бирә алар.

— Бар бит әле. Синә җитәр. Без эчмибез... Мин эчмим.

— Теңкәсенә тимә әле егетнең,— дип, Сәгыйдулла бабай да аның сүзен җөпләде.

— Авылыгыз тимер юлдан еракмы? — дип сорады Искәндәр.

— Алты чакрым. Нигә?

— Күренә микән дигән идем.

— Көндез күренә дә, хәзер...— Ул чем кара күзләрен мөлдерәтеп торган тәрәзәгә ымлады.

Сәгыйдулла бабай чемоданына вак-төякләрен тутырды да чөйдәге пальтосын алып кия башлады.

— Төшәсеңме? — диде аңа Мотыйк.— Әллә минем белән ары китәсеңме? Икебез дә ялгыз кешеләр. Бер-беребезнең күңелен юатырбыз. Югалмабыз, авылда бикле өй тора минем. Кайтып мичкә ягып җибәрербез. Авылыңа кайтып кыш өстеннән нишләмәк буласың син? Сельсовет председателе кибет янына чыкмаска кушкан.

Сәгыйдулла бабай чемоданына үрелде.

— Үзем күтәрәм, озата чыгам,— дип, Искәндәр чемоданны аның кулыннан алды. Ай-һай саллы бу, алтын тутырдыңмы әллә? Ничек күтәреп кайтырсың моны? Каршы алучың бармы соң?

— Хәбәр-мазар биреп тормадым. Эш кешесе бит алар, борчып йөрисем килмәде.

— Туган-тумача арасында борчып йөрү дигән сүз булмый инде.

Алар өчәүләшеп тамбурга таба киттеләр. Поезд, Сәгыйдулла бабайның төшәргә җыенганын сизгәндәй, йөрешен әкренәйтте. Тәрәзә артында, кара төн пәрдәсенең сары ямаулары булып, анда-санда утлы тәрәзәләр чагылып узды. Сәгыйдулла бабай төшәр дә шул төн пәрдәсе артына кереп югалыр кебек иде. Тамбурга җиткәч, ул рәхмәтен белдерергә теләгәндәй Искәндәрнең иңенә кулын салды.

— Син, улым, минем өчен борчылма, мин дөньяның ачысын-төчесен күргән кеше. Ничек тә югалмам. Шул алты чакрымны үрмәләп булса да кайтып җитәрмен. Шуннан ары китәр җирем дә, китәрлек дәрманым да юк минем. Менә синең юлың озын, яшисе гомерең озын. Кая барып чыгарсың? Шул турыда уйлап килдем әле мин, үзем турында түгел. Кая барасыңны да тәгаен белмисең, әллә белеп тә яшерәсең... Яшерсәң, яшерерсең. Әмма ләкин кайда гына яшәсәң дә, бер нәрсәне онытма: кешеләрдән читләшә күрмә, янында якын кешең булса, берчакта да югалмассың. Әнә син, туганнар арасында борчып йөрү дигән сүз булмый, дисең. Анысы шулаен шулай. Ярый ла туганнарың булса... Авылда сыңар туганым да калмады бит минем. Тамыры корыды безнең нәселнең. Заманында өрлектәй алты егет идек. Шулардан хәзер берүзем торып калдым. Икесенең башына кулаклар җитте, өчесе Ватан сугышыннан кайтмады. Авылда кереп баш төртерлек бер туганым да калмады. Бәләкәй чакта бергә уйнап үскән дустым янына кайтып йөрим хә-

зер. Рәхмәт инде аңа, ачык йөз белән каршы ала, тәмле тел белән оза-та. Дуслар кирәк, дус-иш кирәк якты дөньяда яшәгән чакта.— Ул кинәт кенә Искәндәрнең йөзенә күтәрелеп карады.— Син нишләп болай тик-томалга күтәренеп юлга чыктың соң әле? Үзең башлы-күзле кеше дә икәнсең.

Искәндәр уң кулындагы балдагына карап куйды, нәрсә әйтергә белмичә ык-мык итте.

— Хатыннан уңмадым дип әйтмәк буласыңмы әллә? Хатын-кызның барысы да бер камырдан аның. Шул камырдан үзеңә ошаганын үзең әвәләп ясарга тиеш син. Шуны булдыра алсаң — синнән ир чыга, шуны эшләсәң — күгәрченнәр кебек гөлдер-гөлдер килеп яшисең, булдыра алмасаң — гомер буе иза чигәсең.

«Күгәрченнәр кебек» дигәч, Искәндәрнең күз алдына бүреген баты-рып кигән, алсу йөзле, түгәрәк бүксәле Рүдәл килеп басты. Ул йөзен җыерды.

— Минем күгәрчен кебек яшисем килми...

— Һә-әй, онытып торам, музыкант дип әйттең бит әле син. Сандугач нәселеннән, димәк. Ә сандугач көз җилләре исә башлауга җылы якка китә... Җәй җиткәч, тагын бу якка кайта. Шулай җылыдан җылыга очып, кышны күрмичә гомер кичерә ул. Шуңа күрә матур сайрый, дөньяның гүзәллегенә соклана. Ә мескен чыпчыклар, песнәкләр, тук-раннар, туган җир, туган ил дип ябышып ята. Аның рәхәт чагын да, михнәтле чагын да күрә. Сандугачка караганда, туган якның чыпчыгы кадерлерәк миңа.

Проводница вагон ишеген ачты. Поезд тавышсыз-тынсыз гына тук-тап калды. Әйтерсең, аның төн кочагына кереп оеган станцияне йокы-дан уятасы килми иде.

Сәгыйдулла бабай, сул кулына чемоданын күтәргән килеш, уң кулы белән Искәндәрнең җилкәсеннән какты.

— Әй, улым, улым,— диде ул аңа, яратып.— Күп гиздем мин дөнья-ны, бәхет күреп булмады. Сиңа киңәшем шул: кайт кире, семьяңа, ха-тыныңа кайт. Кайткан малда өмет бар диләр.

Искәндәргә, кинәт кенә, шушы станциядә аны Сөмбел белән Ләйсән көтеп торадыр сыман тоелды. Ул башын сузып станция ягына карады. Ләкин тирә-юнь буп-буш, тып-тын иде. Бары тик күктәге йолдызлар гына үзләре янына чакыргандай бер-бер артлы күз кысыштылар, сары иреннәрен тутырып, үртәгән сыман ай елмайды.

— Хушыгыз, оланнар, гаеплләп калмагыз. Хәерле юл сезгә! — дип, Сәгыйдулла бабай вагон баскычыннан төшә башлады.

Менә ул, чемоданын җиргә куеп, як-ягына карангалады да болай да алга сөрлеккән гәүдәсе белән тагын да алгарак иелә төште. Гүя аның бу чиксез дөньяда шушы җирдән башка сыеныр урыны калмаган, гүя шуны сизенеп Җир аны үзенә тарта иде. Искәндәр вагон тоткасына ябышып, бөтен гәүдәсе белән алга омтылган килеш, күзләрен Сәгый-дулла бабайдан алмады. Менә ул, хәл алырга чемоданы өстенә утыр-ды. Авырлык белән кузгалды да әкрен генә атлап китте. Һәм төн караң-гылыгына чумып юкка чыкты. Шулчак күкнең утлы күз яше җир өсте-нә тамып төште — йолдыз атылды.

Балта остасы Мотыйк та кинәт кенә аңына килгәндәй, Искәндәрне бер читкә этәреп, вагон баскычына чыгып басты. Вагон тәгәрмәчләре: «Кит-тек, кит-тек»,— дип пышылдый-пышылдый алга тәгәрәделәр. Ис-кәндәр Мотыйкны кулыннан җитәкләде дә коридор буйлап алып китте.

Купега кергәч, Мотыйк бөтенләй мескенләнеп калды. Кулыннан уен-чыгын тартып алган малай, диярсең. Бераздан үпкәләве басыла төште бугай, тыныч тавыш белән Искәндәргә сүз катты:

— Әй, егет, сәгатең ничә әле?

Искәндәр ялт итеп стенага карады, аннары, уңайсызланып, башын аска иде.

— Ун туларга җиде минут күрсәтә...

— Юаштан юан чыга диләр, шактый кызрач күренәсең тагын. Җилтерәтеп кенә алып кердең. Киткән чакта хатыныңны шулай җилтерәтеп алып керәләр ие аны. Менә шунда егет булыр идең. Хатын-кызның аягы китәм дигәндә, күңеле китмим дип әйтә аның. Катлаулы халык алар. Мин нәрсә? Мин кеше исәбеннән күптән чыккан инде. Менә кая сөйрәсәң дә була.

— Бер дә кире якка китмәгәнсең әле, үз аягың белән авылыңа кайтып барасың.

— Кая барыйм соң мин? Кешенең бер баш төртер җире булырга тиеш бит инде.

— Гомерең буе шулай буйдак булдыңмыни соң син?

— Гомерең буе... — Ул, исәнме дигәндәй, башын капшап карады.— Әгәр минем гомерне дә гомер дип булса?.. Өйләнгән идем мин. Бер кызым да бар...

Искәндәрнең чигәләре сулык-сулык килергә тотынды, аның колагы томаланып бөтенләй ишетмәс булды. Аңа Мотыйк үз язмышын түгел, юри аның киләчәге турында сөйлидер кебек тоелды.

— Эчмим дисәм, эчмичә дә тора алам бит,— дип эчке бер горурлык белән сүзен дәвам итте Мотыйк.— Эчәсе килгәннән эчмим мин, күңелемдәге бушлыкны тутырырга эчәм.

— Йортым да бар дисең бит. Нигә соң үз авылыңа кайтып кына яшәмисең? Балта остасына колхозда эш бетмәгән.

— Нәрсә беләсең син? Мин кем? Бүген егылып үлсәм — беркем белмәячәк...

— Алай ук түгелдер инде.

— Алай ук түгелдер... Сугышта пленга эләктем мин. Анда күргән газапларны күз алдына китерсәм, әле хәзер дә чәчләр үрә тора. Сугыш беткәч, коткардылар. Берничә ел иза чиккәч, авылга кайтып егылдым. Җиң сызганып эшләргә, халык алдында йөз аклыгы алырга иде исәбем. Ә мине... — Мотыйк сулкылдап елый башлады. Бераздан, тынычланып, сүзен дәвам итте.— Башны аска иеп, телне аркылы тешләп ике елга якын йөрдем. Өйләндем. Кызым туды. Ләкин дөньям түгәрәкләнмәде. Җай чыккан саен, пленны искә төшереп, җанга тоз сибәләр. Шулай әкренләп салгалый башладым. Авылда әле ул чакта аракыны авызга алган кеше сирәк иде. Шулай бара торгач, кеше исәбеннән бөтенләй төшеп калдым мин. Хатын да баласын алып әниләренә кайтып китте. Күрше авылдан иде ул. Әни белән эти карт та дөнья куйдылар. Мин берүзем калдым.

— Ә хәзер? Хәзер ул заманнар түгел. Кайт та яшә.

— Башың яшь шул әле синең. «Бер кергән суга ике мәртәбә кереп булмый»,— диме әле бер философ абыең. Бер киткән җиргә дә кире кайтып булмый...

— Шунда кайтып барасың түгелме соң әле?

— Мин анда кесә тулы акча белән менә шушы ярсу аргамакка атланып кайтам,— ул өстәлдәге шешәгә күрсәтте.— Үлгәндә дә үз аягым белән авыл капкасын атлап керә алмас идем. Ә бу алып кайта, ул бер нәрсәдән дә курыкмый. Шуңа атланып кайтам, кесә бушап, аргамагым ташлап качкач, кеше күзе күрмәгәндә генә ындыр артлап тагын чыгып таям.

— Утырып сөйләшерлек бер кеше дә юкмыни соң авылыгызда?

— Айнысам, үз-үземнән ояла башлыйм, бөтен кеше миннән көләдер төсле.

— Айнык баштан берәр кешегә сүз катып караганың бармы соң?

Мотыйкның йөзенә рәхәт елмаю җәелде. Ул елмаюын озаккарак сузарга, шул елмаю нурында җылынып калырга теләгәндәй, авызын ерып торды. Ләкин тора-бара йөзе кырысланды.

— Моннан берничә ел элек авылга кайткач, авыру аяктан екты мине. Тән кызыша, баш чатный, укшыта — грипп булды ахрысы. Бер ялгызым түшәмгә карап тик ятам. Тән кайнарлыгын басмасмы дип, көчхәл белән торып су эчәм дә тагын урынга килеп егылам. Ничә көн шулай ятканмындыр, хәтерләмим, берзаман аякка баса алмас хәлгә килдем, онытыла башладым. Караваг белән түшәм тыя алмыйча... белән төпсез чокырга кинәт кенә убылып төшеп китәм дә озак-озак итеп тагын өскә күтәреләм. «Җан бирсәм, күземне йомдыручы да юк бит»,— дип, үз-үземне тыя алмыйча җылап җибәрдем. Шулчак кемдер йомшак куллары белән яшьләремне сөртте. Күзләремне ачарга тырышам, ачылмыйлар. «Кем ул?»— дип пышылдадым. «Мин бу, күрше, Зәмзәмия»,— дигән аваз колагымда бик озак зеңләп торды.

Бер атна янымнан китмәде ул, сабый баланы караган кебек карады. Мәтрүшкәле чәйләр кайнатып эчерде, көчли-көчли ашатты. Бераз хәл алып, тирә-юньгә күз ташласам, шаккаттым: инде ничә ел су тимәгән идәннәр ялт иткән, саргаеп, акшарлары кубып беткән мич, ярәшелгән кыз сыман, балкып көлеп тора, тәрәзә кашагалары күз явын алырлык! Башта үз өемне үзем танымый тордым, кемнәргәдер кертеп салганнардыр дип уйладым. Зәмзәмиянең кулын кысканмын да җибәрмим генә икән. «Нишләвең бу, Мотыйк абый?— ди ул, миңа аптырап-гаҗәпләнеп карый.— Кулны авырттырасың ла... Каян килде синдә бу кадәр көч? Үзең чирле... — Үзе сөйли, бахыр, үзе көлә. Аннары такмаклый-такмаклый биергә үк тотынды: — Терелде, терелде, Мотыйк абый терелде!»

Рәхмәтемне ничек белдерергә дә җай тапмыйча, тик ятам урында. Ниһаять, телем ачылды. «Ничек керәсе иттең, Зәмзәмия? — мин әйтәм.— Нинди фәрештәләр колагыңа изге сүз пышылдады?» — дим. Ул, күзләрен хәйләкәр уйнатып, озак уйлап тормыйча гына, әйтеп салды: «Кызганам мин сине, Мотыйк абый. Шуңа кердем. Күңелем сиздe. Элек ике-өч айсыз китми идең бит. Ә бу юлы бер айдан юкка чыктың. Бер-бер хәл булды микән әллә дип кердем. Шикләнә калдым. Шуңа кердем. Сиңа зәхмәт кагылган булырга тиеш. Больницада ятып чыгасыңмы әллә, Мотыйгулла абый?» «Рәхмәт, Зәмзәмия, рәхмәт,— дип, аның кулларыннан сыйпадым,— Син кермәсәң, якты дөнья белән саубуллаша идем». «Син үзең дә мин авырган чакта янымнан китмәдең бит. Менә, әҗәтемне түләдем»,— диде ул моңсу гына. Шул сүзләрне әйтте дә, күңелендәге олы кайгысы уянгандай, сыгылып төште. Аннары, саубуллашмый-нитми тиз генә чыгып китте. Шуннан соң күргәнем булмады аны. Авылдан китеп, төзелешкә эшкә урнашкан, диделәр. Шәһәр сала башладылар бит бу якларда...

— Нигә җибәрдең соң аны? Тотарга да шуңа өйләнергә иде...

Искәндәрнең сүзләре Мотыйк абыйга ошамады, ул аяк астына төшкән шешә бөкесен ачу белән тибеп җибәрде.

— Тотарга да өйләнергә... Сез генә хәзер биш минутта көйләнеп, ун минутта өйләнеп куясыз. Аннан, алга-артка карамый, шул хатынны ташлап качасыз.

— Ә син үзең? Кешегә гаеп ташларга барыбыз да оста. Үзеңнеке күренми. — Искәндәрнең тавышы калтырап чыкты. Ул үз-үзен көчкә тыеп калды.

— Миңа тимә син, егет. Мин күргәнне күрсәң, хатыннан гына түгел, якты дөньядан да китеп барган булыр идең. Хатын хәзер дә чакырып тора. «Кил, эчүеңне ташласаң, менә дигән итеп яши башларбыз. Бала хакына кил, аны ятим итмик»,— ди.

— Нигә бармыйсың соң?

— Кызымнан оялам.
— Үз кызыңнанмы?
— Үземнекеннән шул. Кешенеке булса, оялмас идем. Уналты ел буе синнән башка ятим үссен дә, кеше булып җиткәч кенә, туп итеп ничек килеп керим мин анда? Менә, әтиең мин булам инде, үзгәрәм, эчүемне ташлыйм, акылга утырам, кабул гына итегез дип әйтимме? Мин аны карап үстерергә, акыл-киңәш бирергә, аңа таяныч булырга тиеш идем бит. Ә хәзер үзем алардан таяныч эзлимме? Юк, кайта алмыйм мин анда, мескен булып кайта алмыйм. Үткәнгә кире кайтып булмый икән ул...
Купе ишеге шыгырдап ачылып китте, аннан проводницаның тулы гәүдәсе күренде. Ул, Искәндәргә көйдереп карап куйды да, ягымлы тавыш белән Мотыйкка эндәште:
— Йоклап кала күрмәгез дип керүем. Сезнең станциягә җитеп килләбез.
— Сизелмичә дә калды,— дип көрсенде Мотыйк.
Проводница күпме юл йөреп башына килгән бердәнбер фәлсәфи фикерен әйтми кала алмады:
— Гомерең дә шулай үтеп китәр, сизми дә калырсың...— Аннары капыл гына шешәгә төртеп күрсәтте.— Тагын кирәк түгелме?
Искәндәр, кирәк түгел дигәнне аңлатырга дип, башын селкеп куйды. Проводница аңа ялт итеп карап алды да кырт кисте:
— Кешедән алдан сикермә, синнән сорамыйлар.
Проводница ишекне шапылдатып ябып, чыгып китте.
— Күңел бик нәзберек икән синең, егет,— дип эндәште Мотыйк.— Һәр әйткән сүзгә авыз турсайта башласаң, иреннең кабартма булыр. Төкер син аларга.
— Аларның һәрберсенә төкереп йөрсәң, төкерегең җитмәс.
Мотыйк шаркылдап көлеп җибәрде, Искәндәр янына күчеп утырды, аны кочаклап алды.
— Үз улым кебек,— дия-дия аркасыннан сөйде ул аның.— Төштә кызымны һаман бишектә елап яткан килеш күрәм. Минем өчен һаман шул мәм-мәм сорап яткан елак кыз әле ул. Аның шундый чагын гына күрдем бит. И-их, урам буйлап җитәкләп йөрергә, мәктәпкә озата барырга, «икеле» алып кайткач, юри генә ачуланырга иде бер үзен! Бергәләп киноларга йөрергә, бәйрәмгә яңа күлмәк алып бирергә иде!
Искәндәр аның сүзләренә кушылмады, бу минутта ул Ләйсәнне җитәкләп шәһәр урамыннан бара иде. Ләйсән кибет тәрәзәсенә төртеп күрсәтә, алар эчкә керәләр дә кочакка сыйган кадәр курчаклар, китаплар, уенчыклар төяп чыгалар, аннан, авыз кырыйларыннан тамыза-тамыза баллыбоз ашыйлар. Ләйсән урам читендәге афишага карауга ук, ул аны сүзсез аңлый, алар көлешә-көлешә киногa керәләр. Залда ут сүнә, Ләйсән, караңгыдан курыккандай әтисенә сыена, ул аны кочагына ала.
Мотыйк белән башларын башка салган килеш кочаклашып утыруларын күргәч, Искәндәрнең күңеле нечкәреп китте.
— Ярый, сиңа җыенырга вакыт,— диде ул, кырысрак булырга тырышып.— Әллә төшәргә уйламыйсың инде?
— Төшми кая барасың? Һәркемнең — үз станциясе... Син үзең генә каласың инде. И-их, яшь чакларым булса, ияреп китәр идем сиңа!..
— Кайсы станциядә төшәсең син, Мотыйк абый?
— Менә сиңа иске авыздан яңа сүз: киләсе станциядә дип торам ич.
— Анысын беләм, станциянең исеме ничек, дим.
— Ә-ә-ә, анысын әйтәсеңмени? Тыңламас станциясе, ә авыл Баганалы дип атала безнең. Бу авылда кылынган эшләргә патша хөкүмәте җавап бирми, дигәнне аңлаткан ул. Юлаучылар, безнең авылга кермичә, читләп үтә торган булганнар. Шул кара баганалы авылның бер ма-

лае инде мин. Минем язмышның да капка төбенә кара багана утыртып куйганнар бугай. Гомер буе бәхет читләп үтте. Бөтен юанычың шушы зәмзәм суына калгач, юк инде ул...

— Әй, сөйләп бетермәдең бит әле син, Мотыйк абый, теге Зәмзәмия кая китте соң ул? Нинди әҗәтен түләде ул сиңа?

— Зәмзәм суы, дигәч, исеңә төштеме? Инде аяк сузам дигәндә, чынчын зәмзәм суы булды ул миңа. Язмышы бик гыйбрәтле ул Зәмзәмиянең... — Мотыйк, станциягә якынлашып килүләрен дә онытып, иркенләп сөйләргә тотынды. Тамак төбенә утырган ачы төерне йотып җибәрде дә иркен сулап, сүзен дәвам итте... — Сугышка хәтле үк булды бу хәл. Минем егермене тутырып килгән чак, Зәмзәмия ике-өч яшькә кечерәк. Нәрсәдән булгандыр, белмим, көннәрдән бер көнне моның бөтен тәне шешә башлады. Аны өшкертеп тә карадылар, догалы су да эчерделәр. Ул чакларда врач дигәнне ишетеп кенә беләләр иде авылда. Имтом белән шактый тилмерттеләр кызыйны. Зәмзәмия көннән-көн үзгәрә барды, күзләре тонықланды, ут янып торган йөзенә ваемсыз саргылт төс кунды, сүзләре дә бутала башлады. Авылда аның турында имешмимешләр таралды. Әти-әниләре аны кешегә күрсәтмәскә тырышалар, урамга бөтенләй чыгармыйлар иде. Шулай бер көнне ул өйдә кеше юклыгын гына чамалап торган да урамга чыгып йөгергән. Артыннан куып та тота алмаганнар. Ике көн, ике төн эзләгәннән соң, аны урман буендагы «Изгеләр чишмәсе» янында тапканнар. Күлмәкләре ертқаланып беткән, аяк-куллары сыдырылган, чәчләре тузгыган — урман пәрие диярсең. Чишмә кырыендагы ташка утырган да, бар дөньясын онытып, җир астыннан кайнап чыккан суга карап тора ди. Авыл халкы аның алмашынганын инде үз күзләре белән күргәч, сүзләр ачыктан-ачык йөри башлады. Әти-әнисе чакырмаган карчык, эчермәгән үлән, укылмаган дога калмады, ләкин Зәмзәмия терелмәде. Үзең беләсең, авыл халкының эше бетәрлек түгел бит, гел аны гына саклап утыра алмаганнардыр инде, тагын берничә тапкыр өйдән качып чыгып китте ул. Бу юлы да шул чишмә яныннан таптылар аны.

Ул еш кына безгә керә иде. Керә дә ишекле-түрле йөренә башлый, үзалдына туктаусыз сөйләнә: «Ямьле язлар да җитте, сыерчыклар да кайтты. Миң генә кайтмадым. Мин сыерчыклар белән ничек сөйләшим? Алар мине аңламый бит.— Аның тавышы шундый сагышлы, шундый кызганыч чыга, мин җылап җибәрмичә көчкә тыелып торам. Ул сыерчыкларга бармак төртеп,— карагыз әле, карагыз, сыерчыклар кара күлмәк кигән! Яз көне кем кара күлмәк кия инде? Минем күлмәгем матур, минем күлмәгем матур,— дип баласынып итәк очларын тотатота бөтерелә. Бөтерелеп арыгач, минем кулдан ала да урамга әйди башлый.— Әйдә инде, әйдә инде, Мотыйк абый!» — ди, еламсырап миңа карый. Мин ихтыярсыз аның артыннан иярәм. Юл буе бер сүз эндәшмичә, тын гына барабыз. Чишмә янына җиткәч, ул каушап калгандай була, кемнедер күрергә теләгәндәй, тезләнеп, күзләре талганчы чишмә суына карап тора. Аннан чишмә суында кулларын юа, битләрен, чәчләрен, колакларын, аякларын чылата. Шул вакытта беразга гына аның хәрәкәтләренә мәгънә кергән кебек тоела, күзләрендә бәләкәй генә очкын кабынып алгандай була. Кичке эңгер төшкәч кенә кайтыр юлга чыгабыз. Кайтып җиткәч, ул минем баштан сыйпый да «әбәк» дип, җилкәгә сугып, өйләренә йөгереп кереп китә.

Җәй буе мине ияртеп көн саен чишмәгә төште ул. Бүтән беркемне дә якын җибәрми, беркем белән дә сөйләшми, беркемнең дә сүзен тыңламый — бары мине генә үз итә иде. Ә көз җиткәч, аны шәһәргә больницага илтеп салдылар. Ике елдан соң терелеп кайтты авылга...

Әмма авыл халкы өчен мәңгегә Сәер Зәмзәмия булып калган иде инде ул. Чибәрлек ягыннан тирә-юньдә аңа тиңләшерлек кыз булмаган-

дыр дисәм, валлаһи, алдау булмас. Кашыкка салып кабып йотарлык иде, бичара. Шулай да егетләр аны читләп үтәләр иде, кызлар да үз араларына алмадылар. Ул моны бик авыр кичерә, шуңа күрә торган саен кешеләрдән читләшә бара иде.

Шулай бер көнне инде караңгы төшеп килгәндә әнисе безгә йөгереп кергән. «Зәмзәмия югалды, иртән чыгып киткән иде, һаман юк»,— ди. Минем күңел нидер сизенде бугай, «Изгеләр чишмәсе» янына төшеп киттем. Менә бүгенге кебек айлы төн иде. Ерактан ук күрдем мин аны. Чишмә буена су алырга төшкән ап-ак күлмәкле Зөһрә кыз төсле, суга иелгән дә, үз матурлыгына үзе сокланган дай, шәүләсенә карап тора.

Себер ягына ниндидер төзелешкә эшчеләр җыеп йөриләр иде, әтиәнисе кинәш иттеме, әллә үз хәлен үзе аңладымы — озакламый шунда китеп барды Зәмзәмия. Шул китүеннән юкка да чыкты. Сугыштан соң авылга кайтып, берничә ел узгач кына хәбәрен ишеттем. «Кияүгә чыккан, бер баласы туган, менә дигән итеп яшәп яталар икән»,— дип сөйләде әниләре. Аларның сүзен расларга теләгәндәй, аннан ай саен диярлек посылка килеп торды. Тик үзе генә кайтмый иде.

Әниләре инәлеп-инәлеп чакыра торгач, ире белән баласын ияртеп кайтты ул сабан туена. Киемнәр ефәктән генә, элеккечә үк булмаса да, төс-кыяфәт тә Комган Әптери кызлары белән янәшә куярлык түгел. Авыл урамы буйлап үткәндә, бар халык капка төбенә йөгереп чыга иде. «һе-һей, менә сиңа мә, Җүләр Зәмзәмиягә дә кияү чыккач, ул да ефәкбәрхеткә төренеп йөрерлек булгач, безнең кызларга ни сан инде»,— дип хатыннар тел шартлата. Кызларның да күзе кыза, читкә китәм дә читкә китәм дип, әти-әниләрен тинтерәтә башлый. Егетләрнең моңа ачуы чыга, менә-менә куеныңа керәм дип торганда, җиде җир читенә җибәреп булмый бит инде кызны. Авыл халкының авызында сүз торамыни! Сүз иярә сүз чыгып, бер җае килгәндә Зәмзәмиянең иренә кайсыдыр төрттереп куя. «Авыл авыл инде ул. Кешегә хөрмәт бар шәһәрдә. Әнә, синең хатынга элек бездә «Җүләр Зәмзәмия» дип, көлеп карыйлар иде. Шәһәр нишләткән үзен, хан кызы булган бит, кем әйтер аны хәзер «Җүләр Зәмзәмия» дип». Бу сүзләр әлеге иргә җитә кала, кайта да Зәмзәмиясен табалый башлый: нигә моңа кадәр миңа бу турыда әйтмәдең ди. Зәмзәмия бөтенесен дә сөйләп бирә. Ире, башы поезд астына кергере нәрсә, ташлап китә моны. Зәмзәмия аның артыннан бармады, авылда торып калды... Хәзер яңа калага эшкә урнашкан, диләр...»

Мотыйк озак итеп башын селкеп торды-торды да көрсенеп куйды. Поезд станциягә якынлашып килсә дә, аның җыенырга исәбе юк иде сыман. Искәндәр аңа бу турыда әйтмәкче булды, ләкин уйларыннан бүләргә базмады.

«Кайтмаска иде аңа кире, бар дөньясына төкереп яшәп ятарга иде шул Себерендә. Утка алданган күбәләк кебек, гел күз алдында торгандыр шул авыл. Барыбер түзәргә кирәк иде. Хатын-кыз күңеле күбәләк кебек шул...» — Мотыйк Искәндәргә күтәрелеп карамады, аның барлыгын да онытты бугай, үзалдына сөйләнеп, үз-үзе белән бәхәсләшеп барды.

— Син нигә кайтасың соң? Син дә кайтма. Тот та Зәмзәмия янына барып эшкә урнаш.

— Нинди эшкә?

— Үзең «атаклы балта остасы» дисең, үзең...

— Авыл өчен — атаклы. Авыл йортын күз йомып та житкерәм мин аны. Шәһәр бит ул... Аннары... шәһәргә күңел дә ятмый минем, һава җитми миңа анда.

— Алайса, Зәмзәмияне ал да берәр авылга барып төплән.

Ул арада ишекне каты итеп дөбердәттеләр, җавап биргәнне дә көтмичә ачып җибәрделәр.

— Каласың бит. Поезд туктады. Синең станция. Әллә төшмисеңме?

Мотыйк теләр-теләмәс кенә кузгалды, утыргыч астыннан рюкзагын алып идәнгә куйды. Хәрәкәтләре артык салмак, дәртсез, хәлсез иде аның. Ул, станциягә җиткәннәренә ышанмагандай, тәрәзәдән тышка карады. Анда төннең кара пәрдәсеннән башка берни дә күренмәде. Күктәге ай да, сезнең арттан күпме барырга була дигәндәй, каядыр артта калган иде. Бары тик йолдызлар гына, сүнеп барган учак көле арасында ялтырап киткән күмер күзләре кебек, җилдә дөрлиләр.

Искәндәр рюкзакны алып купедан чыкты. Мотыйк һаман кузгалмады. Аннары лып итеп утыргычка иңеп төште.

— Чыкмыйм әле. Йөрәгем кага,— диде ул ыңгырашкан тавыш белән.— Авылга кайтып җитә алмам кебек.— Ул мөлдерәгән күзләре белән Искәндәргә текәлде. Хәзер аның тезләренә башын куяр да үкси-үкси елый башлар сыман иде Мотыйк. Аның иреннәре калтырады, борын яфраклары кабарды.— Китәсем килми минем моннан, Искәндәр энем, китәсем килми,— диде ул хәлсез тавыш белән.— Инде күптәннән бер кеше белән дә болай рәхәтләнеп сөйләшкәнем юк иде. Эч серләремне сөйләгәнем юк иде. Күңелем бушап калды. Яңадан туган кебек булдым. Ачуланма, тагын бер генә станца барыйм әле. Миңа кайда туктасам да, барыбер. Ул станциядән теге яңа калалары да якын гына. Исәп итсәм, Зәмзәмия янына да сугылып чыгармын. Хәлен белермен. Елаша-елаша сөйләшеп утырырбыз бер. Яңа елга алып чыгасым килми бу кайгы-хәсрәтләремне. Яңа елда яңача яши башларга иде!..

Мотыйк, сүзен әйтеп бетерә алмыйча, ютәлләргә тотынды, һава житмәүдән изүләрен чишеп җибәрде, керфекләрен күтәрмичә генә Искәндәргә endәште:

— Әйдә минем белән! Гостиницага урнашырбыз! Ду китереп Яңа елны каршы алырбыз. Әйдә, җыен, төшәбез дә калабыз. Зәмзәмия апаң белән дә танышырсың. Кияү җегете булып барырсың. Табабыз аны, өй борынча йөреп булса да табабыз. Шәһәр дигәч тә, безнең авыл хәтле генә әле ул. Җиткерә генә башладылар. Кайчан телисең, шунда китәрсең. Билет өчен борчылма. Кирәк булса, йоклап яткан түшәгеннән кырыена китереп бирерләр. Акча китерттерә ул... Әйдә инде, яшь кешегә бер җилкенеп алу ни тора ул?

Мотыйк Искәндәрнең пальтосын чөйдән алды, бүреген кидерде, иңнәреннән сыпырды. Ничек кенә булса да Искәндәрне күндерәсе, үзе белән алып каласы килә иде аның.

— Булмый, Мотыйк абый,— диде Искәндәр. Бу сүзләрне ул шундый авырлык белән әйтте, әйтерсең, ниндидер зур җинаять эшләде, әйтерсең, тиктомалга Мотыйкның яңагына китереп сукты.

— Алла хакы өчен, тыңла сүземне! — дип инәлде Мотыйк.— Бәйрәм арасы бит. Бәйрәмне кайда үткәрсәң дә барыбер түгелмени? Монда ошамаса, безнең авылга кайтырбыз. Авыл халкының күзен кыздырып, урам буйлап узарбыз. Мотыйк абзыйларының бөтенләй төшеп калган кеше түгеллеген күрсеннәр! Алар сөйләшмәсен, ә ул менә нинди гөрнәдирдәй егетләр белән йөри! Аннары Сәгыйдулла абыйның хәлен белеп килербез. Бәлкем, бер-бер ярдәм кирәктер. Нияте зурдан бит картның. Исәп итсәк, Бригадир Ибрайга да сугылырбыз. Талканы коры булуга карама, күңеле туры ул кешенең. Шундый кешеләр ясаган да инде революцияне, тоткан җирдән өзә торган кешеләр. Безнең ишеләр түгел...

Сөйләгән саен аның йөзе ачыла барды, сыгылып төшкән гәүдәсе турайды, күзләрендәге сүрән очкыннар уянып ялтырый башлады, әйтерсең, ул инде, чынлап та, үзе хыялланган дөньяда йөри иде. Ул поезд кузгалып киткәнне дә сизмәде, Искәндәрнең пальтосын яңадан чөйгә элгәнен дә күрмәде. Бары тик, поезд тизлеген арттырып, вагон як-якка чайкала башлагач кына әкренләп аңына килде.

— Шулай итеп, минем белән калмаска булдың инде?..— диде бераздан, илтифатсыз гына.

— Юл кешесенең юлда булуы хәерле.

— Мин сине базга ябарга җыенмыйм лабаса.— Мотыйк чын-чынлап аны ачуланурга ук күчте.— Ике-өч көн бәйрәм итәрбез, күргән-белгәнне йөреп чыгарбыз да, син тагын үз юлың белән китеп барырсың.

— Бер туктагач, авыр кузгалам мин. Китә алмый, шунда калырмын дип куркам.

— Куып җибәрермен. Бер станцага бер бәхетсез җиткән...

— Мин үземне бәхетсез санамыйм...

— Тиктомалга кубарылып юлга чыкмый бәхетле кеше. Ялгыз кеше — бәхетсез кеше инде ул. Ничек кенә күңелеңне юатырга тырышма, ялгыз барыбер ялгыз инде.

Искәндәрнең җавап кайтарасы да, башлап сүз әйтәсе дә килми иде. Ул утыргычка матрас тәгәрәтеп җибәрде дә, ике кулын башы астына салып, чалкан ятты. Аның ялгызы гына калып тынычланасы да килә, Мотыйкны да кызгана. Ул киләсе станциядә төшеп калыр да, кибән эченә кереп югалган энә кебек, йортлар, авыллар, кешеләр арасында юкка чыгар, аны беркем дә күрмәс, эзләмәс, тапмас кебек иде.

— Йокламыйсыңдыр бит?

Искәндәр җавап бирмәде, күзләрен генә зур итеп ачты.

— Йоклама! Яңа елны йоклап каршы алырга ярамый.

— Нигә?

— Андый кеше вакыт кадерен белми, гомере заяга уза аның.

— Үзеңнән беләсеңме?

Искәндәр ваемсыз-дорфа тонга күчкәнен аңлап, эчтән үзен битәрләп куйды.

— Әйе, үземнән.

— Йоклап калсаң, нәрсә була. — Кызыксынганын сиздерергә теләп, ул торып утырды.

— Яңа ел чиге — ил чиге генә түгел ул, энем. Ил чикләрен күп үттем мин. Шуның аркасында күпме каһәр ишеттем. Кеше күңеле барысын да күтәрә, барысына да ризалаша. Тик менә вакыт үтүенә, гомер узуына гына ияләшә алмый. Үлемгә өйрәнә алмый кеше. Ә иске ел синең гомереңнең үлгән бер елы бит ул. Яңа елны каршы алганда кеше тын калып шул турыда уйларга, тормышның кадерен аңларга тиеш. Шул вакытта йоклап ятсаң, сиңа ике дөнья — бер моржа. Кеше Яңа елны нигә уйлап тапкан? Үзен юату өчен. Шулаймы?

Искәндәргә Мотыйкның авыл картлары шикелле башын бер якка кырын салып, күзләрен хәйләкәр кыскалый-кыскалый, үзе кичергән хәлләр белән ныгытып фәлсәфә сатуы ошый иде.

— Нигә тындың? Дөрес әйтмәдемме әллә?

Ул, бишектә оеп тирбәлгән бала кебек, гаҗәпләнгән күзләрен тутырып карады да тагын онытылды.

— Телеңне йоттыңмы әллә?

— Вакыт — юк нәрсә ул, Мотыйк абый. Вакыт төшенчәсен кеше үзе уйлап тапкан. Аны сәгатьләргә, көннәргә, айларга, елларга бүлгән. Чиксезлекне, мәңгелекне башына сыйдыра алмаганга шулай эшләгән ул. Мәңгелек янында үз гомеренең молекула хәтле дә булмавын аңлаган, шуңа күрә еллар уйлап чыгарган да, илле ел яшәде, йөзгә җитте дип, кеше гомерен зурайтып күрсәтергә тырышкан.

— Башны бутыйсың син, энем. Юк белән башны бутыйсың.

Шулчак, ачы сызгырып, тәрәзә артында поезд үтә башлады. Мотыйк, җөмләсе поезд астында калгандай, шып туктады. Искәндәр тәрәзәгә капланды. Аның күз алдыннан бер-бер артлы якты тәрәзәләр йөгереп узды. Һәр тәрәзәдә кемнеңдер йөзе чагылып калды. Ул үзе ташлап киткән шәһәр ягына да поездлар йөрүенә, шунда кешеләр баруына сә-

ерсенгәндәй, күзен алмыйча соңгы вагон үткәнче карап торды. Каршы килгән поезд, артыннан куа килүче Яңа елны житкерергә теләмичә чабадыр сыман тоелды аңа. Ә ул, киресенчә, Яңа елның каршысына ашыга, тәгәрмәч авазларына кушылып типкән йөрәге, иң якын кешесе белән очрашуны көтеп ярсыгандай, алгысына иде.

Искәндәр сәгатенә карады. Бу юлы ул стенага күтәрелеп карамады, ул инде үзенең поездда баруына күнегә башлаган иде. Үзе өчендерме, әллә Мотыйк ишетсен дипме, аһылдап әйтте:

— Бер сәгать кенә калган.

— Унбер тулдымыни?

Алар икесе дә сагаеп, тын калдылар. Гүя шушы бер сәгать эчендә ниндидер зур вакыйга булырга, алар гомер буе көтеп килгән ниндидер бер нәрсә чынга ашарга тиеш иде.

Мотыйк ашыкмый гына рюкзагын иңенә элде, бүрек колакчыннарын чишеп яңадан бәйләде, бияләен киеп салды. Аның нәрсәдер әйтәсе килә, ул нәрсәдер көткән сыман иде. Менә ул башын аска иеп купедан чыкты. Ишек төбендә тукталып калды. Искәндәр аның китәсе килмәгәнен бөтен җаны-тәне белән аңлады. Әйтерсең, шушы поездан төшеп калса, ул вакыт арбасыннан төшеп калыр, айларның, елларның исәбен югалтыр, болай да буталчык тормышының мәгънәсен таба алмыйча, мәңгелеккә китеп барыр кебек иде. «Вакыт арбасы,— дип уйлады ул эчтән генә.— Менә ни өчен, бар дөньяга кул селтәп, шушы поездга ашыккан икән ул. Вакыт арбасы. Ул, дөнья мәшәкатьләре арасында буталып, хыялы артыннан житешә алмый башлагач, вакыт каршына үзе чыгып йөгергән. Хыялын куып житмәк булган. Күктәге кошлар — кешеләрнең җаны түгел, хыялыдыр алар. Хыялсыз кеше — канатсыз кош, дип юкка әйтмиләрдер. Кеше, дөнья ваклыкларына чумып, хыялын оныта, ул, аны ташлап, күккә очадыр».

Ул, хыялын капшап карарга теләгәндәй, күкрәгенә кулын куйды. Йөрәк ярсып-ярсып тибә иде. «Димәк, ул хыялын куып тоткан. Бригадир Ибрай, Сәгыйдулла бабай, Балта остасы Мотыйклар белән очрашмаган булса, бу ачышны ясый алыр идеме икән ул?» Искәндәр шунда гына Мотыйкның саубуллашмый-нитми чыгып киткәнен аңлады. Купе тузгытылган кош оясы кебек буш һәм шыксыз иде.

Мотыйк, ярты гәүдәсе белән ишектән кереп, проводницага нидер сөйли.

Менә ул купедан башын алды да Искәндәргә таба атлады. Кулында проводницалар йөртә торган кызыл флагчык иде аның. Килеп житкәч, кулын аның иңенә куйды, авыр итеп көрсенде.

— Яңа елга бирәр нәрсә бүләк итәсем килгән иде. Алдан уйланылмаган. Очрашасын кем белгән аның. Менә, сиңа — кызыл флагчык. Теләгем шул: каршыңа бәхет килсә — уздырып җибәрмә, шушы флагчыкны күтәр.

Ул бүген беренче мәртәбә шулкадәр сөенеп елмайды, хәтта Искәндәрнең күзләренә яшь килде. Кулда йөри-йөри керләнеп, таушалып беткән флагчыкны күкрәгенә кысты да кат-кат бер сүзләрне кабатлады:

— Рәхмәт, Мотыйк абый! Рәхмәт, Мотыйк абый!

Алар, бер-берсенә сыенышып, буш коридорда икесе генә шактый озак басып тордылар. Мотыйк рюкзагын рәтләп куйды һәм:

— Килеп җиттем,— дип, тәрәзәгә таба ымлады да тамбурга таба китте.

Поезд туктауга, Искәндәрнең йөрәге дә тибүдән туктаган сыман булды. Аның тәне буйлап суык йөгерде, аяклары хәлсезләнде, керфекләре авырайды, куллары салынып төште. Ул вагон баскычына басты да, сикереп төшәргә җыенгандай, бар гәүдәсе белән алга — караңгы төн кочагына сөрлекте. Мотыйк берничә адым атлады да туктап кал-

ды. Кинәт кенә борылып, яңадан вагон баскычы янына килде. Искәндәрнең кулына чытырдатып ябышты.

— Соңгы кат әйтәм, төш монда. Кал! Берүзем генә нишлим мин монда? — Аның тавышы иңрәп, инәлеп чыкты.

Искәндәр, төшеп калудан курыккандай, вагон тоткасын бар көче белән кысты, иреннәрен тешләде. Шулчак поезд кузгалып китте. Мотыйк, Искәндәрнең кулын ычкындырмыйча янәшә атлап барды. Вагон тәгәрмәчләре дөпелдәгән тавыш Искәндәрнең йөрәк авазын кузгатты. Аның йөрәге торган саен ярсыбрак тибә, йөрәге, ярсыган саен поезд да тизләгеп арттыра иде. Мотыйк әле һаман Искәндәрнең кулына тотынган килеш поезд белән янәшә йөгерә. Ул гәүдәсен көчкә сөйри башлады, бармаклары язылып, Искәндәрнең кулын ычкындырды. Егылып китүдән куркып, ахрысы, юл читендәге баганага барып сөялде.

— Сау бул, Мотыйк абый! Зәмзәмия апага сәлам әйт! — дип кычкырды Искәндәр.

Салкын җилдән Искәндәрнең йөзе уттай кызышты, чәчләре тузгыды. Җил җан ачысы белән сызгырды, үкси-үкси елады. Җиһан белән саубуллашучы иске елның хәсрәтле җиле аңа шулай үзенең соңгы серләрен сөйли иде.

— Төшеп каласың бит! Аннары җавап бир сезнең өчен.

Проводница, Искәндәрнең иске елда төшеп калуыннан курыккандай, вагон ишеген бикләп куйды.

Искәндәр кинәт кенә үзенең гәүдәсе җиңеләя башлаганны тойды, әйтерсең, борчып, күңелен газаплап торган бар уйлары Мотыйк белән бергә шушы станциядә төшеп калганнар иде. Ул кулындагы флагчыкны әйләндерә-әйләндерә карады, ачык ишекле купе янына җиткәч, проводницага эндәште:

— Шушы нәрсә белән поездны туктатып буламы?

— Туктамый, кая барсын ул?

Купе эчендә әле дә Мотыйкның җылысы саклана иде кебек. Ул сәгатенә карады. Уникe туларга егерме җиде минут калган. Искәндәр сәгатен сыйпап куйды. Әйтерсең, егерме җиде минуттан аның каршында бәхет капкасы ачылырга тиеш иде.

Ул купе почмагына сөялеп утырды да иске елның соңгы минутларын санап дөпелдәүче йөрәк авазын тыңлый-тыңлый оеп барганын сизми дә калды.

...Поезд бар тәрәзәләре белән балкып, сөенеп Яңа елның ап-ак дәүләтенә килеп керде дә шатлыгыннан кычкыртып җибәрде. Искәндәр моны сизмәде дә, ишетмәде дә. Ул бар дөньясын онытып, изрәп йоклый иде.

Төшендә ул Яңа елның бәллүр капкасы өстенә эленгән галәмәт зур сәгать күрде. Әйе, бу аның өендәге сәгать, бабасыннан калган борынгы сәгать иде. Сәгать бар дөньяны яңгыратып төнге уникенe суга башлады. Ләкин элеккечә буыла-буыла, гыжылдый-гыжылдый түгел, ә илаһи музыка авазлары таратып, ярсый-ярсый суга иде. Искәндәр бу илаһи музыканың сәгать сугуыннан түгел, үз күңеленнән агылып чыкканын аңлап һушсыз калды. Күзләрен күккә төбәп, әкрен генә пышылдады: «Бабай сәгате терелгән. Борынгы сәгать терелгән. Иске сәгать дөрес йөри!»

Ул йокысыннан уянганда поезд Якты юл станциясенә якынлашып килә иде.

Малеевка—Казан—Чаллы.
1981 ел.

## Нәҗип Мадьяров

### Чаллы

Нигез итеп Ватан ышанычын,
Бердәмлеккә туплап халыкны,
Кама буе, синең мәгърурлыкка
Һәйкәл булып шәһәр калыкты.

Үсә, гөрли, биеклеккә үрли,
Һәрбер «КамАЗ» — аның адымы...
Чаллы шулай кешеләрне данлый,
Ә кешеләр данлый Чаллыны.

### Ике агым

Авазларын ерак ишеттереп,
Ике агым бизи Чаллыны.
Берсе аның мәшһүр Кама булса,
Икенчесе «КамАЗ» агымы.

Ике агым! Ике гигант агым!
Берсе юлын чикли Иделдә.
Икенчесе, кара, алаймы соң?—
Җәелеп ага бөтен илемә.

●

Тыныч кына ага кебек Кама,
Юк, биредә тыныч түгел ул.
Ил сокланып аренага илтә
Турбиналар аша үзен ул.

Миллионнарча энҗе-утка, әнә,
Әверелдерә һәрбер тамчысын.
Шуңа Чаллы нурда коена бүген,
Киләчәккә төшереп яктысын.

●

Турбиналар җырлап әйләнәләр,
Әйләнәләр көчле ток биреп.
Нәрсә кирәк тагын?
Шәһәремне
Балкыталар якты ут биреп.

Турбинага охшаш гомерем дә,
Әверелдерә хисен җырларга.
Берни көтмим, дуслар күңелен
бераз
Күмә алсам якты нурларга.

## Июнь

Сиңа тагын килеп кердек, июнь,
Изүләрне ачып.
Агылып керә җылы мәрхәмәтең
Күңелләргә ташып.

Басып алды болын, аланнарны
Чәчәк патшалыгы.
Бер-бер артлы кабатланып тора
Хуш ис атналыгы.

Күк йөзләрен чагылдырып балкый,
Сулар көмеш кенә.
Балаларның коенуларына
Түзсен инеш кенә.

Күтәрелә арыш дәрьясында
Серкә бураннары.
Күз тиярлек анда кыр юллары —
Иген урамнары.

Яңгыр белән аралашып кояш
Нурны мул яудыра.
Яшел төсен аклап, һаман өскә
Дөнья үрли тора.

Ул гынамы? Сөенеч мәйданына
Ни кирәген белә,
Җырлап-биеп, гармуннарын сузып
Сабан туе килә.

Бары да хак. Өр-яңача балкый
Суың, җирең, күгең.
Максатларга кыю омтылыр чак:
Сиңа кердек, июнь!

# Хәниф Хөснуллин

## Тукайның яңа ватаны

### 1

*...Агач атларга атланган малайларны карап, көнләшеп тора идем.*

Г. Тукай

Әйләнә, карусель әйләнә,
Агач ат чаба да чаба ул.

Син аңа тиеннәр бир генә,
Җайдагын үзе дә таба ул.

Таба ул җайдагын агач ат,
Олылар атлана, кечеләр.
Юк ләкин сыңар бер тиене —
Нишләсен Габдулла ишеләр.
Габдулла кебекләр нишләсен,
Ничә яз, ничә җәй җәйләнә...
Ата юк, ана юк — ятим ул.
Әйләнә, карусель әйләнә.

Балалык карамый түбәнгә,
Хыялы биектә аллана.
Юыртсаң, кешнәсәң, ярый ул —
Таяк та ат кебек җанлана.
Җанлана таяк та ат кебек,
Уенны акчага бәйләмә...
Дәвере кызганыч, баласы —
Әйләнә, карусель әйләнә.

## 2

*Автомобиль китә торган җиргә барып, никадәр көтеп торсак та, безгә нәүбәт бирмәделәр*

Гасыр башындагы истәлекләрдән

Яңалык, шәһәрдә яңалык.
Нигә дип бу кадәр чират бар?
Балалар чәүкә күк шаулаша,
Ни өчен тартыша ир-атлар?
Ни кызык, ни мәзәк, ни сәбәп
Шәһәрне бу чаклы гөр иткән?
Олысын кузгаткан, кечесен,
Беразга юлларын бер иткән?
Яңалык, шәһәрдә яңалык,
Яңалык кайчан да бар бит ул:
Шәһәрдә — беренче машина!
Әйләнә һаман да карусель.

Берләрен утырта машина,
Үзенчә юата ир-атны:
«Озаклап күрсәгез — шул җиткән,
Барыбер саклагыз чиратны».
Нәүбәт юк, тик усал гайбәт бар,
Вакытың уздырма, Габдулла.
Утыртмый тәкәббер машина,
Атлансаң, хыял да ат була.
Утыртмый машина. И дөнья,
Кешене урама хәйләңә.
Көннәре өметсез, дәвере —
Әйләнә, карусель әйләнә.

## 3

Яңа төс, яңа көч елларда,
Үткәннең эзе дә калмаган.
Кешеләр үзгәрткән заманны,
Һәм заман кешене аңлаган.
Эзе дә калмаган үткәннең? —
Түгел лә, мең кабат түгел лә:
Тукайның мәңгелек сүзләре
Ялкынлап тормыйммы күңелдә?!
Шагыйрьме, әгәр ул белмәсә
Кемнәргә нәрсәләр кирәген?
Юл ярып, караңгы көннәрдә
Ут итеп кабызган йөрәген.
Еракта — әйләнгән карусель,
Ул күргән беренче машина.
Калдырып өметсез көннәрне,

Кешелек яктыга ашыга.
Ә халкы — ата да, ана да —
Төзәтә элекке хатаны.
Тукайча таныла дөньяга
Тукайның өр-яңа ватаны.
...Ул үзе бу җирдә тумаган.
Бу якта тормаган бер көн дә...
Бу кырлар, авыллар, бу шәһәр
Тукайның шигыре иркендә.
Агач ат ятсынган шагыйрьне,
Төзәтә замана хатаны:
«КамАЗ»лар җиткерә,
«КамАЗ»лар
Тукайның өр-яңа ватаны!

# Александр Чурбанов

# БЕРЕНЧЕ ҖӘЙ

хикәя

## I



Безнең дәү әни кешеләргә әллә ни ышанып бетмәсә дә, өйдә йозак һәм бик ише әйберләрне тотмый иде. Гөнаһтан курыккан шикелле ул тавыштан, шау-шудан курка, аларны кеше башына килгән бәла дип саный. Бәлки шуңа күрәдер дә әле, Шурик өйалдына килеп кергәч, ишек тә, идән сайгагы да, хәтта юеш чүпрәк чорнап аяк сөртер өчен куелган себерке дә шытырдамады. Ишек ырмавына кадакланган киезне күреп, Шурик бу өйдә тынычлыкның иң кебек изге булуына тагын бер ышанды.

Бусаганы атлап кергәч, ул бер ара өй эчен күзәтте. Монда тынлык белән ярым караңгылык хөкем сөрә. Һәм бу караңгылык почмакта янып торган лампада белән зур өстәлдән башка бөтен әйберләрне дә үз эченә йоткан кебек тоелды. Өстәлдәге суынып җитмәгән самавыр белән чәйдән калган чынаякларга карагаңда, дәү әниләрен өйдән нинди дә булса ашыгыч эш чакырып чыгарган булырга тиеш. Гадәттә, туган-тумачадан берәрсе вафат булганда яки бер-бер хәл килеп чыкканда гына лампада яндырыла иде. Шулай аптырап басып торганда Шурикның карашы почмактагы җитди йөзле изгеләр сурәтенә төште һәм шунда ул, гомерендә беренче тапкыр, иконадагы йөзләрнең дәү әнисенә охшавын күрде. Бәлки дәү әнисе аларны шуңа тотадыр да әле...

Шул вакыт баскычта аяк тавышы ишетелде.

— Шурка! — Бусагада шактый тазара төшкән туганнан туган абыйсы Митька күренде.— Синме бу?! Кара ничек үскән! Дәү әни дөрес әйтә ул: безне сукалыйсы-чәчәсе юк — үзебез үсәбез! — Митька аны калку күкрәгенә кысты да малай чактагы шикелле маңгаеннан чупылдатып алды.

— Дәү әни кайда соң?— диде Шурик, Митьканың шулай куанып каршылавыннан уңайсызланып.— Әллә ул минем телеграмманы алмадымы?

— Алды, алды.— Митька һаман әле авызын җыя алмый иде.— Китте ул. Медичка Ира алмага килгәнне. Грачевода, моннан җиде чакрым ары, безнең Васятканың Нюркасы бала табып ята икән. Үзе чучка кебек чиный, ди. Ә Ирка нәрсә?! Үзе бала-чага бит әле. Укып кына кайтты. Иөкле хатыннарны мунчада гына күргәндер. Коты ботына төшкән.

Ә дәү әнисен, үзен беләсең, андый эшкә кулы ята. Үзе дә уникене тапкан. Ирка янына ярдәмгә китте.

— Ә Нюркага ни булган? Ник кычкыра?

— Алар гел кычкыра,— диде Митька бик белдекле кыяфәт белән.— Минем Лидка да соңгы юлы әллә ниләр кыландырып бетерде. Тавышын ишетеп, дәү әни йөгереп килде дә мине өйдән төрткәләп тә чыгарды. Торам шулай ишек артында, колакларны торгызып. Ә Лида Шаляпинмыни — бакыруын белә. Шунда өйдә кинәт лампа сүнгән. Дәү әни ишекне ачты да: «Ут, ут, тизрәк ут яндыр!»— ди. Туры килсә, килә икән ул, кабаланудан лампа куыгын төшереп ваттым. Ярый әле трактор капка төбендә ие, кабыздым да фараларны тәрәзәгә караттым. Ә Лидка... акырыпмы-акыра! Мин дә үземнекен итәм — үкертәм генә газны. Җир селкенә, өйдә — концерт! Таңга хәтле фараны сүндермәдем. Ярты бак солярка бетердем. Ну, Лидка да молодец, ике малай тапты. Иртәгесен ирләр көлә: син, Митька, газны ачып җиткермәгәнсең ахры, диләр.— Ул башын артка ташлап рәхәтләнеп бер көлеп алды.— Игезәкләрне тапкач, Лида, ничектер, тазарып, мамыкланып китте, ә элек — чиртсәң өзелергә тора ие,— диде.

— Яшь хатынга артык таза булу килешми инде,— диде Шурик.

— Килешми сиңа. Ташла, Шурик, хатының бакчадагы түтәл шикелле булырга тиеш: орлык ташладыңмы — тапсын! Уйлап кара, җилдән чайкалып торган хатын андый эшне башкара алырмы икән? Йоклаганда ялгыш кына сытмыйм тагын, дип яшәгәч, булмый инде ул.

Теле бик кычытса да, бу өлкәдә тәҗрибәсе булмаган Шурик каршы сүз әйтә алмады.

— Мин бит сине алмага килдем,— диде Митька, көзге каршында тузгыган чәчен тарый-тарый. Әмма дәү әниләренең тарагы чыдамады, тешләре сынып коела башлады. — Дәү әни тиз генә кайтмас, сине кайгыртырга кушты. Мин хәзер өйдә балалар белән генә. Лидка фермада. Синең кайту хөрмәтенә без дә лампада яндырырбыз,— диде ул, күңелле генә башын селкеп. Чәчендә калган сынык тешләр идәнгә коелды.

— Әйдә, алайса, киттек,— диде Шурик.

Митькаларга алар турыдан гына, бакча артлатып киттеләр. Караңгыда әле былтырдан калган салам өемнәренә, әле киртәләргә килеп төртеләләр иде. Хәтәррәк урыннарда (сыгылмалы басма аша) Митька аны кулыннан тотып чыгарды.

Митьканың өе үзенең ныклыгы, иркенлеге белән Шурикны гаҗәпкә калдырды. Түр якка үткәнче алар элек болдырны, өйалдын, кухняны уздылар. Почмак саен бала иде монда, арада игезәкләр дә бар. Караватка баскан килеш алар әтиләренең кулга алуын сорыйлар иде.

— Таныш бул, Шурка. Менә бусы — Василий... Теркин! — Митька игезәкләрнең чаярагын башыннан сыйпады.— Үлә инде сәгать дип. Сәгать теленә карап ятмаса йокыга да китми. Ә монысы,— ул күлмәк итәге белән малайның борынын сөртеп алды,— Иван... Мичурин. Күз-колак булмасаң, гөл яфрагын авызына тутыра. Ну, нишлибез соң?.. Бакчага чыгыйкмы? — Ул ике стакан һәм ипи кыерчыгы эләктереп ишеккә китте.

Бакча ишеген ачып, эчкә үттеләр...

— Мить, син салырга яратасың, ахры? — диде Шурик.

— Мин?.. — Митька уйланып торды.— Авылдагы башка ирләр кебек. Бәйрәмдә тоткалыйм. Ә болай, сәбәпсез — ни, ни... Хәзер бәйрәмнәр дә күп бит.

— Әйдә, Мить, сал тагын берәрне дәү әни саулыгына. Ул бит безнең нәселне башлап җибәрүче, дәү әни булмаса, без дә булмас идек.

— Менә монысы дөрес, рәхәтләнеп кушылам,— диде Митька.— Безнең дәү әни ул алыштыргысыз кеше. Ә үзең нишләргә уйлыйсың соң? Аттестат алдың да тынычландыңмы?..

— Минме? — диде Шурик уңайсызланып. Дөресен генә әйткәндә, аның бу сорауга җавабы әзер түгел иде әле.— Минем өчен эти барысын да хәл итте инде. Әйдә, улым, бер-ике ел авылга, әбиең янына кайтып тор, икмәкнең дә ничек үскәнен күрерсең, ди.

— Бик дөрес,— дип хуплады Митька.— Икмәкнең ничек үскәнен һәркем белергә тиеш. Шунсыз кадерен дә белмисең.

...Шурик белән Митька төн урталарында гына аерылдылар. Шурикны култык астыннан тотып, Митька аңа ничәнче тапкыр инде:

— Атаң хаклы! Мильен тапкыр хаклы!..— дип кабатлады.

## II

Грачеводан дәү әниләре өченче тәүлек киткәндә генә кайтып керде. Кулында оныгы, ә янәшәсендә килене — алсу йөзле, сузчән, бала тапканның өченче көнне үк җиде чакрымлы юлга чыгарга батырчылыгы җиткән Нюрка атлый иде. Шурикның шәһәрдән монда торырга кайтканын ишеткәч, дәү әниләре шатлыктан кулларын җәеп җибәрде.

Аннан ул урындыкка куелган сабыйга иелде, иркәләү сүзләре әйтәәйтә төрергә керешге: «Кара син аны, усал малайны. Үзе дә йокламый, әнкәсен дә йоклатмый. Нәрсә, әллә эчең авыртамы? Күпкән шул, күпкән. Көчән, әйдә, көчән. Менә шулай, менә шулай, ай рәхмәт, менә молодец... Булды бит, тырыша торгач булды. Ну-ка, әнисе, яңа чүпрәк китер әле...»

Шул вакыт өйгә, авызын ерып, Митька килеп керде. Иңенә зур кәрзин аскан, ә кәрзиндә елмаешып «Мичурин» белән «Теркин» утыралар. Җылыдан киендерелгән игезәкләр моңа күнеккәннәр булса кирәк. Этиләре кәрзинне солдат каешы белән бәйләп, матча кадагына элеп куйды да:

— Во! Карап ятыгыз шунда, биектән ул шәбрәк күренә,— диде. Һәм чалбарының арткы кесәсенә сузылды.— Әйдә, Шурик, племяшны юабыз, Петр дип кушканнар,— диде.

— Петр, Петр,— диде яшь килен, бәхетле елмаеп.— Дәү этиләре истәлегенә булсын дидек.

Шурик шикләнеп дәү әнисенә карап алды. Ә Митьканың үз сүзе сүз:

— Син аңла, миңа бүген дә рәтле йокы тәтемәде. Сине озаткан гына идем, бригадир килеп җитте. Бар, Митька, тракторыңны кабыз, ди. Грязные Ключи янында товар төягән машина батып ята, ди. Нишлисең? Киттем. Ул көнне болай да уникे сәгать эшләнгән. Аек килеш бармас та идем, төшергәч — ни, ни!.. Белеп торам, соңыннан икеләтә әләгәчәк. Беренчедән — салмыш булганга, икенчедән — баш тартканга. Таң беленгәч кенә машинаны өстерәтеп алкайттым.

Митька аракыны стаканнарга бүлде. Дәү әни белән Нюрканы бала туу белән котлады да эчеп куйды, аннан Шурикка карап:

— Бетте, Шурка. Шушы көннән эчүне онытабыз. Эшкә тотынырга вакыт. Бүген безнекеләр тайгадагы ерак болыннарга чыгып китәләр. Сине дә бригадага беркеттем, җыен. Ә сез,— Митька үзенең игезәкләренә елмайды,— дәү әнине бик борчымагыз. Ату әнигезгә илтәм дә тапшырам, ә ул белә инде нишләтәсен.

Болай да тып-тын утырган игезәкләр кәрзингә сеңделәр.

Күп тә үтмәде, Шурик белән Митька саубуллашып чыгып киттеләр.

Митька чалгы, тырма, янавыч, чүкеч ише әйберләр хәзерләгән арада, Шурик авыл артына карап торды. Анда урман, елга борылышы, күл күренә, һәркайсына аерым сукмак сузылган. Мондый күзгә бәрелеп тормаган матурлыктан Шурикның күңеле әллә нишләп китте, гүя ул үткән гомеренә ниндидер йомгак ясый иде. Һәм шунда ул ата-бабалары

турында: «Каян килгән аларга мондый көч, мондый рух? Күпме сугышлар, бәла-казалар кичереп...»,— дип уйлап алды.

Менә Митька да күренде, иңендә чалгы.

— Кузгалдык! — диде ул.

Гадәттә, идарә каршындагы мәйданчыкта иртәнге сигезләрдә халык инде таралган була. Ә бүген, төш вакыты якынлашып килүгә дә карамастан, монда шыгрым тулы халык, ыгы-зыгы, шау-шу, арбалы атлар, чалгы, тырма, капчык тоткан кешеләр — кыскасы, печән вакытында ни кирәк булса, барысы да шушында.

Митька карашын Шурикка төбәп:

— Ярый, булган бу. Хәзер менә төяләбез дә кузгалабыз,— диде.

Күп тә үтмәде, арбаларга төялгән халык, авылдан чыгып, урман юлы белән китеп барды. Беренче чакрымнардан ук Шурикның күңеле төште, янында Митька булмаса, уйлап та тормыйча кире авылга кайтып китәр иде. Йөз метр саен атлар корсагыннан кереп баталар да, хәлдән таеп, саз пычрагына яталар. Алар шундук тугарыла, йөк корырак урынга ташыла. Һәм тартып чыгарылган атларны тагын җигәргә, йөкне төяргә кирәк.

— Түз, энекәш. Бераздан җиңеләер! — дип Митька энесенең күңелен күтәрергә тырышты.

Әмма юл бер дә әйбәтләнергә ошамый иде. Инде аның ахыры булмас шикелле тоела башлады. Вакыт-вакыт, аркылы ауган агачларны кисеп, юлны арчырга туры килә.

Кояш урманның кырлы сыртына төшеп, кызгылт тасма офыкка таралганда, печәнчеләр әле ярты юлны гына үткәннәр иде. Менә караңгы да төшә башлады. Чираттагы уйсулыкны чыккач, Шурик ботакка сөртенеп барып төште. Шундук янына Митька килеп җитте:

— Син егылудан курыкма, алга атла. Күп калмады,— диде ул.

Митька зажигалкасын яндырды, папирос кабызды. Ут яктысында Шурик аның тирләгән йөзен, изүе ачык күлмәген, шешенеп киткән күз кабакларын күреп алды.

Елга ярында урнашкан урман өенә җиткәндә Шурик инде аягында көчкә басып тора иде. Бусагага килеп җиткәч тә әле керә алмыйча күпмедер ара ишек яңагына сөялеп торды. Һәм, үзен мәҗбүр итеп, эчкә атлады да былтыргы салам җәелгән сәкегә ауды.

Иртәгесен ул черки талаудан, өйдәге тоташ безелдәүдән уянып китте. Беренче мизгелдә аңа йөзләгән кеше чалгы кайрый төсле тоелды. Менә ул кулларына таянып күтәрелде дә сызлаган буыннарын капшап карады, чалбарыннан чыккан күлмәген рәтләде. Печәнчеләр ничек эләкте шулай таралып яталар, баш асларында ыңгырчактыр, капчыктыр, рюкзактыр. Бригадирны да исәпкә алсаң, ирләр бары тик биш кенә кеше булып чыкты. Калганнары мәктәп балалары икән. Үзе белән генә мәшгуль Шурик аларны юньләп күрмәгән дә. Алар кичә олылар белән беррәттән йөк тә ташыганнар, атларны да тугарышып җиккәннәр — кыскасы, юл газабын бергә күтәргәннәр. Үзенең шундый иркә, йомшак булуыннан Шурик кызарып куйды, сәкедән мыштым гына төште дә ишеккә юнәлде.

Кояш күтәрелеп кенә килә. Урман өстенә алсулык йөгергән, үзәндә томан. Шурик хозурланып торган арада ишек шыгырдады. Аннан ялан-аяклы, йокыдан шешенгән бригадир Силантьич күренде, авызын зур ачып иснәп куйды. Олы гәүдәле, балаларча беркатлы бригадир Шурикка үз итеп елмайды да:

— Йокламасаң, әйдә, Шурик, минем белән кичүгә барыйк. Анда Надюшка Полынина килергә тиеш. Яңгырдан соң елгада су артты, әкызыйның аты бик кире. Берәр хәл булмагае дим. Надюшка безгә аш пешерәчәк.

Ярты сәгатьтән бригадир белән Шурик кичү урынында иделәр инде. Силантьич каршы ярга карап торды да нәрсәнедер ошатмыйча:

— Кызый йоклап калган, ахры,— диде.— Әтәчләр дә уята алмаган үзен. Инде күптән монда булырга тиеш иде. Надюшка-а! — Ул кычкырып җибәрде, тавышы урман өстеннән, елга буйлатып үтте дә кайтаваз булып кире кайтты.

— Ау!... Силантьич! — диделәр теге яктан.

Куаклар артыннан атка атланган Надюшка күренде. Аты чыктан ялык-йолык килә. Бригадир елмаеп куйды, аннан төк баскан ияген сыпырып алды да:

— Күр, Шурка, нинди кызлар китте хәзер, тазалар, чибәрләр, туклар. Ә сугыштан соң без әтиең белән ни күрдек? Мәхәббәт тә ул чакны шинельле иде бит. Их, яңадан бер туып карыйсы иде!

— Силантьич! Мальва суга керергә теләми. Курка! — дип кычкырды теге яктан Надюша.

— Ә син аңа солы каптыр, солы каптыр!

Кызның аты киреләнә, башын боргалый.

— Әйтәм ич солы каптыр дип,— диде Силантьич.

Ак чәчле Надюшканы күзәтеп торган Шурик берни аңламады: каян килсен монда солы? Кулында сумка да, капчык-мазары да күренми.

Кызый атына бер-ике сыдырды, ат шуның кызуы белән каршы ярга чыгып та җитте. Кыз китеп баргач та аның аксыл чәчләре байтак вакыт әле болын өстендә күренеп торды, аннан соң гына томанда эреп югалды. Шурик, матур төш күргәндәй, аның артыннан карап калды.

Иртәнге сәгать алтыларга стан төрле тавышлар, ыгы-зыгы белән тулды. Берәүләр чалгы көйли, кемдер кирәк-яракны кайгырта, укучылар атлар турында бәхәсләшә, үткән җәйне искә төшерәләр иде.

Ашап алгач, Митьканың командасы яңгырады:

— Атлы авиация бүген куак араларыннан чабылган печәнне ташыячак. Ату печән кичкә хәтле юештә ятачак,— диде ул.

Укучылар каударланып тырмаларга ябыштылар. Һәм елганың югары башына таба киттеләр.

— Мить, ул нинди атлы авиация соң? — диде Шурик.

— Ә-ә... — Митька көлгәндәй итте.— Әнә күрәсеңме алдан барган малайны,— ул укучы балалар ягына төртеп күрсәтте,— шул уйлап тапты. Күптән инде. Абыйсы очучы аның, капитан. Ялга кайткач, малайны кулына алган да: «Егорк, син нинди частьтә хезмәт итәргә телисең?» дигән. Ә Егорка күп уйлап тормастан: «Атлы авиация»,— дигән. Шуннан соң телгә керде дә инде. Атларны бик ярата. Күз-колак булмасаң, бригаданың икмәген ашатып бетерәчәк,— диде Митька һәм, сүзне тәмамлавын белдереп, Шурикка чалгы сузды.— Сакла, ул хәзер синеке, тик шуны онытма: кызларны иркәлиләр, чалгыны саклыйлар! Шулай бит, Надь,— диде ул, янәшәдә торган кызыйга хәйләкәр елмаеп.

Кызыйның битенә кызыллык йөгерде, аска карады.

— Белмим, Мить. Мин егет кеше түгел.

— Белмәгәч, син дә кулыңа чалгы ал. Сине алданрак җибәрербез. Төшлекне әзерләп өлгерерсең. Ит яңа суйган, тиз пешәр.

Көн кызу килде. Печәнчеләр куак араларында, чокыр-чакырларда, атлы чапкыч керә алмаган урыннарда чаптылар. Беренче айканудан ук Шурикны сәер халәт биләп алды, гүя ул бу тирәләрне кайчан да булса күргән инде, тик күпмедер вакытка онытып кына торган. Кабат монда килеп чыккач, гүя барысы да исенә төшкән, яңарган, күңелен җилкендереп хәтерендә уянган иде.


Көн дәвамында Шурик берничә тапкыр Надюша белән янәшә туры килде. Кызның очраклы күз карашы егетне оялта, аның чалгысы аксый башлый иде. Шуңа да карамастан, күкрәп үскән бу үләннәрне кызганакызгана чапты да чапты ул. Ял иткән чакларда егет Надюшка янына-

рак килеп утырды, хозурланып елга борылышларын күзәтте, судагы кояш тәңкәләре, үз уйлары кебек тынгысыз иделәр.

Шурик, арып-талып, әле үзенә дә аңлашылып җитмәгән хисләрдән яңарып, станга кайтырга чыкканда күктә беренче йолдызлар калыкты. Болынның чуар матурлыгы эңгер-меңгердә эри бара, үзәнгә таман төшкән, шәфәкъ сүрелеп, елга да йокыга талган иде. «Сәер,— дип уйлады Шурик, тынлыкка колак салып,— нишләп миңа һаман саен бу тирәләр шундый таныш, үземне танып белгәнгә хәтле үк күрелгән шикелле тоела. Әллә чыннан да шушында ничәмә гасырлар яшәгән ата-бабаларымның кан тавышымы бу? Бәлки мондый хисләр чын юлга аяк баскан һәр кешедә уянадыр ул?..»

Бу хакта уйланып кайта-кайта Шурик юлны сизми дә калды. Әстанда бу вакытта арып кайткан печәнчеләргә Надюша аш бүлә иде.

Русчадан **СОЛТАН ШӘМСИ** тәрҗемәсе.



**КамАЗның төп конвейерында**

Н. Курамшин фотосы.

## Ямаш Игәнәй

●

Утлы корыч кебек кызган бу көнне
Сандалына салып заман чүкеде.
Шуннан чәчрәп очкан якты чаткылар
Төнге күккә йолдыз булып сибелде.

Утлы корыч кебек кызган бу хисне
Сандалына салып заман чүкеде.
Шуннан чәчрәп очкан якты чаткылар
Күңелләргә йолдыз булып сибелде...

●

Тирә-ягым дөм караңгы булса да
Кай якка юл тотасымны беләм мин.
Чөнки алдымда җемелдәп, нурланып
Торучы бер якты йолдыз күрәм мин...

●

Күлдә кояш.
Дөньяга сибелде якты.
Җемелдәде болын —
Гөлләр чәчәк атты.
Диде язмыш:
Күр җирең бәхетле чакны!..

●

Койды яңгыр. Күкләр гүя
Үксеп-үксеп түкте яшен.
Күңелдәге болытларны
Парә-парә телде яшен.
...Йөрәгемә үтте яшен,
Үз дигәнен итте яшен...

•

Бераүнең гомерен язмыш
Нәни генә бер нур итте.
Шул хәлендә вакыт аны
Мәңгелеккә алып китте.
Уйлыйм: миллион еллар үтәр,
Нур — билгесез планетага
Барып җитәр.
Андагы сәер затларга
Кайдадыр, бик еракларда
Кайчандыр нурга әйләнгән
Җан яшәвен хәбәр итәр...

•

Сөю килә сиңа беркөн. Йөрәгеңдә
Нәни генә бер гөл гүя чәчәк ата.
Аннары ул — я бәхеткә әверелә,
Я җаныңда утлы ярчык булып ята...

# Мәхмүт Газизов

## Субайлар

*КамАЗ нигезендә — субайлар*

Төзелеш тәҗрибәсеннән

Нигез!..— диделәр
Без кирәк булдык,
эзлә генә, һәрчак бер җай бар;
Без түзәбез, чыдый, күтәрәбез,
шуның өчен дә без — субайлар.
Эстакадаларны күтәрәбез,
торбалары пешерә, су — кайнар;
Җәйге челлә, кышкы суыкларда
чатнап-чатнап китә маңгайлар...
Эш өлгерә. Әллә каян күренә
түбәдәге елтыр калайлар;
без — тирәндә, ялтырамый гына
хезмәт итәбез без, субайлар.
Күр, муеннан балчык, җир эчендә
безнең башлар! — инде күп айлар;
безне күрсә бары күрә алыр
күңел күзе үткен агайлар.
Кемнең даны китми кай тарафка,—
көпчәк тәгәрәр дә тел сайрар;

тик онытма, КамАЗ, антейларың:
күтәрәләр сине субайлар!

●

Җиксенмәгез, читсенмәгез,
хәл белеп киткәләгез;
без ялан кыр уртасында
ак шәһәр күтәрәбез.
Барырга ерак димәгез,
юллар пычрак димәгез,
үзләшерсез, үзегезне
безнең белән тиңләгез...

Кунак итәрбез, уртада
ипи-тоз ризык булыр;
без бер мактанып алырбыз,
сезгә дә кызык булыр...
Сез — килегез, безнең эшне
күз-сүздән үткәрергә,
шәһәр күтәргән халыкның
күңелен күтәрергә.

●

Үстердек без,— үстергәннәр белә! —
аз тидеме канга, җилеккә...
Без үстердек сине, таң шәһәре,
бәхетең булыр дигән өметтә.

Һәр мәйданың таныш, һәрбер йортың —
күз алдында җиткән кыз кебек.
Кыз-улларга яшьтәш каеннарың
безнең ядкарь; әнә — төз, биек.

Язмыш уртак: синең туфрагыңда
урманыбыз безнең, оябыз;
тамыр төрттек монда, бөрегә уздык,
яфракны да монда коярбыз.

...Кайтып киләм. Шаулы урамнарын
язга ачып куйган Чаллыяр —
Ак шәһәрем! Син ул миңа — Париж,
син Неаполь, Сочи... Син — Болгар!

Альберт Сафин

# ХЫЯЛ

хикәя



Шаулы шәһәрләрдән ерак, олы юллардан читтә утырган кечерәк кенә бер авылда түбәсе калай белән ябылган кечкенә генә бер мәктәп булыр. Аның бөтен бүлмәләре дә алтын-сары көзнең моңсу каеннары балкышыннан һәрвакыт якты торыр. Кышларын исә бу каеннар һәрбер иртә, көн өчен туйдагы кәләш сыман актан гына киенеп куярлар. Өсләренә төнлә йолдызларның көмеш тузаны яуган диярсең, җемелдәп торучы куе бәскә төренерләр дә ул каеннар, үз-үзләренә хәйран калып, тын гына утырырлар. Бөтен тирә бу аклыктан әкияти серле булыр. Яшел төскә буялган мәктәп бинасы да ап-ак агачлар арасыннан матур әкият өе сыман күренер.

Аны менә шул мәктәпкә укытырга җибәрерләр. Һәрбер йорты күз күрке булырлык авылның чирәмле урамнары, җиләк-җимеш бакчалары, борылып-борылып аккан суы һәм шаулы урманнары, беренче күрүдә үк аның күңеленә хуш килер, искиткеч гүзәл табигате сокландырыр, гашыйк итәр. Тик шулай да бу авылга килеп төшкән көннәрдә бик ямансу булыр аңа. Үзе укыган педучилищены, шаулы студент елларын сагыныр, иптәшләрен, дусларын юксыныр. Яңа җирдә башта ялгыз, ятим сизәр ул үзен. Авыл кешеләре аңа чит күренерләр.

Күңеле моңланган чакларда ул урманга китеп барыр. Озак итеп аның сукмаклары буйлап йөрер, шавын тыңлар. Монда һәрвакыт җанына җиңел һәм рәхәт булыр. Көзге урман аны аңлыйдыр сыман тоелыр, үзенең авазлары, сагыш тулы матурлыгы һәм шифалы һавасы белән юатырга, ярдәм итәргә телидер кук тоелыр.

Шундый көннәрнең берсендә, уйга батып, урман юлы белән барганда ул һич көтмәгәндә а н ы очратыр. Кызгылт яфраклар түшәлгән юлдан җиңел адымнар белән каршысына килүче кызны ерактан ук күреп алыр ул. Аларның аралары якынайганнан-якынаер, тик ул, һәрвакыттагыча, каушап югалып калыр, кызга сүз әйтү түгел, туры карарга да куркып үз юлын дәвам итәр. Кыз аңа үзе эндәшер:

— Исәнмесез,— дияр ул,— Үзәнле Тау авылынаеракмы икән әле?

— Ерак түгел. Урманнан чыгу белән күрерсез ул авылны...

— Рәхмәт.

Һәм кыз китеп барыр.

Ул таныш түгел кызның матур йөзендә оялчан елмаю кабынуын күреп өлгерер, кызыксыну белән үзенә төбәлгән зур зәңгәр күзләрен хә-

терләп калыр. Көтелмәгән бу очрашудан соң аның күңелен нигәдер сагыш һәм шул ук вакытта якты да, шатлыклы да дулкынлану биләп алыр. Әлегәчә ят авыл, аның кырлары, юллары кинәт бик тә якын, үз булып күренә башлар. Моңсу урман да әллә нидән үзгәреп, яктырып киткәндәй булыр. Ул туктап калыр һәм, күңелендәге хисләрнең асылын аңларга теләгәндәй, китеп баручы кызга озак итеп карап торыр. Кыз да артына борылыр. Аларның күз карашлары очрашыр...

Аннары ул көне буена зәңгәр күзле кызны уйлар. Икенче көнне мәктәпкә барганда да, укытучылар бүлмәсендә үзенең беренче дәресенә әзерләнеп утырганда да уенда шул кыз булыр. Аның кем икәнен белү теләге егеткә тынгы бирмәс. Таныш түгел кызны яңадан күрәсе килер, сагыныр. Шул вакытта ишек ачылып китәр һәм бүлмәгә китаплар күтәреп зәңгәр күзле кыз үзе килеп керер. Алар күпмедер мизгел бербереннән күзләрен ала алмый торырлар. Әмма шушы кыска гына мизгелдә дә ике йөрәк арасында салават күперенең беренче кыюсыз нурлары сызылырга өлгерер.

Алар бер-берсенә гашыйк булырлар. Соңыннан, берничә ай узгач, шушы очраклы очрашуны бүләк иткән өчен язмышына мең мәртәбәләр рәхмәт укыр ул. «Башка мәктәпкә җибәргән булсалар...», дип әллә ничә тапкырлар куркып уйлап куяр.

Соңыннан, берничә ай узгач...

— Төне нинди? Керәсе дә килми,— дип пышылдады кыз.

— Синең өчен генә килгән төн бу,— диде ул да, пышылдап кына.

— Безнең өчен генә...

— Җаным...

Тып-тын. Шылт иткән аваз да юк. Зәңгәр көртләргә күмелеп утырган җылы өйләрдә күптән инде утлар сүнгән. Ап-ак томан эчендәге ул өйләр билгесезлеккә китеп баручы корабларны искә төшерәләр. Мәктәп янындагы каеннар да ак хыялга төренгәннәр. Ә томан куерганнан куера һәм тын гына агыла.

Бу гаҗәеп төн эчендә алар икәү генә булырлар. Бер-берсенә сыенган хәлдә, агылучы томанга карап торырлар, үзләренең дә ак томаннар белән бергә ниндидер серле илгә — мәңгелек язга, яктыга китеп баруларын тоярлар...

Хыял, хыял! Синдә генә яшәп булса икән...

*
* *

Шаулы шәһәрләрдән ерак, олы юллардан читтә утырган кечерәк кенә бер авылда түбәсе калай белән ябылган кечкенә генә бер мәктәп бар. Һәр ике ел саен яңартып, тышкы ягын яшелгә, ә түбә каласен кызылга буяп торганга күрә, мәктәп бинасының тузган булуы әллә ни күзгә бәрелеп тормый. Әмма ул, чынында, шактый ук таушалган инде инде. Кышкы суык көннәрдә моның шулай булуы үзен аеруча нык сиздереп куя. Искесе урынына яңа бина салырга күптән җыенып йөриләр. Тик авыл балалары әлегә һаман шушы мәктәптә укый. Аның сигез классын тәгәлләп чыкканнар күрше авылның урта мәктәбенә йөри. Анысын да тәмамлагач, алар шаулы шәһәрләргә китеп баралар.

Ул, педучилищены бетергәннән соң, менә шушы мәктәптә өч ел тыныч кына эшләде дә, көннәрнең берендә, яңа уку елы башланыр алдыннан гына моннан китәргә карар кылды.

Хыялый һәм басынкы холыклы егетнең кинәт мондый фикергә килүенә гади генә бер вакыйга сәбәп булды.

Район үзәгендә август конференциясе барган көннәр иде. Җыелышларда бик нык арып йончыган укытучыбыз бераз саф һавада йөреп, ял

итеп кайтырга ниятләде. Урамнарда уйланып шактый гына йөри торгач, үзе дә сизмәстән, тимер юл вокзалына килеп чыкты.

Перронда поезд тора иде. Ул яңа гына килеп туктаган булырга охшый, вокзал яны гөр килә. Китәргә җыенганнар, чемоданнарын күтәреп, вагоннарга таба ашыгалар, ишекләр янында торучы ишләре белән кушылалар. Кайтып җиткәннәр исә, перронга төшү белән, кыр казлары кебек тезелешеп, тиз-тиз автобус тукталышына юнәләләр. Һәммәсе ашыга, һәммәсе дә каядыр омтыла. Бер тарафта кемнәрдер саубуллаша, икенче тарафта исәнләшәләр-көлешәләр. Вагоннарның берсеннән «Червоны гитары» ансамбле җырлары яңгырый.

Чуар киемле кешеләрнең ыгы-зыгы килеп йөрүе, бәйрәм һәм саубуллашу вакытларында гына була торган ыгы-зыгы һәм шау-шу, еракъюллар турындагы җыр, каяндыр сизелер-сизелмәс кенә килүче алма исе — бар да яшь укытучыда күңел күтәренкелеге һәм ашкыну хисләре уятты. Аның шушы бәйрәм эченә кереп чумасы, менә бу кешеләр шикелле ашыгасы, алар белән бергә кая булса да еракка-еракка китеп барасы килде. Тик беркая да китәсе юк шул аның. Берәүне көтәсе дә, озатасы да юк. Тормышның бәйрәмнәре аның яныннан поездлар шикелле узып кына китәләр. Ә ул аларга һәрвакытта читтән генә карап тора. Ят бер кеше шикелле. Чынлап та, шушы көнгә кадәр нинди дер чит бер кеше гомере белән яшәде түгелме соң ул? Нидер көтте, күңеле белән һәрвакыт үзенең бәйрәменә, якты һәм шатлыклы бәйрәменә әзерләнде. Ә еллар үтә торалар. Үкенүләр, ялгызлык, эч пошулар һәм яңадан көтү — менә ул елларның хатирәсе. Аның тормышы шундый булырга тиеш идемени? Гүзәл хисләр, гүзәл максатлар белән үтәсе көннәр, дуслар белән гөрләшеп гомер итәсе көннәр, мәхәббәт-бәхеттән исереп Мәҗнүндәй бар дөньяны онытып йөрисе көннәр — кайда алар? Хәзер дә менә, ярымкараңгы перронда басып торасы урында, әнә шул якты вагон эчендә утырасы кеше түгелме соң ул? Офыклар артындагы бәхетле шәһәрләргә китеп баручы поезд тәрәзәләре артындагы тормышны күз алдына китереп хыялга бирелү — шулкадәр таныш хис ич аның өчен.

Егет, кинәт сискәнеп, хыялларыннан айнып китте. Соңгы вагонның ишегендә көлешә-көлешә бер төркем кызлар басып тора иде. Кыска итәкле җәйге күлмәк кигән төз аяклы, сылу гәүдәле кыз аңа таба карап иптәшләренә нидер әйтте дә тегеләре гөр килеп көлешеп алдылар.

— Чибәр егет, киттек безнең белән! Бәхетеңнән колак кагасың килмәсә, киттек! — дип кычкырды шук тавыш белән әлеге кыз һәм бик кинешле генә итеп аңа елмайды.

Егет шунда бүген чалбарын үтүкләми киюен исенә төшерде, гаҗәпләнеп, җавап сүзе таба алмый казык шикелле басып торуның чынлап та көлке икәнен аңлады, тик урыныннан кузгалып китә алмады.

Поезд, үзен сырып алган озатучылардан тизрәк арынырга теләгәндәй, кисәк кенә тартылып куйды да, салмак кына шуышып алга үрмәләде. Вагон ишегендә басып торучы кызлар егет белән тигезләштеләр. Ул әлеге шаян кызның бик тә чибәр булуын күреп калды. Кыз елмаймый иде инде.

— Моңаерга кирәкми, егет! — дип кычкырды ул һәм үз итеп аңа кул болгады.

Поезд, әлеге сылу кыз белән яшь укытучыны аерып, кичке караңгылыкка кереп югалды. Бушаган перрон кырында ай нурларында ялтырап салкын рельслар гына сузылып калды.

Егет рельсларга текәлеп шактый басып торды. Күз алдына ни сәбәптәндер, үзе яшәгән квартира хуҗасы — гомерен ялгызлыкта үткәргән карчыкның: «Ходайга шөкер, бүген дә кич җитте»,— дия-дия, ялан аяклары белән идәнгә авыр басып, утны сүндерергә баруы килеп басты. Ул көлемсерәп куйды: «Китәргә кирәк ул авылдан»,— дип уйлады һәм нинди дер үкенеч белән яңадан зәңгәр күзле кызны исенә төшерде.

Зәңгәр күзле кыз яшь укытучының иң кадерле хыялы һәм беркемгә сөйләми торган сере иде. Ул аны педучилищены тәмамлаган җәйне туган авылында ял итеп ятканда — үзенең киләчәк тормышын күз алдына китереп йөргән вакытта уйлап чыгарды. Дөресрәге, зәңгәр күзле кыз аның күңеленә һич көтмәгәндә, үзеннән-үзе килеп керде. Керде дә бүтән чыкмады. Тора-бара егет әлеге кызның дөньяда булуына һәм аның белән һичшиксез очрашачагына ышанып йөри башлады. Тик ул эшкә килгән мәктәптә зәңгәр күзле кыз юк иде. Укытучыларның һәммәсе дә олы яшькә җиткән абруйлы кешеләр. Дөрес, пионервожатый булып бер кыз эшли эшләвен. Әмма ул да инде утыздан узып киткән иде. Авылның бармак белән генә санарлык кызлары арасыннан да күңеленә охшаганы булмады. Шулай итеп, бу авылда зәңгәр күзле кыз юк иде. Ләкин егет аны оныта алмады. Ялгызлыктан яисә эч пошудан газапланган вакытларында ул һәрвакыт хыял дөньясына чума, анда һәрвакыт зәңгәр күзле кыз белән очраша иде.

— Төне нинди? Керәсе дә килми.

— Синең өчен генә килгән төн бу.

— Безнең өчен генә...

Андый вакытларда күңелендә моң булып сөю һәм сөелү теләге, кемдер өчен җан атып йөрү, газаплану, ихлас шатлану, яну теләге уяна иде.

Өч ел вакыт узды, тик зәңгәр күзле кыз килмәде бу авылга. Ул аны беркайда да очратмады, күрмәде һәм мәхәббәт турындагы яшерен өмете акрын гына сүнә башлады.

...Һәм менә, ниһаять, ул китеп бара.

Борчылулар, икеләнүләр, хәтта, үкенечләр белән тулы көннәр. Эштән китү белән бәйле мәшәкатьләр артта калды. Башта «җибәрмим!» дип аяк терәп карышкан директор үзенең бигүк хаклы түгеллеген аңлады бугай, берничә тапкыр үгетләп тә карады. Тик егет сүзендә нык торгач, бераз гына булса сабыр итүен үтенде.

— Урыныңа кеше тапканчы эшләп тор,— диде.

Көтә торгач, РОНОдан яңа укытучы җибәрергә вәгъдә иттеләр. Директор егетнең гаризасына кул куйды. Ул район үзәгенә барып эшләрен бетерде, документларын алып кайтты. Кичә киемнәрен, китапларын бер чемоданга тутырды һәм... менә ул китеп бара. Җаны ияләшкән һәм инде кадерле була башлаган җирләрдән соңгы тапкыр атлый. Олы юлга да күп калмады. Хәзер, менә шушы тар гына урманны чыгасы да бераз үр төшәсе. Ә анда, олы юлда, машиналар очып кына тора. Шуларның берсенә утырыр да район үзәгенә китеп барыр һәм бүтән беркайчан да килмәс ул бу авылга. Түбәсе калай белән ябылган мәктәбен дә бүтән күрмәс ул. Тик бу кечкенә мәктәпне оныта да алмастыр, мөгаен. Беренче тапкыр бусагасын атлап кергән көн, мөстәкыйль беренче дәрес, беренче дулкынланулар, сөенүләр — истән чыга мени алар. Кем белә, бәлки сагыныр да әле ул бу авылны. Аның шук һәм сөйкемле балаларын, олы җанлы, ярдәмчел кешеләрен, менә шушы иркен кырларын, урманнарын, юлларын сагыныр. Нихәл итмәк кирәк, гомер китабының менә тагын бер бите ябылды. Бүген уникедәге поезд аны калага алып китәр. Аннары...

Шәһәр аны күктәге йолдызлардай сибелгән бихисап утлары һәм кичке җырлары белән каршылар да, үзенең чоңгыл шикелле кайнап торган тормышына суырып алыр. Бу тормыш татлы булыр аның өчен, шатлыклы, якты булыр. Шул шәһәрдә хыяллары чынга әверелер. Быел ул институтның әзерлек бүлегенә керер, студент булыр. Кеше тормышында студент елларыннан да бәхетле чор бармы соң? Әнә шундый бәхетле көннәренең берсендә ул, һичшиксез, Аны очратыр.

Кызыл яфраклар түшәлгән юлдан җиңел адымнар белән каршысына килүче кызны ерактан ук күреп алды ул. Сары куртка кигән бу кыз

аңа урманның сагыш тулы матурлыгы эченнән килеп чыкты сыман тоелды. Аларның аралары якынайганнан-якынайды, тик егет, әллә нидән югалып, каушап калды, кызга сүз әйтү түгел, туры карарга да куркып, үз юлын дәвам итмәкче иде. Кыз аңа үзе эндәште:

— Исәнмесез,— диде ул,— Үзәнле Тау авылы еракмы икән, әйтмәссезме?

— Ерак түгел. Урманны чыгу белән күрерсез ул авылны.

— Рәхмәт.

Һәм кыз китеп барды.

Ул таныш түгел кызның сөйкемле йөзендә оялчан елмаю кабынуын күреп өлгерде, кызыксыну белән үзенә төбәлгән зур зәңгәр күзләрен хәтерләп калды. Уртача буйлы, ябык гәүдәле кыз әллә ни чибәр түгел иде, әмма аның күзләре эчке нур белән тулы иделәр, бу нур зәңгәр күзләрнең карашын кабатланмас назлы, ә кызның йөзен искиткеч мөлаем итә иде. Егет зәңгәр күзле кызны беренче тапкыр күрсә дә, аның йөз сызыклары, елмаюы, күз карашы, хәтта тавышы бик тә таныш, үз һәм кадерле булып тоелды.

Бу көтелмәгән очрашудан соң аның күңелен нигәдер сагыш һәм шул ук вакытта якты да, шатлыклы да дулкынлану биләп алды.

«Кем бу? Кайда гына күргәнем бар соң минем бу кызны?»

Егет, гаҗәпләнеп туктап калды һәм китеп баручы кызга озак итеп карап торды. Юл чатына җитәрәк, кыз да артына борылды. Аларның күз карашлары очрашты... Әмма егет үзе киткән мәктәпкә кайтып баручы хыялын танымады.

## Рафис Сәлимҗанов

# КИЧКЕ АВАЗ

Парчалар

*
* *

Җиргә эңгер-меңгер төшеп килгәндә бер шау ишетелде. Таныш тавыш ул. Таныш аваз. Аңа барысы да сыйган: үткән көннәр, киләчәк гомерләр, уйлар һәм язмышлар — бөтен җиһан.

Яңгыр тавышы иде ул.

Төне буе яуды, икенче көнне дә туктамады яңгыр. Кич җитте. Көн буе колактан китмәгән шушы гөжелдәү төнлә йокларга яткач та, караңгылык эчендә бер көчәеп, бер әкренәеп, һаман ишетелә иде әле. Иртә белән — тагын...

Яңгыр ява да ява. Томанлы пәрдә артыннан меңләгән хатирәләр, әллә кайчан онытылган вакыйгалар күтәрелә башлый.

Үземдә дә нindидер гөрелте артканнан-арта бара кебек. Чү! Тавышлар көчәя... Җир тетри... Су... Давыл... Янар таулар...

*
* *

Гаҗәп ил — күпме барсаң да, һаман чиксезлеккә алып чыга торган фикрият иле. Аның болыннары буйлап кайчак шул кадәрле ераклыкларга барып җитәсең — яшәү дә, үлем дә, монда килә алмыйча, үз чикләрендә туктап кала. Мәңгелекнең бер кисәге булып, йолдызлардан төшкән балкыш эчендә теләгәнчә йөзәсең дә йөзәсең.

Гаҗәп ил — фикрият иле.

*
* *

Мин дөнья турында уйлыйм икән, димәк, үзем турында уйлыйм. Мин үзем турында сөйлим икән, димәк, дөнья турында сөйлим.

Син нинди булсаң, дөнья да шулайдыр ул. Бала булсаң, ул сиңа балаларча карый, карт булсаң — картларча йөзен чыта. Шат булганда — ул да шат, моңсу булганда — ул да моңсу. Һәм күпме күзәтсәң дә, уйнаганга — уенлы ул, җырлаганга — җырлы, гашыйкларга — гыйшыклы; яшәгәндә яшьни торган, син юкка чыкканда синең белән юкка да чыга торган хикмәтле дөньядыр бу.

Мин уртада хәрәкәтсез торам, тик дөнья гына хәрәкәттә кебек. Кешелекнең иң сәер алдануларының берсенә охшаган бу: мең еллар буена Җир тирәли Кояш һәм йолдызлар әйләнеп йөри дип саналган. Чынында — киресенчә икән.

*
* *

Мин учак ягып, аңа карап утырырга яратам.

Утта кешене җәлеп итә, аны үзенә тарта торган бер төрле магик көч бар. Аңа карыйсың да, чыбык-чабык «йотып», ашыкмыйча «сөйләшә-сөйләшә» янган учак белән синең яшәвең арасында ниндидер уртаклыклар эзли башлыйсың. Учак янында ялгызлык та сизелми. Янәшәңдә тагын бер җан иясе — ут бар.

Кеше уттан яралган дип, борынгылар, бәлки, юкка әйтмәгәннәрдер. Мин дә — учак. Миңа да, башка тереклек ияләренә дә кояштан «ут элгән».

Учакны болгатып куясың һәм төнге күккә күз төшереп аласың. «Әнә — күктә дә миллиардлаган учаклар дөрли,— диясең эчеңнән.— Галәм янудан тора. Бөтен яшәешнең янудан торуы бер дә гаҗәп түгел».

Ут янмый, ә нидер сөйли сыман. Учакка карагач, күзаллау колачы үзгәрә: бәләкәй генә әйберләр дә чиксез зураеп күренә. Ут эчендә уйнаган көчле гарасатлар, бураннар, кешеләр, хәтта ниндидер вакыйгалар да шәйләнә кебек. Учак фантастик китап битләрен бер-бер артлы ача тора. Ут эчендә вакыйгалар кайный. Йөзләгән, меңләгән кешеләр... Кемнәрдер йөри, болгана, кемнәрдер туктап калган... Аларның битендә кызыл шәүлә булып ялкын уйный. Кешеләр янып кара ноктага әверелләр һәм берәм-берәм юкка чыгалар.

Учак яна.

Мин дә янам.

*
* *

Төн яркапатлары канат җәю белән Көн кануннары күздән гаип була. Адәм баласы Көннең ак китабын куеп, әүвәлге заманнардан ук

язылып килгән шомлы, мажаралы Төн китабын ала. Андагы һәр сурәт, һәр рәсем — канда яши.

Кеше күңелендәге караңгылыкка дару бармы дөньяда? Явызлык, мәкер, ялганны, угрыларны тыя торган көч кая ул?

Төн барысын да эшли. Әмма Көн барысын да ача, фаш итә. Тик ифрат якты һәм кырыс булырга тиеш Көн кануннары — жиде Төн уртасына ярып кереп, адәм баласының тирә-ягын яп-якты итәргә тиеш.

*
* *

Хәтеремдә: бик бәләкәй чакта мине бер уй борчый иде. Дөньяда «Мин» мин генә микән, әллә бүтәннәр дә үзләрен «Мин» дип йөртә микән?

Бүтәннәрнең сөйләшүенә колак салдым. Кем генә булмасын— «Мин» икән. «Мин»нәр бик күп икән.

Кеше дигәнең, күрәсең, гомер буе моның шулай икәнен тулысы белән аңлап бетерә алмыйча азаплана торгандыр. Югыйсә, ничек итеп бүтән кешегә үзеңә теләмәгәнне теләргә мөмкин?

*
* *

Яхшылык, яманлык...

Адәм баласы чишә алмаган иң борынгы табышмактыр ул.

Чишелеш исә авыр түгел сыман: сиңа эшләргә ярамаганны, бүтәнгә эшләмә. Кул белән дә эшләмә, тел белән дә эшләмә, кыяфәт белән дә эшләмә, кием белән дә эшләмә.

Үз-үзенә начарлык эшләгән кеше юк...

*
* *

Алма чәчәгеннән өзелеп төшкән ак күңел... дим мин. Нинди җилләргә очып, нинди зилзиләләрдә бөтерелеп, нинди эсселәрдә көеп уңдың соң син? Тик сүнгән саен нурың яктырак сыман. Әнә, барыр юлга сөттәй ак нур төшкән. Еш кына мин синең шәүләңне еракта күргән кук булам. Шул якка карап барам.

Бар иде бит җиһанда алма чәчәгеннән өзелеп төшкәндәй ак күңел, дим мин. Бар иде бит...

*
* *

Бирәүдән дә көнләшергә ярамый — мизгелләр искәртә торсын. Мизгел тиз үтә. Гомер озын.

Һәркемнең иңендә шактый авыр йөк. Кеше үз язмышын, борынгы батыр Атлант күк гөмбәзен күтәргән сыман, күтәреп тора. Бу йөк кая гына барсаң да, дөя өркәче шикелле, үзеңнән калмый. Син яшәгән шалашларга да, син яшәгән алтын сарайларга да ияреп керә. Алтын сарайларда да шатлык белән кайгы төн артыннан туган шикелле берсе артыннан берсе килә тора. Анда да күк гөмбәзе иңнәрдә утыра. Тик... Андый вакытта сизелми генә ул. Күк җимерелгәндә генә аның бөтен авырлыгы искә төшә.

Мизгелләр әйтә торсын...

*
* *

Каян килеп кая барасың, кеше?!

Адашканга бер генә юл бар — кире кайту. Үткәннәреңә, үскән җиреңә, туган бишегеңә кире кайту.

Туган йортың янында үскән йөз яшьлек тополь сине сагынып һаман яшь коя...

Абынуың тиз, яңадан аякка басуы гына авыр. Егылганыңны да белми яшәвең бар.

Адашырга җиңел, юл табарга авыр. Адашканда да дөрес юлдан барам дип уйлавың бар.

Каян килеп кая барасың, кеше? Адашканга бер генә юл — кире кайтып үзеңнең каян килгәнеңне искә төшерү...

*
* *

Көчленең көчен күргәч, көтмәгәндә кимчелекле ягын да күреп, аптырашка кала торган идем. Ул — көчнең дәвамы икән.

Көчсезнең йомшаклыгын белгәч, сизмәгән җирдән куәтен, дәһшәтен күреп исем китә иде. Бу — көчсезлекнең дәвамы икән.

Кимчелексез шәхесне күпме эзләсәм дә, таба алмадым. Чынлап та, тимер кимчелеге — йомшак булмауда, мамык кимчелеге — каты булмауда түгелме соң?

Тормыш үзе исә бер катылык сораса, бер нечкәлек сорый. Анда бер салмаклык кирәк булса, бер кызулык кирәк, әле акыл, әле наз кирәк. Ә кеше атлы үсемлек, җирнең тарту көчен җиңгәндә фәкать бер якка гына каерылып үсәргә ярата.

*
* *

Яңгыр ява, ә мин тәрәзәдән тышка карыйм. Тәрәзә рамындагы бер тамчы бик кечкенә иде — зурайды, түгәрәкләнде. Аннары, җиргә төшеп, челпәрәмә килде. Бар иде тамчы, юк инде тамчы... Әгәр ул тамчы — син булсаң?

Гөлгә бер көнлек чәчәгенең таҗлары да мәңге коелмас кебек тоеладыр. Кеше дә дөньяга мәңге яшәргә дип килә. Шулай яши.

Искәрмәстән җиргә тама...

*
* *

Тагын кич.

Кичке шәфәкъ! Син дә сүнәргә итәсең, дим мин. Күңелдә уйнаган мең гөслә чыңы астында кояш офыктан иңеп бара.

Көн саен дөньяны ике тапкыр ялкын чорный. Иртә һәм кич. Шушы ике шәфәкъ кызуында мин үземнең яшәвемне бөтен көчем белән сизәм.

Иртә һәм кич. Исәнме белән сау бул. Исәнмесез — үтәсе юллар. Сау булыгыз — үтелгәннәре!

Тормышның бөтен гүзәллеге — аның белән күрешкәндә. Бөтен матурлыгы — аның белән аерылышканда.

Кеше шәфәкъләр кызуында яши.

*
* *

Моңы белән, шатлыгы белән тере бу кеше!

Чиксезлеккә, мәңге яшәүгә тәне белән ирешә алмый кеше, ә моңы белән, шатлыгы белән — үзенең җырында, биюендә, сәнгатендә — ирешә. Тойгылар акылга караганда борынгырак бит. Шуннан киләдер бу.

Ерак галәмнәр! Яктылык тизлегенең дә еллары белән исәпләнә торган хикмәти ара! Минем өчен мәңгегә калырлык бер генә чынбарлык яши шушы мәлдә. Минем күккә карап моңсу елмаюым. Инде мин мәңгелек турында уйламыйм. Мин мәңгелектә.

Моңы белән, шатлыгы белән бөек бу кеше!

*
* *

Әнә — тагын...

Тагын мин кичке эңгердә бер шау ишеттем. Исем китеп шул авазны тыңлыйм. Таныш аваз ул. Аңа барысы да сыйган.

Әкрен генә, уйчан гына, ниндидер бик тирән мәгънәле серләр сөйләгәндәй яңгыр ява.

## Мансур Сафин

# ЧАЛЛЫ ЭТЮДЛАРЫ

### Гөмбәле урын

Юк, сез ул вакытларны һич кенә дә хәтерләмисездер, берсеннән-берсе биек бу йортлар урыны ул чакта искиткеч шәп гөмбәлек иде. Ул йөнтәс гөмбәләр дисеңме, майлы гөмбәләрме, ак гөмбәләрме — барысы да бар иде, ә хәзер алар урынында йортлар, йортлар, йортлар. Алар, бер-берсе белән янәшә басып, иртәнге нур эченә күмелгәннәр. Тәрәзәләр таң балкышы белән ямьләнеп җемелдиләр. Шул вакыт мин аларны элек биредә үскән гөмбәләргә охшаткандай булдым, күңелем шатлыклы хисләргә күмелде. Алар да, әйтерсең, җирдән үсеп чыкканнар. Күккә ашкан биек түбәләре иртәнге ямь эчендә тирә-якка ап-ак нур таратып, яңа көнне, яңа заманны бетмәс-төкәнмәс хозурлыкка күмеп балкыйлар.

### Әтәч тавышы

Без яңа квартирага кич төнгә авышкан чакта гына күченеп килдек. Олаудан кечкенә семьябызның тегенди-мондый әйберләрен тиз генә бушаттык та дүртенче катка менгердек. Әлбәттә, лифт белән түгел, әле ул эшләми. Йортның бер подъездында гына кешеләрнең күченү тантанасы гөрли, ә икенче башында төзелеш дәвам итә.

Иртән мин кояшның ягымлы нурларыннан иркәләнеп уяндым. Ул нурлар пәрдәләр куелырга өлгермәгән тәрәзә аша үтеп кергәннәр иде.

Уянсам да торырга ашыкмыйм, чөнки бүген — якшәмбе. Шул вакыт гадәттән тыш матур итеп әтәч кычкырган тавыш ишетелде. Каян килде соң әле бу аһәңле аваз? Әллә колагыма ишетелгәндәй генә булдымы соң? Алай түгел икән, әтәч тавышы тагын кабатланды. Шул вакыт мин яткан урынымнан сикереп тордым да тәрәзәгә барып капландым. Каршымда Боровецкое авылы пәйда булды. Шул чакта мин үземнең туган авылымны хәтергә төшердем. Күз алдымнан аның ниләре беләндер жанга якын агач йортлары, коелары, чишмәләре, күлләре, аларда йөзеп йөргән каз-үрдәкләре чагылып узды.

...Юк, онытылмас бу авыл. Аның урыны бульдозерлар, машиналар белән тигезләп калдырылмас. Бирердәге авыл безнең күңелләрдә мәңгемәңге сакланып калыр. Ул бит шәһәргә әверелә, йөрәкләребезгә өр-яңа гүзәллек булып үтеп керә. Күрәсең, әтәч безгә әнә шул хәбәрне житкергән.

## Нарат урманында таң ата

Минем тәрәзәм нарат урманына карап тора. Ул урман кырыеннан кечкенә генә Шильнә елгасы агып уза. Кулымдагы китабымны карават өстенә куеп, әнә шул тәрәзә аша дөньяны күзәтәм. Аннан миңа зәпзәңгәр күк йөзе һәм офыклар ап-ачык булып күренә. Хәзер табигатьнең яшәреп ямь-яшел төскә кергән вакыты. Зәңгәр күк тә, яшел киңлекләр дә җәйге иртәнең алтынсыман нурларында өртелгәннәр.

Мин бу күренешне ничәнче кат инде Шишкинның «Нарат урманында таң ата» дигән билгеле картинасындагы күренешкә тиңләп күзәтәм. Әмма бирердә Шишкин ясаган аю балалары юк. Ә алары кайда икән? Күңелдә ул матур җәнлекләр якында гына яшеренеп яталардыр дигән хис уяна. Менә-менә алар хәзер үк килеп чыгарлар да елга ярындагы агачларга ябышып бер-берсе белән шаяра-шаяра уйный башларлар кебек тоела.

## Кояш хәзинәсе

Көзге озын кичләрдә Пришвин хикәяләрен укырга яратам. Бигрәк тә «Кояш хәзинәсе» ошый. Төнге сменадан арып-талып кайтканда күңелем яңа хисләр белән тула. Аяк астымда үләннәр кыштырдый, өстемә аккаеннар үзләренең алтын-сары төскә кергән яфракларын коялар. Күңелемә күзгә күренми торган нур җепләре урала, җаным дөньяның бетмәс-төкәнмәс гүзәллеген тоеп дулкынлана.

Шул чакта әнә шундый алтын утлар балкышын үзем эшләгән шаушулы металл кою заводы цехларына охшаткандай булам. Әйтерсең, минем бөтен тирә-ягым ниндидер тылсымлы гүзәллек белән күмелә. Күңелем яңадан өр-яңа иртәнең сихри матурлыгы белән сугарыла.

Кояш хәзинәсе! Ул бит бирердә генә түгел, ул металлның алтын укләры чәчкән нурларга уралып балкучы безнең цехта да, шул нурлар белән балкучы дусларымның шатлыклы йөзләрендә дә ачык чагыла.

## Беренче сентябрь чәчәкләре

Безнең шәһәрдә яңа мәктәп ачу гадәти бер хәлгә әверелде. Минем үземә дә бу бәйрәмнәрдә күп катнашырга туры килде. Әмма иң соңгысы аеруча хәтергә сеңеп калды. Бу вакыйга Сидоровка поселогында, дүртенче мәктәптә булды. Беренче сентябрь көне иде. Мәктәп ишегалды

чәчәкләр белән тулы. Ул чәчәкләр диңгезне хәтерләтәләр. Күз алдымда гөлбакча диярсең. Аның гөлләре — укучылар, ә бакчачылары — укытучылар. Яхшы аңлыйм, бакчачыларга бала күңелендә иң яхшы, иң кыйммәтле фикерләр, иң садә гөлчәчәкләр үстерергә туры киләчәк. Моның өчен аларга киң фигыльле, зур җанлы, зирәк акыллы бакчачы булырга туры киләчәк.

Мәктәпкә килүчеләр арасында игътибарны аеруча беренче класска аяк басучылар җәлеп итә. Сизәм, алар безнең какшамас нигезле ҚамАЗ туфрагына тамыр җәеп күтәреләчәкләр.

Музыкантлар чәчәкләргә гимн уйный. Кояш нурында Кызыл флаг ялкынланып җилферди. Һәм һәркемгә тансык кыңгырау авазы яңгырый. Мәктәп белем киңлекләренә яңа сәяхәтен башлый.

## Орловка артериясе

Биредә әле бернечә ел гына элек зур авыл җәйрәп ята иде. Ә хәзер ул кечерәйгәннән-кечерәя бара, иске йортлар көн аралаш бер-бер артлы юкка чыгалар. Әйтерсең, көзге яфраклар кебек, заман җиленнән коела торалар. Әмма бу өйләрнең урыны буш калмый. Орловка җире бушлыкка әверелми, ул үзенең йөзен заман таләбенчә үзгәртә, бизи генә. Әнә анда бернечә ай гына элек тузанга баткан, тәбәнәк, төсен югалткан, күңелсез, шыксыз йортлар бөкрәеп утыра иде. Ә хәзер күр, анда автомагистраль күтәрелә. Ерактан караганда ул киеренке хезмәттән бүртеп чыккан кан тамырын искә төшерә. Әйе, ул чыннан да киң тормыш белән сугарылган артерия, Чаллының хезмәт кайнап торган организмына көч бирүче артерия.

Биредәге йортлар сүтеп алынганнар, әмма бакчалар һәм коелар калган, күзгә ташланып торалар. Тиздән монда да биек йортлар калкыр, Орловка шәһәрнең гүзәл бер өлешенә әверелер, ул да ҚамАЗ артериясенә яңадан-яңа куәт, көч өстәр.

## Җырчы дамба

Мин бу проспект турында — җир өстеннән алты метр биеклектә җәяүлеләр генә йөриячәк проспект турында беренче тапкыр Чаллы ягын өйрәнү музеенда белдем. Әлеге кызыклы хәлдән соң күңелем гел әнә шул гаҗәеп проспектны күрергә ашкынды.

Ниһаять, мин булачак Түбән Кама диңгезе ярында торам. Бөтен җирдә бушлык, тик ара-тирә кечкенә нарат агачлары очраштыргалый һәм иркәле җил генә исеп куя. Әмма тиздән, монда да төзелеш киң колач алыр, хезмәт симфониясе өстенлек итә башлар.

Краннарның катлаулы, шул ук вакытта гади эшләрен күзәтәм, төзелеш музыкасын тыңлыйм һәм күңелемне «Биектәге проспект» — «Җырчы дамба» җилкендерә. «Җырчы дамба» — шагыйрь Евгений Евтушенконың моннан күп еллар элек язган поэмасының исеме дә шулай иде бит. Бәлки ул бу хакта шул вакытта ук белгәндер. Әйе, безнең ышанычларны җырлаучы, хезмәт горурлыгын музыка итүче дамба ул, күтәрелсен, хәере белән күтәрелсен, хезмәт халкын биектән, югарыдан йөртсен ул.

## Инна Лимонова

●

Дөнья ярып и кычкырды әтәч! —
Чыгып бастым чыклы болдырга:
Сәламләргә кирәк яңа таңны
Һәм кояшны каршы алырга...

Алсуланып янып көн кабына
Офыкларда, ерак-еракта,
Таудан төшкән ак томаннар гүя
Эреп юкка чыга... Таң ата...

Уяначак хәзер тымызык күл...
Якты дулкын тибрәп уйнаклар,
Шыбырдашыр җем-җем чыклар коеп
Таң җилендә яшел куаклар.

Кычкыр, әтәч! Бар дөньяга кычкыр!
Таң сәламен дөнья ишетсен —
Уят җирне, уят — йокламасын! —
Бу мәлеңдә шагыйрь кебек син...

**ЗӨЛФӘТ** тәрҗемәсе

## Евгений Кувайцев

### Дәү әнием хатирәсе

Ерак еллар яңарып
Уза хәтер түреннән.
Кайткан гүя терелеп
Дәү әнием гүреннән.

...Назландым күпме тапкыр
Эңгер төшкәч, кич булып,
Тулган ай яктысында
Мин, алдыңа утырып.

Тоям әле хәзер дә
Кулларыңның җылысын.
Сөйлисең күк син һаман
Айлы кичләр тылсымын.

Авыл тын. Кешнәп куя
Болында атлар гына.
Өй алдында җай гына
Гәп кора картлар гына.

Парлылар җитәкләшеп
Килә чишмә янына.
Чишмәдә йөзеп йөри
Ак чабактай ай гына.

...Дәү әнием карый күк
Ерак еллар түреннән.
Күптән иңгән кабере,
Үлән баскан, күмелгән.

Нинди гаҗәп: барсы да
Кабатлана яңадан.
Айлы кичләр тылсымын
Улыма мин аңлатам.

Улым тыңлый хикәят,
Эңгер төшкәч кич булып,
Тулган ай яктысында
Тез өстемә утырып.

**ГОСМАН САДӘ** тәрҗемәсе

## Юрий Малков

●

Кояш батты, кошлар йоклый инде,
Ә мин һаман янам утларда,—
Кешелеккә төбәп әйткән сүзем
Ирек бирми миңа йокларга.

Сүз артында яткан чынбарлыкның
Хикмәтләрен телим эзләргә.
Хакыйкатьнең үзе булып шулчак
Дөнья тула минем күзләргә.

Таң алдыннан сүнә якты йолдыз,—
Нуры кала җиргә коелып:
Буразнада нәни орлык шыта
Нурларында шуның коенып.

Мәңгелеккә мин сакларга телим
Җиргә төшкән йолдыз яктысын.
Сүзләрем дә тормыш киңлегендә
Тулган орлык булып яктырсын...

**РАШАТ НИЗАМИЕВ** тәрҗемәсе

## Николай Алешков

●

Уяналсам тагын яратылып,
тыныч кына, җылы кочакта,
тәрәзәдән чаган-яшел болыт
бер үрелсен иде шул чакта.

Авылымда өйнең кыегы да
белә миңа ниләр кирәген,
кошлар булып очып чыгар аннан
үткәннәрдә калган серләрем.

Исертте дә мине, чәчәк койды
бал исләре килгән юкәләр.
Өр-яңадан туар көнемдер бу,
онытылыр бөтен үпкәләр.

Чакырмасын кичке күләгәләр
аерылырга туган җиремнән,
мин оныткан хатирәләрне дә
саклаган ул вакыт җиленнән...

Көтәсеңме мине, туган йортым?
Синдә калган бала чагым бар —
Айның төсе бәлки бакчаларда
август элгән алсу алмалар?..

**ХӘЙДӘР** тәрҗемәсе

## Рина Асылбаева

●

Бер ак болыт күгемнән
Китми дә китми —
Җиргә дә таммый, аны
Җилләр дә тетми.

Серләре бар шикелле
Нурлана һаман.
Төнлә шулай шатлыклы
Төш күрә сыман.

Әй, ак болыт, ак болыт,
Сереңне белдем!
Куеныңнан кояш чыккач,
Үзең дә көлдең.

**РӘШИТ ӘХМӘТҖАНОВ** тәрҗемәсе

## Павел Юлаев

### Юатучы

Ачы җилләр арасында,
Безнең кибет каршында
Яши нәзек билле каен,
Күрә каен барсын да.

Ир-атларның кайберләре,
Таралганчы өйләргә,
Сарылалар ак каенга,
Аһ-зарларын сөйләргә.

Елыйлар кочып каенны:
— Хәлебезгә кер! — диләр,
Һәм бер очтан хатыннарын,
Аракыны тиргиләр.

Аекларны да... кемне дә
Юатып була ла ул,
Ләкин кая китсен үзе?
Кая китә ала ул?!

Ялгыз... ятим... Кешеләрнең
Көтә бер җылы сүзен:
Хәлләрең ничек, каенкай?
Боекмыйсыңмы үзең?

**РОБЕРТ МИҢНУЛЛИН** тәрҗемәсе

## Михаил Федосенко

### Җил тегермәне

Юл тузанын йоткан елларның ул...
Инде менә калган адашып:
Кара төндә гаҗизлеккә төшкән,
Белә алмыйча кая барасын.

Дөнья сулый, хәрәкәттә җиһан.
Камадагы акчарлаклар күк,
Төнге җилләр иске тегермәнгә
Дәшеп уза, хәтер яңартып.

Төн карасы эреп юкка чыга,
Җир өстенә якты таң тугач;
Бер ташыдай иске тегермәннең
Нурлар тарта күктә ал кояш...

Шул тегермән канатларымыни!—
Җиргә тими инде очам мин;
Хыял җиле тарта еракларга,
Чакырмагыз — кире төшәлмим...

**ХАРРАС ӘЮПОВ** тәрҗемәсе

## Лев Воздвиженский

●

Сагынып былтыргы җәйнең
Таудан узган давылын —
Үзәнлектә — йоклый да күк,
Йокламый да авылым.

Зәңгәр күле — мәңгелеге,
Кирәкми китәр юллар...
Юалар тал тәпиләрен
Йокымсыраган сулар.

**РӘШИТ ӘХМӘТҖАНОВ** тәрҗемәсе

# «КАМА ТАҢНАРЫ» ӘДӘБИ БЕРЛӘШМӘСЕ (ТҮБӘН КАМА)

## Мөхәммәт Шәйхи

### Кичерешле уй

Киттем. Тәкәббер тауларның
Иңенә басыйм әле,
Болытлардан түшәк җәеп
Бер ауныйм, шашыйм әле.
Килдем. Мин, дала егете,
Биеклек күргәнмени,
Киңлекләргә хәйран булдым
Ямь-яшел үргә менеп.
Мендем. Исәрләнгән башым
Күкләргә тиеп тора,
Кайсыбызны сайлыйсың дип,
Йолдызлар биеп тора.
...Җаным өшер биеклектән
Үзәнемә ашыгам.
Даладагы яшел үрем
Йөгереп килә каршыма...
Тауга да сабырлык кирәк
Биеклеккә түзәргә.
...Горур ташлар томырылып
Тәкәлгән үзәннәргә.

### Тугрылык

*Туган җирдә кышлаучы кошлар уе*

Кемгә җиле ошамады,
Кемгә кары, бураны.
Киттеләр... Без яшәп калдык
Җил-давылга уралып,

Төпләндек, безгә башкача
Ярамый да, булмый да:
Туган җирдә ел әйләнә
Кышлар булып тормый ла!..

Кышларга түзәргә була,
Тәндә җан булган чакта.
Тик, килер язлар хакына
Җанны өшетми сакла!

## Сагынулы уй

Чыгып китте...
Моңга тулган җаны
Таш урамга әллә сыймады.
Шәһәр читендәге әрәмәдә
Төне буе гармун уйнады.

Сызды гармун... Офыкларга җитеп
Әремнәрне тарап җил чапты —
Җил ерактан килгән... Авазында
Ишетелмәгән яңа моң тапты.

Моңнар кайтавазы өзгәләнде,
Бетон диварларга бәрелеп.
Аннан ятты сузылып дымсу җиргә,
Алларына тансык әремнең.

Җанны баскан сагышларны өереп
Кузгалдылар хисләр давылы...
Синнән киткәннәр дә синдә яши,
Үпкәләмә, зинһар, авылым.

Син булмасаң җирдә, күңелләргә
Каян килсен безнең бу моңнар?
Шәһәрнең дә төшләренә кереп,
Йокыларын бүлә авыллар.

## Төшкә кергән уй

Ул якларга хатлар йөрми, әти,
Кайтмас өчен китә кешеләр...
Соңгы вакытларда минә бик еш
Син керәсең минем төшемә.
Әллә нинди сәер төшләрем дә,
Саташумы чиксез-чамасыз? —
Акбүз атта чабып, безнең якка
Күз дә салмый үтеп барасың.
Аваз салам, никтер эндәшмисең,
Бездә синең нинди үпкәң бар?
Аңламыйбыз мәллә,
Шулай бездән
Йөз чөерә бәлки киткәннәр?!
Үткәннәрне тузан-туфрак күмә,
Телләр сүнә, бакча-ил яна,
Ата белән бала аңлашыр сүз
Бетеп бара мәллә дөньяда?!
Китми булмас җирдән. Бер китәрбез,
Вакыт дәшеп алыр үзенә.
Калганнарны уятырбыз микән,
Төшләренә кереп без менә?!

## Мизхәт Хәбибуллин

### Табындым

Булды ул... Айкалып күгемнән
Тик кара болытлар актылар.
Шул чакта күзләрем күктәге
Иң якты сызыкка бактылар.

Булды ул... Кылып бер тантана,
Ялганны әйттеләр дөрес дип.
Шунда да мин синең җиңүгә
Ышаныч җуймадым, Дөреслек.

Булды ул... Очрады күп җирләр,
Бер күргәч күңелең кайтырлык.
Анда да мин сине эзләдем,
Тик сиңа табындым, Матурлык.

## Альбина Мортазина

### Язгы төннәр

Язгы төннәр, язгы төннәр —
Кемгә кыска, кемгә озын.
Талның йомшак песиләре
Тыңлый микән яз сулышын?

Язгы төннәр, язгы төннәр —
Кемгә бәхет, кемгә сагыш.
Кызыгып пар шәүләләргә,
Авыр сулап йөри язмыш.

Язгы төннәр, назлы төннәр —
Кемгә айлы, кемгә болыт...
Җилләр миңа пышылдыйлар:
«Вакыт инде, оныт, оныт!»

## Кави Зиннәт

### Синең туйда

Кояшың була алмадым,
Аем, диярсең әле.
Җете зәңгәр күлмәгеңне
Тагын киярсең әле.

Ак күлмәгең дә килешә,
Карасаң, күпме сафлык!
Уйларым һаман чуала,
Җанымны талкый хаклык.

Япа-ялгыз түгелмен лә,
Хыялым — уем тиңе.
Кояшың була алмадым...
Ай гына булмыйм инде!

## Рифкат Имаев

### Ут кирәк

Төн эченә төбәп күзләремне
Ут чаткысы эзлим: ут кирәк.
Бер мизгелдә булган яктылыктан
Кабынырга әзер бу йөрәк.

Ник уйнамый яшен, кайда болыт,
Тәрәзәдә нигә ут сүнгән?
Коткарыгыз, җилләр, бер очкынны
Учак өстен япкан шул көлдән.

Ник атылмый икән тик бер йолдыз?
Ут чаткысы эзлим: ут кирәк.
...Бер чаткысы тисен карашыңның,
Ут булачак минем бу йөрәк.

## Раил Рахман

### Авылда

Әйләнәм дә кайтам. Күрше карчык
Күреп калып урам чатыннан,
«Бәрәкалла, күз тимәсен» диеп,
Карап кала минем артымнан.

Мин — хыялый, җилфер-җилфер килеп,
Чабуымны ачып буранга,
Канатларын җәйгән кошка охшап
Очып киләм ап-ак урамнан.

Шул мизгелдә шаян бөтерчектәй,
Хатирәләр уйнап ярсына,—
Колакчыны күзләренә төшкән,
Малай чагым чаба каршыма...

# Рахмай Хисмәтуллин

# СУСАУ

**хикәя**

*Журналист дустым үтенечем*



Бу шәһәр урамнары буйлап, дөнья куудан тәмам арып, көннәремнең әчпошыргыч бертөрлелегеннән гарык булып, боегып, ничәмә-ничә тапкырлар үтелгән иде инде. Ямьле итеп дөнья күтәргә нәрсәм житми соң? — дип сорый идем мин үз-үземнән. Бөтен нәрсәм дә житү кебек: квартирам да әйбәт, эшем дә, хәтта гаиләм дә... Нигә соң минем бу шәһәргә беренче килгән чакларымдагы кебек рәхәтләнеп көлгәнем дә, дуслар белән күңел ачып утырганым да юк? Нәрсәмне югалттым мин? Дусларымнымы? Яшьлек хыялларымнымы?..

Мин инде хорафатларга да ышана башлаган идем бугай. Әллә инде минем күңел салкынлыгыннан — миңа ничә ел жәйләрнең дә рәтле килгәне булмады: я тоташ салкын яңгырлар яуды, я бөтен дөньяны эссе көйдерде. Табигать гүя минем белән бергә авырый иде. Урманнарга, кырларга, болыннарга чыксам, кошлар тавышын ишетә алмадым, яшь чагында жыеп йөргән чәчәкләр патшасы — мәхәббәт гөлләрен дә очрата алмадым. Болар барысы да күңелемдәге изге үй теләкләрне сүндерә барганым өчен, яшьлек антларыбызга хыянәт иткәнем өчен жәзадыр, дип уйлый-уйлый газапларда яна-көя идем...

Тормышымдагы миңа бу көтелмәгән борылыш тәэсирендә ахры, үзем дә сизмәстән, бу шәһәргә беренче тапкыр килеп яши башлаган тулай торак янына барып чыкканмын... Тәрәзәләрдән дәртле жырлар, шат көлүләр, гармун, гитара тавышлары һаман шулай түгелә икән бит.

Минем дә бар иде бит тулай торакта яшәгән иркен чакларым. Ун ел гомерем шунда үтсә дә, әле һаман да туйдырмаган икән ул. Әйтеп бетергесез хыялый, кызык фикерле яшьләрнең романтика тулы шаушулары миңа бүген бик-бик кадерле булып тоелды. Һәм мине әллә нинди үкенечле сагыну биләп алды. Күпме тыңласам да, тыңлап туймас кебек моңсуланып, йорт каршындагы эскәмиягә барып утырдым. Миңа хәзер... Без яшәгән бүлмә балконының ишеге ачылыр да... аннан ак күлмәкле егет күренер. Миңа ул елмаеп килеп чыгар да ерактан ук:

— Нихәлләрегез бар? Барыгыз да бәхетлеме? — дип шарран ярып исәнләшер сыман...

Ә нигә, бәлки мин моңарчы бик озакка сузылган төш кенә күргәнмендер дә, бүген генә, әле хәзер генә уянганмындыр. Балконда басып торган ак күлмәкле егеткә мин хыялым аша эндәшәм. Ерак та ул миңа, якын да... Ишетә дә ул мине, ишетми дә...

...Шушы тулай торакта кайчандыр без аның белән бергә яшәгән идек. Ә беренче мәртәбә... моннан егерме ел элек нефть шәһәрләренең берсендә танышкан идек.

Бервакыт мин утырган редакция бүлмәсенә, туптай тәгәрәп, әле солдат формасын да салырга өлгермәгән яшь бер егет килеп керде. Керде дә:

— Шаулап үсеп килүче нефть якларының беренче номерлы романтигы Әсгать Тимершин! — дип елмаеп таныштырды ул үзе белән. Бер

урында гына басып тора алмыйча, бүлмәне яшәү рухы бөркеп торган дәртле сүзләр, тынгысыз кул һәм гәүдә хәрәкәтләре белән тутырды. Яшь чагым булса да, миңа нәкъ аңардагы терелек, җанлылык җитешеп бетми иде. Башка көннәрне дә ул:

— Һей, нишләп бүлмәдә күксеп ятасыз. Әйдәгез, мин сезне нефть промыселларына алып чыгам. Анда нинди гаҗәп кешеләр эшләвен күреп берәр нәрсә язарсыз. Әйдәгез, әйдә, «бобик» капка төбендә! — дияр-дия безне объектларга алып чыгып китә иде.

Күп тә үтмәде, без күптәнге танышлар, хәтта туганнар сыман, бик тиз дуслашып та киттек. Без икәү бергә булганда әллә нинди диңгезләрне кичә алырбыз, әллә нинди тауларны күчерә алырбыз сыман иде.

Редакциягә беренче килгән көнне үк мәкалә алып килгән иде ул. Гап-гади нәрсәләр турында да, башкаларга охшатмыйча, газета стандартларыннан читкә чыгып, рухланып язган иде.

Бастырып та чыгардык. Әмма Әсгать халык арасында йөргән «газетага шыттырыбрак язсаң да бата ул», дигән сүзләргә ышанган булган, күрәсең, мәкаләсендә фактларны бераз исбат итеп булмый торганча күпертебрәк җибәргән булып чыкты. Алай ярамаганлыгын раслап, шунда ук мәкаләсенә шикаять тә килеп керде. Тикшермичә, авторга ышанып бастырганым өчен, (ул фактлар дөрес иде, ләкин без исбатлый гына алмый идек) мине җыелышка куеп бик каты пешерделәр һәм шелтә дә чәпәделәр. Аңа ышануыма бик каты үкендем. Әмма ни гаҗәп! Шуңа да карамастан, әллә нишләп Әсгатьне үз итү хисләрем әз генә дә сүрелмәде. Киресенчә, бу хәл безне тагын да якынайтып җибәрде шикелле.

— Әсгать, кара әле, малай,— дидем мин аңа,— синең бит ашкынуың түгелеп тора, яз син, яз! Тик менә фактлар белән генә саграк бул, яме.

Ул үзенең әдәбият дөньясына омтылуын да сиздерде. Ашкынуына, хыялларына, ялкынына караганда бу эштә ул берәр нәрсәгә ирешергә тиеш иде.

...Һәм без аның белән дистәләгән бүлекләрдән торган план-йөкләмә төзеп, шуңа икебез дә кул куеп, үтәргә антлар итештек. «Эчмәскә, тартмаска, Сервантестан һәм Шекспирдан алып бүгенге дөнья һәм совет классикасына хәтле йөзләрчә том әдәби китаплар укып чыгарга, туган телне ныклап өйрәнергә, өйләнгәндә бер-беребез белән киңәшеп өйләнергә» дигән кебегрәк пунктлар да бар иде анда.

Көтмәгәндә ул «муеннан» гашыйк булды һәм рөхсәтсез-нисез өйләнеп тә ташлады. Әмма хатыны Рәсимә Әсгать хыялланган кеше булып чыкмады. Ул егетнең романтик канатларын әкренләп кенә йолыккаларга кереште. Күбрәк акча эшләвен, тизрәк квартира алуын, эштән соң төп-төгәл сәгате-минуты белән өйгә кайтуын таләп итте. Бу Әсгать өчен, әлбәттә, үзе теләп алган әсирлек иде.

Озак та үтмәде, аларның мәхәббәт чәчәкләрен кырау сукты. Хатыны белән аерылышкан көнне ул, икенче тапкыр безнең антны бозып, бик каты эчкән иде. Әсгатьнең йөрәк авыруы кузгалды. Аны больницага салдылар. Мин аның янына бардым. Әмма кая ди ул элеккечә кайнарланып сөйләшүләр?! Без бер-беребездән әллә ничек сәер ерагайган идек.

Тормыш дулкыннары безнең икебезне ике якка ташлады. Мин Казанга күченеп киттем. Ә ул каядыр башка җиргә бугай. Гомумән, антны бозганнан соң минем аңа карата күңелем сүрелеп, җанда әчкелтем бер юшкын утырып калды...

Еллар, үзенекен итеп, ул юшкыннарны юдылар, ахры. Ничектер, без бер-беребезне юксынып яшәгәнбез икән. Мин моны дүрт ел чамасы күрешми торганнан соң, ниһаять, нәкъ менә шушы яңа шәһәр төзелешләрендә кабат очрашкач аңладым.

Бирегә менә хат язып ул үзе чакырып китерде. Әсгать рөхсәтеннән башка (һәм кая инде ул ата-ана хәер-фатихасын алулар?!) өйләнгән хатыным Тәзбирә белән икәүләп аның фатирына килеп төштек.

Шул көнне үк ул минем өйләнүгә мөнәсәбәтен дә белдерде.

— Син дә антны бозып өйләндең. Ахыры ничек булыр икән соң, Фәрһад, ә? — диде ул уйчанланып.— Төкле аягы белән булса, бик әйбәт. Син моны якты киңлекләргә алып чыгарга тырыш инде.

Ул вакытта әле минем яңа гына өйләнгән чагым иде. Бу сүзләренең нинди бәя торганын аңламыйча көлеп кенә куйдым. Ә бит аның бу сүзләре генә түгел, бөтен гомере минем өчен гыйбрәт-сабак булырлык иде.

Аның гомере... Аны сөйләмичә мин берни дә аңлата алмамдыр, ахры.

Лаеш шулпаларын шактый чөмердек, инде акыл утырттык диеп уйласак та, без әле Әсгать белән һаман да бик әз генә кырау тиеп үткән романтиклар булып калган идек.

Ул резин итекләре белән төзелеш мәйданнарында байтак ләм ярырга өлгергән иде инде. Теге вакыттагы мавыгуларыбыз да бушка китмәгән, каләмен дә чарлаган. Шигырьләре дә басылып чыккалаган. Ул инде редакциянең сотрудникы булып эшли иде.

Әсгать үзгәргән дә, үзгәрмәгән дә кебек. Мин аны аңлап бетерә алмыйча күп уйлана идем. Икебезнең дә күзләребез яшел, буйларыбыз бер ише тәбәнәк булса да, кыяфәтләребез Тукташ белән Мокамай кебек шактый аерыла иде. Бөтенләй үк кара, кысык күзле булмасам да, мин монгол тибындагы түгәрәк табак битле, базык гәүдәле, тырпак чәчле идем. Ә аның чәче аксыл сарырак, йөзе Европа кешеләренеке сыман озынчарак, гәүдәсе чандыр. Әйтерсең лә без икебез ике раса кешеләре.

Хатыным Казаннан бөтенләйгә күченеп килгәнче, шушы тулай торакта икәүдән-икәү калып, айлы төннәр буе нилэр турында гына чөкердәшми идек без. Зур төзелешне алып баруның бердәнбер дөрес юлын гүя без генә беләбез, без генә бик күп мәсьәләләрне гадел хәл итә алабыз. Шуңа күрә зур-зур абзыйлар да төзелеш һәм шәһәр тормышы мәсьәләләрен безне чакырып, безнең белән хәл итәргә тиешле шикелле тоела иде безгә. Гомумән, безнең фикердән башка яңа шәһәрнең матур яшәве мөмкин түгел шикелле иде. Әлегә дөньяның безгә артык исе китмәвенә гайре вакытлы күренеш, аңлашылмаучылык диеп кенә карый идек. Һәм шәһәр житәкчеләренең безнең кебек гаҗәеп кешеләрне монарчы күрми йөрүләренә үпкәли дә идек бугай әле...

Әйе, мең төрле каршылыклар аша үсеп килгән яшь шәһәрнең әллә нинди серләрен, әйтерсең лә, без икебез генә белә идек. Кемнәр генә юк иде бу шәһәрдә: берәүләре турыдан-туры халык байлыгына кул сала, икенчеләре гел төшемле урын гына эзли, өченчеләренең дә, эшчеләр хакын кысып, премияләрне үзләренә умырырга куллары кызыша...

— Уйлап кара, Фәрһад, ничек шундый хапуга булырга мөмкин?! Ничек шулай байлык өчен генә яшәргә мөмкин бу матур дөньяда?! Язан әле шул хакта, язам! — дип кабынып китә иде ул. Аның ярсуы яман юлда йөрүчеләрнең барысын да утлы дулкын булып күмеп ташлар сыман иде.— Юк, мин беркайчан да идеалымны шарманкага алыштырмаячакмын!

Шундый сигналларның берсе буенча мәкалә язарга рөхсәт сорап, ул редакторы янына кергән.

— Бер заводтан төзелеш материалларын читкә озаталар, акча үзләштерәләр. Бу мине бик борчый. Сигнал дөрес. Каракларны кайнар табага бастырып бер материал эшләргә рөхсәт итсәгез иде.

— Соң әле өстән күрсәтмә булмады бит. Торып тор, аннары...

— Юк, ничек инде? Без бит журналистлар, үзебез инициатива күрсәтергә тиеш ләбаса. Бу бит инициативаны...

— Булдыра алырсың микән соң? Син бит артык кайнар. Дөресен генә әйткәндә, тәҗрибәң җитенкерәми,— дип редактор аны кире борган.

Мин мәкаләләр күтәреп дубляж газетага еш килгәли идем. Редакторның гаҗәеп оригиналь тип икәнлеге күземә чалынмый калмады. Тудырса да тудыра икән табигать: Әсгать белән алар бөтенләй капма-каршы кешеләр иде.

Әсгать тормыш буйлап шат көлүнең үзе булып, шаулап тәгәрәп барырга яратса, редактор Вафичның беркайчан да көлгәнен хәтерләмиләр иде. Әсгатьнең йөзеннән ниндидер бер эчке нур сибелсә, Вафичныкы тәмәке сарысыннан саргаеп беткән сыман төссез, үзгәрешсез, рухсыз була, чәчләре дә яңгырда чыланган түбә саламын хәтерләтә иде.

Кайчагында аның кул астында эшләүче кайбер журналистларның сүзләренә кушылып, фикерләрен хупларга әзер булуымны сиздерсәм, яшьләр бигрәк тә ярсыйлар иде.

— Инде күпмеләрнең ваклык белән җанын ашап, хурлык белән эштән кудырды. Ә шуны һаман постында тоталар. Эх!..

— Ул бит имән күсәк, ул бит иҗатны кысучы, буучы,— дип кызып китә иде икенче «яшь даһи».

Алар шулай редакторның үзе югында теләсә ничек аның тетмәсен тетәләр, яныйлар, ләкин минә үзе алдында, Әсгатьтән башкалары, берсе дә әз генә дә каршы сүз әйтә, әз генә дә чеметә алмый иде.

Вафич бик төгәл һәм бер яктан да тотып алырга җай бирми торган бик шома кеше иде. Эчү-фәлән белән дә, дус-ишләр белән дә чуалмады. Постыннан да явыз ният белән файдаланды дип әйтеп булмас иде. Ул, алдан борып куелган механизм кебек, иртәгә, берсекөнгә, хәтта ун ел буена ни ашыйсын да белә, бер сәгатьтән түгел, бер ел, ике елдан соң ни эшләргә тиешлеген дә, хәтта кайчан үләргә тиешлеген дә белеп яши иде сыман.

Ә Әсгать андый педантлыкны бар дип тә белмәде. Дөньяны аркылыга-буйга кичкән биш-алты ел буе тормыш күчәрен сандалда үзе таптаган кадровый эшче егетнең күңеленә гүя җир шарының бөтен тулай торfaклары сыйган иде. Өч йөзләп кеше яшәгән торакның яртысыннан артыгы аның дуслары иде бугай. Ул кемнәр белән генә ерактан кычкырып килеп елмаеп күрешмәс иде дә, кемнәр генә аннан папирос алып, бер рәхәтләнеп гәпләшеп тартмас иде.

Гомумән, аның дөнья байлыгына исе китми, соңгы сыныгын да теләсә кем белән урталай бүлешә, ә инде хезмәт хакы алган чакларында аның бүлмәсендә күпләрнең дә төшенә керми торган бәйрәм: анда оста баянчылар көй суза, җыр яңгырый, матур кызлар турында күңелле хикәятләрнең иге-чиге юк. Алга йөгереп әйтим: квартира алгач, өй туена чакырды. Өстәл юк, урындык юк, ашъяулык юк, савыт-саба җитешми. Ә юклыктан читенсенүнең ни икәнен дә белмәгән Әсгатьнең авызы колакка җиткән:

— Әллә мәңгегә килгәнме бу дөньяга?! Министрларыңнан да болайрак итеп бер утырыйк әле, дуслар, ә?! Нәрсә ул хрустальләр — чүп, дөньяда рухың бәйле булмасын,— дия-дия, байларча кыланып, идәнгә газеталар җәеп чыкты. Кунакларны утырта-утырта һәм рюмкалар урынына банкалар, кырлы стаканнар тезә-тезә:

— Иң шәп чәркә бөек керәшен Кәлигә!— диеп, алдына пластмасс чәчәк вазасы китереп куйды.— Мәңгелек тостымны әйтергә рөхсәт итегез, дуслар,— диде.— Кадерлеләрем, минә шушы якты дөньяда яшәвең, сезнең белән бергә көлергә, җырларга мөмкин булуы минем өчен үзе тиңсез бәхет.

Ул көнне уен-көлке, шат сүзләр һич тынып тормады.

Кәлинең бик нык күңеле булган чагында гына әйтә торган сүзе бар иде. Һәм ул, ниһаять, кичә ахырында шуны әйтми булдыра алмады:

— Бу бит на грани фантазии, Әсгать!

Соңгы елларда Әсгатьнең шактый кызыклы әйберләр язганын мин белми идем. Ул инде иҗат серләрен минем белән бүлешми иде. «Ник язмыйсың, язарга кирәк сиңа!» — дип мин аны бик каты боргычлый идем. Шул чакларда әллә аның, әллә минем гаебем белән, арадан салкын җилләр искәли иде. Ул минем тәнкыйтьне аеруча күтәрә алмый иде. «Син — диктатор», дия иде миңа. Шулай дисә дә, мин аңа бөтен җаным-тәнем белән омтыла идем. Ул да икенче очрашуга хәтле күңелендә кер сакламый, урамның кайсы гына чатында очратсаң да, калын иреннәрен мул җәеп, тагын рәхәтләнеп елмаеп күрешә. Бары тик аның белән сөйләшкәндә генә рухым көндәлек ыбыр-чыбырыннан арынып, өскәрәк, биеккәрәк күтәрелә, күңелем иркен бер зәңгәр диңгез өстенә чыккан акчарлак шикелле очына, материаль бәйлелекләрдән котыла, яшәешнең фәлсәфи диңгезләрен айкап тибрәнә, иң көчле, иң дәртле, иң илаһи яшьлек вакытларым кире әйләнеп кайткандай була иде.

...Беренче романтик учак урыннарына биек-биек йортлар калка торды. Ул учаклар кимегән саен, кешеләр үзгәрә бардылар. Төзелешнең тәүге романтикларыннан берсе — Убаренко, эшчеләрнең баракларда, будкаларда яшәп ятуларын күрә торып, ире белән икесенә биш бүлмәле квартира алып, бозау чаклы эт асрый башлады. Менә шунда инде яңа шәһәрдә башкачарак, иркенрәк, биегрәк рухта яшәргә дип хыялланып килгәннәр рәнҗеделәр. Тормыш монда да тормыш булып калырга тиеш булды. Кемнәргәдер ияреп килгән көнләшү, бер-береннән арттырып баерга тырышу микробларына каршы торырлык вакциналар монда да җитәрлек булып чыкмады.

...Ул вакциналарны үз гаиләмә хәтта мин дә таба алмаганмын икән...

Һәм, ниһаять, беренче көннәрнең асыл романтикасы, кызыл китапка кертелгән сирәк очрый торган җанвар сыман, гүя Әсгать бүлмәсендә, гүя бары тик аның йөрәгендә генә сакланып калган да менә хәзер ул аны тарлавыкка куалап кертүчеләрдән харап иттермәү өчен, җаен белмичә, җан-фәрманга тартыша иде.

Тормыш кырыслыгы шуны да күпсенде. Әсгать сакларга тырышкан беренче учак истәлекләрен азмы-күпме сагынып яшәүчеләр, үзләре үк шул учаклы яшьлекләренең кумиры итәрлек егеткә нинди таш аткаларын да чамаламыйча, аның кемнәрдер алдында баш имичә горур яшәргә тырышуын тормышка җиңел караш диделәр, бар тапканын дуслары белән бүлешүен (кызы-ык!) дөнья рәтен белмәү дип гаепләп сөйләделәр. Бу шәһәрдә беренче төнне кем куышында уздырганын онытып, минем сөекле Тәзбирәм дә рәхәтләнеп шуларга кушылгалый иде.

Менә бер заман төрлечә материал табып дачалар төзү, төрле дәрәҗәдә, төрле күләмдә, төрле юллар белән байлык бүлешүләр китте. Низаглары редакциягә төрле сигналлар булып ява башлады. Ә икенче яктан барыбер тазара барырга тиешле тормышның көчле саф дулкыны бәрә иде. Бу хәлләр Вафичны җитмешкә төрләнергә мәҗбүр итә иде.

Әсгать, хатлар бүлеге мөдире буларак, ул низаглы сигналларны намуслы рәвештә җентекләп тикшерә, җеп очын таба, эшне ахырына кадәр җиткерә, җәзасын бирдертә иде. Әмма аның күңелен вакыт-вакыт бик боектыра торган бер читен як бар иде. Вафич аның тәнкыйть мәкаләсенең стиленә, грамматик хаталарына бәйләнә, материалларын бракка чыгара башлады. Көймәгә су керде.

...Еллар тавына менә-менә үткәннәргә борылып карыйм. Үзәкләр өзелеп китә. Эх, сез, Бакыр Маңгай дия-дия каләмнәр сындырган Әсгатьнең дуслары, кайларда сез хәзер?! Сез үзегез дә сынаттыгыз түгел-

ме соң? Тормышның кырыс таләбе булып, уңай һәм кире зарядларны туплап, яшенле бушануларны үзе аша бары тик гадел итеп кенә уздырырга тиешле редактор белән ник сез бер генә мәртәбә булса да каләмкылычларыгызны кынныннан чыгарып сөйләшә алмадыгыз? Һәрберегез үзегезне әчтән генә мин Тургенев, мин Толстой, мин Чеховлар дип хис иткән сабырсыз иҗатчылар, кайда соң сезнең бөек әсәрләрегез? Нишләп берегезнең дә исемнәре бүгенге иҗат мәйданнарында күзгә чалынмый? Әдәби әсәр түгел, ялкынлы мәкаләне дә салкын йөрәк белән генә язып булмый.

Газета ашкынулы холыкларны үзенә сыйдыра, туплый торган иң кызыклы урын, тормышны матурайту өчен дөньяның күбрәк уңай яклары калку итеп күрсәтергә, кешеләрне шул яхшылыкка ияртергә тырышучы иң гадел урын буларак, нәкъ менә Әсгатьнең характерына бик нык туры килгәнен сез барыгыз да яхшы белә идегез. Редакция оешкан чакта кешеләр житешмәгәндә эшкә алынган Әсгатьнең сезнең ярдәмгә бик мохтажлыгын да аңлый идегез. Ник ярдәм итмәдегез?

Ә мин үзем ник ярдәм итмәдем?

Батырып эшләп китә алмавын Әсгать үзе дә сизенә, борчыла, иптәшләре каршында җиңелеп калуны, эштән чыгарылуны ул иң авыр хурлыкка саный иде. Шулай булуына карамастан, ул утның уртасына ташланды.

Шул ук заводтан, урлашуны фаш итүне үтенеп, бу юлы инде коллектив жалоба килә. Әсгать хатны күтәреп редакторга керә. Ут белән су йөзгә-йөз бәрелешә.

— Менә эшчеләр таләп итәләр, бу эшне нәкъ менә без тикшереп газетада фаш итәргә тиешбез.

— Безнең моннан мөһимрәк эшләребез дә күп, — ди редактор.

Әсгать җир шары өслегенең күпчелек өлеше судан торганлыгын онытып җибәрә.

— Мин моны югарыга язачакмын!

— Юк, югарыга язып маташма, энем. Лучше син үз теләгең белән эштән китү турында гариза гына язып керт! — ди Вафич...

Мин инде ул чагында аерым квартирада яши идем... Әсгать белән очрашулар сирәгәйгән иде.

Белми дә, сизми дә калдык, икенче көнне үк Вафич аны эштән чыгарган иде. Сизми дигән булам... Сизде-ек. Ләкин дәшмәдек. Ә бит эшләр яңадан бөтенләй башка якка борылып китте. Соңыннан гына аһ-уһ килешкән булдык.

Еллар тавыннан ул якларга борылып карaганда нигә соң мин аны шулай сагынам, нигә мин аны шулай юксынам дип, сәбәпләрен ачыкларга тырышып, ул чаклардагы көндәлекләремне дә актарып утырганым булды.

Без фәрештәләр булмаганбыз... Дөресрәге, мин фәрештә булмаганмын...

Әйе, башта без дуслыкны гел мөкиббән татулыктан гына, бер-беренә гел яхшылыктан гына торадыр дип уйлый идек. Ә ул алай булып чыкмады. Хәзер башымны селкеп хәйран калып утырам. Әйе, дуслык та, хәтта дуслык та нәкъ мәхәббәт сыман ук, үзара көрәштән тора икән. Ә шулай да кара якларның берсе дә күңелдә уелып калмаган. Әсгать хыялымда я гел кояшлы салават күперендә басып тора, я нурлы чәчәкле аланнарда йөри, я карурман буйлап җырлап уза, көлә, шаяра. Ни өчен алай? Шат күңелле булгангамы?

Ак халатлы яшь, чибәр кибетче кызлар янына ул шар ярып, кулы белән үбү ишарәсе ясап, килеп керер иде дә:

— Карама, сандугач, үлчәвеңнең угына, миңа кара. Миңа кара да өстә алмаюыңны, теләсә нинди җитмәгәнне, гөнаһларны басар,— дип җибәрер иде. Хәзер ул кызларга бик күңелсездер инде...

Майны мул салып, теленне йотарлык тәмле итеп бәрәңге кыздырыр иде дә, бөтен күрше-тирә бүлмәләрдәге егетләрне чакырып, табынына утыртыр иде. Уен-көлке сибелер иде. Бервакыт кемдер:

— Әсгать, син нишләп квартира алмыйсың? Сиңа бирәләр инде аны,— диде. Әсгать, авызын зур ачып, күңелне кытыклый торган итеп сөйләп китте.

— Һи-и, егетләр, ни пычагыма кирәк ул ялгыз кешегә квартира. Шулай, малайлар, мин бервакыт Себердә яшәгәндә квартира алган идем. Шулкадәр күңелсез булды ялгызыма яшәве, чыдый алмыйча бик каты эчә башладым бит. Бер тапкыр айныткычка барып эләктем. Карыйм, малай, минем квартирага караганда айныткычта күңелле. Шуннан таптым җаен, аз гына салган булам да, барып кагам айныткыч ишеген: Әй, дуслар, дим, кертегез әле, дим, ялгызыма өйдә күңелсез дим. Ачалар, кертәләр. Мин үземнең теге таныш ятагымны эзләп табам, соң айныткыч хуҗалары белән дуслашып беттек инде, әйдә, әйдә, түрдән уз дип кенә каршы алалар, әйе, эзләп табам да анда әбизәтелне, нишләптер чит кеше яткан булыр иде, мин аны өстерәп төшерәм, айныткыч хуҗалары чөнки үзебезнеке, төшерәм дә менеп ятам. Менә ичмаса күңелле! Катыда дуслар белән рәхәтләнеп йоклап китә идем.

Малайлар ышанырга да, ышанмаска да белмичә, тыңлап утыралар иде дә, Әсгать шар ярып көлеп җибәргәч кенә, чыдый алмыйча, эчләрен тотып көләләр иде.

Ул әллә нинди иде?! Бервакыт без аның белән автовокзал аша базарга үтеп барабыз.

— Слушай, әллә кая китә минем акча. Зарплатага хәтле ике-өч көн буе дуслардан алып тора башладым. Менә соңгы биш тәңкә барые әле. Әйдә әле бер чүәк алып киик,— ди.

Шулчак автовокзал киоскысы төбендә бер апаның елап торганын күреп алды бу.

— Ни булды, апа? Ник елыйсың? — диде Әсгать, үз анасына дәшкәндәй хәленә кереп.

— Менә әйберләремне урлаттым, балалар. Акчаларым да шунда иде. Хәзер авылга кайтырга автобус та утыртмый. Нишләргә дә белгән юк.

— Мә, апа, елама. Үкенсәң дә, еласаң да үткән эш кире кайтмас,— дип Әсгать теге биш сумны чыгарып аңа сузды.

— Ә ничек кайтарырмын, балам? Кем буласың соң син? Безнең авыл кешесенә охшамагансың бит.

— Ал, апа, ал! — дип Әсгать акчасын ирексезләп апаның алдына куеп китте.

— И, рәхмәт, балам, рәхмәт, адресың ничек соң, балам. Китерермен,— дип калды әлеге апа.

— Җан ышыгы, җан тынычлыгы телә, апа! — дип кычкырды Әсгатем еракта көлемсерәп...

Алалы-колалы ямьсез бер ноябрь көнендә күңелем алдан ук нидер сизенеп, ниндер бик борчылып, үз-үземә урын таба алмыйча, мин аның фатирына ашыктым. Моңарчы беркайчан да беркем белән дә уртаклашмаган уйларым борчый иде. Ул мине болай тиргәр сыман тоелды: беренче мәкаләмне бастырып үсендерүче кем иде? Син! Ачы да, татлы да иҗат дөньясына кем алып керде? Син! Алсу хыялларга батып, кем белән бергәләп ант-планнар кордык? Синең белән! Ә ахыры нинди кызганыч тәгалләнде. Син минем яшьлегемне ялгыш юлдан юнәлттең, син гаепле минем бу хәлемә, син!!

...Әмма ул, бар дөньяга битараф кеше сыман, караватында ята. Мин аны шундый боеккан хәлендә беренче тапкыр күрүем иде. Аңарда гүя ниндидер бер эчке ут сүнгән иде. Квартирасы да тулай торак булмәсе сыман яшьлек рухы бөркеми, ул иркен дә, якты да түгел: әллә ничек,

әрәкләр уйнаган шикелле шомлы, караңгы, күңелсез иде. Кая аның горурият тулы кыяфәт белән: «Үлсәм, үләм, әмма идеалымны шарманкага алыштырмыйм!» — дигән чаклары?!

— Нигә мин болай бәхетсез инде, Фәрһад, ә? Берәүгә дә зыян китермәдем бит. Гел яхшылык кына эшләргә тырышып йөрдем,— дип башлады ул койкада яткан килеш.— Нигә болай бу? Кая талпынабыз? Барысы да файдасыз бит! Аһ, бәхетсез мин, бәхетсез. Тәки Рәсимәгә өйләнеп харап булдым...

Эше турында зарланыр инде бу дигән идем. Ә ул әнә... Каф тавы артында калып, әллә кайчан онытылып беткән Рәсимә турында сүз башлады. Аның характерына хас булмаганча, зарланудан башлады. Мин аның нәрсәнедер әйтеп бетермәвен шәйләп, сүзсез калдым.— Хатын-кыз тудыра, хатын-кыз үтерә бит безне, Фәрһад. Ул кеше итә, ул юк итә. Ул шедеврлар да яздыра, ул безне бөтенләй юлдан да яздыра. Соңгы елларны мин бит тыштан гына көлеп йөрдем. Эчемне мәңгелек үкенеч уты көйдерде. Мин бит Рәсимәгә, беренче мәхәббәтем Рухиямне читкә кагып, ниндидер бер тиле юләрлек белән генә өйләнгән идем. Рухия хәзер шушы шәһәрдә яши, исерек бер шоферда. Ике баласы бар. Минем бит дөньяны матурайтасым, яктыртасым килеп төннәр буе язуларым да шул Рухиям өчен иде бит. Ул укыр, белер дә, яныма бер килеп чыкмый калмас дип өметләндем. Минем аз гына да җан тынычлыгы таба алганым булмады. Аз гына да! Күңелемне мин шар ачык тотып яшәргә тырыштым. Ләкин алай яшәве дә бик авыр бит бу дөньяда. Җитешсезлекләремне эләктереп алып, гаепләргә генә тордылар. Үзең беләсең, «буш мичкә кебек йөри шунда дыңгырдап» диючеләр дә аз булмады. Тирә-ягымда кемнәр ни сөйләгәнен сизми бу дип уйладыңмы әллә син?! Син мине аз язуым өчен әрли идең. Ләкин әсәр язып та, аларны дөньяга чыгару өчен нинди ныклык кирәклеген син үзең дә татыган кеше бит, Фәрһад, беләсең.— Ул кинәт урыныннан торып, юл йөреп кыршылып беткән чемоданын карават астыннан тартып чыгарды, аннан папкалар, калын-калын дәфтәрләр бушата башлады.— Менә минем соңгы биш елда иҗат иткәннәрем. Син боларны белмисең әле. Миңа тагын да ныклап эшлисе иде. Әмма өстәл артына кадакланып утырырга күңел утырып җитмәгән иде. Мин, бөтен дөньяны йөрәгемә сыйдырасым килеп, гаҗәеп тормыш тәэсирләрен комсызланып эчтем дә эчтем. Ә менә болары синең миңа язган хатларың. Өйләнгәнче язган хатларың. Син ул хатларыңда шундый матур олы җанлы кеше идең. Бәллүр романтик идең бит син дә. ...Әмма син үзең дә бөтен талантыңны, бөтен яшьлегеңне ныграк харап иттең. Мә, ал хатларыңны, алар миңа башка кирәкмиләр инде. Минем иң күрә алмаган кешеләрем—һаман байлыкка омтылучылар. Аксакалыбыз керәшен Кәли әйтмешли, бу дөньяда бөтен ызгыш-талаш артык байлыкка омтылудан башлана. Артык байлыкка омтылу кешегә мәңге бетмәс вөҗдан газаплары китерә.— Идән уртасына басып ул элекке горур һәм таза кыяфәтенә кереп сөйли иде.

Мин тормышта сынатканымны, чын дуслык хисенә ахыргача тугры булып кала алмаганымны бары тик шунда гына аңладым... Ләкин инде берни дә эшли алмый идем. Күңелне шом басты. Өйгә кайткач, Әсгатькә ничек ярдәм итү турында хатын белән дә киңәшеп карадым. Ләкин аның әз генә дә исе китмәде.

— Әллә нинди кирәкмәс кешеләр турында кайгыртып үлдең инде,— диде.

Миң ике-өч көн буена аның турында уйланып йөрдем. Аны каядыр эшкә урнаштырасы иде бит. Ләкин мин көчсез, ихтыярсыз булып чыктым, бер эмәлен дә таба алмадым. Ә дүртенче көнне тетрәндергеч хәбәр китерделәр... Йөрәге!

...Тулай торак балконындагы ак күлмәкле егет миңа таба борылды. Юк... бу Әсгать түгел, бу ул түгел иде. Үзәкләрем өзелеп, айнып киттем...

Аны соңгы юлга озатканга инде ничә еллар үткән... Кара, ничек соң әле бу дөнья Әсгатьсез, аңлыйсызмы, Әсгатьсез яши ала? Бу башка сыймый, бу бит һич мөмкин түгел...

Ул тормыштан җиңелүче булып китмәде. Ул чакны озак та үтмәде, завод караклары турындагы эш кабат кузгатылды. Әсгать югарыга язарга өлгергәндерме, юкмы, белә алмый калдым, әмма яшь кадрларны тәрбияләүдәге тупаслыклары һәм хезмәт иярләре хатларына салкын караганы өчен Вафичны эшеннән алдылар.

Әсгатьнең хаклылыгы шушы гына булса, мин бу тарихны сөйли дә алмаган булыр идем.

...Тулай торак балконында теге ак күлмәкле егет юк иде инде. Әмма анда кояш төшкән. Июль кояшы, чын, таза, рәхәт кояш! Тәрәзәләрдән гитара тавышлары, яшьлек куәте ташып торган җырлар яңгырады. Күңелне үзәк өзгеч нечкә тойгылар телгәләде. Юк, мин яшьлегем белән, яшь шәһәрнең романтик чоры белән, Әсгать белән араларны бөтенләй өзеп бетермәгәнмен ич әле!

Мин болай гына, гади генә сүнеп кала алмыйм. Әсгатьнең адашулы, ялгышулы, хаталы, әмма җәүһәр кебек ялтырап торган тормыш юлы мине яңа көрәшләргә, кояшлы яңа юлларга чакыра.

Юк, мин болай гына сүнеп, сүрелеп кала алмыйм. Тиеш түгел! Кирәк булса, мин яңадан тагын бер кеше гомере яшәрмен, соңгы сулышыма хәтле антыбызны яңабаштан үтәп чыгар өчен көрәшәчәкмен. Мин, үткәнем белән яңадан кавышып, урынымнан кузгалам.

Әйе, ул бар иде. Ул әле хәзер дә бөтен җирдә җыр уятып, яшьлек сарайлары — тулай тораклар буйлап йөридер сыман... Әмма бу шәһәрдә түгел. Ул башка җирдә, башка зур төзелешләрдә...

Инде мин дә тынычландым, үз юлын, үз агымын тапкан бу иске тормышым белән канәгатьләнеп кала алмыйм... Бүтән Әсгатьләр инде күптән яңа төзелешләрдә. Мин дә иртәгә юлга кузгалам. Мин анда, һичшиксез, яңа Әсгатьләрне очратачакмын...

Айдар Хәлим,
башкорт шагыйре

## Беренчеләр

ПОЭМАДАН ӨЗЕКЛӘР

●

Ята урман — яраланган аю.
Бар кодрәте белән үкерә —
Җәяүле гаскәрдәй, төпкелләргә —
Рекогносцировкага җил керә...
Язгы кояш вакытында килде.
«Келт» ватты да бозлар йозагын,
Ташты Кама...
Гөрелтеләр акты...
Ярларына төште үзагым.
Кошлар кайтты симфония төяп.
Үлчәп мәхәббәте күләмен,
Күкрәде күк... Миннән эш тормас дип,
Сикереп чыкты бәпкә үләне...
Яфрак җиле чытыр-чатырлардан
Әвәләде яшел чүмәлә...
Буласы булган, буяу сеңгән инде! —
Карагайлардан энҗе сумала
Тамды...
Исме яз шул — кымшануы даһи!
Тып-тын гына шаулы яшеллек
Уратып ала сине, моңга сала...
Үзен бөек тоя кешелек.
— Яз килде, яз! Бәрәкәтең белән!
Урманнарда чыжлый пычкылар.
Делянкада кояш тәгәрәп көлә,
Ера-ера ботак кучкылын...

Республика буйлап — кыллы тавыш!
Сыек баткак, быжык ләм аша
Тимер-авто юллар салучылар,
Кышкы камалыштан исән чыккан
Техника,
промбаза,
поселок,

Көне өчен түгел, иле өчен
Яшәр көрәшчеләр — эшчеләр,
Вагон,
барак,
землянкалар,
базлар,
Баткак диңгезендә —
КРАЗлар,
МАЗлар,

Антенналар,
Нигезләрдә кызынган бала-чагалар,
Бауларда кипшенгән керләр —
Барысы да шул ук шаукымда:
— Саумы, Кояш,
Саумы, Яз! — диләр...

Еракларга иңен салды төзелеш,
Якынайды меңәр чакрымнар.
Һөҗүм арты һөҗүм...
Акрынлап
Һәр бөеклек зур сынаулар аша
Алга манган сымак ил таңын,
Киредән түгел, беренче битеннән
Яза икән тарих китабын...
Еллар үтәр, кешеләр туа торыр,
Матур туар, туар яман да —
Әйләнер дә,
Беренче мәхәббәт кебек
Беренчеләрен сагыныр замана...

●

*Беренче каучук алынды.*
*Ул төндә шәһәр бөтенләй йокламады.*
Газеталардан

...Химкомбинат,
Рейдка туктаган
Крейсердай таңны каршылый.
Ул кояштан, гүя, ялкын ала
Киләчәккә үтеп барышлый...
Бу ялкынны, хезмәт дәртен өстәп,
Йөрәгеннән эшче үткәрә.
Үткәрә дә, илебез абруен
Галәм киңлегенә күтәрә.

Шулай күрәм, шуңа инанам мин:
Бар эчтәлек килә тормыштан.
Кояш чыга комбинат өстеннән,
Урыны шунда аның тумыштан.

Изопрен-мономер [1],
Йөкле ана сымак,
Көнең-төнең булды санаулы —
Дөньяга син җитәкләп чыгардың
Каучук исемен йөрткән малайны...
Көмеш шарлар тәлгәшендә пешкән
Карлыганга бигрәк охшаган —
Җәйге табыш итеп урманнардан
Болан тәгәрәтеп, гүя, чыгарган...
Шарлавыктай утлы ташкын ага,
Әйтерсең лә путал нәкышлар —
Җем-җем килеп, таң балетын бии
Нур күлендә җитез аккошлар.
Киләчәктән куркып чигенгәннәр
Ялгышларын аңлап савыксын,
Дигән сыман, рәт-рәт цехлар баскан...
Таңга калырсың!

...Искә килә хәтирәле еллар,
Үзәк өзгеч, сыкрау бураннар,
Вагоннары белән рәткә тезелеп,
Пропискасын көткән урамнар...
Төзүчеләр, дуслар, рәхмәт сезгә!
Нарядларны дөрес яптыгыз.
Дастаннарның тигәнәген чүпләп,
Рифмаларны алдан таптыгыз!

Рифмаларны җыеп, җәяү киләм.
Мин алардан җырлар тукыймын.
Бәйрәмнәрдә — төзүчеләр, сезгә,
Цехлар — сезгә
Егылганчы шигырь укыймын.
Рәхмәт сиңа, рәхмәт, Кама таңы,
Җырым йомгакларын чорнадың.
Үз кулларым белән төзедем дә,
Ничек тойдым, шулай җырладым!..

*1968—81* *Түбән Кама — Уфа.*

[1] Изопрен-мономер — каучук өчен чимал җитештерелә торган цехлар.

## Николай Шәмсетдинов,

Төмән шагыйре

# АН-2

Урман төсле яшел. Карлар сарган.
Уңайлы да үзе, гади дә.
Ышанычлы. Җиңел. Өйрәнелгән.
Урнашабыз җайлап — нәкъ өйдә.

Күтәрелде тайга өстенә ул,
Калдырды да тирән кар илен.
Кар аралаш корыч хәрәкәтне
Югарыга менеп карыймын.

Чәчи-чәчи гүли таныш мотор.
Бозлы яшьләр күзгә тулыша.
Тундра, гүя, төлке түше белән
Каршыбызга безнең шуыша.

Ә юлдашым объективы белән
Җирне күзли, нидер эзләнә.
Утлар биеп кала. Ә манзара
Күз алдында меңгә үзгәрә...

Дөнья якты, ярсу һәм тынгысыз!
Көмеш боланнарның юлына
Каршы чыккан әнә боргаланып
Тыйнак кына елга — Елена.

Без — очабыз! Хезмәт шавы белән
Таң нурлары бергә кушыла.
Алтын кояш ал нурлары белән
Сәлам юллый Себер кышына.

Кайный Себер җире! Кайнар — җиле!
Ә офыкта ал таң сызыла.
Көнчыгышның кан тамыры кебек
Себер аша торба сузыла.

Эшчеләрнең бу — гадәти көне.
Алар инде монда күптәннән,
Корыч кебек җилдә кайный-кайный,
Себер халкы булып беткәннәр.

Эшче хезмәтенең бөек көче
Хәрәкәткә җирне китерә,
Чирәм җирне иген кыры итә,
Тайгаларда сазлык киптерә.

Килеп керә блокнот битләренә
Эшче кебек кырыс шигырьләр.
Ә аларда — Себер күкрәүләре,
Себергә хас кырыс шөгыльләр.

Үзәкләргә үтсен һәрбер шигырь —
Охшап торсын Себер җиленә.
АН-2 нең канатлары әнә
Ода яза Себер җиренә!

## Кырык беренче ел

Уяна дертләп таңнарда
фронтка киткән солдатларның кызлары —
Тын таңнарда җанны өзеп
ишетелә составларның узганы.

Ерагая Донны кичеп,
яу кырының карасу төтеннәре,
кырынмаган, кырыс йөзле
әтиләрнең окоптагы төннәре.

Хатлар — сирәк, хатлар — кыска...
Ерткаланган кырлар тар-мар ителгән.
Кургашын яңгырларыннан
зәңгәр күкнең чит-читләре кителгән.

Ишетелә ераклардан
авыр-авыр сулаганы чиратның —
шырпыга чират торганы
үсмерләрнең, хатын-кызның, ир-атның.

Карлыганнар — каралганнар,
сытылырга тора алар бакчада.
Ә кояшта янган кызлар
тулып пешкән — нинди авыр чакта да.

Аларның күләгәләре
Ватан буйлап көнбатышка сузылган...
Әтиләрнең юллары да
Шулар аша Берлинга ук узылган.

**РОБЕРТ МИҢНУЛЛИН** тәрҗемәләре.

Газиз Кашапов

# АШКЫН ЙӨРӘК



иденче агрегатны җибәрәсе көн якынлашып килә иде.

Ел башында Кама автомобиль гигантының икенче чираты объектларын корып бетереп, файдалануга тапшырган «Камгэсэнергострой» берләшмәсе төзүчеләре Ватаныбызның иң югары бүләге — Ленин ордены белән бүләкләнгәннән соң тагын да рухланыбрак, дәртләнебрәк эшләделәр. Ак шәһәр — Чаллыда бер-бер артлы өр-яңа йортлар торгызылдылар, торак һәм социаль-көнкүреш комплекслары үсә, күбәя барды.

Партиянең XXVI съезды барган көннәрдә күп меңле төзүчеләр коллективына тагын бер олы бурыч — Татарстан атом электр станциясен һәм аның янындагы йөз илле мең кеше яшәргә тиешле шәһәрне салу бурычы өстәлде. Озак-
ламый анда геодезистлар эшкә керәште, аннары төзүчеләрнең беренче десанты җибәрелде.

Ел саен бер миллион ике йөз кырык сигез мең киловатт-сәгать электр энергияе эшләп чыгарырга тиешле Түбән Кама гидроэлектростанциясенең җиденче агрегатын эшкә җибәрәсе көн якынлашып килә иде.

Берләшмә начальнигы Евгений Никанорович Батенчукны эш урынында туры китерүе гаять читенләште.

**Батенчук Евгений Никанорович** 1914 елда туган, 1939 елдан КПСС члены, милләте — украин, югары белемле, Бөек Ватан сугышында катнашкан...

Хезмәт эшчәнлеген 1930 елда Одесса шәһәрендә слесарь буларак башлаган, 946 елдан бирле СССРның энергетика һәм электрификация министрлыгы системасында эшли. Төзү идарәсе механигыннан башлап, илебездәге иң эре төзелеш ешмасы җитәкчесенә кадәр күтәрелгән. «Сочигэсстрой»ның механигы, «Ангарагэстрой»ның баш механигы, «Вилюйгэсстрой»ның төзелеш начальнигы вазифаларын амус белән башкарган. 1971 елның февраль аенда Кама автомобиль заводлары омплексын төзүче «Камгэсэнергострой» производство берләшмәсенә җибәрелә.

Хөкүмәтебезнең иң мөһим заданиеләрен тормышка ашырып, Кама зур йөк авомобильләре җитештерү берләшмәсен проекттагы куәтенә, Түбән Кама ГЭСының лты агрегатын, төзелеш индустриясе заводларын төзеп сафка кертү, дүрт йөз еңгә якын кеше яши торган Яңа шәһәр һәм аның янында авыл хуҗалыгы зонаын, Зәй ГРЭСын коруда Батенчук Е. Н. бетмәс-төкәнмәс энергия, эшчәнлек һәм ештыру сәләтен күрсәтә.

Социалистик Хезмәт Герое. Өч тапкыр Ленин, Октябрь Революциясе, Хезмәт ызыл Байрагы, Кызыл Йолдыз орденнары һәм дистәгә якын медаль белән бүләкәнгән.

Партиянең XXIII һәм XXVI съездына делегат булып сайланган. ТАССР Верэвный Советы депутаты.



**Е. Н. Батенчук — төзелештә.**

К. Ситдиков фотосы.

Чаллы җирендә хезмәт данына күмелгән Уматгәрәй Наурбиев җитәкчелегендәге автоскреперчылар бригадасы унынчы бишьеллыкның дүрт ел да ун аенда ике бишьеллык заданиесен үтәп чыкты. Шушы уңай белән җыелган митингта Евгений Никанорович егерме милләт вәкилләреннән торган бригадага кызыл вымпел тапшырганда:

— Бүгенге гүзәл җиңүне яуларлай бригадаларыбыз булганга күрә без иң катлаулы төзелеш елларында да сынатмадык. Партия һәм хөкүмәт кушкан барлык заданиеләрне намус белән үти бардык, киләчәктә дә сынатмабыз, — диган иде.

Без, корреспондентлар:

— КамАЗның икенче чират объектлары үзвакытында, ягъни съезд ачылган көннәргә сафка кертелерме? — дип сорадык. Чөнки ул көннәрдә барлык эшкә түземсезләнеп карарга күнеккән идек. Билгеләнгән срок җитеп бара, ә эшләрнең иге-чиге күренми сыман.

Евгений Никаноровичның, бераз гына көлемсери төшеп, өстендәге төзүчеләр кия торган бушлат-куртканың төймәләрен чишеп җибәрә-җибәрә:

— Сезгә, иптәшләр, билгеле булырга тиеш: КамАЗ — гаять үзенчәлекле төзелеш, — диде. — Аны проектлаштыру һәм кору бер үк вакытта башкарылды. Безнең төзүчеләр биредә фән һәм техника казанышларының иң яңа алымнарын кулланып, тормыш сынавы аша уздырдылар. Алай гына да түгел, күп очракта дөньяның иң яхшы заводларында ирешелгән технологияне камилләштерүгә дә ирештеләр. Дөрес, мондый хәл төзүчеләргә өстәмә кыенлыклар тудырды. Ләкин безнең төзүчеләр, монтажчылар әлеге кыенлыкларны намус белән җиңеп, тапшырылган бурычларның һәркайсын үзвакытында башкардылар. Шулай булгач, бөтен эшләребезнең максаты булган, барлык омтылышларыбыз тупланган бурычны да үтәмичә калмабыздыр дип уйлыйм.

Тагын ике ай ярымнан без моның шулай икәнлеген үз күзләребез белән күрдек. Без КамАЗ гигантның проектта каралган барлык куәтләрен файдалануга тапшыруның шаһитлары булу бәхетенә ирештек. Евгений Никанорович Батенчук һәм аның кебек талантлы инженерлар җитәкләгән күп меңле коллективның чын батырлыгы иде бу.

Кама автогигантының беренче чиратын сафка керткәч, КПСС Үзәк Комитеты Генеральный секретаре, СССР Верховный Советы Президиумы Председателе Леонид Ильич Брежневның төзүчеләргә, монтажчыларга һәм барлык эшчеләргә җибәргән котлау хатындагы «Еллар үтәр, әмма барлык совет кешеләре Кама буендагы хезмәт батырлыгын горурланып искә алырлар» дигән сүзләрнең хаклыгы тагын бер тапкыр расланды.

Евгений Никанорович Батенчукның җирдәге эзләре беркайчан да югала торганнардан түгел. Гомеренең буеннан буена ару-талуны белмәгән бу кеше җир өстендә җуелмас һәйкәлләр калдыра.

Төнге икеләр тирәсе. Тышта ябалак-ябалак кар ява. Яңа шәһәрнең кырык сигезенче комплексындагы күккә ашкан ак йортларның тәрәзәләрендәге утлар сүнеп бетте. Батенчукның тормыш юлы белән танышам, аның турында, ул эшләгән коллективлар турында язылган китапларны алып укыйм.

Евгений Никаноровичның тормышы белән кызыксынуымны белгәч, Вилюй ГЭСы төзелешендә данлыклы «Атакай»ның урынбасары булып эшләгән, ә хәзер «Главульяновскстрой» берләшмәсенең «Спецстрой-механизация» трестының механизация буенча начальник урынбасары Павел Алексеевич Ежов дулкынланып-дулкынланып миңа болай сөйләде:

«...Евгений Никанорович сүзгә саран кеше. Дөрес, моңа карап аның тормыш юлы безгә, Вилюй ГЭСында аның белән дистәдән күбрәк ел бергә эшләүчеләргә, сер түгел иде... Одесса янындагы кечкенә бер шәһәрдә туган ул. Беренче Бөтендөнья сугышы башланган елны. Совет власте елларында мәктәптә укый, хәзерге сез күргән, һәрвакыт диярлек эш киеменнән, төзүчеләрчә гади, пычракка буялган итекләрдән йөри торган мәһабәт гәүдәле, Сократныкы сыман киң маңгайлы житди кеше кайчандыр колгасар чандыр үсмер була. Соңрак рабфакта укый, химия промышленносте машиналары төзү белгечләре әзерли торган институтны тәмамлый. Уралдагы төзелештә беренче чынығу ала, сынау үтә. Ләкин аңа институтта алган белемен тормышта кулланырга, кыю хыялларын тормышка ашырырга туры килми. Бөек Ватан сугышы башлана. Аны 48 нче укчы дивизиянең 328 нче полкына пулеметчылар отделениесенә җибәрәләр... Авыр, ялыктыргыч, күңелләрне әшетә торган чигенү юллары, чолганыш артыннан чолганыш. Авыр яраланган отделение командирына үзенең дошман кулында, әсирлектә икәнлеген белүнең никадәрле кимсетүле, никадәрле җан әрнеткеч фаҗигагә әйләнүен аңлыйсыздыр, билгеле. Ләкин кыю йөрәкле коммунист анда да үзенең намусына тап төшерми, өметсезлеккә бирелүчеләрнең дә күңеленә яшәү чаткылары сала.

Үлемгә дучар ителгән әсирләр лагеренда яшерен төстә листовкалар тараталар. Фашистлар үз шымчыларына моның әзенә төшәргә, башлап йөрүчеләрне табарга кушалар. Ләкин алар никадәр генә тырышмасын, листовкалар чыга тора. Ул листовкаларның ахырында имза урынына гел бер төрле саннар сугылган була — 2311925.

Совет гаскәрләре тарафыннан азат ителгәннән соң тиешле тикшерүләр башлана. Шунда берәү Батенчукка яла яга, ул фашистларга хезмәт итте, дип күрсәтә. Батенчук тикшерүчеләр алдына кабат баса. Үзен акларлык дәлилләр китерергә туры килә. Ләкин аларны кайдан аласың, бергә көрәшкән иптәшләренең кайсылары ачлыктан, кайсылары туктаусыз җәзаларга түзәлмичә һәлак булган... Батенчук иң соңгы, ләкин кире кага алмастай дәлилне китерә. Яла ягучыны китерүләрен, аңа бер сорау бирергә рөхсәт итүләрен үтенә. Китерәләр.

— Үлем лагеренда таратылган листовкаларның ахырында, күргәнегезчә, имза урынына җиде урынлы сан тора, әгәр дә листовкаларны сез җитәкләгән төркем чыгарган, безнең катнашыбыз юк икән, әйтегез — ул саннар нәрсәне аңлатала соң? — ди Батенчук шикаятьчегә.

— Билгеле инде,— ди теге,— шартлы саннар, без үзебезнең фамилияләрне күп чыгарырга тиеш идекме соң?

— Шулаен шулай,— ди Батенчук тикшерүчеләргә туры карап.— Ләкин ул саннар очраклы рәвештә генә минем партбилетым номеры була аламы соң?

Тикшерел карыйлар — нәкъ шулай. Евгений Батенчук партиянең тугрылыклы солдаты булып калуын, иң кыен шартларда да көрәштән ваз кичмәвен раслый...

Сугыштан соң Евгений Батенчук җир йөзендәге иң кешелекле һөнәр — төзүчелек эшен сайлый. Башта бернечә ел рәттән Кавказ тауларында юллар сала, кыя ташларында үзенең эзләрен калдыра. Аннары танылган гидростанцияләр төзүче Семен Константинович Калижнюкка юлыга һәм үзе дә аның һөнәре белән мавыгып китә. Дөрес, әле яшь инженер бу һөнәрнең гомерлек булачагын белми, ләкин бер сайлаган юлдан ныклы адымнар белән атларга тырыша. Шуның өчен дә электр станцияләре төзү турындагы барлык китапларны укып чыга, бик күп нәрсәне ачыклый, өйрәнә. Озакламый аңа Себер киңлекләренә китәргә, анда төзүчелек өлгергәнлегенә имтихан тотарга туры килә. Һәм Батенчук сынатмый. Аның турында төзүчеләр арасында легендалар туа башлый. Аларның берсен танылган рус язучысы Анатолий Злобин үзенең «Тәмамланмас очрашу» исемле китабында болай тасвирлый.

Вилюйдагы төзелешнең икенче елы бара иде. Искиткеч салкыннар башланды. Термометрдагы терекөмеш 62 градусны күрсәтеп тора. Барлык эшләрне туктатырга туры килде. Беренче көнне үк сууткәргеч торбалар салынган траншеяның күмелмичә калганлыгы мәгълүм була. Әгәр дә мәгәр аларны һич кичекмәстән күмеп ташламасаң, торбалар шартлаячак. Ә алар төзүчеләр поселогына кайнар су җибәрә, җылытып тора.

Әйтергә кирәк, мондый кырыслыкка уралган дөреслек озак та үтми легендага әверелә. Алга таба вакыйгалар болайрак дәвам итә. Батенчук мич янында җылынып утыручы бульдозерчылар янына килә. Егетләр, ди ул, менә шундый-шундый хәл, поселокны һәлакәттән коткарырга, торбаларны күмәргә кирәк. Ә егетләр, чынлап та, яшьләр, кыюларның кыюлары. Җитмәсә, төзелеш башланганга нибары икенче генә ел бара, коллектив тупланмаган, һәркем үзенә тарта, үз кайгысын кайгырта. Егетләрнең кайсы шаяртуга бора, кайсылары исә сүгенеп үк җибәрә, ә берсе, иң башкисәре: «Син, агай-эне, ди, бар әле яхшы чакта үзең шушы траншеяларны күмдер әле»,— ди. Шул вакыт, легенда тасвирлаганча, Батенчук бер бульдозерчының алдына барып тезләнә һәм аның тракторга утыруын сорый, ялына башлый. Теге ояла: төзелеш начальнигы аның каршында тезләнеп торсын әле. Түзмиләр, ике егет тракторларның туңып барган двигательләрен җылыталар да, кабызып, эшкә керешәләр...

Евгений Никанорович Батенчук Кама автомобиль заводлары комплексын төзүче «Камгэсэнергострой» берләшмәсенә 1971 елның чатнама суык февралендә килеп төшә. Шушы көннәрдән алып аның исеме КамАЗ һәм Чаллы шәһәрен корычыларның телендә тырышлык һәм фидакарьлек, кырыслык һәм миһербанлылык, партиячел таләпчәнлек һәм принципиальлек символы буларак йөри.

Башкарыласы эшләрнең күләме, киңлеге шул кадәр олы була ки, КПСС Үзәк Комитеты һәм совет хөкүмәте КамАЗ төзелеше начальнигы итеп СССРның энергетика һәм электрификация министры урынбасары Н. М. Иванцовны раслый.

Төзелешкә яңа начальник билгеләү Евгений Никаноровичның мәшәкатьләрен аз гына да киметми, чөнки ул, беренче урынбасар буларак, Кама буенда башкарыла торган эшләрне үз җилкәсендә күтәрүне дәвам итә. Мәсәлән, КамАЗның иң беренче һәм вакытында иң мөһим объекты булып ремонт-инструментлар заводы калкып чыга. Ул көннәрдә, хәтта «РИЗ — КамАЗ өчен көрәш фронтының алгы сызыгы!» дигән лозунг игълан ителә. Министрлыклар, хөкүмәт, партия Үзәк Комитеты андагы эшләрнең барышы белән даими кызыксынып тора. Чөнки бу заводның корылышы белән Экономик Ярдәмләшү илләре һәм Көнбатыш илләрендәге сиксәнләп фирма кызыксына. Алар техник җиһазлар куярга тиеш... Завод күз өстендәге кара каш булып еракларга күренә, әмма төзү-монтаж эшләренең билгеләнгән графигы үтәлми, сроклар өзелә. Җәй айларында эшләр бармый, елның соңгы аенда исә 700 мең кубометрга якын җир казырга, аны ташып икенче урынга чыгарырга, 70 мең кубометрдан күбрәк бердәм бетон салырга һәм башка бик күп эшләрне башкарырга кирәк. Ремонт-инструментлар заводын файдалануга кертер көннәр якынлаша...

Җир эшләре төзү-монтаж эшләренең иң күләмлесе һәм иң күп көч сорый торганы.

Илебезнең энергетика һәм электрификация министрлыгының төзү-монтаж идарәләре, мәсәлән, ел саен 800 миллион кубометрдан күбрәк күләмдә җир эшләре башкаралар.

КамАЗ төзелешендә ел саен 60 миллион кубометр җир эшләре башкарылып килде.

— Әйе, шундый күләмле эшләр. 1974 елга кадәр КамАЗ төзелешендәге җир эшләре аерым машиналар һәм механизмнар, транспорт белән башкарылдылар. Шунысы да бар, һәр очракта машиналар, транспорт яңабаштан туплана, механизаторлар һәм автомобиль йөртүчеләрнең эше, аңа түләү дә шушы бурычка карап, төрлечә түләнә иде. Димәк, механизаторлар һәм транспортчыларның эш нәтиҗәләре белән кызыксынуы да төрле, соңгы нәтиҗә белән кызыксынуга зы-

ян кылә. Моның өстәвенә, эш процесслары белән идарә итү кыен, чөнки объектлар таркау иде,— ди төзелешне механикалаштыру идарәсе начальнигы Иван Федорович Мухрыгин ул көннәрне искә төшереп. Башкарыла торган эшләрнең үзенчәлегенә, аларның күләменә, технологиясенә карап төзелештәге машиналарны, механизмнарны һәм транспорт көчләрен бергә туплау кирәк иде.

Батенчукка кешеләрнең инициативасы, яңача уйлавы, кыенлыклардан курыкмавы, эшкә атлыгып торулары кадерле. Алай булганда ул утка да, суга да керергә әзер.

Җитәкчеләрнең ихтыяри карары белән җир эшләре тулысы белән төзелешне механикалаштыру идарәсенә тапшырыла, КамАЗ мәйданнарында беренче агымнар барлыкка килә башлый.

— Нибары 5 ай эчендә яңача эшләүче комплекслар 87 көнгә алга чыктылар. Мәйданнар хәстәрләнеп бетте. Евгений Никанорович Батенчук бөтен җаны-тәне белән яклаган бу яңалык та үзенең тормышчанлыгын аклады,— ди төзелешне механикалаштыру идарәсенең хезмәтне фәнни оештыру бүлеге мөдире Фарук Нигъмәтуллович Монасыйпов — үзе дә яңалыкны гамәлгә кертү, киләчәктә аны тагын да камилләштерүгә көчен, белемен, вакытын кызганмаган кеше.

Ул көннәрдән соң да инде вакыйгаларның мөһимлеге, эшләрнең колачлыгы белән ялкынлы хезмәткә уралган еллар узды. Кама гигантының беренче һәм икенче чиратлары сафка кертелде. Түбән Кама ГЭСының котлованнарына су тутырылды, алты агрегат-турбина кыймммәтле энергия җитештерә. КамАЗ төзелешенең иң киеренке көннәрендә Батенчук белән Мухрыгин һәм тагын бик күпләрнең иҗади фикерләве белән туган яңалык тормыш сынауларын бары тик «бик яхшы» билгеләренә генә биреп бара, үсә, көчәя, бөтен илгә тарала.

...ГЭС котлованына су тутыру көннәре җитеп килә, ә андагы җиһазлардан соң калган нигез төпләре, башнялы краннар, тау-тау булып яткан җирнең иге дә, чиге дә юк. Берләшмә җитәкчеләре тегеләй дә, болай да уйлап карыйлар, ләкин билгеләнгән көчләр белән генә калган көннәрдә котлованны чистартып чыгу һич мөмкин түгел дигән карарга киләләр. Нишләргә? Евгений Никанорович Батенчук шул чакта төзелешне механикалаштыру идарәсе начальнигы Иван Мухрыгинга төбәп:

— Мин котлованны билгеләнгән көнгә чистартып чыгардай бер генә коллективны беләм: Уматгәрәй Наурбиев җитәкләгән механикалаштырылган комплекс,— ди.

22 сәгать 00 минут. Мухрыгин Наурбиевнең өенә шалтырата, хәлне аңлатып бирә, югыйсә тантаналы вакыйганы кичектерергә туры килә бит, ди.

23 сәгать 40 минут. Ничәмә-ничә линияләр аша үтеп: КамАЗ заводларының теге башында, тимерчелек заводы корпуслары янында эшләгән мехкомплексы тулы составы белән — 70 кеше һәм 21 скрепер, ремонт машинасын да иәртеп, Кама ярларына килеп чыга.

23 сәгать 50 минут. Мәһабәт филләр сыман, скреперлар бер-бер артлы котлованга төшәләр, эшкә керешәләр.

Соңыннан бу күренешне искә төшереп, тагын бер мәртәбә күз алдыннан үткәреп булса кирәк, Евгений Никанорович Батенчук дулкынлануын тыя алмыйча:

— Илебездәге иң олы төзелешләрне күргән-белгән кеше мин, ләкин, турысын әйтәм, ул сәгатьләрдә Наурбиев егетләре эшләгәнне карап тору тетрәндергеч күренеш иде,— диде.

**Төзелешне механикалаштыру идарәсе начальнигы Иван Мухрыгинның «Правда» газетасының 6 май санында басылган мәкаләсеннән.**

«КамАЗ төзелешенең иң киеренке көннәрендә туган яңалыкны камилләштерә барып, механикалаштырылган комплекслар соңга таба бригада подряды белән эшләүгә күчә башладылар. Һәм хезмәтне оештырудагы элеккеге системаның барлык кимчелекләре бер-бер артлы аермачык күренә башлады. Түбәндә планлаштыру, эшләрне инженерлык хәстәрлеге белән тәэмин итү кебек мөһим мәсьәләләрнең яңалык белән яраша алмавына тәмам ышандык. Төзелешне механикалаштыру идарәсенең идарә хезмәтләре норматив-техник документация хәзерләп өлгерә алмый. Алар гаять катлаулы, күп көч һәм вакыт таләп итә иде. Аларны

ничек гадиләштерергә соң? Безнең инженерларыбыз санап чыгардылар: җир эшләренең барлык төрләрен 38 технологик төркемгә, ә соңыннан, башкару ысулларына карап, 12 гә тупларга мөмкин. Безнең идарәдә шуңа карап 12 бердәм комплекслы бригада оештырылды. Алар бер-берсеннән машиналар һәм механизмнар төрлелеге белән генә аерылалар. Һәр төркем өчен технологик-экономик мәгълүматлар хәзерләп куелды. Алар электрон исәпләү машиналары аша барлык исәп-хисап өчен нигез нормативлары буларак кулланыла.

Болай эшләүнең файдасы әйтеп бетергесез: исәп-хисап эшләре кимеде, кәгазьләр хәзерләү тизләтелде. Нарядлар язу һәм аларны ябу кирәкми, чөнки эш хакы соңгы нәтиҗәләргә карап билгеләнә».

Аның янында ике-өч көн утырсаң, берләшмәдәге барлык эшләрнең барышын белергә, күп кешеләр белән танышырга мөмкин, ләкин бер шарт... күнегелмәгән тизлек, тыгызлыктан, өзлексез уйланулардан, белгеч булмаган хәлдә гаять катлаулы төзелеш проблемаларына төшенергә тырышып маташудан баш чатный башлый, саф һавага чыгасы килә. Хәер, саф һава дигәннән, Батенчуктагы киеренке киңәшмәләрдә утыручы инженерлар, күп төрле подразделение җитәкчеләре еш кына ишек катындагы зур тәрәзәне тутырып ачып куялар. Томырылып кергән салкын өермәләренә аларның исе дә китми, чөнки кайнарлык җитү...

Килеп керүгә башыма килгән беренче уй «хәерсез сәгатькә әләктем бугай» дигән уй иде. Чөнки Евгений Никанорович моңарчы мин беркайчан да күрмәгән төсле ярсу иде. Тагын берничә минуттан мондый хәлнең сәбәбе ачыкланды. Керамзит заводында авария — яндыручы һәм смена мастерының битараф салкынлыгы аркасында тулы бер линия эштән туктаган. Җитмәсә, шуңа охшаш «чп» икенче мәртәбә, икесендә дә бер үк кешеләр гаепле икән. Евгений Никанорович кайнарлык белән:

— Кичекмәстән судка бирегез, икесен дә, җитте, күпме кичерергә мөмкин,— дип, карышырга урын калдырмыйча боерык бирде.

Батенчук яхшы күңелле, ярдәмчел кеше, ләкин эш дигәндә, принципиаль мәсьәләләрдә Батенчуктан да каты, аңардан да принципиаль кеше бармы икән?

Миңа, мәсәлән, берләшмә җитәкчесенең ярыйсы ук кискен чакларын күрергә туры килде.

Берләшмәгә беркетелгән хәрби төзү отряды командиры сөйләшми-нитми генә ике йөз хәрби төзүчене «Отделстрой»га бирмичә, икенче эшкә җибәргән. Бу хәл Батенчукка мәгълүм булды.

— Ярты сәгатьтән минем янга аңлатма белән керегез! — диде ул һәм трубкасын куйды...

Керамзит заводындагы эшчеләр белән дә шулай булды. Тагын ярты сәгать үтәме-юкмы, завод директоры шалтыратты.

— Евгений Никанорович,— диде ул селектрлы телефоннан,— сәгать өчләр тирәсендә линияне эшкә җибәрәбез. Эшчеләр, ремонтчылар баш күтәрми эшлиләр. Гаепле иптәшләрнең өстенә карарлык түгел, җитмәсә икесенең дә балалары бар...

Евгений Никановичның кырыс йөзе үзгәреп, уртлары уйнап алды:

— Ярый, эшләсеннәр,— диде ул. Бу инде эшчеләрнең язмышын хәл итү иде.

Алдан әйткәнемчә, ГЭСның җиденче агрегатын әйләндереп җибәреп эшкә башлатыр көннәр җитеп килә иде. Сигезенчесен монтажлау бара... Узган төнне бу эш тоткарланган. Ни өчен? Сигезенче агрегатка дежур электриклар билгеләнмәгән икән. Нигә мине уятмадыгыз? Нигә тиешле күрсәтмә үтәлмәгән? Нигә, нигә, нигә?

Мин озын-озакка сузмыйча үзем хәстәрләп килгән сорауны әйтеп салдым.

— «Камгэсэнергострой» берләшмәсе тулы бер армияне тәшкил итә, әмма КамАЗ төзелеше чорында һәм менә инде аннан соң да, берләшмәдән, аның эре предприятиеләреннән җитди имтиханнарда сынатмаган җитәкчеләр китә, башка төзелешләргә китүче Геройлар да булды. Әмма берләшмә яңадан яңа уңышларга ирешә, куелган бурычларны намус белән үти. Моның сәбәбен ничек аңлатасыз соң, Евгений Никанорович?

Ул бераз хәйләкәррәк елмаеп, миңа карап-карап алды да, аталарча ягымлы тавыш белән:

— Язып куегыз,— диде ул (үзе нинди генә катлаулы проблемалар турында сөйләшкәндә дә «хәтер өчен» язып бармый, әмма бер нәрсәне дә онытмый) — соңгы вакытларда мин уйланып йөри торган бер нәрсә дәвамчанлык дип атала. Теләсә нинди коллективта булырга тиеш ул. Бездә, мәсәлән, КамАЗның беренче чиратын сафка керткән көннәрдән соң узган биш ел эчендә мондый нәрсә кадрлар мисалында аермачык чагылыш тапты. Соңгы биш елда берләшмәдәге җитәкче кадрларны икенче тапкыр алмаштырдык. Берәүләр югарырак урыннарга тәкъдим ителде, ә икенчеләрне яңа төзелешләргә җибәрергә туры килде. Алар урынын кичәге мастерлар һәм прораблар алды. Әлбәттә, тәҗрибәле җитәкчеләрне җибәрүе шөбһәле иде, ләкин яңа күтәрелгән кешеләр, алар белән тиешенчә эшләгән һәм сайлап алган очракта, һәрвакыт үзләре белән яңалык алып киләләр. Мондый күренеш беренче вакытта аларның тәҗрибәсезлеген тулысынча аклый. Аннары берләшмәдә тупланган тәҗрибә кала бит, алар даими хәрәкәттә, эштә. Дөрес, бик дөрес әйтәсез, КамАЗның икенче чират объектларын кору тагын да катлаулырак шартларда барды, чөнки күпчелек предприятиеләр инде продукция җитештерә, объектлар кечерәйде. Шулай да, моңа карап, берләшмәнең сыйфат күрсәткечләре төшмәде. Киресенчә, яхшыра гына барды. Безнең бүлекчәләр планнарны физик күләмдә генә түгел, эшләп чыгару күрсәткечләре буенча да үти башладылар. Монда, минемчә, иң беренче чиратта, бригадаларның тәҗрибәсе, эшне оештыруның яхшыруы хәлиткеч рольне уйнады...

— Төзелештәге социаль проблемалар ничегрәк хәл ителә, мәсәлән, вакытлы поселоклар, андагы баракларны бетерү проблемасы?

— Сез инде яңа төзелешләрдә йөри торган «канатлы» сүзләргә ишарә ясыйсыз. Чынлап та, яңа төзелешләрдәге иң гомерле корылмалар — вакытлыча дип корылганнары дигән сүз йөри. Ләкин, миңа калса, Чаллыда мондый сүзләргә салынган киная үзенең вазифасын үтәмәячәк. Дөрес, КамАЗны төзи башлаганда вакытлы поселоклар, бараклар гөмбәләр шикелле калыкты. Әмма безнең берләшмәдә генә дә узган бишьеллыкка 16 мең кеше вакытлы поселоклардан өр-яңа йортларга күчерелде. Тагын 10 меңгә якын кеше калып бара. Озакламый, бу бишьеллык дәвамында, Чаллыдагы вакытлы поселокларны сагынып сөйләргә генә калса калыр инде. Ун-унбиш ел чагыштырмача кыска вакыт түгелме соң?

— Евгений Никанорович, сез элегрәк үзегез турында язучы журналистлар һәм язучыларны да кыен хәлгә куйгансыз. Ләкин бит безгә сезнең тормышыгыздагы кайбер фактларны үзегезнең авыздан ишетүе гаять мөһим, шулай бит?..

— КамАЗ төзелеше, чын мәгънәсендә хуҗалык итү, хезмәтне оештыру, җитәкче һәм эшче кадрларны тәрбияләү мәктәбе булды. Килешәсезме? Фактлар? Рәхим итегез. Элек бездә баш инженер урынбасары булып эшләгән Ю. Д. Чечин шанлы Атоммаш төзелеше начальнигы, берләшмәнең «Автозаводстрой» начальнигы булып башлаган Владислав Александрович Фоменко башта берләшмә җитәкчесенә күтәрелде, аннары министрлыкның Баш идарәсе начальнигы дәрәҗәсенә үсте, төзү-монтаж идарәсе начальнигы Я. А. Григорян «Автозаводстрой»ны җитәкләде. Хәниф Кыямович Беляев 61 нче төзү-монтаж идарәсеннән «Отделстрой» төзелеш идарәсе начальнигы булды. Мондый мисалларны йөзәрләп китерергә мөмкин. КамАЗ заводларын без үстердек, ә алар безнең кешеләрне үстерделәр. Хезмәтне оештыручы бригадирлар — безнең алтын фондыбыз. Аларның күпчелеге КамАЗ төзелә башлаган көннәрдән бирле эшли. Мәсәлән, Наурбиев, Панков, Новицкий, Альчиков, Иваницкий, Зотов, Геворгян, Галак, Сәлахов һәм башкаларның исемнәрен кемнәр белми?..

Җиденче агрегатны җибәрәсе көн якынлашып килә иде. «Камгэсэнергострой» берләшмәсе начальнигы Евгений Никанорович Батенчукның бүлмә тәрәзәләреннән гидроэлектростанция панорамасы тулысы белән күз алдында. Бер уйласаң, шушы плотина бетонына күпме язмышлар береккән, күпме кешенең хәләл хезмәте салынган... Шуның өчен дә шул борынгы Чулман елга дулап-борчылып карый да, мәңгелеккә дип салынган ныгытмаларга бәрелеп, кире чигенә. Кешеләрнең рухына бәреләләр алар. Ашкын йөрәкле кешеләр рухына. Алар нык, мәңгелек.

# Равил Вәлиев

# СИРЕНЬНӘР



Ай азагы җиткәндә КамАЗның баш конвейерында вакыт исәбе минутлап-секундлап санала. Автомобиль җыю заводының производство-диспетчерлык бүлеге башлыгы Першко еш кына:

— Геологлар белән диспетчерларны аяклары туендыра,— дип әйтергә ярата. Һәм бераздан, әрекмән яфрагыдай киң галстугын тагын да кысып бугач, өстәп куя: — Бүреләрне дә!

Кайберәүләр мондый чакта:

— Анатолий Тихонович, һәр кешегә дә бүре булып улау сәләте бирелмәгән ич! — дип акланырга керешәләр.

— Ә мин баш конвейерда өлкән диспетчер булып эшләгәндә, кесәмә гел тәмле конфетлар салып йөри идем... Кирәге чыкса, чибәр туташларга бирү өчен...

Ай азагында безнең эше диспетчер халкына былбыл булып сайрарга да кирәк икән, Першко әйтмешли, бүре булып уларга да туры килә. Тик кирәкле деталь генә табылсын, тик конвейер гына туктап калмасын!

Баш конвейерда хезмәт киеренкелеге бүтән көннәрне дә кимеп тормый, анысы. КамАЗ предприятиеләре проектта каралган куәткә әле һаман ирешә алмаганлыктан, еш кына я тегесе, я монысы җитеп бетми. Ә инде ай ахыры якынлаша башладымы, әҗәл даруына әйләнгән дефицит детальләрнең бермә-бер кимүен көт тә тор!

Бу чакта инде баш конвейер пультындагы өстәл телефоныннан шалтыратып утырып кына әллә ни кыра алмыйсың. Чөнки, нindидер детальне сорап, кем белән кайсы цех яки завод белән генә бәйләнешкә кермә — җавап бер:

— 064 номерлы чекамы? Лимит, туганкаем, ли-ми-ит!..

— Ничек инде лимит?

— Шулай... Бу айда тиешлесен баш конвейерга җибәреп бетердек инде.

— Алай булгач, кайда соң ул 064, кайда? Конвейердагылар әлеге каһәр төшкән детальне кабып йотмыйлар бит инде, ләбаса, үзегезгә мәгълүм булганча, автомобиль рамына беркетәләр...

— Йотмыйлар анысы, беләбез... Менә нәрсә: складыгызда «яшеренеп» ятмый микән, тагын бер тикшереп карагыз әле.

— Тикшердек инде... Бер генә түгел, ун мәртәбә тикшердек!

— Соң?

— Конвейерда эшләүчеләр тарафыннан бракка чыгарылганы бар, әлбәттә. Аларын изоляторга озаттык. Тиздән үзегездә булыр.

— Кхм-м... Ә ни өчен брак?

— Анысын инде сез белергә тиештер, шәт.

— Карарбыз...

Әнә шулай итеп, безнең көймә комга килеп терәлә.

Кайбер шомарак җитәкчеләр:

— Җибәрербез... «НЗ» фондыннан алып, ун комплект булса да җибәрергә тырышырбыз, — дип, озын-озак уйлап тормыйча, вәгъдә биреп тә ташлый. Һәм, сүзе ышанычлырак булып тоелсын өчен, өстәп тә куя әле: — Тик карагыз аны, монысы — соңгы мәртәбә! «НЗ», үзегез беләсез, Әндри казнасы түгел! Бары баш конвейер хакына гына...

— Ун комплект?.. Ул бит баш конвейерның кече теленә дә йокмый!

— Амин диген!.. Анысын бирергә дә директорыбыз риза буламы әле, юкмы...

Юк, әлбәттә! «НЗ» шуның өчен дә «НЗ» инде ул: аның фондыннан, гадәттә, иң кыен, иң аварияле ситуация килеп туганда гына файдаланалар. Анда да әлеге авыр хәл теге яки бу заводның үз гаебе аркасында килеп чыкса гына.

Ә инде коры вәгъдәне, ул нихәтле генә юату көченә ия булмасын, автомобиль рамына беркетеп куя алмыйсың. Автомобиль рамына беркетү өчен деталь кирәк!

Ниләр күреп, ниләр генә кичерми ай азагында конвейер диспетчерының газиз башкае! Аягың тәпелдәмәсә, авызың чәпелдәмәс дигәндәй, кайларга барып, нинди генә ишекне шакып керергә туры килми аңа! (Бик тәпелдәмәс идең дә, бөтен КамАЗның күзе бездә — бүтән заводларның да ай буе ничек эшләве баш конвейердан күпме автомобиль төшүгә карап бәяләнә шул!

Ә менә УСП (Арадаш предприятиеләр идарәсе) складларында дефицит деталь юк икән, Першконың үзе булсаң да эшләр барыбер пешми. Чөнки бирегә детальләр Советлар Союзының йөзләгән шәһәреннән генә түгел, хәтта чит илләрдән дә китерелә. Аеручa ашыгыч булганнарын самолетлар ташый. Әнә шуңа күрә көннәр аз гына бозылып киттеме, тоткарлык килеп чыгачагы көн кебек ачык!

Менә бүген дә, май аеның иң соңгы көнендә, Башкортстанның, Бәләбәй шәһәреннән чәнти бармак кадәрле генә 853302 номерлы шпилька кайтып җитмәү аркасында баш конвейерыбыз сәгать буе диярлек туктап торды. Бу безнең тез астына китереп суккандай булды. Болай да айлык графиктан көч-хәл белән генә калышмый бара идек. Инде менә, тик торган вакыт өчен, тагын өстәмә рәвештә унбишләп «КамАЗ»ны конвейердан төшереп өлгерергә кирәк. Барысын бергә кушсаң, смена азагына хәтле калган ике сәгать эчендә кырык биш автомобиль җыелырга тиеш булып чыга. Бары тик шушы очракта гына айлык план уңышлы үтәләчәк.

Сәгатенә егермедән артык автомобиль!

Әйтергә генә ансат: инде ничәнче елын эшләүче баш конвейерда мондый күрсәткечкә әле бер мәртәбә дә ирешелгәне юк иде. Өстәвенә, шимбә көн булу аркасында, баш конвейерның бер генә линиясе һәм бер генә сменада эшләвен исәпкә алсаң... Атна буе шөреп-гайка борып арыган, бүген исә төшке ялга да туктап тормаган (кыска көн!) автомобиль җыючыларга, күрәсең, тагын калып эшләргә туры киләчәк инде!..

Менә шундый үтә җаваплы һәм киеренке минутларда, тыгыз җиргә — тыгынчык дигәндәй, баш конвейер буйлап килүче туристлар төркеме күренде. Кайсылары иңнәренә фотоаппарат, кайсылары уч төбенә сыярлык кына транзистор аскан. Сирень чәчәкләре тоткан бер егетнең транзисторы исә Казан радиосы дулкынында сөйләп үк тора. Эфирда шимбә концерты бара иде. Гали Ильясов җырлый...

Туристлар икән, туристлар! Аларга инде биредә күптән иялəшеп беттелгән: Парижга барган һәркем иң башлап атаклы Эйфель башнясына ашкынган кебек, Чаллыга килгән кеше дә, әлбәттә, үзенең иң беренче бурычы итеп баш конвейерны күреп китүне саный.

«КамАЗ» автомобиле рамына барлыгы сигез мең деталь беркетелә. Шуны күздә тотып булса кирәк, баш конвейерда эшләүчеләр арасында хәтта әлеге туристларны «сигез мең дә беренче деталь» дип йөртү дә гадәткә кергән. Шаяртып, әлбәттә!

Тик «В» сменасы начальнигы Сәгыйть Шәйхуллович Кашаповның гына бүген туристларга карата талканы корырак булып чыкты:

— Тапканнар вакытын да!.. Куянга — җан кайгысы, аучыга — мал кайгысы! — дип куйды ул, телефоннан сөйләшүеннән бүленеп.

Ул арада, кайсыдыр позицияләрдә тоткарлык чыгуны белдереп, сигнал пультында бер-бер артлы кызыл утлар кабынды. Шул мизгелдә үк, болында чикерткәләр сайрашуына охшап, өстәлдәге телефоннар телгә килде.

— Оһо-о!.. Фей-йер-верк! — дип куйды Сәгыйть Шәйхуллович һәм, бер телефон трубкасын колагыннан алмаган хәлдә, икенчесенә — кызыл төстәгесенә үрелде.— 111нчеме? Нигә дип туктап калдың әле анда, Хөснетдинов? Тотма конвейерны! Өлгермибез, имеш!.. Өлгермисең икән — уздырып җибәр: 011нче трубаны соңыннан да куярга мөмкин.

Әйе, Кашаповның бу минутлардагы хәлен аңларга була иде. Бөтен сменада башкарылган эш өчен җаваплылык — аның җилкәсендә. Ул конвейерда төп хуҗа кеше!

Ай азагында Кашаповка йомышның төшәргә ямасын. Ике колагында — ике те-

лефон, кулында өченчесе булыр. Әгәр дә инде куллары җитми башласа, телефон трубкасын колагына кысып торырга җилпучтай киң иңбашлары ярдәмгә килә. Алар гына аз булса, каршысында рация! Селекторлысы да, селекторсызы да...

Соклануlары йөзләренә чыккан туристлар, теге яки бу позиция турысында тук-тала-туктала, баш конвейер янәшәсеннән баруларын дәвам иттеләр. Егерме икенче позициядә алар гадәттәгедән озаграк тукталып тордылар.

Моның сәбәбе биредә Татарстан Верховный Советы депутаты Шәүкәт Хөснетдинов җитәкләгән атаклы бригада эшләүдә генә түгел иде, әлбәттә. (Илебезнең бар почмакларыннан диярлек агылып торган туристлар бу хакта каян белеп бетерсен соң әле?!) Моның хикмәте, миңа калса, шасси җыю участогындагы беренче позициядән бирле «чалкан» ятып килгән автомобиль рамының, әлеге турыга җиткәч, очучылар теле белән әйтсәк, «үлем элмәге» ясап алуында иде. Гигант торнаны хәтерләткән механизм, корыч «томшык»лары белән рамның баш-башларыннан электерә дә, күз ачып йомганчы аны йөзтүбән каплап та куя. Һәм шушы гаять җаваплы операцияне кем башкара дисез? Бияләй хәтле генә гәүдәле Гөлүсә Җаббарова! Кулындагы бәләкәй пульт төймәләре белән ул шул хәтле оста идарә итә — моңарчы инде шасси участогында алгы һәм арткы күчәрләр төрле зурлыктагы кардан валлары, штанга-баллоннар кебек эре детальләр белән авыраеп өлгергән автомобиль рамы, һич карышусыз, конвейерның корыч иңсәләренә менеп ята һәм салмак кына алгы позицияләргә таба йөзеп китә.

Менә туристлар, бу сокландыргыч тамашаны күреп ләззәтләнгәч, акрынлап, баш конвейер очына таба үтеп беттеләр. Тик теге сирень чәчәкләре күтәргән егет кенә, «көтүдән» аерылып калуын сизмичә, сихерләнгәндәй басып торуын белде. Биек иңбашына эленгән транзисторыннан һаман җыр агыла үзенең:

**Сине күреп, бар табигать,**
**бар табигать сөенгән.**
**Әллә инде өзелгәнсең,**
**өзелгәнсең сиреньнән!**

Юк, Гөлүсә Җаббарова «сиреньнән үк өзелеп төшәр» дәрәҗәдә чибәр түгел иде түгелен. Ара-тирә сипкелләр кунгалаган озынча битле йөз. Соргылт чәч. Колак яфракларыннан асылынып торган борчак кадәрле генә алкалар. Еш юылып торудан инде төсен югалта башлаган зәңгәр спецовка. Егетне, кызның килеш-килбәтеннән бигрәк, бүтәннәрне сокландырырлык итеп эшли белүе сихерләгән иде, шәт.

Менә ул, ниһаять, башкалардан аерылып калуын төшенеп, алга таба талпынып куйды. Ләкин күңеле, йөрәге белән, ирексездән, Гөлүсә янына тартылды.

— Менә... Конвейерда эшләүче иң чибәр туташка бирермен дип җыйганыем. Үзебезнең бакчаныкы... Ык буе чәчәкләре...— диде ул, сирень бәйләмен Гөлүсәгә сузып.

Үзен иң чибәр дип атаганда, кайсы кызның күңеле тыныч кына кала алсын инде? Бу минутларда Гөлүсә Җаббарованың да чокырланып кергән бит урталары, түшендәге комсомол значогы төсле, кызарып чыккан иде:

— Рәхмәт!.. Абау нинди хуш иселәр!.. Җәл булмадымы соң? Бакчагыздан өзүе диюем...

— Түгел лә-ә... Барыбер бөтен авылыбыз диңгез астында каласы! ГЭС төзелеп беткәч, кәнишне!

— Ә аннары?

— Аннары дип... Күз күрер әле. Бәлки сезнең янга — машиналар җыярга киләсе булыр...

Җылы гына саубуллашты да Ык егете, йөгерә-атлый иптәшләре артыннан китеп барды. Ләкин транзисторыннан өзелеп калган соңгы җыр юллары Гөлүсә Җаббарованың колак төбендә озак яңгырап торды әле:

**Мөмкинме соң танышырга,**
**кавышырга сиреньсез!**

Зәңгәр тәлгәшләрдән бөркелгән хуш ис Гөлүсәнең бөтен җанын иркәләде. Учка алу белән эреп китәрдәй бигрәк йомшак, бигрәк назлы иде шул быелгы язның

беренче чәчәкләре! Аның иртәдән бирле конвейерда автомобиль рамнары «йөздереп» арыган тән-буыннарына яңа көч, яңа куәт өстәлгәндәй булды. Смена азагына хәтле калган бер-ике сәгатьтә генә түгел, тагын ун, егерме сәгать конвейерда басып эшләсә дә, ул үзен мәңге армастай хис итте.

Кинәт Гөлүсәнең бу шатлыкны бүтәннәр белән дә бүлешәсе килеп китте. Ул, күперәп торган чәчәк бәйләмен йөзенә якын ук китереп соңгы мәртәбә иснәде дә, аны каршыдагы автомобиль рамының ниндидер деталь беркетелергә тиешле уентыгына кадап куйды.

Китте агып конвейерда сирень чәчәкләре! Бер позициядән — икенче позициягә, бер йөрәктән икенчесенә...

Гөлүсә Җаббарова исә шасси участогыннан килгән автомобиль рамнарын төп конвейер иңсәләренә бер-бер артлы яткырып кына торды. Смена азагы якынлашкан саен, тимер ташкын тизрәк ага барды. Әнә инде үзәк пролет өстенә эленгән кара таблода, утлы лампочкаларын җемелдәтеп, «5980» саны биешә башлады. Димәк, айлык планны тутыру өчен, егермеләп кенә автомобиль җыясы калып бара дигән сүз!

Смена азагында эшнең шулай майлагандай баруын күреп, конвейер начальнигы урынбасары Кашапов та җиңел сулап куйды. Ул, сигарет алырга теләп, кесәсенә тыгыла башлаган гына иде — өстәлдәге телефоннарның тагын берсе чылтырап куйды. Бу юлы сигнал пультында, кайсыдыр позициядә конвейерның туктап калуын белдереп, кызыл ут та янмаган иде, югыйсә. Шуңадырмы, Кашапов гаҗәпләнүдән иңбашларын сикертеп куйды һәм телефон трубкасына үрелде:

— Җитмешенче позицияме?.. Тагын нинди деталь җитми, Сычев? Деталь җитә, сирень чәчәкләре? Ә-ә!..— Сәгыйть Шәйхулловичның борчулы йөзе кинәт ачылып-яктырып китте.— Тәк, тә-әк... Кабинаны урнаштырганда сиреньнәр комачау иткән... Димәк, Титов бригадасы чәчәкләрне конвейерга кабат куеп тормаган?.. Димәк, конвейер очындагыларның да сирень иснәп карыйсы килә?..

Кашапов трубканы телефонга куйды да тиз генә кире алды:

— Надя, кырык алтынчы позицияне тоташтыр әле, зинһар!.. Кәтәм... Нәрсә? Сөйләшәме?

Ләкин Кашаповның бу юлы телефон бушаганын көтеп торырга сабырлыгы җитмәде. Ул, тиз генә рацияне тоташтырып, кулына микрофон алды:

— Игътибар!.. Смена начальнигы Кашапов сөйли... Бригадир Титов, кичекмәстән сирень чәчәкләрен конвейерга куегыз! Кабатлыйм...

Без, пыяла будкада Сәгыйть Шәйхуллович белән янәшә утырган диспетчерлар, ирексездән, бер-беребезгә карашып куйдык. Артык шау-шу ясап, автомобиль җыючыларга комачау итмәс өчен, конвейер микрофоныннан, гадәттә, иң ашыгыч, иң кирәге чыккан минутларда гына файдаланыла. Анда да сүз бары тик исемнәре ниндидер шартлы кодларга, катлы-катлы саннарга төренеп беткән детальләр хакында гына алып барыла. Менә шуңа күрә, бөтен конвейер буйлап яңгыраган ниндидер сирень чәчәкләре турында ишетү безгә бик сәер һәм... тансык иде.

Смена тәмамланыр алдыннан, мин җитмешенче позициягә китеп бардым. Конвейер очындагылар сирень чәчәкләре турында каян ишетеп өлгергәннәр диген! Кызык, барып җитә алырмы әлеге чәчәкләр анда, әллә юкмы?..


Юкка шикләнгәнмен икән. Мин барып җиткәндә, кабинасының алгы ягында бер бәйләм сирень чәчәкләре тирбәлешкән яңа «КамАЗ» нәкъ менә җитмешенче позициягә якынлашып килә иде.

«КамАЗ» белән бергә, баш конвейердан автомобиль җыючыларга күпме шатлык, күпме көч өстәгән сирень чәчәкләре дә төште!

Яңа автомобиль үз «аяк»лары белән йөреп китүгә, мин үзәк пролет өстендәге электр таблосына күтәрелеп карадым. Бу вакытта анда, күңелләрне сөендереп, безай буе көткән «6000» саны яна иде.

Фәтхулла Абдуллин

# КӨМЕШ ТӘҢКӘЛЕ НИГЕЗ



Бусагада чигәләре чалара башлаган хуҗа күренде, беркемгә дә игътибар итмәде, өйдәгеләр белән җиңелчә генә исәнләште дә, ишектән керүгә, телефонга үрелде.

— Владимир Дмитриевич! Сез бүген Әлмәткә барып кайттыгызмы? — диде ул телефон чыбыгының икенче очындагы кешегә. Тегесе, күрәсең, кушылганны эшләмәгән иде бугай. Кәрим Хәмидулловичның болай да сүрән йөзе тагын да кырысланды.— Беләм, Владимир Дмитриевич, беләм. Тәүлектә егерме дүрт кенә сәгать икәнен дә беләм. Тик, зинһар, акланып маташмагыз. Яратмыйм шул сыныкка сылтау эзләүчеләрне...

Аннан соң ул тагын кемнәргәдер шалтыратты, кемнәргәдер кызып-кызып исбат итте, бәхәсләште, таләп итте. Бәләкәй Равил әтисенең сүзләрен тыңлап торды-торды да, туктар исәбе булмагач:

— Безнең әти бүген тагын УГБ белән үпкәләшкән икән,— дип, бүлмәсенә уенчыклары янына кереп китте.

Ил күләмендә генә түгел, түгәрәк җир шарында тиңнәре сирәк булган этилен комплексын сафка бастыргандагы кайнар көннәр иде. Канализация һәм су торбалары, җылылык һәм газ трассалары үткәрүче «Спецстрой» төзелеш идарәсенә цехлардан чыккан пычрак суны чистарту корылмасына агызу өчен юан-юан торбалар салырга кирәк иде. Төзүчеләр өчен күнегелгән эш: тиешле тирәнлектә траншея казы да торба сал. Идарәдә тәҗрибәле белгечләр дә җитәрлек. Ә эш җитди, катлаулы. Торбаларның диаметры зур (1200 мм), никадәр промышленность объектлары аша чыгасы. Тагын да кыенрагы: тимер юл станциясен кисеп үтәргә кирәк! Проект төзүчеләргә җиңел: станция аша үтәсе дип сызганнар да куйганнар. Ә ничек үтәргә? Дөрес, проектта «җир астыннан» диелгән.

Борының белән боз ярсаң да, үз эшеңне төгәл, графикта күрсәтелгән вакытта үтәргә тиешсең. Һәм, чыннан да, һәркем шуны аңлап эш итә.

Менә шулай: Кәрим Хәмидулловичның кылны кырыкка ярырдай булып йөргән көннәре. Ә алар башкарасы эш уйлаганнан мәшәкатьлерәк булып чыкты. Мәртәбәле киңәшмәләрдә мәсьәлә бер генә тапкыр тикшерелмәде. Бүгенге киңәшмәгә тимер юлчыларны да чакырганнар иде.

— Әйләнеп үтегез! — диделәр алар.— Станциянең утыздан артык юлын сүтеп җыюга караганда, перегондагы бер юл аша чыгу җиңелрәк булыр. Кирәк вакытта «тәрәзә» бирербез.

Тимер юлчыларның тәкъдименә киңәшмәдәгеләрнең күбесе кушылды: бер генә юлны сүтү отышлырак. Мәсьәләне хәл ителгәнгә санап, китәргә үк җыена башладылар. Кәрим Хәмидуллович кына, үзалдына уйланып, блокнотына нидер сызгалап утыра бирде.

— Тагын өч чакрым торба кирәк булачак. Ничаклы эш өстәлә,— диде ул, барысына да ишеттерерлек итеп.

— Өстәлсә, сезнең идарәгә эш! — диде кемдер.

— Менә бәхет! — диде «Промстрой» начальнигы күршесенең кулбашына дусларча кагылып.— Ничаклы эш көне әрәм итеп, бер урыннан икенче урынга күчеп мәшәкатьләнәсе юк. Эшлә дә эшлә генә. Болай булса, айлык планны 200 процентка үтисез сез!

— Эш пландамыни? — диде Вәлиуллин, коңгырт күзләрен күршесенә төбәп.— Металл күп китәчәк, металл!

— Китсә китә инде! — диде заказчы, исе китмәгән кыяфәттә кулларын җәеп.— Ил күләмендәге мөһим объект. Өч чакрым торбага карап торып булмый.

Тик менә...— Ул эшнең җитдилеген үзе дә сизеп, башын селкеп куйды.— Кемгәдер Мәскәүгә торбалар сорап барырга туры киләчәк.

Кәрим Хәмидуллович бирешмәде:

— Әйләнеп үткән очракта су агар өчен тиешле авышлыкны саклап калып булырмы соң? Моны трассаның топографик сызымын алмаган килеш ничек әйтә аласың?

— Монысы вак мәсьәлә! — диде проект институты вәкиле.— Өч-дүрт урынга насос куярбыз да басым белән кудыртырбыз.

— Ә насос станциясен төзүне кем үз өстенә ала? — диде партиянең өлкә комитеты вәкиле Калабухов.

Кәрим Хәмидуллович һаман тынмады.

— Ә нигә кирәк ул өстәмә чыгымнар? Без инженерлармы, түгелме?

Кемдер, канәгатьсезлек күрсәтеп, борын астыннан гына мыгырданып алды:

— Бәхәсләшергә, «мөгез чыгарырга» дисәң, Вәлиуллинны куш инде.

«Мөгез чыгару» дигәннән, әле үткән айда гына Кәрим Хәмидулловичның тәкъдиме белән алар бер участокта җылылык торбаларын әзер эстакада өстенә күтәргәннәр иде. Алай иткәч, җир казыйсы да, лотоклар саласы да булмады, ничәмең сум акча янга калды.

— Алайса, мәсьәлә бүген дә хәл ителмәгән килеш кала, иптәшләр! — диде өлкә комитеты вәкиле.

Вакыт соң иде инде. Иртәгә эштән соң тагын җыелырга булып таралыштылар. Икенче көнне дә, өченче көнне дә мәсьәлә ачыкланмады. Киңәшмәдәгеләр икегә бүленде. Проект институты вәкилләре һәм заказчылар, ничаклы юл сүтеп мәшәкатьләнгәнче дип, бертавыштан станцияне әйләнеп үтүне хупладылар. Институттагылар ул участокның топографик сызымын алырга хәтта инде геодезистлар җибәргәннәр иде. Шулай булгач, алар башка фикерне гел кире кактылар.

— Акчасын без түлибез! Безгә тизрәк кирәк! — диделәр заказчылар да.

Субподряд оешма вәкилләре генә торбаларны тимер юл астыннан сузуны өстен күрделәр. Алай иткәндә, өстәмә чыгымнар сарыф ителмәячәк иде. Исбат итә торгач, аларга «Химстрой» җитәкчеләре дә кушылды. Чөнки станцияне әйләнеп үткән очракта торба салу «Спецстрой» идарәсе өстендә калса да, насос станциясен төзү, генподряд оешма буларак, алар җилкәсенә төшәчәк иде.

— Горизонталь бораулау җайланмасы — УГБ агрегаты булса! — диде Кәрим Хәмидуллович.— Тимер юл астына өелгән балчыкны тишеп кенә үтәр идек. Поездлар хәрәкәтенә дә зыян килми.

— УГБ да УГБ! — диде өстәл башында киерелеп утырган заказчы.— Юкны каян аласың инде?

Икенче көнне Кәрим Хәмидуллович Әлмәткә чыгып китте. «Татнефть» берләшмәсенә кереп, горизонталь борау эзләп йөрде.

— Вертикаль бораву бар. Рәхим итегез! Җир шарын үтәли тишә аласыз! — диделәр нефтьчеләр шаяртып.— Ә сезгә кирәклесе, гафу итегез, юк.

Болай булса, заказчылар әйткәнчә, станцияне әйләнеп үтәргә туры килер микәнни?

Бер чыккан юл дип, «Спецстрой» начальнигы үзе төзелештә беренче адымнарын атлаган шәһәргә — Лениногорскига сугылып чыгарга булды. Аны ачык йөз белән каршы алдылар.

— Сез зур эшләр майтарасыз икән. Радиодан да, газеталардан да көн саен сезнең хәлләрне сөйләп кенә торалар. Чын булса, хәтта Мәскәү кешеләре сезнең белән бүрек салып күрешә диләр.

Вәлиуллинның сүрән йөзе беразга гына яктырып китте.

— Ышанмагыз сез аңа, Иван Маркович, бу кадәресен журналистлар арттырадыр инде.

Иван Маркович очрашудан канәгать иде.

— Ә шулай да молодец! Яңа төзелешкә китеп, син бик дөрес эшләдең.

Хәл-әхвәл сорашкач, ул гозерен әйтте:

— Юк шул! — диделәр аңа.— Булса, кызганмас идек.

— Иван Маркович, хәтерем ялгышмаса, бар иде бит алар.

— Ә без аларны гамәлдән чыккач, тураклап металл ватыгы итеп тапшырдык инде.

Кәрим Хәмидуллович монда зур өметләр баглап килгән иде. Булмады. Ә бәлки туры Ленинградка кеше җибәрергәдер? УГБ ясый торган заводның үзенә. Кызганычка каршы, ул агрегатны анда да серияләп чыгармыйлар, бер ел алдан бирелгән махсус заказ белән генә эшлиләр булып чыкты. Дөрес, ел ахырына бер агрегат эшләячәкләр икән. Тик ул инде БАМга тәгаенләнгән. Шулай итеп, ул агрегатны кулга төшергәнче, Түбән Кама төзүчеләренә тагын бер ел көтәргә туры киләчәк икән. Ә бит аларга бүген үк кирәк! Хәзер үк!

*
* *

Кәрим Хәмидуллович, көндәгечә, төштән соң икенче каттагы бүлмәсенә күтәрелде. Идарә җитәкчеләрен җыеп, тагын бер кат сөйләшәсе килде. Шул чак секретарь кыз аңа кәгазь сузды.

— Кәрим Хәмидуллович, сезгә телеграмма!

Ул Лениногорскидан Иван Марковичтан иде. Анда нинди могҗиза беләндер металлга тапшырылмый калган бер агрегат табылганын әйткәннәр. Күп частьләре юк. Кирәк тапсагыз, килеп алыгыз дигәннәр.

Төзүчеләр өчен күктән төшкән бәхет иде бу. Кәрим Хәмидулловичның шатлыгы йөзенә бәреп чыкты. Ниһаять, агрегат табылды. Лениногорскига шундук йөк машинасы җибәрделәр. Алып кайткач, аны аякка бастыру өчен күп көч түгәргә туры килде. Әмма, ни дисәң дә, төзүчеләр кулында хәзер җирне горизонталь тишә торган агрегат бар иде инде. Тик шатланырга иртәрәк булган икән шул әле. Аны көйләп, метр ярым җир үтелдеме-юкмы, мотор сүнде.

— Ә бәлки, безнең исәп-хисап дөрес булмагандыр? — диде прораб.

— Ул чагында кискеч я аска, я өскә китәр иде,— диде Кәрим Хәмидуллович инженерларга хас ышаныч белән.

Сәбәбе кискечне кире алгач кына мәгълүм булды — каты токымга эләккәннәр икән. Ә бу горизонталь бораy өчен хәтәр нәрсә — ул фәкать йомшак балчыкны тишәргә генә исәпләнгән. Тизлекне бермә-бер киметергә туры килде. Инде кыенлыклар бетте дип, сөенешеп кенә торганда, каяндыр су бәрә башлады. Траншея-туннель су белән тулды. Суны суыртыр өчен насос куйдылар. Эшнең барышы белән кызыксынырга килгән заказчы җәйге челләдә саз итекләре киеп траншеяда эшләп йөргән сварщикларны күргәч, әйтә куйды:

— Кәрим Хәмидуллович, сез безне Иван Сусанин кебек сазга батырмакчы икәнсез. Ул да французларны сазлыкка шулай батырган.

— Ялгышасыз, Александр Павлович. Иван Сусанин полякларны батырган ул.

— Тагын бәхәсләшәсез! — диде заказчы ирония белән.

— Дөреслек өчен бәхәсләшсәң дә ярый.

— Ә минемчә, Иван Сусанин сазга французларны батырган,— диде заказчы.

— Юк, полякларны!

— Бәхәсләшәбезме!

— Риза!

Ирләр кул сугышты.

— Бигрәк сулы участок икән, торбаларга тагын бер кат изоляция ясагыз! — диде заказчы саубуллашканда.— Акчасыннан тормабыз.

— Ярар, эшләрбез.

Өч чакрым өстәмә торба белән чагыштырганда тагын бер кат изоляция ясау тиеннәр генә иде инде.

— Кәрим Хәмидуллович, ә сез ул Сусанинны каян хәтерлисез? — диде прораб заказчы киткәннән соң.— Алтынчы класста укыган тарихны онытткан булсагыз да гаҗәп түгел ич.

Кәрим Хәмидуллович яшь һәм әле төзелештә беренче адымнарын гына ясаучы егеткә сынап карады.

— Үзең ничек уйлыйсың? Тәгаен белмәгән килеш бәхәсләшер идеңме?
— Юк.

*
* *

Бу арада эштән гел соңга калып кайта торган Кәрим Хәмидуллович бүген, ниһаять, өйгә үз вакытында кайтып керде. Зәкия ханым моңа ышаныргамы, ышанмаскамы дигәндәй, бер — сәгатькә, бер иренә карап алды. Кирпеч шакмаклары, уенчык экскаватор, бульдозерлар белән уйнап йөргән Равил, этисе кайтып керүгә, аның кочагына ташланды.

— Эти, эти! Акча бир әле!

Кәрим Хәмидуллович аптырап китте.

— Ә нигә кирәк ул сиңа?

— Мин зур йорт салам, эти. Шуның нигезенә акча салырга кирәк!

— Моңа сине кем өйрәтте?

— Әни әйтә, яңа йорт башлыйсы булсалар, этиең кесә тутырып көмеш тәңкәләр алып китә торганые,— ди.— Үзең дә бит көмеш тәңкәле нигез бәхетле була дисең.

Әйе, 1960 елның салкын декабренда алар да Түбән Кама шәһәренең нигезен көмеш тәңкәләр салып башлаганнар иде. Кешеләр бәхетле, мул тормышта яшәсен дигән изге теләк белән. Аларның хыялы тормышка ашты: Түбән Кама туфрагында үзләренең көмеш тәңкәле нигезен тапкан ничәмә мең гаилә гомер кичерә. Ул үзе дә монда килеп, көмеш тәңкәле нигезен — бәхетен тапты.

## Фаяз Дунай

# ДӘҮ АПА



Октябрь таңы сызылган еллар булган бу. Сөялле куллары на яу кылычлары алган ярлыларның я үләбез, я гомерлек хөррият язына киләбез дип изүчеләргә каршы хәлиткеч көрәшкә күтәрелгән утлы-яшенле гарасат еллары.

Ул чакта Минзәлә өязе дә утлар боҗрасы эчендә калган. Ирләрен, якыннарын яу кырларына озаткан меңнәр сыман, Шәмсиҗамал да бу хәвефле чакта «Исәнме икән, саумы икән? Аклар кулына юлыгып, хараплар гына булмадымы икән?» — дип, ире Гани өчен ут йотып, керфек какмый төннәр уздыргандыр, күндезләрен, моңлы күзләре талганчы, туплар гөрселдәгән тарафларга карап, курка-курка уйланып торгандыр. Ә шәфәкъ ялкыннары сүнеп, җиргә эңгер иңгән ямансу кичләрдә, аксыл ефәк чәчле, зәңгәр күзле кызчыгын тезләренә утыртып, җырлап алган чаклары да булмый калмагандыр.

Ләкин Гани яу кырыннан кайта алмаган. Арысланны аударырлык йөрәк белән дошман өстенә ташланганда, утлы ядрә аны бу мәхшәрле дөньядан үкенечле тынлыкка алып киткән...

Әле яңа тәпи баса башлап, кояшлы тәрәзәдә лептердәшкән күбәләкләрне исе китеп күзәткән кызчык ана башына килгән кайгы-хәсрәтнең тирәнлеген, яшьли тол калган ана йөрәгенең сызлануын аңларлык түгел әле.

— Әтиең юк шул инде, ии, балам! Яуда шәһит булган, кызым. Күңелең китек үсәр инде. Ятимлектә, типкенлектә узармы икән, ии, гомеркәйләрең...

— Дәү булып үс, кызым, яме. Тырышып укы, кызым, яме! — Зәңгәр күзле кызыйның калын толымнарын зәңгәр тасма белән үрә-үрә, ана шулай ак бәхетләр тели, аны беренче кат мәктәп сукмагына озата чыга. Һәм ананың теләкләре кабул була...

Фаизә Ганиевна турында миңа төрле елларда, республикабызның төрле районнарында, белемнәре, дәрәҗәләре, һөнәрләре, холыклары белән һәрберсе үзгә булган дистәләрчә иптәшнең хатирә сүзләрен ишетергә туры килде. Хәкимовага экономик, иҗтимагый-политик шартлары төрлечә, салкын бозы да, кояшлы яңгыры да яуган, ай да тотылып торгалаган үзгә елларда төрле җаваплы вазифалар башкарырга туры килгән. Тормыш кырыс, гомере буе кешеләр белән җитәкче эштә эшләү җиңел түгел — төрле чаклары булгандыр. Әмма аның үзәк һәм иң даим асыл сыйфатларын — соклангыч миһербанлы, аяулы һәм бөркет йөрәкле ир-егетләрчә тәвәккәл булуын кемнәр генә олылап, сагынып искә алмый?

Аңа җидееллык мәктәпне тәмамлагач ук үз хезмәт юлын башлап китәргә туры килгән. Шаулы беренче бишьеллыклар чоры. Социалистик төзелеш авылларда да тормышны тамырыннан үзгәртеп кору юнәлешендә бара. Кешеләрдә яңа аң, якты рух, дөньяга материалистик караш тәрбияләү, үзара социалистик мөнәсәбәтләр урнаштыру — көрәшнең үзәгендә тора. Яшь буынны укыту һәм тәрбияләү дә төп бурычларның берсе санала. Бу чорда Ленин комсомолы искиткеч дәрт, романтик канатлану белән сугышчан походлар оештыра. РСФСРның мәгариф халык комиссариаты һәм ВЛКСМ Үзәк Комитеты «мәктәпкәчә поход» дигән чакыру игълан итәләр. Комсомолның Минзәлә райкомы вәкиле буларак, зур, тынгысыз эшләрдә зәңгәр күзле, толым-толым куе алтын чәчле ундүрт яшьлек кызый — Фаизә Хәкимова да бөтерелеп йөри башлый. Башын иеп, кушканны гына көтеп тормый, үзе дә белеп эшли, күп укый, өлкәннәрдән тарсынмый сораша, җаваплылыктан тайчынмый торган гадәтен сизенеп алгач та, «өлкән комсомол абыйлар» шушы ундүрт яшьлек Фаизәне яңа пионерлар лагере оештырырга җибәрәләр. Үзе юлбаш-вожатый да, завхоз да, начальник та.

«...Я батам, я калкам дип, күз йомып суга сикергән кешедәй, бары үз йөрәгемә ышанып, беренче кат пионерлар алдына чыгып бастым да, анысын хәтерләмим инде, ни хактадыр, ии, кызып-кызып сөйләргә тотындым. Тисә тиргәккә, тимәсә — ботакка. Бер мәл кайсыдыр сүзнеме, саннымы онытып буталып калдым. Балалаларга текәлебрәк караган идем, ии, әнекәем, мөлдерәп торган йөзләп күз! Һәм барысы да: «Әй, апаем, син үзең дә безнең ише генә шул әле. Акыл бирмәек буласың тагы...» дип, эчтән көләләр сыман тоелды. Йөрәгем жу итеп китте. Тәнәфескә чыккач, кысылган йодрыкларымны ачкан идем — бер уч чәч! Дулкынланудан аптырап, толымнарымны йолкыганмын икән...»

Бераздан, әлегә хисләрен дә яшерергә өйрәнеп җитмәгән тәвәккәл кызның карусыз хезмәтен, якты максат, ихлас ашкынуларын күреп, аны комсомол райкомына бүлек мөдире итеп күтәрделәр.

Социализм өчен көрәш, яңарышларның һәр мәйданында ул чорда Минзәлә районы яшьләренең алгы рәтләрдә атлаулары күп елъязма-документларга теркәлеп калган. Бу истәлекләрдә «эшне ударникларча башкаручы, большевикларча кыю, тырыш комсомолка» Фәизә Хәкимова исеме дә еш кына пафос белән телгә алына.

Мәшәкать-сөенечләре белән һәр максатлы көнне бизәп, удар еллар сизелми дә уза, тормыш-көрәш дулкынында буыннары гына түгел, холкы да ныгый, колачкарашлары киңәя бара — Минзәлә хезмәт ияләре егерме яшьлек Фаизәне район Советы башкарма комитеты председателе урынбасары итеп сайлыйлар. Ә бер елдан Татарстан Верховный Советына депутат. Ул үзенең «Депутатлык эшемә бер ел» исемле мәкаләсендә: «Узган ел минем өчен гүзәл ел булды. Бу ел минем гомеремдә бервакытта да онытылмас. Сайлаучылар миңа зур хөрмәт һәм ышаныч күрсәттеләр. Мин гомерем буе халыкның бу ышанычын акларга тырышырмын»,— дип илһамланып яза. Һәм шушы якты антын, халыкның хөрмәтен ул изге амәнәт, зур мәртәбә итеп кырык елдан артык, соңгы сулышына кадәр саклап-аклап

яшәде, илебезнең ал байрагы эмблемасы булган депутатлык билгесен зур горурлык белән кадап йөртте.

*

* *

Сугыш башлана... Дошман Мәскәүгә ябырыла. Ил язмышы барысыннан да өстенрәк. Сынмаска, сыгылмаска кирәк! Менә шундый хәвеф-хәтәрле чакта ул «Ленин байрагы» газетасында, депутат һәм ана буларак, районның барлык хатын-кызларын яуга киткән ирләре урынына басарга, изге Ватанга тугрылыклы корыч ихтыяр һәм хезмәттәге фидакарьлек белән расларга чакырып мөрәҗәгать белән чыга.

...Халкыбызның горурлыгы — Муса Җәлилнең шул киеренке вакытларда Минзәләдә хәрби курсларда укуы мәгълүм. Бүген-иртәгә ут сызыгына чыгып китәр алдыннан да Минзәләдә булган көннәрен искә төшереп, каһарман шагыйрь Мәскәүдән район Советы башкарма комитеты председателе исеменә җылы хат язган. «Минзәләдә булган аз гына вакыт эчендә мин сезнең, миңа күрсәткән игътибарыгыз һәм кайгыртучанлыгыгызны күреп, үземдә Ватанны саклауга һәм әдәби эшемә чиксез зур дәрт үскәнне сиздем. Минем Ватанны саклаучы бөек Армия сафында булуымны һәм татар совет әдәбиятына күрсәткән азмы-күпме хезмәтләремне искә алып булса кирәк, Минзәләдә чакта мине Минзәлә партия һәм совет органнары җитәкчеләре аерым зур игътибар һәм кайгыртучанлык белән чолгап алдылар»,— дип яза шагыйрь (Муса Җәлил. Әсәрләр. 3-том. Казан. 1976. 557 бит.) һәм аңа «Һәр эштә ярдәм итәргә, кайгыртучанлык күрсәтергә тырышулары» өчен берничә иптәшкә, шул исәптән, Хәкимовага «тагын бер кат рәхмәтен һәм кайнар сәламен» җиткерә. «Сезнең бу кадер-хөрмәтегезне фронтта булсын, әдәбиятта булсын, чын эш белән акларга сүз бирәм»,— дип, ант сүзләрен язган рух баһадиры!

Фаизә Ганиевнаның бу хакта шагыйрьнең илле еллыгы көннәрендә сагыну белән елмаеп искә төшергәнен беләм. Ул шагыйрьне толыпка төреп, тик «елтыр күзләрен генә калдырып», печәнле чанага утыртып озатуларын сөйләгән иде...

Партиянең җитәкче йогынтысын бу хәлиткеч чорда аеруча көчәйтергә кирәк. Сугыш шартлары партия органнарын иң төгәл һәм оператив штабларга әверелдерүне таләп итә. Фаизә Хәкимова да бу елларда әнә шундый җаваплы штабларның берсендә — Чаллы районының «Татарстан» совхозы политбүлегендә начальник урынбасары һәм бер үк вакытта партия оешмасы секретаре.

Туган ил үзенең булдыклы кызын еллар белән бергә үстерә барган. 1944 елдан 1949 елга кадәр Фаизә Ганиевна Ширәмәттә партия райкомының кадрлар буенча секретаре булып эшли. Балачагы шул елларда узган шагыйрь Хәниф Хөснуллин моң аралаш сагынып искә төшерә:

— Ул очрашу еллар томанында якты шәүлә булып тора. Без ул чакта ферма йортында яши идек. Әнкәй сарыклар карый. Мин шунда маллар арасында уйнап үсәм. Көннәрнең берсендә өйгә ике кеше килеп керде. Колхоз җитәкчеләрен, терлекчеләрнең барысын беләм. Ат җигәргә килгән авыл кешеләрен дә яхшы беләм. Ә бу ике кешене күргәнем юк иде. Керүчеләрнең хатын-кызы әнине сорады.

Мин әнинең эштә булуын әйткәч, бу апа янындагы ир кешегә сораулы караш ташлады. Беренче күрүгә үк бик тә ягымлы күренгән әлеге апа кешенең һәр хәрәкәтен йотылып күзәтеп торганмын, күрәсең, аның бу карашы мине үтә кызыксындырды: нәрсә дияче икән? Ул арада ир кеше яшел кителенең күкрәк кесәләрен, галифе чалбары кесәләрен ниндидер бер серлелек белән караштырырга тотынды. «Монысында юк икән, тегесендәдер» дип, шаяртып әзли торгач, күкрәк кесәсеннән кәгазьгә төрелгән бармак озынлыгындагы бер әйберне алды да: «Менә кайда качып яткан икән!» — дип, аны һавада уйнатып куйды, аннары апа кешегә бирде. Апа кеше исә: «Абыең сиңа менә нинди күчтәнәч алып килгән!» — дип, кәгазьле әйберне миңа сузды. Ят кешеләрнең кинәт болай керүе, ир кешенең әлегәчә мин күрмәгән киеме, икесенең дә елмаеп карап торулары мине дулкынландырган, оялткан, күрәсең, күчтәнәчкә үрелергә кыймадым. Апа кеше бик кыстагач кына аны алып, учыма йомарладым. Апа кеше кәгазьне әрчеп, күчтәнәчне кабып карарга кушты. Әй, бик тәмле икән ул кәгазьле әйбер, бик тәмле икән ул конфет дигәннәре! Бигрәк тә әлегәчә аны татып карамаган балага!

Әнкәй эштән кайткач, бу ике кеше турында да, кәгазьле конфет турында да аңа иләсләнеп сөйләдем, аларның кемнәр булуын сораштым. Әнкәй бик якын кешесен искә алгандай:

— Фаизә апаң ул, улым. Безнең хәлне белеп йөри ул. Ширәмәттә олы урында эшли. Дәү кеше! — диде...

Еллар дәвамында миңа Мөслим, Балык бистәсе газеталарында эшләргә туры килде. Кайчакларда, җаваплы-четрекле мәсьәләләр килеп чыкканда:

— Нигә инде «беренчегә» үк шалтыратасың? — дип куркынып сораучыларга мин кырыс җавап бирәм, ә үзем бу минутларда райком белән редакцияне бер юнәлештә иңгә-иң торып атлаучы көрәштәшләр итеп санаучы Фаизә Ганиевна Хәкимованы күз алдына китерә идем.

Беркөнне: «Әйдә әле, җилләнеп, дөнья күреп кайт»,— дип, Фаизә Ганиевна мине дә машинасына утыртып, авылларга алып китте. Мөрәләгә — К. Маркс исемендәге колхозга барып кердек. Секретарь колхоз җитәкчеләреннән хуҗалыктагы хәлләрне сорашты, исемнәр, саннар атады, көлде, шелтәләп алды, урак өстендә эштә танылганнарга биреләсе бүләк-премияләрнең шартларын белеште. Аннары, партоешма секретаре Гөлсем ханым Таһированы да алып, урман буендагы җәйге туплауга, савымчылар янына киттек. Җилсенгән алсу яңаклы апалар, сеңелләр аны дәррәү урап алдылар да — көткәннәре хуш килгән! — китте тәгәрәп сер-киңәшләр йомгагы. Тарсынып тору, читенсенү юк — сүтелеп бетмәле түгел. Ә Фаизә Ганиевна үзе дә шук тел белән әңгәмә кора белә. Әмма бераздан ул кинәт кенә сорап куйды:

— Безнең Миңҗиһан кайда соң бүген? Нигә күренми ул?

— Ул авырый бит, дәү апа. Кулы шешкән. .

— Больницада ятамыни?

— Юк, өендә.

Капка төпләренә райком машинасы килеп туктаганын күргәндер, мөгаен, очынып-каударланып өйалдына бер туташ йөгереп чыкты. Чыга-чыгышлый ук Фаизә Ганиевнаның муенына сарылды да:

— Кулым бик яман шеште бит, дәү апа. Йөрәгемә төшеп сызлый бит,— дип, очынып елап та җибәрде. Ни яшерергә тырышса да, секретарьның үз күзендә дә яшь тамчылары елтырады.

— Хәзер үк больницага, Миңҗиһан! Әйдә, җыен. Ишетәсеңме? Бу сиңа — партия поручениесе!

Берәр айдан соң мин савымчы Миңҗиһанны райком баскычыннан елмаеп төшеп килгәндә очраттым.

— Исәнмесез! Ни йомыш дип... Партиягә кердем! Кандидаттан күчерделәр. Партбилетны дәү апа үзе тапшырды. Онытмаган, көлә. «Хәзер инде кулың сызламыймы, Миңҗиһан», ди...

Редакция алдына «беренче»нең биек шассилы аксыл «Победа»сы килеп туктады. Шофер абзый Чүти авылыннан кирегә утыз чакрымнар артык машина куып, мине алып китәргә кайткан. Фаизә Ганиевна «Ике-өч көнгә ниятләп килсен», дигән. Кесәгә куен дәфтәре тыктым да юлга чыктык. Тикмәгә эшеңнән бүлмәс тынгысыз «беренче».

Чүти, Чүти. Шактый катлаулы, буталчык хәтәр вакыйгалар, четрекле иҗтимагый-социаль борылышлар, яңарышлар кичергән усал, тәвәккәл, тырыш та, булдыклы да авыл ул — Чүти.

Чүтидәге «Гигант» колхозы бу төбәктә шактый мәртәбәле, мал-мөлкәтле хуҗалык иде. Минем Чүтигә беренче генә килүем түгел. Иң әүвәл аның эре сөякле, салмак — сабыр табигатьле колхоз председателе Биктимер абыйны хәтергә төшерәм. Ике генә тәгәрмәчле тартма арбага — таратайкага кунаклап, басу-кырларны, җәйләүләрне әйләнеп чыктык. Башта ук күзгә чалынган рухи бизәк шул: кайда да председательне олысы-кечесе ихлас хөрмәт белән, баш иеп, алдан сә-

лам биреп каршылыйлар. Аның алдында тавыш күтәреп сөйләшү яки үзара тел әйтешү юк. Биктимер абзый үзе дә тыныч кына: «Бакчы, улым, кырның бу читен ашыгыбрак тырмалагансың бит, кантарлар калган». Яки: «Кара әле, кызым, бу сыерың өшәнеп киткән түгелме? Куригы да бик каткан икән. Карый төш үзен, сауганда тиберчено дип, үги күрмә. Көңелен күр, өрәт, тиберченмәс»,— кебек киңәш-боерыклар биреп китә. Һәм ул әйткән сүзнең үтәләсенә шикләнмәскә була. Биктимер аганың хуҗалык башлыгы буларак матур сыйфатларын яд итеп сагынганда әлеге сүзләр хәтергә төшә:

— Малны таба белү генә җитми, улым: аны тота да белергә кирәк. Җәмәгать мөлкәтеме ул, үз тапканыңмы...

Беренче килүемдә үк авылдашлары үз итеп миңа бер вакыйганы җиткергәннәр иде. Олы юллардан, районүзәк, шәһәрләрдән шактый еракта, эчкәре яшәүләрен истә тотып, аннары, председательнең шактый олы яшьтә булуын да исәпкә алып, шул ук дәү апа — Фаизә Ганиевна, ул чакта әле бөтен республикада бик тә санаулы, дефицит булуына карамастан, колхозга «Волга» машинасы сатып алырга булышкан. Тик әкәмәт: «Биктимер ага бу «җәннәт арбасына» утырып йөрергә базмый, уңайсызлана, үзенең шул тартма таратайкасын кулайрак, җайлырак саный икән. Һәм озак та үтми, ул «Волга»ны, мут елмаеп, йөк машинасына алыштырып та кайткан. Бермәл сүз җаенда Биктимер аганың үзеннән бу хакта сораштырдым.

— Ну бит, улым, ул «Волга»га бер-ике кешене утыртып чабудан ни файда? Примерга бусын гына ал. Район безгә ерак, үзең беләсең, тәҗел йомыш белән барыр кешесе дә күп аның. Берсен дә юл чатында кыерсытып калдыргы келәми. Шыңа да машинаның зуррак яшшеклесен караштырып йөрдем шактыйдан.

...Чүти, Чүти! Юллардан бигрәк озын булган уйлар әнә шулай бу авылның үткәннәрен урап кайтты.

Без идарәгә килеп кергәндә, Фаизә Ганиевна авылның унбишләп ир-аты уртасында утыра, шул яңгыравык көйле тавышы белән әле бәхәсләшә, әле җаваплар даулый, я бер дә яшерми-тартынмый көлә, «Ии, шуны да аңламаска инде» диди бирәрсен битәрләп ала, я мут елмаеп, «йон уңаена сыйпаштырып куя». Әлегә рәсми утырыш түгел икән бу, киңәш-табыш итешү генә. Мәсьәлә шуннан гыйбарәт икән: партия райкомы хәлле «Гигант»ны күрше Тәүгилде авылындагы мескен хуҗалык белән кушарга ниятләгән. Зурдан кубып, «Гигант» дип атасалар да, Чүтидәге хуҗалык үзе дә, әнә, Фаизә Ганиевна саннар-мисаллар белән исбат иткәнчә, «хәзерге заман өчен, ии, бәләкәй бит инде ул». Аның нибары ике мең гектардан аз гына артыграк чәчүлек җире, сиксән гектарлап урманы, 100 баш савым сыеры да, 600 ләп сарыгы, югарыдан кушканга гына асрала торган 50 баш дуңгызы бар. Әмма теге чакта, әнә, Биктимер ага үзе әйткәнчә, малны бәрәкәтләп тота белгәнгә, хуҗалыкның кесәсе шактый калын, бурычлар юк, техника ул еллар өчен шактый күп, йолдыз кашка, ак бәкәлләргә мәхәббәтләре дә канга сеңгән аларның, җигү атлары гына да 100 башка якын. Ә иң кадерле өстенлеге, райком өчен дә иң кыйммәтле сыйфаты шунда: «Гигант»та коллектив бик бердәм, ихлас тәртип, эшчәнлек, уңганлык, тынгысызлык...

Тәүгилдедә исә хәлләр, чыннан да, мөшкел, ни дәүләткә, ни колхозчыларның үзләренә файда юк диярлек, бурычлары күп. Шуңа күрә дә бу ике хуҗалыкны кушып, яхшылар үрнәгендә Тәүгилде кешеләрен дә олы юлга чыгарырга кирәк. Әмма җепне җепкә бәйләгәнче инде шактый чәбәләнгән-чиләнгән төенне чишәсе бар икән. Чүти халкы кушылырга аяк терәп каршы тора! Трибунага чыгып, ләммим сүз әйтүче юк, ә үз араларында ду киләләр.

— Ул ата ялкаулар өчен көчәнәсебез юк. Үзләре өрәнсеннәр адәм сыман эшләргә!

— Колхоз малын төгел, үз дуңгызларын да юннәп карамыйлар диген, яшьти. Хайваннары — шыр кабырга! Кочык кабарлык итләре юк дип әт.

Ике авылның да халкын чакырып, уртак җыелыш уздырып та караганнар икән — юк, килештермәле түгел...

— Җилсез тегермәнгә ышанып соң, факыр, һәйбәт чалбарыңны ыштансыз белән бүлеш тә, үзең бозга утыр, имеш, ә!..

Гадәттәге базымлы холыклы Биктимер агай үзе дә бу мәсьәләдә һәмишә кистереп җавабын әйтми: «Мин бит инде, оланнар, картрак якка авыштым шул. Анәтрәк, азау ярган яшьләргә колак салыйк, заман аларга кала»,— ди-ди, икелемикеле уйларына чумып, мыштым гына утыра бирә икән.

Менә шуны хәл кыласы, Гөбнә агымын таратып яткан мүкле таш, черек төпчекләрне алып аткандай, күңел елгаларын да «үземнеке генә» хисеннән арулап, шик-шөбһә йомычкаларын агызып җибәрәсе бар. Әнә шуның өчен дә Фаизә Ганиевна бу юлы үзе килгән.

Тирәсенә утырткан ир-атларның каршылыгын сындырып, фикердәшләр иткәч тә, иртәгә янә уртак җыелыш җыярга булып, урыннарыннан кузгалдылар.

«Беренче»нең миңа да ашыгыч зур йомышы бар икән. Икәү генә калгач, ул миңа халыклар дуслыгы темасына лекция-әңгәмә хәзерләргә кушты.

— Кичке алтыга кадәр биш сәгать вакыт бар әле — өлгерәсең,— диде.— Яттан сөйләргә тырыш, яме. Белгәнеңне сөйлә. Бик әдәбиләштермәсәң дә ярый, үзегезчә, мишәрчәрәк сөйлә, яме.— «Беренче» идарә бүлмәсен иңләп, салмак кына йөренә, кулларын угалап ала.— Мин, мәсәлән, сүзне төрле милләт халыкларының уртак революцион көрәшеннән үк башлап китәр идем. Гражданнар сугышы вакыйгаларыннан мисаллар... Аннары, егерме беренче елдагы корылык, ачлык турында укып беләсеңдер. Шул чакта ук күп милләтләрнең, үз авызларыннан өзеп, ни бар шуның белән безгә ярдәмгә ашыгуларын телгә ал. Аннары инде колхозлар оештыру, Днепрогэс, Магниткаларны төзү турында иркенләп сөйли аласың. Ә Ватан сугышы еллары инде... Һәркайсыбызның диярлек йөрәгенә сеңгән... Бары бергә, югы — уртак иде...

Мине дә тыңлавын дикъкать, уйчан йөз белән тыңладылар. Ә менә Фаизә Ганиевна җыелышта чын-чыннан тутыккан, янчелгән күңел йозакларын ача барды, ача барды. Халыкның, туры сүз таш ярыр, татлы тел тау билэр дигән гыйбарәләренә конкрет ситуациядә янә бер кат инандым. Һәм халык белән сөйләшә белүнең мөһимлегенә. «Беренче»нең чыгышы, бергәйле һәр сүзе йөзләрне яктырта барды, уйландырды, көлдерде.

Чүти авылы халкы күрер күзгә дорфа, кискенрәк күренсә дә, холыклары белән тәэсирләнүчән, реакциягә җитез, кыю, тәвәккәл халык. Һәм кешене үз күреп, яратып өлгерсәләр, ихлас олылый да, риясыз тугрылык белән буйсына да беләләр алар.

Кушылдылар!

Фаизә Ганиевна үзе дә тәгаен хәтерләми иде: башта кайсы төбәктә — Чаллыдамы, Лаештамы, Кайбычтамы — аны үз күреп, олылап «дәү апа» дип атаганнар икән? Баштарак үзеннән купкә өлкән агайлар да шулай эндәшкәч, сәерсенеп, хатын-кыз буларак, бераз үпкәләгәндерме — белмим. Әмма дистә еллар агымында да җуелмаган, яме китмәгән бу икенче исеменә тәмам күнегеп җиткән иде инде, үзе дә якын итә иде. Халык, күрәсең, аны яшьтән зурлап, хакны әйткән. Чыннан да, рухы-җаны, кылган эшләре, акыл колачы, миһербаны белән дәү иде ул — совет халкының азамат кызы Фаизә Хәкимова!

...Йөзләр, меңнәр олы күргән бу асыл кешенең арабыздан китүе авыр, уйлы-сагышлы кичерелде. Каләм соңгы ноктаны куярга базмый...

# ОЛЫ БӘХЕТ ИЯСЕ

Бервакытны Петербург газетасының якшәмбе кушымтасында яшел күзле шаян кызның — ишегалды малайлары атаманының хикәясе басылып чыга. Уйламаганда, көтмәгәндә, кулга гонорар килеп керә. Ул чагында ундүрт яшьлек бу кыз һәм аның унике яшьлек сеңелесе Һиндстанга бару турында хыяллана-лар икән. Хикәя язып акча эшләү ерак сәфәргә чыгу көнен тизләтер кебек. Айга ике хикәя бастырсаң, бер елга шактый акча тупларга мөмкин. Юлга да, барып җит-кәч ашап-эчәргә дә җитәрлек булачак. Ул төнне күзгә йокы керми, ике туган төне буе исәп-хисап белән мәшгуль була. Кысып тотсаң, барысына да җитәр кебек, ә те-ләкнең чамасы юк.



— Сонечка, акчаны ашарга әзрәк тотсак, бер бәләкәй фил дә сатып алырбыз әле, ярыймы,— ди сеңелесе.

Шул көннән соң Софья бик тырышып хикәяләр яза, ләкин инде аларның бер-се дә матбугатка чыкмый. Бары тик утыз дүрт ел үткәч кенә, хәзер инде балаларның сөекле язучысы булган Софья Борисовна Радзиевскаяның — ин-де танылган энтомология белгеченең беренче чын хикәясе басыла.

Шәһәрнең соры таш стеналары ара-сында яшел утрау булып торган җиләк-җимеш бакчасындагы кечкенә флигель-дә үткен, җитез, шаян кыз булып үсә Софья. Яшьтәш малайлары аны ярата-лар, барлык уеннарына катнаштыралар. Хәтта бер вакытны үзләренең атаман-нары итеп тә куялар. Үсә төшкәч, ул әтисе белән ауга йөри, мылтыктан атар-га өйрәнә, ат өстендә шәп кенә юрта. Һәм шул ук вакытта бик йомшак күңелле, хискә бирелүчән, табигатьнең матурлыгына сокланып туя алмаган шигъри җанлы кыз да була. Җирдәге барлык тереклек ияләрен ярата ул. Бөҗәкләрнең, корт-ларның ничек яшәүләрен аңларга тели, этләр, мәчеләр, тиеннәр, попугайлар аның дуслары була. Хәтта соңыннан, ерак сәфәргә йөргәндә, барс баласы да сатып ала. Табигатьне ярату, гимназияне тәмамлаганнан соң, аны Бестужев курсларының мате-матика факультетына, аның да табигать бүлегенә укырга китерә.

Бала чакның сәяхәтләр турындагы самими хыялы кызның күңеленнән китми, зәң-гәр мираж кебек һаман тартып, әйдәп тора. Беренче курсны тәмамлагач, ул җәйге каникулларын шәһәрдән читтә, үзенә таныш булмаган җирдә үткәрергә тели. Кайда булса да барыбер, шушы таш стеналардан котылырга гына кирәк кызга. Аның күңеле яшел урманнарга, иркен болыннарга тартыла.

Бу эшкә ризалык биргәндә, кызның әтисе ул кадәр ерак сәфәрне күздә тотмый, билгеле. Үзеңә җитәрлек акча эшли алсаң, барырсың, ди. Софья ерак Манчжуриядән кайткан офицер хатынының балаларына чит тел укытучысы эзләвен белеп ала. Оч-рашып сөйләшәләр, килешәләр. Әни кешенең йөрәге сызлый сызлавын, ләкин бу гаиләдә биргән вәгъдәңне үтәми калу гадәте юк — ризалашырга туры килә.

Унтугыз яшьлек кыз ул җәйне Маньчжурия сопкалары арасындагы яшел дачада үткәрә. Тик тормас Софья шушы тыныч, тын дача тормышында да үзен баш китәрлек мажараларга дучар итә. Контрабандист хунхузлар кулына эләгү дисеңме, текә кыялардан егылып, башын-күзен җимерүме, карурманда ялгыз төн кунуны әйтәсеңме... Соңыннан, еллар үткәч, бу мажараларның күбесе турында без «Зәңгәр махаон» повестеннан укып беләбез. Кояшлы текә яр читендәге чуар чәчәкләргә гашыйк зәңгәр күбәләк икән ул махаон. Бик зур һәм бик матур икән. Инде бөҗәкләр, күбәләкләр коллекциясен шактый баетырга өлгергән Софьяга менә шушы ят күбәләк тынгы бирми икән. Шуны кулга төшерү өчен ниләр генә эшләми ул. Хәтта бервакыт биек, текә кыядан егыла. «....Ашыгып, кулым белән кыядагы ярыкны капшыйм. Соң инде. Аягым таеп, астагы җир убыла башлады. Бер генә минут сул кулымда асылынып тордым. Котым очып, оеган бармакларымның ычкынуын сизәм... Бетте! Мин аска очам!»

Софья Борисовна бу китабында нинди генә куркыныч хәлләрне дә кояшлы көн кебек якты буяулар белән, бала күңелендә оптимистик уйлар тудырырлык итеп яза. Шул вакыйгаларның уңышлы бетәсенә, ничектер, алдан ышанасың. Ләкин бу ышану, җеп очларын җыя белмәгән талантсыз язучының әсәрендәге кебек, барын да алдан күреп тору белән бер түгел. Логикадан бигрәк, эчке сиземләү ул, тойгылар ышануы. Контрабандистлар кулында да бит кызның тормышы кыл өстендә була. Куркуны җиңәргә тырышканда аның кыланышлары бик үк акылга сыярлык булмый. «Курыкмыйм дигәнгә мин ышанмыйм. Җаны бар кешедә курку тойгысы барыбер була. Берәүләр аны җиңә ала, ә икенчеләре юк. Без әсәрләребез белән әнә шушы әшәке тойгыны җиңәргә өйрәтик»,— ди Софья Борисовна.

Ул нәни геройларын төрле фаҗигаләр барышында сыный. Озын-озак итеп аларның эчке халәтен, психологик кичерешләрен сөйләп тормый. Балалар әдәбияты таләп иткәнчә, күбрәк урынны хәрәкәткә бирә, әсәрләренең динамикалы булуын кайгырта.

«Сазлыктагы робинзоннар» повестенда урманда уйнап йөргән малайларны немецлар атып китә. Арадан берсе — Саша исемле малай очраклы гына исән кала һәм яшеренгән җиреннән шушы канлы вакыйганы күреп тора. «Саша кычкырып җибәрмәс өчен ике кулы белән авызын тота һәм агач куышының мүкле стенасына маңгаен тери.

— Андрейка, Мотя, Ивашка,— дип бертуктаусыз пышылдый ул.— Андрейка, Мотя, Ивашка...»

Нәкъ менә шушы мәгънәсез пышылдау, үтерелгән иптәшләренең исемнәрен бертуктаусыз кабатлап тору малайның акыл җуяр дәрәҗәдә куркуын һәм кайгыга төшүен күрсәтү өчен җитә дә инде. Озаклямый без аның егыла-тора урман юлыннан йөгерүен күрәбез. Авыр аңар, чигәсенә кан бәрә, сулуы капкан, ләкин ул йөгерүен белә. Курку гына түгел, авылдашларын кисәтү теләге аны шулай ашыктыра.

Язучы курку дигән нәрсәгә каршы шифалы дару тәкъдим итә. Авылдашлары турында кайгыртуы Сашаны әнә шушы курку чиреннән дәвалый. С. Б. Радзиевскаяның бик борынгы чордан язылган «Рам һәм Гау» исемле тарихи повестенда да, «Батырлык үтравы» әсәрендә дә кардәшләрең алдындагы бурычыңны үтәү һәм хезмәтнең генә кешене кеше итү хакыйкате ачык тасвирлана.

Софья Борисовна Радзиевская үзе дә гомерендә гаҗәп күп эшләр башкара. Украинада, Муромда, Брянскида, Кулунда даласында, Урта Азиядә энтомолог булып эшли, урманнарны, мамык кырларын зарарлы бөҗәкләрдән саклау чараларын эзли, таба. Ташкент университетында лекцияләр укый, бөҗәкләр турында фәнни китаплар яза. Мәскәүдә авыл хуҗалыгы халык комиссариатының мамык бүлегендә эшли, ерак сәяхәтләрдә йөри, Казан университетының сирәк очрый торган кулъязмалар бүлегендә фәнни хезмәткәр була. һәм 64 яшендә пенсиягә чыкканнан соң бөтен вакытын балалар әдәбиятына бирә.

Софья Борисовнаның урыннан урынга, эштән эшкә күчеп йөрүе зур акча, шәхси бәхет эзләү аркасында түгел. Аларның бервакытта да артык байлыклары булмый, ә бәхетне эштән табалар. Софья Борисовна үзе һәм СССРның атказанган урманчысы булган ире хөкүмәт кушуы буенча күченеп йөриләр, иң кирәк җиргә, ил кушкан эшне үтәргә баралар. Нарын елгасының башланган җиренә оештырылган экспедицияләрдә генә дә

ул ике тапкыр катнаша. Ә бит ул ир-егетләрнең дә бик сирәкләре генә түзә алырлык авыр юл була.

Софья Борисовнаның мажаралар тулы тормышы гомере буе язып та бетәрлек түгел. 1932 елны Ташкентта аның балаларга багышланган ике китабы басылып чыга. Берсе «Хайваннар турында хикәяләр», икенчесе «Пум» дип атала. Беренче китапларының басылып чыгуы хакында язучы үзе болай дип сөйли.

— Ул вакытта без Ташкентта яши идек. Ирем тау битләрендә Әстерхан чикләвегенең яңа сортларын үстерү белән мавыга, ул хәтта Америкадан чикләвекнең беккан дигән бик шәп сортын да кайтарткан иде. Ә мин мамык кортлары белән көрәшәм. Бер кыз, бер малай үстерәбез. Бала чакта Һиндстан турында хыялланган сеңелем дә безнең белән тора. Буш вакытларымда мин балаларыма баштан үткән хәлләрне сөйли идем. Тыңларга күршедән дә бала-чагалар җыела. Кызыграк булсын дип, хикәяләремне алдан уйлап, язып та куя торган булдым. Көннәрдән бер көнне сеңелем минә шул язмаларымны җыеп алган да нәшриятка илтеп биргән. Чакырып алып, китабыгызны чыгарабыз, дигәч аптырап киттем.

Исемнәре хайваннар турында булса да, бу китаплар күбрәк кешеләр хакында сөйли. Олы һәм кече, яхшы һәм яман кешеләр турында. Аларның табигатькә, тереклеккә мөнәсәбәтләрен күрсәтә. Йорт хайваннары һәм җәнлекләр сизгер, яхшы күңелле кешеләргә иярәләр, начар холыклыларны да тиз таныйлар.

Бик билгеле бу хакыйкатьне раслаган «Джумбо» хикәясендә гыйбрәтле вакыйга бар. Бик матур һәм акыллы эт Джумбоны, хуҗасы өйдә юктан файдаланып, Максим дигән кеше үзенә алып китмәкче була. Муенына элмәк салганда ук эт бу адәмнең каты куллы, рәхимсез җан икәнен сизенә. Джумбоны җиңә алмаган Максим, ачудан, этнең башына күсәк белән сугып юлда ташлап калдыра. Автор Максимның портретын бирми, без аның кылган гамәлен генә күрәбез. Комсыз, ерткыч кеше икәнен беләбез. Аның килеш-килбәтен, төсен-битен тормышта үзебез күргән, белгән начар кешеләргә охшатабыз. Шуңа күрә ул тагын да реаль, җанлы булып кабул ителә. Күп хикәяләренең герое булган Сонечка портретын да автор тәфсилләп сурәтләми. Без аны күбәләк тотып йөргән чагында, тәрәзәдән сикереп урманга качканда, тау кушында ялгыз төн кунганда һ. б. кызык һәм куркыныч хәлләрдә очратабыз, шуннан чыгып, күңел күзе белән аның кыяфәтен тулыландырабыз.

Автор, язар материалын бик яхшы белгәнгә, әсәрләрендә ясап, яраклаштырып, уйлап чыгарырга азапланмый. Үзенә таныш булмаган тормышны сурәтләгәндә исә ул материалны галимнәрчә, җентекләп өйрәнә. Кешелек дөньясының борынгы чорына багышланган «Рам һәм Гау» повестен язу өчен Софья Борисовна материалны биш ел өйрәнә. Аның чит телләрне күп белүе (француз, немец, инглиз телләрендә иркен сөйләшә, латин һәм борынгы инглиз телен белә, фин һәм венгр телләреннән кала, Көнбатыш Европаның барлык телләрендә сүзлек ярдәмендә укый) беренче чыганаклардан файдаланырга мөмкинлек бирә. «Рам һәм Гау» бу темага язылган әдәби әсәрнең дөньяда өченчесе була. Кульязманы укыгач, атаклы археолог академик Нестух: «Уңышлы башкарып чыгуыгызга хәйран калдым»,— дип әйтә.

«Батырлык утравы» повестен да ул озак өйрәнеп яза. Мин аның Төньяк диңгезгә бару өчен Язучылар союзыннан иҗат командировкасы алып йөргәнен хәтерлим әле. Бу вакытта инде язучы сигезенче дистәне ваклый башлаган иде.

Софья Борисовна Радзиевская менә кырык ел инде Казанда яши. Аның иң актив иҗади эшчәнлеге Казан чорына туры килә. Биредә фәнни эш белән дә актив шөгыльләнә ул. Казан университеты нәшриятында сирәк кульязмаларның дүрт томлык фәнни аңлатмасын чыгара. Күп санлы хикәяләрен, зур күләмле әсәрләрен Казанда яза. Татар язучыларының әсәрләрен русчага тәрҗемә итә, яшь язучыларга булыша, телевидение, радио аша чыгышлар ясый. Бу чыгышлар «Соня әби хикәяләре» дигән исем белән дәвамлы рәвештә озак еллар барды һәм балалар арасында гына түгел, олылар өчен дә бик популяр булды.

Бай тормыш юлын үткән талантлы язучы, халык хуҗалыгында күп хезмәт куйган оста белгеч, яхшы күңелле иптәш, коммунист Софья Борисовна Радзиевская 90 яшен «Мең еллык төн» дигән зур күләмле тарихи роман тәмамлап каршылый. Инде аның күптән тынычлап ял итәргә хакы да зур. Ләкин ул эшсез яшәүне күз алдына да китерми. Өстәлендә — язылып ята торган яңа китап. «Ел әйләнәсендә» дигән бу әсә-

рен автор республикабызның бай табигатен сурәтләүгә багышлый. Аның әле язасы, яшь буынга әйтәсе сүзе бик күп. Бер җыентыгының сүз башында ул балаларга мөрәҗәгать итеп: «Әгәр сез биредә тасвирланган җәнлекләрне, кошларны, табигатьне мин гомерем буе яраткан кебек яратсагыз — бу китапны сезнең өчен юкка язмаганмын булып чыга»,— ди. Сезнең өчен... Сезнең өчен яшәдем, сезнең өчен эшләдем, дип әйтә алу нинди зур бәхет ул.

Софья Борисовна Радзиевская — әнә шул олы бәхеткә, каләмдәшләренең күп санлы укучыларының зур ихтирамына лаек язучы.

**ЛӘБИБӘ ИХСАНОВА**

## Софья Радзиевская

# МЕҢ ЕЛЛЫК ТӨН

РОМАННАН ӨЗЕК

*Тарихчылар Урта гасырларны кайвакытта мең еллык төн дип атыйлар. Бу чорда наданлык, кыргыйлык, явызлык, мәкер хөкем сөргән. Туктаусыз сугышлар, авыр табигать шартлары, хәерчелек түбән катлау кешеләренең меңләгән гомерләрен алып китә. Әмма шушы авыр шартларда да мәхәббәт, намус һәм тугрылык яши. Гаделлек, ирек өчен көрәшчеләр күтәрелеп чыга. XII гасырдагы инглиз тормышыннан язылган роман шул турыда сөйли.*

Бу вакыйгаларга инде ун еллап вакыт үтте. Локслей замогы меңнәрчә флаглар, утлар белән бизәлеп, гадәттәге шыксызлыгын югалтты, ялтырап, яктырып китте. Шат күңелле барон Джон Локслей бердәнбер кызы Элеонораны кияүгә бирә. Унбиш яше тулып узган чибәр кызга күбәүләр күз ата башлаган һәм картаеп барган атасыннан, бөкре энесеннән дә куәтлерәк берәр кешенең аны үз канаты астына алуы бик кирәк иде.

Гентингтон графы яшь барон Уильям Фицусның замогы күрше калкулыкта тора, биләмәләре дә Локслейлар җире белән янәшә, ә үзе аларга ерак кардәш туры килә, байлыгы һәм дәрәҗәсе белән дә тиң. Шулар Элеонораның язмышын хәл итәргә җитә калды. Кызыннан «Яратасыңмы?» дип сорарга ата кешенең хәтта башына да килмәде. Элеонора үзе берни дә әйтмәде, гадәттәгедән ныграк агарынып китте дә тагы да азрак сүзлегә әйләнде. Тик кыздагы үзгәрешләрне берәү дә сизмәде.

Замокта күңелле шау-шу башланган иде. Яңа парны котларга килгән бай киемле кунаклар күңел ача. Күрше-тирәдәге һәм читтәге барлык замокларның горур бароннары, затлы графлары үзләренең якыннары, хезмәтчеләре һәм сакчылары белән килгәннәр. Тынычлык белән дуслык үпкәләү-дошманлашуга әйләнмәсен дип, һәркайсының байлыгына, дәрәҗәсенә карап урын бирергә, мәҗлес өстәленә утыртырга кирәк— урыны үзеннән затлырактан югары да, кайтышрак та булмасын.

Рыцарьларның күбесе үз дәрәҗәләрен дорфалык, тәкәбберлек белән раслаганда, бу бик кыен һәм җаваплы эш иде.

Туйның икенче көнендә мәҗлестән соң ял иткән кунаклар шаулашып, иярләгән атлары янына чыктылар. Гентигтон графы барон Фицус яшь кәләшен үзенең биләмәләренә алып китәргә җыена, кунакларның бер өлеше тантананы дәвам итү өчен алар белән бергә барырга тиеш.

Элеонора тынычрак атка менеп атланган иде инде. Аның күзләре ишегалдына җыелган кешеләр арасыннан кемнедер эзли, әмма таба алмый. Сиздерми генә сеңелесен күзәтеп торган бөкре Эгбертның йөзендә мәкерле елмаю. Менә ул сеңелесенә таба килде һәм мыскыллы пышылдады:

— Гугоның кара күзләре матур, сеңелкәй. Иреңнең соры күзләренә сокланырга сиңа комачауламасын дим мин Гугоны...— Сүзен тәмамламыйча тынып калды да тагын да әкренрәк итеп өстәде.— Кичә кичен мин дә бакчада йөри идем... алмагач астында...

Элеонора аңа бер җавап та кайтармады, ап-ак булып агарынды гына. Моны сэр Уильям күреп алды. Үзенең сугышчан атыннан аңа иелә төшеп:

— Хәлең начармы әллә, кадерле хатыным? — дип сорады.

— Юк, рәхмәт сиңа, — диде Элеонора, иренә ягымлы гына баш иеп. Энесенә әйләнеп тә карамыйча тураеп утырды, ышанычлы кул белән тезгенне тартты.

Ишегалды күңелле шау-шу, мөгез быргыларның тавышына күмелде. Бу тавышлар замок астындагы зинданга да килеп җитте, аларга җавап итеп авыр чылбырлар зыңлап куйды. Локслейлар йортына хас кием кигән кара күзле яшүсмер үзенә бик ошаган иптәшенең кулыннан тотып, идәнгә җәелгән саламнан торгызмаска тырышты:

— Гуг,— дип ялына иде ул күз яшьләре белән,— алла хакы өчен кыймылдама, бугазыңны кисәрсең!

Әмма тегесе акылдан язган кеше кебек бәргәләнә, ике кеше көчкә күтәрерлек авыр богауның пычактай үткен кырлары аның җилкәләренә, муенына батып керә, идәнгә кан ага иде.

Ишегалдындагы күңелле авазларга, быргылар кычкыртуына чылбыр тавышлары кушылды һәм туйчылар артыннан асылмалы күпер шапылдап ябылды. Элеонора Локслей — Гентингтон графинясы туган замогын калдырып китте.

Гуго саламга башын салды. Ул инде бәргәләнүдән туктаган иде, әмма күзләрендә хәтәр ут яна.

— Үтерәм мин аны!

Басынкы Ульрих аның кулларын тотып:

— Алай димә, Гуг, алла хакы өчен. Ул безнең хуҗабыз бит.

— Хуҗабыз? — дип кайнарланды Гуго һәм яңадан сикереп тормакчы булды. Ульрих күз яшьләренә буылып, туганының яралы җилкәсенә кулын салды.

— Карак ул! — диде Гуго,— ул безне урлап китте, әти-әниебезнең кайда икәнен дә белмибез хәзер! Ул безне үзенең колы итте! Аның ни хакы бар? Мин җәядән аннан яхшырак атам. Ә син доганы безнең капелланга караганда да әйбәтрәк укыйсың. Ә хәзер... хәзер... аны алып киттеләр. Ә мин хәттә... Үтерәм мин аны!

— Хода хакына, Гуг,— дип ялвара Ульрих,— хуҗабикәнең энесе бит ул. Син нишләргә уйлыйсың, ул кайгыга калыр.

Гуго башын иде, көчсезләнгән йодрыклары ачылды. Энесе дөрес әйтә иде. Юк, ул аны кайгыга салырга теләми...

Ул арада зиннәтле киемнәр, яхшы кораллар белән бизәнгән туйчылар, далага төшеп, тар юлдан, елганың түбән агымындагы биек ярда утырган замокка юнәлделәр.

*
* *

Ачудан ни эшләргә белмәгән караңгы йөзле барон Эгберт Локслей бушап калган замокның ишегалдында йөренә. Табигатьнең мәгънәсез шәфкатьсезлегe аркасында ул үзе матурлык, сәламәтлек, көчтән мәх-

рүм. Һәм монда ия булган барлык җан ияләре аның җен ачуын чыгара. Кичәге туй ыгы-зыгысы вакытында ул эчтәге ачуын кандырырга җай тапты, ләкин бу да аңа җиңеллек китермәде. Хәзер ул үзенең туганы һәм дусты булган яшь монах белән ишегалдында йөри. Аңар күңелсез, күзләрендә зәһәр ачу, нинди дә булса явызлык эшләп күңел ачарга тели. Монах Рудольф кинәт:

— Сак бул! — дип кычкырды һәм сэр Эгбертны, кулыннан тотып, читкә алып атты, үзе дә житез генә читкә сикерде. Замок стенасындагы чылбырга бәйләнгән аю кинәт бөкрегә ташланган иде. Аюның кәкре тырнаклары Локслейны чак кына эләктерми калды, шулай да монахның җиңен аерып төшерергә өлгерде. Шул аю хәзер оясы янында утыра һәм башын селки-селки ырылдап, тырнакларындагы чүпрәк кисәген теткәли иде. Ачудан күзләре кып-кызыл. Бу җанвар кайчандыр юаш холыклы иде, әмма яшь баронның начар шуклыклары аны да явызландырды, хәзер ул чын ерткыч зәһәрлеге белән теләсә кемгә ташланырга әзер тора.

— Браун кызу йөгерә, ә сикерә беләме икән? — диде аюга карап торган монах. Аның тавышы шундый тыныч ишетелде, әйтерсең лә аю әле генә аның җиңен ертып җилкәдән терсәгенә хәтле кулын тырнап алмаган.

— Хәзер беләбез аны,— диде бөкре, куркудан ул әле дә ап-ак иде. Тыштан булса да сынатмаска, батыр туганыннан калышмаска тели иде ул.— Әй, тәрәзәдән ит кисәге төшерегез! Тиз булыгыз!!

Ләкин аю баш очында селкенеп торган кәҗә ботына күз дә салмады — тамагы тук иде.

— Аны үртәп торырга берәр тере җан булса икән,— диде монах Рудольф.

— Мөмкин,— Эгбертның күзләре ялтырап китте, боерыгын көтеп торган хезмәтчеләренә берәм-берәм карап алды.— Өстән... өстән... монах малайны төшерерсең.

— Әй, Улл, син кинжал белән Браунны үртәп торырсың. Сиңа табан сикерсен. Тырнагына эләкмә, юкса... көләргә дә өлгерми калырбыз,— дип сүзен бетерде Эгберт, эчкерсез бер кыяфәт белән. Үзе сиздермичә генә тирә-юньдәгеләрнең йөзен күзәтте, ләкин барысының да башы түбән иелгән иде.

Юаш холкы, укый-яза белүе өчен Ульрихны монах малай дип йөртәләр иде. Замокның капелланы белән бергә борынгы китаплар укудан да зуррак шатлыгы юк иде аның. Капелланга ул гыйбадәт вакытында да булыша иде.

Узып барышлый бөкренең сүзен ишеткән Ульрих аптырап як-ягына каранды. Туганы, кыю һәм көчле Гуго монда юк иде. Бүген иртә белән аларны зинданнан чыгардылар. Күкрәгендәге, иңбашларындагы яраларына да карамастан, Гуго шунда ук иң кыргый айгырны өйрәтергә алып чыгып китте. Эгберт Гугоның качуыннан курыкмый иде, энесе Ульрих замокта калды бит.

Хезмәтчеләр хуҗаларына каршы килергә кыймадылар. Бер минут та үтмәгәндер, бауга бәйләнгән «монах» малай аюның баш очында һавада тирбәлеп тора иде инде.

— Кинжал белән када, кинжал белән,— дип көлә-көлә кычкырды бөкре. Аю җитез генә арт аякларына утырып, алгы тәпиен югарыга сузган иде инде.

— Кадамыйм! — дип, «монах» малай көтелмәгән бер тынычлык белән кулларын ачык күкрәгенә кушырды.— Теләсәң үтер, ләкин синең күңелеңне ачар өчен берни дә эшләмәм!

— Түбәнрәк төшерегез! — диде Эгберт гыжлап чыккан сәер тавыш белән.— Түбәнрәк, кабәхәтләр, юкса үзегез дә шул бауда биерсез!

Тып-тын булып калды. Хәтта аю да, башын кыек салып, нәрсә бул-

ганын аңларга теләгәндәй, кечкенә хәйләкәр күзләрен йомгалап куйды. Җиргә төшерелгән күпердән ишетелгән ат тоягы тавышына берәү дә игътибар итмәде. Ак күбеккә баткан кара ат ишегалдына килеп керде. Күзләрен кан басып, бөтен гәүдәсе белән калтырап торса да, атның җайдакка буйсынуы күренә иде. «Палач» кушаматлы бу ат сыртына атланырга теләгән күпме кешене җиргә салып таптады. Үткер богау тешләреннән җәрәхәтләнгән Гугоны шушы атка атландырып, китеп барган сеңелесеннән тагын бер кат үч алырга теләгән иде Эгберт. Сеңелесе изге күңелле, чибәр, ә ул үзе явыз һәм бөкре. Шуның өчен ул сеңелесен күрә алмый иде.

Ат һәм җайдак капкада туктап калды. Гугоның үткен күзләре барын да күреп алды. Ул барын да аңлады. Камчы белән каты итеп сугуга «Палач» үрә торды. Тагын бер сукты һәм ярсыган ат туп-туры аюга сикерде. Аның кыргый тавышы хәтта аюны да куркытты, явыз ырылдап, аю үзенең оясына ташланды, ә Гуго, атын туктатып, кулын югары күтәрде.

— Бауны ташла!

Ул шул кадәр кискен итеп әйтте, аптырап калган хезмәтчеләр, бауны ычкындырып, тәрәзәдән читкә сикерделәр. Гугоның көчле куллары әнисен кочып алды.

Тагын бер сугуга «Палач», арт аякларында әйләнеп, капкадан чыгып чапты, күпер төбендәге сакчылар яныннан үтеп, кырга, урманга, ирекке илтүче юлга төште.

Ат авызыннан чәчрәгән ак күбекләр бөкренең чуар киеменә һәм руханиның кара сутанына кунды.

— Мин сине аюга бирәм, кабәхәт,— дип, Эгберт сакчыга ташланды.— Ник чыгардың аны? Ә сез ник аны тотып калмадыгыз,— дип, хәрәкәтсез калган хезмәтчеләренә борылды.— Мин... мин сезне... — бөкренең калтыранган ирен читләре күбекләнде, аяк-кулы тартышып, ишегалды ташына ауды.

Шау-шуны ишетеп йөгереп килгән карт барон Локслей өянәге кузгалган улын алып киткән хезмәтчеләрнең аркаларын гына күреп калды. Кулларын күкрәгенә кушырып, күзләрен тыйнак кына җиргә төбәгән монах Рудольф та алар артыннан атлый иде.

Русчадан **Л. ИХСАНОВА** тәрҗемәсе

Тәлгат Галиуллин

# ЕЛЛАР ЧАКЫРДЫЛАР ЕРАККА...

*Поэма жанры турында уйланулар*

Соңгы еллар татар поэмасында катлаулы яңарыш процессы бара. Аерым шәхеснe тарих һәм бөтендөнья проблемалары югарылыгына күтәреп сурәтләүгә, фәлсәфи тирәнлеккә, фикер белән тойгыны бер үремтәдә тасвирлауга һәм лаконик формаларга омтылу тенденциясе сизелә. Киң гомумиләштерү һәм чор алып килгән яңалыкны бөтен нечкәлекләре белән чагылдыру, кешелеклелек хисләре һәм җылы лиризм соңгы еллар поэмасының мөһим үзенчәлеген тәшкил итә. Поэманы тормышка, кешенең рухи дөньясына, зиһен эшчәнлегенә якынайту юлларын эзләп, шагыйрьләребез бай традициягә, сөйләм теленә, ритмик иреклелеккә, ассоциациягә һәм метафорага киң таяналар. Поэма тукымасында барлыкка килгән структур һәм стилистик үзгәрешләр борынгы жанрның яңаруы, чор таләпләренә, замандашыбызның фикерләү үзенчәлекләренә якынлаша баруы турында сөйли.

Хәзерге татар поэмасының яңа чалымнары бигрәк тә Сибгат Хәким әсәрләрендә ачык чагылыш таба. Соңгы унбиш-егерме елда «Ленин фәрманы белән», «Язгы», Җир уллары», «Үрләр аша...», «Дуга», «Васыятьләр», «Кырыгынчы бүлмә», «Дәверләр капкасы» кебек халыкчан рухлы лиро-эпик һәм фәлсәфи поэмалар белән күп милләтле совет поэзиясен баеткан олы юлның башы 30 нчы елларның икенче яртысына килеп чыга. Эзләнүләр нәтиҗәсе буларак дөньяга килгән «Пар ат» (1938—1939) — үз чоры өчен лирик поэманың бер үре, шактый җитлеккән, катлаулы композицияле әсәр булды. Шагыйрь үткәнгә бүгенге югарылыктан күз сала, шәхси кичерешләре аша Тукай дөньясына юл ала.

Мәсьәләгә тарихи яктан килгәндә исә, С. Хәким поэмаларының нигез чишмәсен, юлбашын поэзиябезнең ерак тарихыннан — «Йосыф-Зөләйха»дан, «Гөлстан»нан, «Сәхипҗамал»дан, Тукай ачышларыннан, бөтен совет поэзиясенең казанышларыннан эзләргә кирәктер. Сугышка чаклы иҗат иткән эпик әсәрләренә көч, илһам биргән шәхес тә — Тукай. Җитмешенче еллар башында язылган шактый камил лирик поэманың үзәгендә дә яңа чор татар поэзиясенә нигез салучы образы тора («Кырыгынчы бүлмә»). Арада киеренке эзләнүләргә һәм ачышларга бай озын юл ята. Яңа бер рухи дөнья тудырылган. Яңа шигъри мәктәп җитлеккән.

С. Хәким поэмаларының тәэсир көче нәрсәдә? Нинди сыйфатлары белән алар рухи дөньяга үтеп керәләр, аңа тирән тәэсир ясыйлар?

Тәнкыйть С. Хәким әсәрләрендәге реалистик дөреслеккә, тормыш драматизмының сәнгатьчә камиллек һәм нәфис тел белән сурәтләнүенә күптәннән игътибар итеп килә. Шагыйрьнең халыкчанлыгы, чуар һәм катлаулы бизәкләү чаралары белән мавыкмыйча, табигый матурлыкка, гармониягә омтылуы турында да фикерләр әйтелде. Бу хакта Н. Юзиев, Р. Мостафин, Х. Хәйри, З. Рәмиев һ. б. тәнкыйтьчеләр бик хаклы һәм ышандырырлык итеп яздылар. С. Хәким каләме тудырган күләмле әсәрләрнең шөһрәте — барыннан да элек, халык язмышына барып тоташкан үзәк вакыйгаларны, борылыш моментларны кеше характеры, шәхес кичерешләре аша фәлсәфи тирәнлек белән калкытып куя алу осталыгында.

С. Хәкимнең шәхес һәм шагыйрь буларак бай рухи дөньясы, олы тормыш тәҗрибәсе һәр поэмасында яңа яклары белән ачыла килә. Утлы Дуга вакыйгалары тәэсирендә иҗат ителгән поэмасында язганча, шагыйрь «төрле буяу, төрле төсләрнең» яңача чагылышларын, билгеләрен, эчке матурлыкларын эзли. Тарихилык рухы, вакыйгаларга әхлакый-фәлсәфи югарылыктан килеп бәя бирүгә омтылу поэмадан-поэмага көчәя, ныгый бара.

Шул ук вакытта олы дөньяны һәм кеше кичерешләрен аңлавенда шагыйрьнең кайта-кайта үстерә, баета килгән даими, тотрыклы алымнары, закончалыклары бар. Шагыйрь күбрәк үз шәхесенә, үз язмышына бәйле тормышчан хәл-вакыйгаларга таяна, тарихи шәхесләр эшчәнлегенә, тормыш юлына мөрәҗәгать итә. Үзәктә Ленин, Тукай образлары тора. Алар артыннан Ибраһим Йосфи, Кол Гали образлары күтәрелә...

«Бакчачылар», «Урләр аша...», «Дәверләр капкасы» кебек поэмаларның геройлары — безнең чордашларыбыз. Аларның үзәгендә дә олы вакыйгалар, илне, халыкны борчыган, батырлыкка күтәргән проблемалар ята. Шул ук вакытта бу әсәрләр стиль һәм сурәтле фикерләү үзенчәлекләре буенча бер-берсеннән бик нык аерылып тора.

В. Белинский лирик поэмаларны романтик әсәрләрнең бер төре дип атый. С. Хәкимнең «Урләр аша...», «Дәверләр капкасы» поэмаларында эпик талгынлык белән кушылып киткән һәм лирик җылылыкка барып тоташкан романтик дулкын үзен нык сиздерә. Шагыйрь баллада жанрының кискен драматизм, динамика, стиль берлеге, психологик сурәтне җәеп җибәрү кебек алымнарын поэмага алып керә, аларны яңа җирлектә үстерә. «Бакчачылар» поэмасында эпик талгынлык, кеше рухын вакыйгалы фонда ачу өстенлек итә.

Тарихи вакыйгаларга таянып эш итү, киң гомумиләштерүгә конкрет, тормышчан хәлләр аша килү С. Хәкимнең бик күп поэмалары өчен характерлы. Мәсәлән, «Дуга» әсәренә кереш сүзендә шагыйрь үзе дә реаль тормыш күренешләренә өстенлек бирүе хакында ачыктан-ачык яза. «Минем бу әсәрем — исталек-биография... Дуга сугышлары Сталинградтан кала иң зур сугышлардан санала. Мин аның бер участогында гына булдым, мин бит бары взвод командиры гына, взводның билгәгән урыны тар, кечкенә. Күргәннәрем күбрәк Ерик белән бәйле. Әсәрдә шул участоктан читкә чыгарга батырчылык итмәдем».

Әлбәттә, шагыйрьнең бу сүзләрен артык эмпирик кабул итеп, аларга тулаем «ышанып» ялгышырга да мөмкин. «Дуга» — вакыйгаларны тукми-чәчми хикәяләүче документаль әсәр түгел. Поэманы укыган кеше аның Дуга сугышының панорамасын кеше язмышлары аша күз алдына бастырган, хыял уенына, типиклаштыру алымына киң таянып язылган сәнгать әсәре икәнлеген тиз аңлар. Шагыйрь дөньяны фашизм коллыгыннан коткарып калган халык батырлыгына шигъри һәйкәл куя, аңа дан җырлый. Геройларының дошманга һәм туган илләренә мөнәсәбәтен, җиңүгә ышанычын, фашизмнан әхлакый өстенлеген сурәтләү юлында шагыйрь тирән экспрессивлыкка ирешә. Сугыш дәһшәтен сурәтләү, «канатлары белән өскә дошман» басып торган эпизод-хәлләрне күз алдына бастыру — кеше характеры тирәнлекләре турында уйланулар юлына алып чыга. Дуамалрак холыклы, бераз кырыс Низаминың фашизмга нәфрәтен шагыйрь бер куплетка сыйдыра алган:

**Ул, куркыныч кырлар уртасында**
**Тыя алмый ярсу акылны,**
**Ачуланса, этләренә түгел,**
**Дошман ягына карап акырды.**

Бурмак Степаннар, Каекбайлар, Низамилар Ерик елгасын, үзләренә билгеләнгән кишәрлекне генә яклап сугышмыйлар, аларның көрәше — гомумән явызлыкка, кара көчләргә, вәхшилеккә каршы. Совет Армиясе менә шундый батыр ир-егетләрдән тора. Шул сыйфатлары белән алар тарихи шәхесләр, олы язмышлы кешеләр: «Ашыгып атлый Низам, калдым күреп Халкыбызның бөек чорын мин», — дип яза шагыйрь.

Биредә реаль хәлләр хыял, фантазия җимеше буларак туган күренешләр белән

тулыландырылып, бергә үрелеп бара. Бу — традицион антитеза алымы гына түгел. Автор яшәешнең төрле яссылыкларында яткан тарихи һәм илаһи эпизодларны капма-каршы куймый, киресенчә, алар арасында эчке якынлык эзли, сәбәплелек бәйләнешенең гамәли чагылышларын сиземли, шул сизэмләүләрен шигырь юлларына чыгара. Шагыйрьнең үткен фантазиясе, кыю зиһене легендаларны «уята», Бөек Болгарны туздырган Аксак Тимер, гүзәл болгар кызы образларын күз алдына китерә... Унөченче гасыр башларында иҗат иткән «төз, мәһабәт», «горур сынлы Колгалинең» Дуга кырларына килеп чыгуы кебек романтик алым да киң тарихи фонда аклана, сурәтнең офыгын, сулышын киңәйтеп, иркенәйтеп җибәрә.

Борынгы шагыйрь образы поэмага тикмәгә генә килеп керми. Ул үткәнгә баш ору кебек бер алым гына да түгел. Билгеле булганча, Колгали язма әдәбиятка шактый ачык төсмерләнгән әхлакый гуманизм идеяләрен алып керә. Дөрес, аның гуманизмы индивидуалистик, стихиячел, күбрәк даирә әһелләренең омтылышларын, ниятләрен чагылдыра. Колгалинең идеалына тарихилык һәм конкретлык җитенкерәми. Шул ук вакытта «Йосыф-Зөләйха» саф мәхәббәтне, дәртле хисләрне олылый, рух матурлыгына дан җырлый, халык иҗаты гәүһәрләренә, язма әдәбиятка юл ача.

Галимнәрнең, язучыларның тикшеренүләре күрсәткәнчә, Колгали үз чоры өчен алдынгы кыю шәхес һәм көчле шагыйрь булган[1]. С. Хәкимнең бу образны иска төшерүе киң мәгънәгә ия. Ул аны фәлсәфи-этик контекстта ала.

Фашизм азатлыкка, кыю шәхесләргә каршы ябырылды. Бу явыз көчкә каршы көрәшендә совет халкы тарихка, культура традицияләренә таяна:

**Бер зур хисне ачык татыдым мин:**
**Ашарга ал юлга өч көнлек;**
**Кимендә мең еллык булсын икән**
**Дошманыңнан рухи өстенлек.**

Кешенең шартлар, тирәлек һәм үз тарихы белән катлаулы мөнәсәбәте, рухи культура өлкәсендәге буыннар һәм дәверләр варислыгы мәсьәләсен калкытып куя шагыйрь. Элгәрләр максималистик кырыслык белән яңа буыннан ил алдындагы бурычларына һәм гуманизмга тугрылыклы калуларын таләп итә. Шигъри фикерләүнең агышы, контексты XIII гасыр шагыйренең Курск дугасына килеп чыгуын аклый.

Колгали тышкы кыяфәте белән дә безнең чордашларга охшаган. Ул сакчылар янына күктән иңми, мина кырларын, алгы сызыкны үтеп, аш китергән ике солдатка ияреп килеп чыга: «Төз, мәһабәт, горур сынлы» һәм «гел сөйләнә үзе». Чордашы Низамны да шагыйрь шул ук алым белән, эре сызыклар аша гына тасвирлый: «Траншеядан чыгып үтеп китте, Күреп калдым туры сынын мин». Ике портретта да әнә шундый гомумиләштерү өстенлек итә.

Совет халкының көче туган җиренә мәхәббәтендә, тарих батырлыгын заман проблемалары аша күрә белүдә. Шагыйрьнең кыю фикере, хыялы үткән белән хәзерге арасында тагын бер рухи якынлык, җанлы җеп таба:

**Ярты халык Галиләрдән тора,**
**Ватанына тугры Галиләр.**

Бу поэма шагыйрьнең тормышны үз фантазиясе, рухи сизгерлеге белән тулыландырырга хакы барлыгын яклый. Колгалине «озатканнан соң», ул ерак мифологиягә юл ала. Югары дәрәҗәдәге гомумиләштерү көченә ия булган символик образлар халык батырлыгы чыганакларын, туган җиргә бирелгәнлекне сурәтле итеп ачу бурычларына буйсындырылган.

Хыял уены белән тарихи үткәнне җанландыру, элегрәк яшәгән шәхесләрне хәзерге буын кешеләре белән очраштыру — С. Хәкимнең күп әсәрләре өчен характерлы алым. «Васыятьләр» поэмасы шуның ачык мисалы. Үлем түшәгендә яткан анасы янында утырган Шагыйрь үзе өчен иң якын, иң газиз кешесенең тормыш юлы турында уйлана һәм фикерләренә ышандыру көче бирү, кичерешләренә аныклык кертү, буын-

[1] Кара: Хисамов Н. Ш. Поэма «Кысса и Йосуф» Кул'али. М., 1979.

лар арасындагы якынлыкны ныгыту ниятеннән чыгып, сурәткә әкиятче Әхмәтҗан, 30 нчы елларда колхозны җитәкләгән кырыс Шәйдулла образларын алып керә. Бу шартлы алым үзен аклый, ышандыра: «Кем телгә алынса, ак карда Сузыла мәһабәт шәүләсе».

С. Хәким поэмаларында «вакыт» аеруча әһәмияткә ия. Шагыйрь бу төшенчәне конкрет һәм фәлсәфи, гадәти һәм киң мәгънәләрдә куллана. «Дуга» поэмасына игътибар итик. Иң әүвәл без дәһшәтле сугыш сынауларын үткән һәм чирек гасырдан соң чиркәүле үр катына килеп чыккан чордашыбыз белән танышабыз. («Минем кебек бәхетлеләр сирәк, Дуслар монда кабат аз кайткан...») Икенче образ — гуманизм белән вәхшилек арасындагы бәрелешнең иң хәтәр нокталарында катнашкан взвод командиры — яшь шагыйрь. Үткән белән бүгенгене, ике буын кешеләрен вакыт якынлаштыра, хәтер бәйли. Бу «ике тавыш», поэманың яңгырашына полифоник төсмер биреп, төрле стиль (романтик-драматик һәм реалистик) агымнарны тудырып, бер-берсен баетә, ачыклый.

«Беренче шагыйрь» статик образ түгел, ул үсештә, динамикада алынган. Яшь командирның йөрәк түреннән актарылып чыккан нәфрәт ташкыны, хисси өермә фашизмны күрә алмау белән генә чикләнми, ул немец халкының телен дә кабул итми, искетик рәвештә кире кага:

**Колакка ят, иманнарга ул ят.**
**Нигә ул ят! Серен тап, өйрәт.**
**Бәрелеп-сугылып йөри кырда сүзләр,**
**Кабул итми кебек табигать.**

Бу — туган иленең азатлыгына кылыч күтәргән, тимер тышау кидерү турында хыялланган вандалларга каршы чыккан сугышчы тавышы, йөрәк авазы. Ләкин взвод командиры, шагыйрь немец халкының гуманистик әдәбияты, сәнгате белән дә таныш. Акрынлап ул халык белән фашизм арасындагы аерманы күрә башлый, максималистик инкяр итү юлын кире кага, мәсьәләгә тарихи, аналитик караш ташлый:

**Әйт, кайчаннан бирле сиңа ул чит,**
**Сиңа ул ят Гете, Гейнеләр!..**

«Дәверләр капкасы» поэмасының үзәгендә дә шәхси кичерешләре, ил һәм дөнья турында уйланулары, борчулары, куанычлары белән шагыйрь шәхесе тора. Ул яңа Чаллы белән танышып йөри, Муса Җәлил урамы буйлап атлый («Йортлар, йортлар, бәрдыр канатлары»), заводлар комплексы төзелеп яткан мәйданга килеп чыга. Шагыйрь иленең киләчәге турында уйлана: «Урамнары буйлап Илбактының — киләчәге буйлап ил бәхетенең гизде уем...» Аның үткен күзе һәр детальдә тирән мәгънә күрә. Мәсәлән, җирнең өске катламын алуны шагыйрь «тарихның өстен» салдыру дип атый. Бу метафора лирик геройның хыялына, уйларына чикләнмәгән ирек бирә, тарихка үтәргә мөмкинлек ача. Эре штрихлар ярдәмендә шагыйрь Чаллының һәм халыкның үткәнен, Идел-Чулман буйларына олы фаҗига китергән ачлык елларны, Бөек Ватан сугышы афәтен күз алдына бастыра. Тарихи уйланулар тикмәгә генә түгел икән. КамАЗ төзелеше — үзе дә тарихи вакыйга. Анда Корчагин, Матросов, Җәлил токымнары эшли, алар, өлкән буыннарның революцион традицияләрен дәвам иттереп, хезмәт батырлыгының югары үрнәкләрен күрсәтә. КамАЗны яшьләр төзи, яшьләр күтәрә. «Кайда яшьлек — анда «Гренада»лар, кайда яшьлек — анда романтика».

С. Хәким поэмасын «Дәверләр капкасы» дип атаган. Бу исем тирән фәлсәфи мәгънәгә ия, ул халыклар арасындагы дуслыкны, илебезнең көчен, ныклыгын символлаштыра. Чаллыны бөтен ил төзи: «һәр халык үз төсен, хисен салып, йортларыңны китсен синең салып».

Вакытка фәлсәфи караш шагыйрьгә киң этик категорияләр белән эш итәргә мөмкинлек бирә. «Кырыгынчы бүлмә» поэмасында ул «Коридордан Тукай заманына Атлап керәм, тап-тар коридор...»,— дип Тукай чоры белән безнең көннәрне символик якынлаштыра.

Социалистик реализмның тарихи ачык эстетик системасы рамкасында яши һәм

үсә килгән романтик стиль, шартлы алым «Ибраһим Йосфи» балладасында яңача үстерелгән иде.

Реалистик шартлылык С. Хәкимгә соңгы поэмаларында тарихи үткәнгә, реаль күренешләрнең эчке мәгънәсенә, рухи сфера нечкәлекләренә үтеп керергә, «җан диалектикасын» сурәтләргә мөмкинлек бирә.

Гадәти белән илаһи арасында ярашу, күп очракта эчке гармония таба белү, төшенчәнең кучерелмә мәгънәсенә таяну аша С. Хәким психологик анализның мөмкинлекләрен үстерә.

**Әкиятләре белән, кар белән**
**Тукай керде өйгә. Казанда аш,**
**Бөтен дөнья тулган пар белән.**

Тукай намусы хәзерге кешенең, хәзерге шагыйрьнең эшчәнлегенә, яшәешенә әхлакый бәянең югары ноктасы, үлчәү билгесе.

**Җырны җырга куеп карыйм,**
**Намусыма — аның намусын.**

Бу — кыю чагыштыру. Ә бит Тукайның рухи дөньясы Пушкин, Лермонтов, Байроннарның батыр җаннарын, мәгърур шигъриятләрен үзенә сыйдырган. Хәзерге шагыйрь дә менә шул киңлеккә, шул идеалга ашкынырга тиеш.

С. Хәким поэзиясендә тормышны җентекләп өйрәнү нәтиҗәсендә туган сыйдырышлы деталь аерым әһәмияткә ия. Дуга эпопеясыннан соң егерме биш ел узгач, шагыйрьне хисләре сугышкан урыннарына алып китә. Үткән белән хәзерге арасында хәтер тора: «Торам уйлап, элек мине монда Чүкеп алыр иде снайпер». «Чүкеп алыр» иде метафорасы трагизмны киметә. Вакыт узган. Сугыш кырында таш мәктәп калкып чыккан. Хәтер яңадан үткәнгә сөйри.

Иҗатының башлангыч дәверендә үк С. Хәким үзенең Тукай традицияләренә, халык иҗаты гәүһәрләренә тугрылыгын раслап чыга. Шул юлыннан баш тартмады, һәр чорда төрлечә киемнәрдә күтәрелеп алган формализм шаукымы да аның халыкчан, саф иҗегенә кагылырга батырчылык итмәде. Олы остазларының иҗат уты яктысында ул үз шигъри мәктәбен тудырды, шуңда да традицияләрдән өйрәнүен, алар белән бәхәсләшүен һәм үстерүен дәвам итте.

Соңгы елларда иҗат ителгән фәлсәфи эчтәлекле, дәвернең катлаулы проблемаларын үзенчә ачып биргән, камил композицияле поэмаларында да С. Хәким халык зиһене казанышларыннан баш тартмый. Мәсәлән, «Дуга» поэмасында шагыйрь халыкның сурәтле фикерләвендә туган берничә алымны «эшкә җигә».

**Июль. Дуга. Дулый көн-төн сугыш...**
**Кем кулында аның нуктасы!**

Халыкның ышануын, тормыш фәлсәфәсен эченә алган, хакыйкатьне, дәреслекне, нигез терәкне эзләү юлында туган бу образны шагыйрь алдагы юлларда тагы да киңәйтә, риторик сорауның мәгънәсен үстереп, аны үз язмышына китереп бәйли. Шагыйрь язмышы ил язмышына килеп тоташа.

**Дуга минем яшьлегемнең дә ул**
**Иң югары кайнар ноктасы.**

Танклар армадасы хәрәкәтен дә шагыйрь күбрәк халык акылы тудырган күзаллаулар һәм чагыштырулар аша тасвирлый: «Ат көтүен куып керткән кебек, Прохоровка үзәннәренә Куды дошман үзенең танкларын...»

С. Хәким поэмаларыннан халык афоризмнарына, халык мәкальләренә якын тирән эчтәлекле, тыгыз мускуллы җөмләләрне күпләп табып булыр иде. Берничә мисал белән чикләнәбез: «Туган тел — аның бар байлыгы...» («Васыятьләр»), «Ил кайгысы — олы елауда», «Кайсы ауды, печән чабып арган Печәнче күк, ятып покоска», «Тузан гына йөзә, беләү күк» («Дуга»).

С. Хәким күңеленә якын шигъри алымнарын туктаусыз үстерә, баета бара. Аның кеше белән табигать арасындагы катлаулы диалектик мөнәсәбәтләрне тасвирлау алымнарында мөһим үзгәрешләр барлыкка килде.

«Пар ат» поэмасында, мәсәлән, табигать кешедән башка яши, хәрәкәт итә торган объектив чынлык, табигый матурлык буларак тасвирлана. Кеше тормышы табигать күренешләре аша сынландырыла.

Әй, чияләр, Җырчы күрми үлде
Сезнең соңгы гүзәл гомерне.
Сез бөрегә яңа җыенганда
Ул чәчәген коеп өлгерде.

Алдагы елларда табигатькә караш катлаулана. Шагыйрь параллелизм алымы, табигатьне җанландыру белән генә чикләнмичә, чынбарлыкка, кешегә хас сыйфатларны күчерә, ике көч арасындагы мөнәсәбәтне бөтен катлаулыгында ачарга омтыла.

Сатащты, тәрәзә төбендә
Улады декабрь, шомлы кыш.

(«Васыятьләр»).

Кеше төсле үксеп, куаклыкта
Балалары елый төлкенең.

(«Дуга»).

Алдарак бу чагыштыру үстерелә, табигать белән кеше арасындагы якынлык әхлакый сферага күчерелә:

Кеше булып елаганга күрә,
Җәзаланган гүя җәнлекләр.

Тормыш тәҗрибәсе үскән, шигъри осталыгы камилләшә барган саен С. Хәким туктаусыз эзләнә, иҗат газаплары кичерә.

Янәдән «Дуга» поэмасына әйләнеп кайтыйк. Нигез итеп алырлык материал әзер. Вакыйга-хәлләр шагыйрьнең үз башыннан кичкән. Хисләр ташып-актарылып тора. Башта проза белән язарга да исәпли шагыйрь. «Язарга утыргач, прозаны шигырь җиңде. Ә шигырь җентекләп язуны яратмый. Ни булса да мин хисләрем артыннан ияреп, шигъри әсәремә кереп киттем»,— дип искә ала ул. Хәзер, шагыйрь үзе язганча, «Ямьмышларны бер урынга җыеп», «бер җепкә төйнәсе», поэманы әйдәп баручы «нокта»ны, образларны, вакыйга-хәлләрне күңелгә «кадаклап» куярдай сурәтле фикерләү системасын тудыру бурычы алга килеп баса.

Поэманың образлар системасы катлаулы, гаять тирән уйланылган. Төп идея-эстетик нагрузка материаль дөнья белән рухи сферадан алынган һәм үзәк шигъри фигуралар буларак үстерелгән ике образга төшә. Шагыйрь табигатьтән «имән»гә барып тоташкан образларны алса, кешенең сиземләве, кичереше белән бәйле рухи халәттән «сыкрау», «елау», «әрнү» кебек төшенчәләрне үзәккә куя.

«Имән», «имәннәр», «имәнлек» сүзләре «серле», «шомлы», «карт», «зур», «олы» кебек эпитетлар, җанландырулар белән төрле контекстларда утыз тапкырлап кабатлана. Алар поэманың пафосын, геройларның туган җирләренә, табигатькә актив мөнәсәбәтен, дошманга нәфрәтен ачуда мөһим функция башкара. Шагыйрь бу табышын эчке сиземләү белән яратып үстерә. Образ бер баскычтан икенчесенә күтәрелә, бер дәрәҗә аша икенчесенә юл ала, семантикасын тирәнәйтә, төрле зурлыктагы дулкыннар шикелле бер-бер артлы ишелеп килгән, әмма үзара тыгыз бәйләнгән сурәтле рәтләргә үсә.

«Имән» беренчел дәрәҗәсендә сугыш барган урынны, ил азатлыгы өчен көрәш-

нең бер кайнар төбәген күз алдына бастыра: «Алда безнең зур имәнлек иде», «Имән нәрнең бер төркеме Баскан чыгып бераз алгарак»...

Шагыйрь бу төшенчәнең идея-эстетик мәгънәсен киңәйтә бара. Иң элек имәнлеккә үзенең уй-хисләр ташкынын алып керә. («Уйларымны, хисләремне үзенә тартып алды күптән имәнлек») һәм акрынлап аны күпмәгънәле образ итеп үстерә: «Карт имәннәр... Дуга кырларыннан җыелганнар кебек солдатлар».

Авторны мондый артык гомуми тиңләү дә канәгатьләндереп җиткерми. Индивидуальләштерү юк. Табигать образының потенциаль мөмкинлеге ачылып җитмәгән. Шагыйрь хыялы яңа контекстлар, образның яңа дәрәҗәсен эзли. Ул һәр имәндә җанлы кеше сынын, кеше язмышын күрә, төрле милләт вәкилләрен таба. Кеше белән табигать арасындагы аерма, мифик фикерләү дәверендәге шикелле, бөтенләй алып ташлана: «Бусы — Низам. Карт имәннәр аны әйләндереп алган уртага», «Яңа имән арттa, Каекбай ул». Бу образлар тормыш һәм язмыш фаҗигасенең әхлакый эчтәлеген, совет кешесенең рухи олылыгын күрсәтүнең бер формасы буларак ачылалар.

Имән-имәнлекнең кулланыш сферасы моның белән генә чикләнми. Аңа тагын бер вазифа «йөкләтелә».

Поэманың үзәгендә олы героик вакыйга ята. Сүз Бөек Ватан сугышында ил язмышы хәл ителгән иң авыр, иң хәтәр бер чор турында бара. Өстән туктаусыз тимер яңгыр ява, безнең сакчылар яткан окопларга таба танклар үрмәли. Җир сыкрый... Тарихта тиңе булмаган танклар бәрелешенең дәһшәтен образлы күзаллау нияте шагыйрьне янәдән үзәк образга алып чыга: «Бик хәвефле итеп, шомлы итеп, Имәнлек тә шаулый...» Табигать вәхшилекне, ерткычлыкны кабул итми, иле, уллары өчен әрни, сызлана. Гуманизм, азатлык, матурлык дошманы бу хәлне абайлый:

**— Рус, бирел,— дип кычкырдылар,— бирел,**
**Имәнлегең — илең таптармын.**

Шушы контекстта имәнлек яңа дәрәҗәгә — туган ил символы дәрәҗәсенә күтәрелә. Табигать сурәтенең роле, мәгънәсе үсә. Шагыйрь бу табышны яратып кабатлый, аның һәр халык өчен якын, газиз кыйблаларын үзәккә ала: «Туган телнең кадерен белергә дә өйрәтте шул серле имәнлек».

Шул рәвешле, шагыйрь үзәк образын рухи дөнья белән бәйли, совет кешесенең дошманнан әхлакый өстенлеген, туган җирнең, табигатьнең мәңгелеген, үлемсезлеген раслау максатына буйсындыра.

Имән — ирлек, батырлык символы. Хатын-кызны искә төшергәндә исә шагыйрь башка образ таба.

**Артта таллар — татар хатыннары**
**Сөйләшәләр төсле лепердәп.**

Шагыйрь кырыс реализмга, тормыш дөреслегенә турылыклы кала, үз буыны язмышына төшкән авырлыкны, ике дөнья арасында барган сугышның дәһшәтен, шаукымын яңа буыннарга тулырак ирештерүгә омтыла. Риторик-купшы тезмәләрне читкә кагып, кеше психологиясен, характерын ачуның яңа юлларын эзли. Үзенчәлекле образлар ярдәмендә ул тарихи үткәнне киләчәккә ышаныч, фәлсәфи уйлануларны тирән оптимистик хис белән кушуга ирешә. Поэманың ышандыру көче менә шунда.

С. Хәким поэмаларының композициясен камилләштерү юнәлешендә дистә еллар буе киеренке эзләнүләр алып бара. Аның лиро-эпик әсәрләре күзгә күренеп кыскара, җыйнаклана һәм тыгызлана бара. «Дала җыры» (1948) поэмасының «сөйләүгә корылган озынлыгы», «күп сүзлелеге хәзер күңелләрдә ризасызлык хисе уята», дип яза шагыйрь «Дуга»ны ачып җибәргән кереш сүзендә.

Уңышлы поэмаларның «формалары шагыйрьнең дәвер белән күзгә-күз карап, ачыктан-ачык сөйләшүе, бәхәсе...» җирлегендә табигый туа. Һәркайсы кабатланмас композициясе, тел-стиль үзенчәлекләре белән аерылып тора.

С. Хәким һаман эзләнә... «Җепләр — юллар, юллар — йомгак, йомгак, Чакырдылар еллар еракка...» Еракларга чакырган еллар әле шагыйрьне киләчәктә янәдәнянә поэма һәм шигырьләргә рухландырыр.

Катлаулы чорыбызны тирән һәм һәрьяклап ачу, иҗтимагый, экономик һәм фәнни ярышның масштабын сәнгатьтә тулырак чагылдыру бурычы поэзиядә барлык уңай традицияләрдән кыю файдалануны, үстерүне, форма мөмкинлекләрен һәм стиль юнәлешләрен туктаусыз яңартып торуны таләп итә. Иксез-чиксез вакыт һәм кеше аңының тирәнлекләренә үтеп керү максаты символика, куерту, фәлсәфи гомумиләштерү, ассоциация кебек шартлы алымнарга киңрәк таянырга чакыра. Язучының шартлы һәм үтә шартлы алымнарга мөрәҗәгать итү хокукын яклап, Ч. Айтматов түбәндәгечә яза: «Мин шәхсән кешене көнкүреш кабыгына ябып куйган утилитар, көнкүреш «реализмына» каршы. Аның өчен дөреслеккә тышкы охшашлык, күпсүзлелек, кирәкмәгән детальләр ыгы-зыгысы, хаос һәм фактография характерлы. Ул иҗади фантазияне, хыялны томалап китә» [1].

Совет әдәбиятында шартлы алымнар реалистик принципларга буйсына һәм сурәтле фикерләүнең, образлылыкның табигатенә яраша. Әдәбият галимнәренең күпчелеге социалистик реализмның гомуми идея-эстетик концепциясенә буйсынган шартлылыкның төрле алымнары хакыйкатьне калкурак күрсәтергә ярдәм итә диган карашта торалар [2].

И. Юзеевның «Тынлык белән сөйләшү», «Таш диварлар авазы», «Өзелмәс кыллар», Ә. Баяновның «Һәйкәл», Р. Әхмәтҗановның «Таш аргамак», Р. Харисның «Җитмеш икенче ел икмәге», «Рәссам», Р. Фәйзуллинның «Көрәшчеләр», Р. Мингалимовның «Минем дәүләтем», «Юл өстендә тургай», «Иртәгә», Ф. Сафинның «Ак канатлы егет» кебек соңгы елларда иҗат ителгән поэмалары эпик жанрның чорны һәм рухи дөньяны тасвирлау мөмкинлекләре чикләнмәгән икәнлекне исбат итте.

Хәзерге укучыны озын-озын тасвирый поэмалар белән шаккаттыруы кыен. Хикмәт вакытның кыйммәте артуда гына түгел, ә укучының интеллектуаль үсешендә, фикерләүдә барлыкка килгән прогресста. Укучы мөмкин чаклы тар мәйданда ачылган олы фикер, киңчереш тирәнлеге таләп итә, шул төр әсәрләргә сусый.

Замандашыбызның фикерләү рәвешенә якынрак килергә, образлы тасвирлау алымнарын яңартырга омтылыш, мәсәлән, Роберт Әхмәтҗановның «Йолдызстан» поэмасында ук күренгән иде. Шагыйрь Җир, Галәм, Биосфера кебек масштаблы образларны сурәткә алып керә һәм бүгенге техник прогресс (тавыштан тизрәк очучы самолет уйлап табу, космоска очу һ. б.) белән тиз йөри торган итекләр, оча торган паласлар уйлап чыгарган халык хыялы арасындагы күпер, уртаклык турында уйлана, кешенең киләчәк уңышларын күз алдына бастырырга тырыша.

И. Юзеевның «Тынлык белән сөйләшү» әсәрендә индивидуальләштерелгән образлар да, канунлашкан сюжет та юк, ара белән вакыт та чиктән тыш гомумиләштереп бирелгән. Художникның кыю фантазиясе рух өргән Бер минутлык тынлык, Вөҗдансыз тынлык, Билгесез тынлык, Хиросима тынлыгы, эпоханың «көч сызыклары»н, XX гасырны тетрәткән фаҗигаларның сәбәбен ачуга буйсына.

Р. Харис «Җитмеш икенче ел икмәге» поэмасында шартлы алымнарга шулай ук киң таяна. Шагыйрь беренче юлда ук — сәнгать «тормыш күчермәсе түгел» принцибы буенча — «хыялым — зурайткыч пыяла» дип, бөртеккә каршы чыккан явызлыкның серен эзләргә юнәлә. Катламнар эчендә «интегеп, кысылып, басылып, нәрсәдер әйтергә тилмереп» ел фасыллары ята. Табигать кешегә «ачык чырай» күрсәткәнчә, ул үзенең хаклыгын хезмәте белән расларга тиеш. Поэманың фәлсәфи һәм этик нигезе шул идеядән үсеп чыга.

«Рәссам» поэмасында шагыйрь чынбарлыкны «проекцияләү» кебек катлаулы алымны үзәккә ала. Бер яктан, берсен-берсе кысрыклап килгән катлаулы проблемалар белән тулы мәшәкатьле олы дөнья һәм вакыт реаль, тойгылы образлар аша гәүдәләндерелсә, җисемле бөтенлеге дә тасвирланса, икенче яктан, әле генә безнең күз алдыннан үткән чынлыклы вакыйгалар һәм күренешләр яшәешне, рухи дөньяны камилләштерү, бизәү нияте белән илһамланган рәссамның ассоциатив-метафорик күрүе аша сынландырыла. Хыял белән баетылып, үзгәртелеп корылган дөнья тагын да гомумиләштерелә, тагын да эреләндерелә. Гүзәл кыз һәм аның киндердәге сыны, рәссамның табигый сынга һәм үзенең иҗат җимешенә мөнәсәбәте, мәхәббәте, сугыш

---

[1] «Литературное обозрение», 1978, № 1, 23 бит.

[2] Кара: Егоров А. Проблемы эстетики. М., «Советский писатель», 1977; Храпченко М. Б. Творческая индивидуальность писателя и развитие литературы. М., «Советский писатель», 1970.

һәм рассамның афәтне күзаллавы бергә аралашып, зиһенне зирәкләндерерлек, хисне хәрәкәтләндерерлек шактый катлаулы структур һәм стилистик бердәмлек тудыра. Шагыйрь үз героеның рухи дөньясына, фикерләү рәвешенә тирән үтеп керә алган.

1978—1979 елларда «Казан утлары»нда поэзия турында барган сөйләшүне башлап җибәрүчеләрнең берсе — Р. Фәйзуллин поэма тукымасында барлыкка килгән яңалыкларга да тукталя: «Поэма хакында әдәбиятчылар күптәннән бәхәсләшәләр. Ләкин бер төгәл фикергә килгәннәре юк, ихтимал килә дә алмаслар... Чөнки яңа әдәби күренешләрнең әледән-әле хасил булып торуы да ниндидер бер тотрыклы нәтиҗәгә килергә ирек бирми... Хәзер безне поэманың классик төшенчәсе канәгатьләндереп бетерми, ә яңа формалары турында фикер туплап бетерә алганыбыз юк».

Һәр эзләнүчән шагыйрь поэма үсешенә үзеннән өлеш кертә. Күреп үткәнебезчә, С. Хәким тарих белән бүгенге арасында җанлы җепләрне эзли, романтик экспрессия алымнарына киң таяна. Р. Фәйзуллин публицистик гомумиләштерү ярдәмендә кешене олы һәм масштаблы итеп тасвирларга, замандашының характерында барлыкка килгән үзгәрешләрне тирәнрәк аңларга омтыла, эчке монологка киң таяна. Роберт Әхмәтҗанов фәнни фикерләү алымнарын шигърияттә яңгырату рухы белән яши...

Шул ук вакытта иң соңгы елларда поэма жанрына игътибарның кимүенә, анык сан ягыннан да элеккеге позицияләреннән чигенүенә игътибарны юнәлтәсе килә (мәгълүм булганча, сан еш кына сыйфатка тәэсир ясый).

«Казан утлары» — әдәбиятыбыз үсешенең барометры. Анда төрле елларда басылган поэмаларның исәбен алып карыйк. 1968 елда әдәби журнал укучысына — 6, 1969 елда — 5, 1970 елда — 5 поэма тәкъдим итә. Җитмешенче елларның икенче яртысында хәл үзгәрә. 1978 елда Ә. Рәшитовның «Тормыш әлифбасы» поэмасы гына дөнья күрә (ул шагыйрьнең үзе өчен дә мәртәбә әсәр түгел), ә инде 1979 елын «Казан утлары» поэмасыз төгәлли. 1980 елда Равил Фәйзуллинның «Сәйдәш» поэмасыннан өзекләре, Илдар Юзеевның «Мәхәббәт китабы» укучыга ирешә.

Яңа басылып чыккан шигырь җыентыкларында да әлегәчә укучыга мәгълүм булмаган поэмалар юк диярлек дәрәҗәдә аз. Иҗат практикасы теоретик аңга да, тәнкыйть сүзенә дә тәэсир итмичә калмый. Матбугатта, поэма кризис чоры кичерә, борынгы жанр заман агышына ияра алмый, аны оператив, тезек шигъри цикллар кысрыклый бара, дигәнрәк фикерләр әйтелә башлады. Р. Фәйзуллин югарыда телгә алынган чыгышында симпатиясенең шигъри бәйләмнәр ягында икәнлеген ачыктан-ачык әйтеп сала: «Ясалмарак поэмаларга караганда тезек шигырь цикллары күбрәк ошый төшә». Чыннан да уртак идея, эзлекле ачылган хис тирәсендә берничә әсәрне укмаштырган лирик бәйләмнәр күп язылды, популярлашып китте. Х. Туфанның «Ә үткәнгә хатлар бармыйлар», С. Хәкимнең «Торыгыз, Мусалар», «Суд залында», «Тукай дәфтәреннән», «КамАЗ көндәлеге», Н. Арслановның «Еллар, язмышлар», Х. Камаловның «Әнкәй истәлеге», Р. Әхмәтҗановның «Идел-йорт», Р. Гатауллинның «Европада татар шагыйрьләре» цикллары, Ш. Галиев, И. Юзеев, Р. Харис, М. Әгъләмовларның идея-эстетик яктан бер-берсенә тартылып торган әсәрләрен туплаган шигъри келтәләре поэзия түрендә урын алды. Сәнгать белән әдәбиятның үзара аралашуы, төрле жанрларның бер-берсенә якынлашуы, фикерләүдәге гомумиләштерүгә, синкретизмга омтылыш поэма белән шигырь арасында торган бердәмлекләрнең активлашуына алып килде.

Шул ук вакытта шигъри цикл безнең көннәр җимеше түгел. Ул Гете, Блок, Маяковский иҗатларында ук зур уңышка ирешә, әдәби процесста үз урынын таба.

«Шигъри цикл» — шартлы билгеләмә. Аны төгәл кануннары, даими, тотрыклы сыйфатлары тәгаен анык булган мөстәкыйль әдәби жанр дип атавы кыен. Шагыйрь иҗтимагый тормышның һәм рухи халәтнең бер торышын чагылдыручы лирик әсәрләре арасында тематик, предметлы, хисси эчке бердәмлек табып, аларны укмаштырырга мөмкин. Биредә төп рольне иҗатчының субъектив нияте, омтылышы уйный. Чынлабрак карасаң, теләсә кайсы уңышлы лирик әсәр авторның башка шигырьләре белән идея-эстетик якынлыкта тора. Бер шигырьнең икенчесенә тартылып торуы шигъриятнең эчке хасияте.

Хәзерге татар поэмасының уңышлары, төрле юнәлешләрдә алып барылган эзләнүләре һәм аерата үсеш кыенлыклары турында уйланганда алтмышынчы еллар уртасында олы шигъри форманың үсеш юллары һәм перспективасы хакында барган

бер сөйләшү иискә төшә. Бу дискуссиядә Көнчыгыш поэмасының тарихы югары бәя алды. Фикер алышуда катнашучылар Көнчыгышның ерак гасырлар түреннән күтәрелгән идея-эстетик байлыгын җитдирәк өйрәнергә һәм бу традицияләрне хәзерге иҗат практикасына кыюрак алып керергә чакырдылар. Төрки халыклары поэзиясен рус телендә яңгырату эшенә зур көч куйган тәрҗемәче һәм шагыйрә А. Адалис «Нәрсә ул поэма?» исемле мәкаләсендә болай ди: «Ни өчен без торган саен ныграк Көнчыгыш поэмасы ягына борылабыз... чөнки тарихка Көнчыгыш классикасы «поэма иле», «поэма патшалыгы» булып керде һәм Европаның урта гасырлар әдәбиятына да йогынты ясады, һәм бу йогынты әлегәчә тарихчылар тарафыннан тиешенчә өйрәнелмәгән»[1].

Поэма үзенең тарихи үсеш юлында төрле чорлар кичерде. Тукай, Такташ, Җәлил, Ә. Фәйзи, Ф. Кәрим иҗатларында ул үсешенең яңа үренә күтәрелде, яңа кеше, яңа әхлак өчен көрәштә әдәбиятның алгы сызыгында булды. Дөрес, аның бәйгедәге мәйданны башка жанрларга калдырып, арткарак чигенгән чаклары да булды. Ләкин анда да поэзиянең олы төре киләчәк көннәр өчен көч туплады, яңа юллар барлады. Җитмешенче елларның икенче яртысы менә шундыйрак чор булды. Әлбәттә, бирeдә чорның «гаебе» юк. «Кешесез поэмалар тууының сәбәбен заманга сылтау урынсыз»[2], дип язуы белән Роберт Әхмәтҗанов хаклы иде. Бу хәлнең сәбәпләре төрле. 60—70 нче еллар арасында нык үскән социализмның әхлакый фәлсәфи мәсьәләләрен эченә алган, масштаблы фикерле, рухи дөнья катлаулылыгын бөтен кискенлеге белән калкытып куйган, форма өлкәсендә дә кызыклы табышларга бай поэмалар күп язылды. Яуланган үр җаваплылыкны арттырды, жанрда яңа сүз әйтү кыенлашты. Поэманың яңа төрләре барлыкка килүе сәнгатьчә фикерләүнең тагын да үсүе, үз эченә индивидуальлекне һәм гомумилекне алган яңа заман тәҗрибәсен, аерым шәхеснең һәм бөтен буынның, бөтен җәмгыятьнең рухи үсешен, яңаруын аңларга омтылу белән аңлатыла.

Хәзер тәнкыйтьтә поэманың ниндидер бер төренә өстенлек бирeп, эпик башлангычны лиризмга, фәлсәфи анализны кешелекле моңга каршы кую, поэманың эчке хасиятен кыскалыкка яисә озынлыкка, тышкы конфликтка, вакыйгаңы сюжетка яисә кичереш динамикасын ачуга кайтарып калдыру фактлары азайды. С. Хәким, И. Юзеев, Р. Харис, Р. Мингалимов, Р. Фәйзуллин һ. б. шагыйрьләрнең уңышлы поэмалары тормышның үзе шикелле үк, бай һәм төрле.



**Язучылар — КамАЗда. Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе Гариф Ахунов (уңнан беренче) кунакларны КамАЗ белән таныштыра.**

К. Ситдиков фотосы.

[1] «Литературная газета», 1975, 15 июль.
[2] «Казан утлары», 1979, 4 сан, 154 бит.

Наип Лаисов

# ШИГЪРИЯТ — ТАБИГАТЬ САГЫНДА

Әйләнә-тирә мохитны саклау — кешелек алдында торган иң мөһим проблемаларның берсе. Табигатькә мөнәсәбәт мәсьәләсе бигрәк тә хәзерге чорда кискенләшә төште. Бу проблема тирәсендә барган бәхәсләр, төрле карашлар бәрелеше бүгенге шартларда идеологик һәм политик төсмер ала. Буржуаз галимнәр фән-техника казанышлары, нинди социаль-иҗтимагый шартларда кулланылуга карамастан, кеше тормышында, культурада табигыйлекне җимерә, юкка чыгара дип расласа, алдынгы, демократик фикер ияләре, прогрессив фән әһелләре исә табигатьне саклау эшен табигать белән җәмгыятьнең үзара йогынтысы турындагы диалектик-материалистик тәгълимат җирлегендә оештырырга кирәк дип исәплиләр, шул позициядән чыгып эш итәләр.

Совет әдәбияты да шушы проблемага, кеше һәм табигать арасында булган катлаулы мөнәсәбәтләрне өйрәнүгә зур игътибар бирә. Социалистик төзелешләр чоры язучысы табигатькә яңача мөнәсәбәт турында уйламыйча мөмкин түгел иде, әлбәттә. Яңа әдәбият алдына кешене стихияләр колы, табигатьнең хезмәтчесе яисә аның корбаны итеп түгел, ә табигатьнең чын-чыннан хуҗасы, дусты һәм юлдашы итеп, аны яңа, фәнни нигездә үзгәртеп коручы итеп сурәтләү бурычы килеп басты.

Күпмилләтле совет әдәбияты «табигать һәм кеше» проблемасын сәнгатьчә үзләштерү юлында М. Горький, М. Пришвин, П. Тычина, Н. Заболоцкий кебек күренекле әдипләрнең эстетик ачышларына таяна, алар традициясен яңа шартларда дәвам итторә. Бу өлкәдә һәр әдәбиятның үз тәҗрибәсе, үз казанышы бар.

Аңлашыла ки, проблема үзе дә, аны сәнгатьчә чагылдыру алымнары да катлаулы һәм күптөрле. Беренче чиратта, бу — жанр спецификасы, аның мөмкинлекләре белән билгеләнә. «Табигать һәм кеше» темасына кагылышлы проблемаларны киң планда, аның фәлсәфи һәм экономик, социаль һәм әхлакый-психологик аспектлары белән, зур күләмле әсәрләрдә генә бирергә мөмкин. Әмма поэзиянең дә, шул исәптән лириканың да, бу өлкәдә үзенә генә хас мөмкинлекләре, ачышлары, эстетик казанышлары бар.

Безнең максат — соңгы еллар татар поэзиясендә «табигать һәм кеше» темасын үзәккә алып язылган аерым шигырьләргә күзәтү ясау, бу проблеманы поэзиядә чагылдыруның кайбер тенденцияләрен билгеләүдән гыйбарәт.

## «Аккош күле тыныч...»

Бөек Октябрьга кадәрге татар поэзиясендә чын мәгънәсендә табигать лирикасының матур үрнәкләре Г. Тукай, Дәрдмәнд, С. Рәмиев, шулай ук З. Ярмәки, М. Укмасый, Н. Думавыйлар тарафыннан иҗат ителә. Төрле буын татар совет шагыйрьләре аларның ачышларына таяна, ул традицияләрне тагын да баета, үстерә. Яңа чор поэзиясендә табигать сурәтен тудыруның юнәлешләре, сызыклары 20 нче һәм, бигрәк тә, 30—40 нчы елларда — һ. Такташ, Х. Туфан, М. Җәлил, Ә. Фәйзи кебек шагыйрьләр иҗатында ачыклана.

Табигать образларына яңа эчтәлек, яңа функция бирeп сурәтләү барыннан да элек һ. Такташта башлана. Шагыйрь иҗатында «саф» табигать лирикасы күп түгел, булганы да шигырь структурасының аерым элементы, кисәге буларак кына килеп керә, әмма аңа карап чын сәнгатьчә эшләнгән табигать рәсеме булуын югалтмый. Бер үк вакытта табигать күренешләре, кош-корт сурәтләре, хайван образлары конкрет бер вакыйганы җанландыру өчен дә, кешенең эчке дөньясын, уй-кичерешләрен тулырак, сиземлерәк итеп чагылдыру максатында да кулланыла.

Х. Туфан шигъриятькә Урал һәм Себернең үзенчәлекле табигатен алып керә, табигать сурәтләре аша чор рухын, чор идеалларын чагылдырырга омтыла, табигать күренешләренә төрле стилистик һәм мәгънәви функцияләр йөкли.

Шулай да 20 нче еллар поэзиясендә табигать лирикасы зур урын тотмый әле. «...Мәңгелек темаларны, шул исәптән пейзаж лирикасын үстерүдә поэзия мәгълүм авырлыклар кичерә», «табигать күрке — җырчы сандугачны «корыч, индустриаль сандугач»ка алыштыруга чакыруларның нигезендә дә табигать күренешләрен берьяклы, искелек калдыгы дип бәяләү ятты. Бу тенденцияләр 30 нчы еллар поэзиясендә дә үзен сиздерә» [1].

Вульгар социологизм тәнкыйте йогынтысы нәтиҗәсендә табигать лирикасына интим лирика үрнәкләре итеп кенә карау таралса да, табигать күренешләрен үзәккә алып язылган шигырьләр торган саен күбрәк басыла, табигатьне тасвирлауның төрле формаларын эзләү тагын да активлаша төшә. Әйтик, Х. Туфан табигать белән кеше арасындагы катлаулы мөнәсәбәтләр турында уйланса, М. Җәлил табигать матурлыгын җырлый, кеше белән табигать арасында иплелек, гармония эзли, Ә. Фәйзи исә табигать күренешләрен рәсемдәге тәгәллек белән сурәтләргә омтыла.

Бөек Ватан сугышы чорында пейзаж лирикасы тагын да җанлана төшә. М. Җәлил, Ф. Кәрим, Ә. Фәйзи, С. Баттал, Н. Дәүли, Г. Хуҗи, Н. Арсланов, Ә. Юныс, Ә. Исхак, С. Хәким һәм башка шагыйрьләр иҗатында табигать сурәтләренең функциясе үзгәрә, тыныч, күркәм табигать сугыш күренешләренә контраст итеп куела, совет солдатының рухи дөньясын ачу өчен файдаланыла. Туган як табигате шагыйрьләрнең иң яратып сурәтләнгән темасына әйләнә.

Сугыштан соңгы елларда да туган җир, аның гүзәл табигате поэзиядә төп темаларның берсе булып кала. Шагыйрьләр, бердән, туган якның аерым төбәкләренә багышлап шигырь язалар, туган табигатьнең гүзәллеген шигырь юлларына күчерәләр, икенчедән, кеше белән табигать арасында гармония эзлиләр, аерым шәхес язмышы белән галәм тормышы арасында якынлыкны аңларга тырышалар, табигатьне кешенең юлдашы, якын дусты һәм киңәшчесе итеп сурәтлиләр. Бу елларда, бигрәк тә Х. Туфан иҗатында, кеше белән табигать арасындагы бәрелешне тасвирлау традициясе дә дәвам иттерелә. Гомумән, 50—60 нчы еллар татар поэзиясе пейзаж лирикасы традицияләрен яңартуда зур сикереш ясый, табигать темасын сурәтләүдә милли поэзиянең моңарчы күрелмәгән мөмкинлекләрен ача.

Татар поэзиясендә табигать лирикасының үсеш тарихына кыскача экскурс ясау шуны күрсәтә: 60 нчы елларга кадәр «табигать һәм кеше» темасы нигездә традицион планда, әлегрәк билгеләнгән юнәлештә ачыла, ягъни поэзиядә, бердән, сугыштан соңгы тыныч тормышны данлау, туган як, туган табигать гүзәллеген җырлау; икенчедән, табигать белән тартышта җиңеп чыккан кешене олылау темасы төп урынны алып тора. Бу, үз чиратында, шул чорның атмосферасы, хәл итәлә торган социаль-экономик проблемаларның характеры белән билгеләнә.

XX съезд хәл иткән чаралар халык хуҗалыгы үсешендә зур борылыш ясарга мөмкинлек бирде. Хуҗалык уңышлары язучыларга рухланып иҗат итү өчен этәргеч булды. Ул елларда бөек төзелешләр темасын сәнгатьчә үзләштерүдә татар шагыйрьләре шактый бай тәҗрибә тупладылар. Төзелешнең үзен һәм фонын, атмосферасын бирү, хезмәт процессының рухи тормышыбызны үзгәртүе турында уйланулар поэзиядә төп урын алды. Әйтик, Х. Туфанның «Талантлы син, Кеше туганым», «Вахтадан кайта егетләр», Ә. Давыдовның «Себер трактында квартал» циклы, Х. Камаловның «Әлмәт эскизлары», шулай ук Г. Афзал, З. Нури, Ш. Галиев, Ә. Маликов һәм башка шагыйрьләрнең әсәрләре хезмәт поэзиясенең матур үрнәкләре булып яңгырады. 50 нче еллардан башлап татар поэзиясенә нефтьчеләр темасы көчле агым булып килеп керде. Бу темага С. Хәкимнең «Вышкалар күченә», «Нефть чыккан җирдә», «Буровой мастер», «Баулы юлында» шигырьләре, «Үрләр аша» поэмасы кебек әсәрләр язылды.

Илебезнең фән, техника, экономика өлкәсендәге уңышлары белән рухланып иҗат иткән шагыйрьләр табигать байлыкларыннан файдалану, табигатьне үзгәртеп кору процессында туган катлаулы һәм каршылыклы проблемаларга әлегә игътибар биреп җиткермиләр. «Аккош күле тыныч» — кеше һәм табигать темасын сәнгатьчә үзләштерүдәге ул чор тенденциясен шулай дип билгеләп булыр иде. Аккош күленең тынычлыгы (ә ул елларда бу турыда язмаган шагыйрь сирәк булгандыр) —

[1] Тәлгат Галиуллин. Социалистик реализм юлыннан. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1977, 90 бит.

табигатьтә иплелек, тынычлык, гармония билгесе. Борчылырга, хәвефләнергә урын юк һәрхәлдә, шагыйрьләргә шулай тоела һәм табигатьне саклау темасы поэзиядә бөтен кискенлегендә куелмый әле.

## «Аккошларым киткән...»

Х. Туфан 1970 елда язылган «Кармәт истәлекләре»ндә болай ди:

**Нечкәрер әле бер хисләрең,**
**Сиңа да аң керер, техника.**
**Синең дә бәгырең-йөрәгең**
**Әверелер әле бер лирикка.**

Чыннан да, ул елларда гына түгел, 50 нче еллар азагы — 60 нчы еллар башында ук инде хәл үзгәрде. «Табигатькә һөҗүм итү», «табигатьне буйсындыру» кебек лозунглар, табигатьне үзгәртеп кору процессында туган четерекле мәсьәләләрне җиңел генә хәл итү идеяләре кими төшеп, җиргә, аның эчке байлыкларына хуҗаларча караш бермә-бер артты, әйләнә-тирә мохитны, табигатьне саклау дәүләткүләм эшкә әверелде. Бу юнәлештә бигрәк тә КПСС Үзәк Комитеты һәм СССР Министрлар Советының «Табигатьне саклауны көчәйтү һәм табигать ресурсларыннан файдалануны яхшырту турында»гы (1972) карары хәлиткеч роль уйнады.

Әлеге карар кабул ителү поэтик фикер үсешендә, аның төп юнәлешен билгеләүдә дә борылыш моменты булды. Табигать һәм кеше проблемасы, фәнни-техник революция тудырган каршылыклар, җир-су, атмосфераны саклау мәсьәләләре бигрәк тә рус поэзиясендә киң чагылыш тапты. Н. Асеев, А. Прокофьев, Б. Пастернак, Л. Мартынов, Н. Рыленков, А. Твардовский, Я. Смеляков, Вл. Солоухин һәм башка шагыйрьләрнең 60 нчы еллар башында чыккан шигырь китаплары туган җирне кадерли белергә кирәклеген искә төшерә, табигать матурлыгын тою хисен югалтмаска, заманча цивилизацияле, әмма җансыз, йөрәксез булудан сакланырга өнди, кешенең рухи дөньясы белән табигать тормышы арасында булган мөнәсәбәтләр турында уйланырга чакыра.

Ул елларда татар поэзиясендә дә «табигать һәм кеше» темасына игътибар сизелеп артты. Дөрес, 60 нчы еллар поэзиясендә проблема күбрәк традицион планда куела: шагыйрьләрнең максаты — туган илгә, туган җиргә, аның бетмәс-төкәнмәс матурлыгына соклану хисе уяту, табигый матурлыкның гүзәллеген җырлау; туган якның урман-сулары, болын-басулары, тау астыннан бәреп чыккан чишмәләре, авылның сабан туйлары, ат, арба, тарантаслары, сары чебешле ишегаллары — барысы да кадерле, барысы да изге, дип искә төшерү.

Әмма бу — поэзиядә инде күп мәртәбәләр җырланган хис-кичерешләрне кабатлау гына түгел. Туган як табигатен данлау, авылны, туган йортны сагыну, табигать кочагына ашкыну кебек традицион мотивлар туган авылның, әйләнә-тирә мохитның киләчәк язмышы турында уйланулар белән бергә кушыла.

Фәнни-техник революция тудырган катлаулы һәм каршылыклы процессларга җавап буларак, поэзиядә ата-баба йортына, нигезгә, сабыйлыкка кайту мотивлары тагын да ешрак һәм көчлерәк яңгырый башлады.

**Нигезем... Шул изге нигезне**
**Син, шагыйрь, үлгәч тә кил эзләп,**

— дип яза С. Хәким «Васыятьләр» (1969) поэмасында. Шагыйрьнең сугышка кадәр иҗат ителгән «Яратам мин...» шигырендә үк үзәккә алынган бу хисләр еллар үтү белән тагын да тирәнрәк чагылыш таба. С. Хәкимнең «Туган як», «Туган җир», «Бу кырлар, бу үзәннәрдә...», «Башка берни дә кирәкми...», «Кырларда давыл», «Кайда да йөрәктә», «Үрләреңне менгәч», «Туган җиргә рәхмәт» кебек төрле елларда язылган шигырьләренә нечкә лиризм һәм кичерешләр драматизмы хас.

«Сабый чаклар. Тагын сезгә киндем...» — Г. Рәхимнең «Елагыз» (1974) шигыреннән алынган бу сүзләр соңгы елларда бу темага язылган шигырьләрнең күбесенә эпиграф була алыр иде. Шулай итеп, шагыйрьләрнең сәнгатьчә фикерләвенә таби-

гать дөньясы халык тормышы белән, көрәштә һәм хезмәттә тудырылган тарих белән бәйләнештә килеп керә.

Бу уңайдан шуны да искәртеп үтик. Иске, патриархаль авылны сагыну, бернинди цивилизация кулы тимәгән табигать кочагына, авыл тынлыгына ашкыну, туган як табигатен үзгәрешсез калган «идиллия» итеп күз алдына китерү кайбер шагыйрьләрдә модага әйләнде; алар тормышның тәмен, ямен шәһәрдән качуда, авылга күчеп яшәүдә генә күрәләр. Бу, үз чиратында, «фәнни-техник революция һәм авыл» темасына, авылның шәһәр белән мөнәсәбәтенә кагылышлы проблемаларны бөтен тирәнлегендә, диалектикасында аңламаудан килә иде.

Безнең шагыйрьләр рус поэзиясендә киң урын алган мондый хис-кичерешләрне тасвирлау белән артык мавыкмасалар да, авыл идиллиясенә табыну Р. Гәрәйнең 1974 елда язылган «Барысы да шул ук...» шигырендә үзен сиздереп алган иде. «Без аунап үскән үзәннәр, без йөргән болын»нар барысы да шул ук, ди шагыйрьнең лирик герое һәм: «Рәхәт соң җанга»,— дип хозурлана. Р. Гәрәйнең 1979 елда дөнья күргән «Үзеңә чакыр мине» китабында да мондый мотивлар күбрәк урын ала сыман. Андагы аерым шигырьләр туган як табигатенә чын-чыннан гимн булып яңгырый, шагыйрьнең иң изге хисләрен белдерә. Шулай да, шагыйрь авыл тормышында, пейзажында барган каршылыклы көрәнеш-процессларга да игътибар итсен иде, дигән теләк туа.

Тагын бер мисал китерик. Аерым шигырьләрдә менә мондый мотив, ситуация еш кабатлана: автор яисә аның лирик герое күптән инде авылдан киткән, шәһәрдә, зур төзелеш барган җирләрдә төпләнеп калган. Шулай кирәк, тормыш шулай куша. Бу темага, мәсәлән, Р. Мингалимов матур гына шигырьләр язды («Авылдашка хат», «Туган як кырларына» һ. б.).

**Киттек тә без читкә, яшәп калдык,**
**Кунакка да кайтмый кайсыбыз.**
**Нефть чыгарабыз, йорт салабыз,**
**Җыр язабыз — бәхет ясыйбыз.**

Әмма алга таба фикер үсешендә логика, эзлеклелек югала төшә. Авылны ташлап киткән өчен лирик герой үзен гаепле сизә («качак кебек сизәм үземне»), кире кайтуның торган саен кыенлаша баруы турында язып, аклану сүзләре әйтә башлый. Бу очракта авторның фикере ачыграк булырга тиеш иде.

«Кеше һәм табигать» темасына язылган әсәрләр рәтендә табигатьне, әйләнә-тирә мохитны саклау мәсьәләләрен үзәккә алган шигырь-поэмалар аерым бер урын алып тора. Шагыйрьләр саксызлык, ваемсызлык аркасында елга-күлләрнең пычрануы, саегуы, урманнарның сирәгәюе, атмосфера һавасының бозылуы турында борчылып язалар, табигатьне яратырга, кош-корт, хайван-җәнлекләргә, бөтен тереклек дөньясына мәрхәмәтле булырга өндиләр.

**Ярдәмем кирәксә, аваз сал,**
**Аваз сал, табигать туганым!**

— дип язган иде М. Шабаев «Ай Ыкка төшкән дә шаяра» (1968) шигырендә. Әйе, табигать шагыйрьләргә үзенең борчулы авазын салды, һәм шигърият табигать сагына басты, моны үзенең изге бурычы итеп кабул итте.

М. Шабаев 60 нчы еллар башында ук табигатьне саклау темасын күтәреп чыккан иде. «...Чишмәсез, Каен, Миләшсез бу дөнья дөньямыни?» — ди ул «Чишмә» шигырендә. Шагыйрьнең «Җикән камыш» (1972) китабы тулысы белән диярлек табигатьне саклау темасын үзәккә алып язылган.

Бу мәсьәләләр үзенең бөтен кискенлеге һәм драматизмы белән Х. Туфан иҗатында да чагылыш тапты. «Кармәт истәлекләре» (1970) циклына кергән шигырьләрендә, мәсәлән, шагыйрь, авылда булган яңалык-үзгәрешләргә куану белән бергә, игътибарны куаклык-әрәмәлекнең, чирәмле сукмак-юлларның азая баруы кебек күңелне борчый торган күренешләргә дә юнәлтә.

Табигать язмышы турындагы уйланулар И. Юзеевның «Карурман» поэмасында да төп урынны ала. Кеше серләр эзли күк йөзеннән, Җир астыннан, диңгез төбеннән. Йолдызларга оча; атомнарның Кара урманына күмелә. Яңа матурлыкны иҗат итә.

Булмаганны таба»,— ди шагыйрь,— «Әмма табигатьсез яши алмый». «Техницизм» белән мавыгучы геройга бабасы васыять итеп өч сүз әйтә: «Сандугачлар... Чишмә... Карурман...» И. Юзеевның 70 нче елларда язылган «Моң турында баллада», «Бакчачы турында баллада»ларында, «Өзелмәс кыллар» поэмасында һәм күпләгән шигырьләрендә дә табигатьне саклау темасы, цивилизация белән табигать арасындагы каршылыктан туган проблемалар калкытып куела. Кешеләрнең табигатьтән ераклашуы, аның көен-моңын, тавыш-музыкасын тыңлаудан читләшә, бизә башлавы турында уйлана шагыйрь. Юк, әле соң түгел, ди ул. Шуңа күрә шагыйрь сүзе табигатьне киләчәк буыннарга саклап калу өчен тагын да активрак, көчлерәк яңгырарга тиеш.

Гомумән, 60 нчы еллар башыннан алып бүгенге көнгә кадәр кешенең табигатькә мөнәсәбәте мәсьәләләре поэзиядә төп темаларның берсе булып кала килә; ул елларда табигатьне саклау, аңа игътибарлы булу кирәклеге турында язмаган бер генә шагыйрь дә юктыр. С. Хәким, Н. Арсланов, М. Садри, Ә. Баянов, Ш. Галиев, С. Сөләйманова, Роберт Әхмәтҗанов, Р. Фәйзуллин Г. Рәхим, Р. Харис, Р. Мингалимов кебек төрле буын шагыйрьләре Җирне, табигатьне, тереклекне яклап чыгалар, замандашларының намусына, вөҗданына эндәшәләр.

«Кеше һәм табигать» проблемаларының куелышында идея-тематик аспектларның, идея-эмоциональ интонациянең үзгәрүен, бу мәсьәләләргә карата шагыйрьләрнең карашы үзгәрүен «аккош күле» образын яисә темасын үзәккә алып язылган әсәрләр бик ачык күрсәтә. Элеккерәк елларда аккошның, аккош күленең гүзәллеген, матурлыгын җырлаган, аны табигатьтә чисталык һәм изгелек символы итеп кабул иткән шагыйрьләр хәзер инде бу иминлек, тынычлыкның бозылуына борчыла башлыйлар.

**Кемнәр килеп рәнҗеткәннәр икән,**
**Аккошларым киткән бу күлдән.**
**Аккошларым киткән... Ә моңнары,**
**Ә моңнары китми күңелдән,**

— дип яза, мәсәлән, Р. Гәрәй «Аккошларым киткән» шигырендә.

## «КамАЗда ат...»

Әлегәчә карап үтелгән шигырьләрдә «табигать һәм кеше» темасы нигездә лирик-публицистик планда куела, өндәү, чакырулар рәвешендә бирелә. Бүгенге поэзия декларатив лозунглар, кешедә билгеле бер хис тудыру максатында әйтелгән лирик-эмоциональ чакырулар белән генә чикләнми, әлбәттә. Шигърият уйлана, эзләнә, проблеманы социаль-әхлакый планда да, рухи-эмоциональ планда да аңларга омтыла.

Табигатьне, мохитны иҗади үзгәртеп коруга юнәлтелгән хезмәтнең нигезендә акыл белән эш итү, табигать дөньясының язмышы өчен җаваплылык хисе тою ятарга тиеш. Әйтик, техник прогрессның авылга үтеп керүе, нефть вышкалары төзү, юллар салу шактый зур мәйданнарда уңдырышлы җирләрне юкка чыгара, урманнарны кисәргә мәҗбүр итә. Әмма, Ә. Маликов язганча, «Нефть скважиналары, шуннан ташып чыккан кыйммәтле җир мае ничәмә йөз мең гектар урманнарны тәтенгә, промышленность чималына әйләнүдән саклап калган. Ил масштабында фикер йөрткән кеше моны яхшы аңларга тиеш»[1].

Мин КамАЗда берничә тапкыр булдым, дип искә ала С. Хәким. «Бер яктан, шат гигантлар салына, икенче яктан, борчу да арта. Шул мәһабәт корыч кою заводлары, тимерчелек цехлары, РИЗлар арасында кысылып калган Мәләкәс инешен дә югалтасы килми»[2]. Әйе, ничек итеп авылның яшеллеген шәһәр тормышының уңайлыклары белән бергә кушарга? И. Юзеев «Өзелмәс кыллар» поэмасында язганча, «Табигатьнең һәм без иҗат иткән машинаның камил аһәңе табылырмы?..»

Әлбәттә, техник-экономик мәсьәләләрне хәл итү юлларын эзләү әдәбият бурычы түгел. Язучының максаты — табигатьне һәм авыл тормышын үзгәртеп кору белән

[1] «Социалистик Татарстан» газетасы, 1979 ел, 8 апрель саны.
[2] С. Хәким. «Халык язмышы — шагыйрь язмышы», Казан, 1979, 328 бит.

бәйле каршылыклы тенденцияләрнең кеше күңелендә, психологиясендә, гомумән, аның яшәешендә чагылышын бирү.

Әйтергә кирәк, яңалыкның искелек белән тартышын, кеше һәм табигать арасында булган мөнәсәбәтләрне диалектик планда куеп язылган әсәрләр татар поэзиясендә әлегә күп түгел. Бу очракта да сүзне элегрәк язылган шигырьләрдән, аерым алганда С. Хәкимнең «КамАЗ көндәлеге» (1972) дип исемләнгән лирик циклыннан башларга туры килә.

КамАЗ турында роман һәм повестьлар, поэма һәм драма әсәрләре, күпләгән шигырь һәм очерклар иҗат ителде. «...лирика РИЗлар, КамАЗларны сыйдырды,— дип язган иде С. Хәким.— Шигырьнең сулышы киңәйде, активлыгы артты, фән һәм техника революциясенең сулышын тормыш лирикага өрде». С. Хәкимнең КамАЗ темасына багышланган үз шигырьләре һәм «Дәверләр капкасы» (1974) поэмасы шундый әсәрләрнең матур үрнәге булды.

Сибгат Хәким иҗатында «кеше һәм табигать» темасы илебезнең үсеш этаплары белән билгеләнә, анда совет әдәбиятындагы гомуми тенденцияләр чагыла. Иҗатының беренче чорында, шулай ук 40—50 нче елларда язылган әсәрләрендә «шәһәр һәм авыл» яисә «фәнни-техник прогресс һәм табигать» проблемалары аерым, мөстәкыйль тема буларак үстерелә. С. Хәким бер очракта техник прогрессның тормышыбызга үтеп керүе, аның казанышлары турында яза, нефть эшендә яисә КамАЗ төзелешендә чыныккан көчле характерлы кешеләргә дан җырлый, икенче очракта исә шагыйрьгә әйләнә-тирә мохитны, хайваннар һәм үсемлекләр дөньясын саклау проблемалары тынгылык бирми. Ләкин төп проблема шушы процесста туган каршылыклар, фикерләр бәрелеше рәвешендә куелмый әле.

КамАЗга багышланган әсәрләре исә С. Хәкимнең иҗади үсешендә яңа этап булды. Шагыйрь зур шәһәр, мәһабәт йортлар фонына көтелмәгән образ-параллель куя:

**Сүтеләчәк йорт өстендә**  
**Тын ай тора,**  
**Айга тотынып,**  
**Зарын сөйләп**  
**Тургай тора.**

М. Рыльскийның беренче бишьеллыклар чорында язылган «Карлыгачлар» дигән шигыре искә төшә. Телефон чыбыкларына кунган карлыгачларда шагыйрь гадәти һәм шул ук вакытта киләчәкне характерлый торган образ күрә. С. Хәкимдә дә — шундый ук «ситуация». Әмма бөтенләй икенче иҗтимагый-тарихи контекст, башка идея-тематик ассоциацияләр.

Сүтеләчәк йорт, үзенең моң-зарын сөйләүче тургай, шәһәр урамында үсеп утырган яшь юкә...— болар барысы да үткәнне, авылны, табигыйлекне белдерүче символлар. С. Хәким турыдан-туры нәтиҗә ясарга да, барысын да укучыга аңлатырга, хөкем чыгарырга да ашыкмый. Максат — элекке белән хәзерге арасындагы конфликтны калкытып куюу, искене үзгәртеп кору белән бәйләнгән каршылыклы процессның кеше күңелендә чагылышын бирү.

Шагыйрьнең сүз сөреше, хис-фикер логикасы КамАЗны бернинди «икеләнүсез» кабул итү, машина чорының җиңүен тану юнәлешендә дәвам итәр сыман. Ләкин автор алга таба хис-кичерешләрне тагын да «катлауландыра», ике феноменны (КамАЗ һәм ат) янәшә куя, «бәрештерә».

Ат темасы, ат образы С. Хәкимнең фронт лирикасында да, сугыштан соңгы елларда язылган шигырьләрендә дә еш очрый. Атка, хайваннарга карата хуҗаларча мөнәсәбәт кирәклеген беренче мәртәбә С. Хәким «Җылы сүз» (1956) шигырендә әйтеп чыга: «Онытмалар, энем, кайчагында бер җылы сүз кирәк атка да». Хәзерге авылда атларга игътибар җитеп бетми, ди С. Хәким «Болында, елга буенда» (1962) шигырендә, чөнки машина чоры, тракторлар заманы, колхозда төп көч — техника. Әмма шигырьдә үзәккә алынган бу хәл конфликт буларак калкытып куелмый әле. КамАЗга багышланган шигырьләрдә генә ат образы үзенчәлекле, оригиналь трактовка ала.

Зур индустриаль шәһәрдә, КамАЗда ат. Бу факт, бу күренешнең үзендә үк инде никадәр драматизм. Шагыйрь КамАЗда гади бер атны сагына, кызгана. Әмма

**Чорын яклап үрә торган ул!**
**Кем дә әйтмәс: үлә торган ул.**

«Дәверләр капкасы» поэмасында бу проблемалар тагын да киңрәк, фәлсәфирәк планда куела. Әсәргә заманча яңгыраш биргән, аның лирик героен заман проблемалары белән яшәүче шәхес иткән сыйфатларның берсе, безнеңчә,— яңа белән иске арасындагы тартышның кискенлеген, драматизмын бирә алуында. Бөек төзелеш белән, анда эшләүче замандашлар белән горурланып, «заманга тиң сүзгә-җырга сусап», Чаллыга килгән шагыйрьне борчылулы уйлар биләп ала: «бар нигезләр кубарылды», «Үз уйларым белән мин бәхәстә»,— ди шагыйрь.

Автор уенда — «алачыклар... алан, чыклар», тугайларда уйнап йөргән атлар, корыч заводлары арасыннан «озын тимер кебек өзгәләнеп» аккан Шилнә елгасы. Әмма С. Хәким чор диалектикасын, тормыш закончалыкларын яхшы аңлый. Аның өчен КамАЗ — «Масштабы чорның, бөтен эше, бөтен рухы чорның, омтылышы».

С. Хәкимнең КамАЗга багышланган шигырьләрендә һәм поэмасында күтәрелгән проблемалар башка шагыйрьләрдә дә киң чагылыш тапты. Аларда да бөек төзелешнең колачы, масштабы, анда эшләгән кешеләрнең рухи дөньясы тасвирлана, төзелешнең тарихи һәм сәяси әһәмияте күрсәтелә, шул ук вакытта шәһәр тирәсендәге табигатьнең, авылларның язмышы турында уйланулар үзәккә алына.

Әмма шагыйрьләр еш кына фәнни-техник прогресс чорында табигатьнең язмышы турындагы уйлануларын инде күп мәртәбәләр кабатланган чаралар (әйтик, шул ук ат, тургай, торна образлары) ярдәмендә белдерәләр, андый әсәрләрдә, Т. Галиуллин үзенең бер мәкаләсендә күрсәтеп үткәнчә, «...ат белән КамАЗлар арасында каршылык күренми, яңа белән иске арасындагы тартышның драматизмы» ачылмый («Казан утлары», 1978, 7 нче сан).

М. Шабаевның элегрәк язылган «Тургайлар» (1971) шигырен алыйк. Менә шагыйрь тургай җырына уяна.

> **Тургай җыры...**
> **Кайдан инде бу!**
> **Төзелеш шавы, чыңы...**
> **Әллә соңгы,**
> **Әллә соңгы тургай инде бу!**

Ләкин төсмерләнеп килгән конфликт-ситуациянең кискенлеге алдагы юлларда йомшый төшә, юкка чыга:

> **Тургай җыры уяттымы диеп,**
> **Кояш белән торсам, ашкынып —**
> **Тургай җырларыннан аһәңлерәк**
> **Кызлар җырын тыңлый ак болыт!**

Тагын бер мисал. Элек торналар «сөеп-сөелеп» йөргән урыннарда», «бала кошлар канат җәйгән болыннарда», төзүчеләр килеп, «Чаллы җирен үзгәртергә керештеләр»,— дип яза М. Садри «Камазчыларга ода» шигырендә. Элек «бик бәхетле ак торналар биегән җир»дә «яшь, гайрәтле батырлар» яңа тормыш төзиләр. Ә торналар туган җирләрен калдырып китәргә мәҗбүр. Әсәр шундый юллар белән тәмамлана:

> **Көмеш һәйкәл куяр идем торналарга —**
> **Бәхет теләп, биюләрен бер карарга!**

Ни әйтергә тели шагыйрь? Торналарның китүе, чыннан да, бөтенләйгәме? Аларның биюләрен бер карау өчен дә көмеш һәйкәл куяргамы? Бу очракта авторның фикерә, позициясе конкретрак, тирәнрәк булырга тиеш иде түгелме?

Йомгак ясап, шуны әйтергә кирәк: «табигать һәм кеше» темасын үзләштерү татар поэзиясенең идея-тематик офыгын киңәйтте, шигъриятне яңа образлар, сурәтләү алымнары белән баетты, шагыйрьләрнең фикерләү ысулына яңа төсмерләр алып килде. Әмма шулай да фәнни-техник революция чоры тудырган катлаулы проблемаларны, әйләнә-тирә мохитны, табигатьне саклау мәсьәләләрен күтәреп чыккан әсәрләр язу шагыйрьләребезнең алдагы бурычы булып кала.

# АВЫЛЫБЫЗ МОҢЫН ЮГАЛТСАК...

*Чаллыга, шагыйрь Кадыйр Сибгатуллинга ачык хат*

Кадыйр!

Сиңа, соңгы елларда данлыклы Чаллы шәһәрендә яши башлаган шагыйрьгә, авыл турында хат язу бәлки сәеррәктер дә. Ләкин син үзең моңа гаҗәпләнмәссең дип уйлыйм. Чөнки, хәзерге көндә шәһәрләрдә яшәп ятсак та, без икебез дә авыл малайлары, авыл егетләре...

Ә бит авыл — чынлап та, дөньяның, тормышның үзәге. Авыл егетләре өчен генә түгел. Ә гомумән тормышның да, гомумән яшәүнең дә. Ни өчен? Җавап бер генә: чөнки монда ипи үсә. Ә ипинең дөнья, тормыш үзәге икәнлегенә беркем дә шикләнми.

Беләсеңме, Кадыйр, хәтта сез кора торган мәшһүр Чаллының да, мин яшәгән матур Казанның да зурлыгы, бөеклеге авылдан башлана икән. Бүгенге зур шәһәрләр һәм зур төзелешләр тудырган бик күп куанычлы уйларыбызның, матур-матур җырларыбызның башы да авылга килеп ялгана икән...

Шуңа күрә Чаллыга адресланган бу хат авыл турында сөйләшүдән башлана да. Бүген Чаллы мәйданында, КамАЗ төзелешендә дөнья күзенә күренгән олы батырлыкның, олы матурлыкның да төп тамыры — кешелек тамыры, рухи тамыры — ипидә, җирдә, авылда.

Эчке ныклыкны һәм күңел тирәнлеген югалтмау, төрле юл чатларында аны җуймау бүгенге иҗатчы өчен үтә дә кадерле хасият сыман... Шуңа күрә бу хатны язу — иҗат турында уйлану да булып күренә.

Алдымда Кадыйр Сибгатуллинның 1974 елда Татарстан китап нәшрияты басып чыгарган китабы — «Әманәт». Ул китаптагы ике шигырь синең шигърият кырларының басу капкасы шикелле күренә. Хис-кичереш кырларына алып чыга, шуларны ачып, башлап җибәрә торган ике багана сыман алар.

Ул шигырьләрнең исемнәрен дә саллы итеп, бик тәэсирле сүзләр сайлап куйгансың: беренчесе — «Иргә чыкмый калган апалар» һәм икенчесе — «Ирләр».

**Печәннәре чәбәләнеп калды,**
**чабылып бетми калды өч алын.**
**Чалгыларын онытып калдырдылар**
**пакусларга кадап очларын.**

«Иргә чыкмый калган апалар» шигыре әнә шулай башланып китә. Авылның өч кызы үзләренең сөйгәннәрен сугышка озата.

**Китте...**
**Китте...**
**Чак-чак өлгерделәр**
**кайнар билләренә кул салып.**
**Калды...**
**Калды...**
**Чынлап үбелмәгән**
**сусыл иреннәре турсаеп.**
**Өч кульяулык болгап өчәү китте**
**Очып киткән кошлар төслерәк.**
**Читлектәге асыл кошлар кебек**
**талпынышып калды өч йөрәк.**

Менә бу юллар сугышка киткән егетләр һәм озатылып калган кызлар хакында гына түгел, ә шагыйрь Кадыйр Сибгатуллин шигърияте турында да күпне сөйли безгә.

Хәзер — китапның укучылар кулына һәм күңеленә барып ирешүенә инде сигез еллап вакыт үткәннән соң — югарыда китерелгән өзек иң башта чын шигърият турында уйландыра. Нинди була соң ул чын шигърият, чын шигырь?

Шул сорауга җавап эзләгәндә әллә кайдан, күңел төбеннән халкыбызның үз җырлары калкып чыга... Халык җырлары белән янәшәгә иң әйбәт шигырьләр килеп баса да, күңелдә үзеннән-үзе бер җавап пәйда була:

— Чын шигърият, чын сәнгать — ул үзәккә үтәрдәй моң икән! Бүтән берни дә түгел: әсәрдә бөек, олы, тирән бер моң яшәве кирәк икән!! Әнә шул бердәнбер сыйфат аерып тора икән чын әсәрләрне.

Синең беренче китабыңдагы әлеге шигырьләрнең бөтен яңгырашы халык рухы белән сулый төсле... Менә бик табигый булып килеп кергән чагыштыруларга гына тукталыйк: «өч кулъяулык болгап өчәү китте, очып киткән кошлар төслерәк». Бирегә кулъяулык — аерылышу билгесе — кошлар төсен ала. Ераклашу хисе көчәйтелә, бер гап-гади әйбер халык күңелендә озак еллар тупланып килгән кичерешләрне кузгатып, җанландырып җибәрә. Хисләр тагын да зуррак төс, киңлек, тирәнлек ала. Ә инде алдагы ике юлда шул ук кош образы менә нинди рәвештә: «читлектәге асыл кошлар кебек талпынышып калды өч йөрәк». Әле генә без күргән кошлар очып киткән иде (алары — егетләр), ә боларын «читлектәге асыл кошлар» дип бирә шагыйрь. Әз генә булса да сәерсенү хисе сизәме икән укучы бу юлны укыганда? Юктыр! Чөнки шигырьнең алдагы өлешендә инде мәхәббәт хакында сүз булган иде. Без беләбез: киткән кошлар да, калган кошлар да, сугыш булмаса, мәхәббәт күгендә иркенләп, сөенешеп очарга тиешле кошлар иде. Ләкин сугыш бу кошларны аерды. Һәр кошның да пары китте. Димәк, хәзергә ялгыз кош өчен мәхәббәт күге юк инде, ул күпмедер дәвергә читлектәге асыл кош сыман....

Укучының күңеле әнә шуларны бик тирән тоеп бара.

...Инде сугыш беткән. Ләкин бу өч кызның егете яу кырыннан әйләнеп кайтмаган... Шигырьнең соңгы бүлеге «Илле яшьлек кызлар чигү чигә...» дип атала.

**Аулак өйдә кызлар чигү чигә,**
**колакларда — сәгать тавышы.**
**Сәгать кебек келт-келт итеп кенә**
**гомерләрнең үтеп барышы.**

**Төшеп беткән инде сәгать гере,**
**күтәрерләр әле, күрсәләр.**
**Уксигездә шиңгән чәчәкләре**
**яулык почмагына үсәләр.**
**Илле яшьлек кызлар чигү чигә,**
**дулкынлана яулык читләре.**
**Ишекләр дә ачык,**
**егетләре**
**бүген тагын кайтып җитмәде...**

Чын-чыннан матур һәм көчле рухлы кешеләр турында әнә шулай тәэсирле итеп сөйләгән идең син безгә үзеңнең беренче китабыңда. Кешеләрнең ныклыгы, ышанычлыгы хакында хәзер дә һәм киләчәктә дә күп уйландырачак юллар болар. Бу апаларга караганда чибәррәк булган безнең бүгенге гүзәлләребез, бүген без сөйгән кызлар, әнә шундый эчке матурлыкка ияләр микән? Үзләренә зур сынау килгән чакта түзәрлек нык микән аларның матурлыклары? Яшермик, бу сораулар барыбызны да бик уйландыра һәм шулай ук дөресен әйтик: без бу сорауга һәр очракта да гел уңай җавап кына бирә алмыйбыз. «Һәр мизгелнең, һәр кенеңнең рәхәтен күреп кал» дип кенә яшәүче яшьләр дә байтак кына күренә әйләнә-тирәбездә. Моның ишеләр белән сөйләшкәндә әлеге апалар хакында сүз чыга калса — гомерне әрәм үткәрүдә, нииндидер юк нәрсәгә сукыр инануда, идеализмда гаепләү ишетәсең...

Мондый салкын акыллы яшьләргә еш кына очракта дәлилләп аңлатып та бетереп булмый. Әмма шунысы хак: андый фикерле кызны ярату түгел, кырыенда басып торганда да җан өши, кар базы салкынлыгы бәрә башлый. Мондый уйдагы хатын-

кызның теге апалар шикелле гаять авыр дүрт елга түгел, ә иң беренче кыенлыкка да чыдамаячагын һәм сине генә түгел, барысын, һәммәсен ташлап, иң җылы почмакка, иң җылы кочакка ташланачагын ап-ачык итеп төшенәсең...

Синең бер шигырең тормышыбызның, бүгенге рухи яшәешебезнең әнә шундый мөһим яклары турында уйландыра, Кадыйр дус!

«Әманәт» китабындагы икенче бер шигырь — «Ирләр». Бу шигырь сугыш чоры авылындагы тормыш авырлыгы һәм әнә шул вакытта малайларның бик иртә ир булулары турында. Шагыйрь хатын-кызлар җилкәсенә төшкән газапларны болай тасвирлый:

**Ирең кебек иманнәрне иңгә салу**
**кыен Банат, кыен Биби, кыен Бану.**

**Тоныкланган болыннарның яңгыравы,**
**янап кына китсәң иде чалгыларын.**
**Үгез тоткан малайларның үртәлүе:**
**авып төшә авыш якка көлтә йөге.**

...һәм «тешен кысып авылына бер ир кайта, Гариф та юк, Гайни да юк, тик бер Гата». Ләкин ул да яралы, аның күкрәгендә кургаш ята, аның бер аягы юк. Шуңа карамастан, Гата «түзеп чаба сыкрауларга, сызланугa, ял итәргә ята басу ызанына: ипи булыр, түкми-чәчми моны ургач — кадап ала соңгы тапкыр салкын кургаш».

Әсәр «Ирләр исән» дигән бүлек белән тәмамлана. Өч тол хатын төенчеккә төреп басуга ашау илтәләр. Кемгә икән?

**Бер басуда бергә туктый өч комбайн,**
**йөгереп төшә заманның өч малае.**
**Әтиләрдән уйнап калган чаклар узган,**
**битләрендә-кулларында шул ук тузан.**

Шигырьдә тагы иң тирән мәгънәле шундый юллар бар:

**Бу да мирас ир кешедән ир кешегә.**
**...Малай чактан ир күмелә ил эшенә.**

Шигъри әсәргә исем итеп куелган «Ирләр» сүзенең иң олы мәгънәсе менә кайда бөтен тирәнлегендә ачылып китте! Юк, бу инде комплиментлар, мактау сүзләре әйтеп кенә, хатын-кыз күңелен күрергә тырышып кына ир булу түгел. Бу — үтә культуралы булып күренергә теләүдән нишләргә, ни кыланырга белмәгән ир затлары да түгел. Болар — тормышның үзе тарафыннан ир дип танылган ирләр. Авылча итеп, гап-гади итеп әйткәндә: ир-атлар.

Шушы фикер әсәрнең буеннан-буена үсеп килә дә ахырда иң калку биеклек булып балкып ала:

**Хатыннарга тынгы бирми яңа уйлар,**
**әллә каян ирләр дәшә, дәшә еллар:**
**«Безнең уллар инде күптән үскән икән...**
**Без бит исән!**
**Без бит исән!**
**Без бит исән!»**

Чын ирләр аша тормыш намусы дәвам итә, яшәүнең яңарак һәм тагын да матуррак биеклекләргә юлана бара икән! Ләкин, бары тик чын ир-атлар булганда гына! Шагыйрь сүзләре белән әйткәндә, «малай чактан ил эшенә күмелгән ирләр» булганда гына!

Шушы урында бөек фикер иясе Н. Г. Чернышевский сүзләре искә төшә. Халыкка кирәкле зур эшкә үз теләге белән алынырга өйрәнмәгән ир заты, яшь ягыннан ничә яшькә генә җитсә дә, барыбер чын ир-ат булмый, күпме генә яшәсә дә, ир-ат булып өлгерми, җитлекми кала,— дип яза ул.

Кадыйр дус! Синең әлеге шигырьләрдәге юллар, бүгенге кайбер замандашларыма карагач, яңадан искә төшә. Безнең әйләнә-тирәбездә яше артса да буыны катмаган, шәхес буларак җитлекмичә картаеп баручы ир затлары шактый күренә түгелме соң?

...Синең шигырьләрең күп төрле уйлар кузгата. Бүген генә хәл ителеп бетми, тиз генә җавап табылмый торган уйлар да бар арада. Ләкин ул уйларның укучыбыз, замандашыбыз күңелендә йөрүе бик мөһим бит.

Кабат авылга әйләнеп кайтабыз... Шәһәр тормышы тудырган байтак мәсьәләләрнең чишелешен табарга теләп кайтабыз без авылга — җиргә, ипи үскән якка.

Ә монда гыйбрәт алыр мисаллар күп, бик күп.

Менә шагыйрь безгә бер яфрак язмышын гына алып күрсәтә. Ямь беткәнне тоеп бар да киткән, таллардан сандугач та качкан. Тик сары яфрак кына калган талларда:

**— Туган җирем шушы,**
**китмим,— диде,—**
**җәен күрдем, күрим кышын да,**
**нәселем монда туган, монда торган,**
**дәвам итәм аны шушында.**

**Сандугач та очып кире кайтты,**
**яшел яфрак күрде талларда.**
**Һәм җырлады:**
**бәхет туган якта,**
**эзләмәгез әллә кайлардан...**

Әйе, бу юлларны укыганнан соң үзең күргән күп хәлләр, байтак тормыш күренешләре турында уйланасың. Үзләрен изге җир, изге эш өчен корбан итүчеләр дә якты ут сыман күз алдына килә, бер чак тегеләй, икенче вакыт болай күренеп, иң шәп кеше дигән дан алырга теләүче акыллы затлар да хәтергә төшә... Һәм шулардан соң күңелдә иман ныгыбрак китә! Йөрәк сизгерләнә. Шагыйрьгә, шигъриятка рәхмәт, дисең.

Гомумән, синең «Әманәт» китабыңнан матур да, мәгънәле дә булган әнә шундый шигырьләрне күп табып була. Алар барысы бергә авыл тормышының, аның кешеләренең зурлыгы, бөеклеге хакында җырлыйлар, истә калырдай күренешләр аша безнең хисләребезне кузгаталар. «Авылым» дигән уртак исем куелган эскизларны гына карыйк. Менә анда нинди юллар бар:

**Изге җаннан икән кешеләрнең**
**иген игеп яши торганы.**

Яки:

**Мәрхәмәтле ана кебек, авыл**
**үзе генә белгән үз хәлен.**
**Зарланмаган.**
**Туендыручылар**
**олы җанлы була, түземле.**

Югарыда китерелгән юллар авылга мәдхия булып кына калмый. Алар тормыш турындагы, безнең асылыбыз, ныклык тамырыбыз хакындагы уйланулар...

Ә гомумән алганда, синең беренче китабың хакында хәзер ниндирәк сүз әйтеп була соң?

Авылда туып-үскән нечкә күңелле бер егетнең яшьлеге дәвамында, моңа кадәрге бөтен гомере дәвамында тупланган барлык эчке моңын, үзенең йөрәк җырын җырлавы иде бу китап. Бу — ипи үсә торган ышанычлы һәм бәрәкәтле туфракта үскән шәхес иде, үз сүзләре аша бик күпләрнең уй-кичерешләрен дөрес әйтеп бирә

алган егет иде. Аның яшәү девизы менә бу юлларда бик ачык яңгырый, бик төгәл ишетелә иде:

Әрәм итәр чаклар түгел инде,
әләм итәр чаклар гомерне.

Әйе, бу сүзләр — яшьлекнең матур башлануын, зур һәм изге эшләргә ашкынган күңелне белгертте, дәртле йөрәк җыры булып ишетелде...

1976 елны Татарстан китап нәшриятында дөнья күргән «Гамь» исемле икенче җыентыгыңны әнә шул фикернең чынга аша башлавы дип кабул иттек без, Кадыйр. Аны укып чыккач сөенеп йөргән бик күп егетләрне хәтерлим. Алар арасында сине күреп белгәннәр дә, белмәгәннәр дә бар иде, ләкин һәммәсе дә тормышны һәм шигъриятне нык ярата иде аларның. Әнә шуңа күрә бу китабыңдагы шигырьләрең аларны чын йөрәктән шатландырды. «Кибәнче карт», «Юлда үскән арыш», «Атлар көтте авыл малайлары», «Язмыш» һәм башка шигырьләр чын мәгънәсендә шигъри әсәрләр, укучыны шигърият тылсымы белән сихерли алырдай әсәрләр иде. Арадан берсе — «Юлда үскән арыш» дигәне бигрәк тә истән чыкмый.

Юлда үскән башак шуңа дучар:
дегет белән буяп уза кучәр.
Әллә буш син, әллә тулы җелек,—
арба күчәреңдә җитә дегет.

Орлык булып йөктә барасың да,
ялгыш кына төшеп каласың да,
интегәсең чиста башың белән
дегет сөртеп көпчәк арасында.

Болай караганда шигырьдә шул ук сүзләр кебек: арыш, арба, күчәр, дегет... Ләкин инде монда, бу шигырьдә, беренче китаптан аермалы буларак — кеше язмышларының катлаулы драматизмы көчлерәк яңгырый. Монысында инде шагыйрь безнең барыбызга да бик ошый торган матур җыр гына җырламый. Биредә аның сүзе инде йөрәкне әрнетә, җанны тынгысызлый, акылны борчый. Чөнки... Чөнки без чиста, керсез күңелле кешеләрнең кайчагында бик үк җиңел булып чыкмаган язмышлары турында уйланабыз... Шигырь биргән уйга тагын үзебез күргән тормыш мисаллары килеп өстәлә. «Кешеләргә карата сизгеррәк булырга кирәк шул...» дип куясың үзүзеңә, онытылмаслык итеп. Әлбәттә, башкалар да шулай итәдер. Һәм, гомумән, шигырь яратучы кеше бүтәннәргә карата кечкенә генә мәкер һәм әшәкелек тә эшли алмыйдыр, дип ышанасы килә...

Синең бу шигырең инде укучыны юл турында уйландыра башлады, Кадыйр. Шулай — беләкләрендә һәм йөрәкләрендә көч ташып торган егетләр өйдә генә утыра алмый шул. Аларны юллар һәм зур-зур эшләр тарта. Алар дәртле күңелләрен бердәнбер юлдаш итеп ерак юлларга чыгалар, замандашлары белән бергә-бергә олы эшләргә алыналар. Ә дөньяның эшләре дә, дөнья үзе дә гади һәм җиңел түгел.

Авыр димим сине,
җиңел димим
үлчәп булмый сине, Замана.
Утыз яшькә җиткән егетләрнең
икенче кат чәче агара.

Әйе, бу — кешенең үзәге өзелеп, әрнеп әйтелгән сүзләре. Бу — безнең кайбер яшьләребез чыгара торган рифмаланган такмак та, янсә чын мәгънәсе томаннар артына яшерелгән «заманча шигырь» дә түгел. Бу — Тукайча, Такташча, Туфанча әрну! Без моның өчен нык куандык, Кадыйр! Бу — яшь шагыйрь өчен мәртәбә, уңыш иде.

Әмма, шушы ук китапта — икенче китабыңда — безне бер нәрсә сискәндереп тә куйды. Авылны калдырып юлга чыгу белән синең лирик героеңда ниндидер

жиңеллек, артык эчкә кереп тормый гына уйлану, фикер йөртү, өстәнрәк кенә хис итү, кичерү чалымнары сизелә башлады. Моны юлчы психологиясе белән акларга тырышып идек — ләкин шигырь бит, көндәлек түгел. Әле җитмәсә алар китапта ук дөнья күргәннәр.

Шуңа күрә синең бу китабыңдагы «Кырым сукмаклары», «Кара диңгез», «Граф паркы»ише шигырьләр безне борчыды, Кадыйр. Бу — моңа кадәр бик күп шагыйрьләр эләккән капкынга синең дә килеп эләгүең иде — күргән бер нәрсә хакында шигырь язарга ашыгу иде. Күңелеңдә тирән моң, көчле кичереш туганны көтеп тормау. «Граф паркы» дигән шигырьне син, мәсәлән, менә болай бетерәсең:

**Юкка гына чинар моңлы түгел лә:**
**күп кешенең моң-зары бар төбендә.**

Соң, бу фикер нәкъ шушы мәгънәдә мең мәртәбә кабатланды бит инде! Мондый очрак китапта бердәнбер булса, бәлки аңа тукталып тормыйча уткәреп тә җибәрер идек, ләкин әйткәнемчә, алар байтак кына урын алган «Гамь» китабында.

Ә янәшәдә генә, әйтерсең чагыштыру өчен юри куелган, «Читтәге авылдашлар» шигыре.

**...Яхшы дип хатлар язалар,**
**ник елашып китәләр!!**

Нишлисең, сүзләр артык инде монда! Ике мисал үзләре үк бик ачык итеп сөйләп тора. Кайсысының чын шигырь булуы бик ерактан күренеп тора. Тик менә шагыйрьнең аларны аера алмавы гына эчне пошыра. Әллә шагыйрь кеше кайвакытта бик әйбәт укучы да булырга тиеш микән соң, ә, Кадыйр?!

Өченче китабың шактый гына көттереп чыкты. Укучы 1976 елдан 1981 елга кадәр синең яңа җыентыгыңны күрә алмады. Без, Казандагы дусларың, синең тормышыңда зур үзгәрешләр булуын, Балык Бистәсеннән Чаллыга күчеп килүеңне ишеттек. Яшермим, бу хәбәр минем үземдә ике төрле, капма-каршырак тойгы уятты. Беренчесе — заманыбызның олы төзелешендә синең дә катнашып китүеңне, КамАЗ коручылар белән турыдан-туры аралашып яшәячәгеңне, язарыңа яңа төрле азык табачагыңны белеп куану, синең иҗатың яңа югарылыкка күтәрелер дип өметләнү иде. Ә икенчесе, күңел төбендәгесе — бер үсемлекне икенче урынга күчереп утыртканнан соң бакчачы кичерә торган борчылуга охшашрак тойгы иде аның. Яңа туфракны ул ничек кабул итәр? Тиз генә үзләшеп, җайлашып китә алырмы икән?.. Ләкин шулай да, бу икенче тойгыда да, өмет дигән өлеше зуррак, көчлерәк иде шикелле. Чөнки без синең авыл туфрагында шактый ныгыган, көч җыйган икәнлегеңне белә идек, очраклы җилләр генә сине ега алмаячагына ышана идек. Ә иң мөһиме: Чаллыдагы гомум күтәрелеш, яшьлек, романтика рухы, һичшиксез, иҗат өчен шифалы, файдалы дип ышандык һәм хәзер дә шулай уйлыйбыз.

...1981 елда чыккан өченче китабыңның исеме — «Авазлар». Әйе, барлык китапларыңның исемнәре дә бик эзлекле рәвештә бер мәгънәне үстерә, тирәнәйтә килә. Иң беренче китабың «Әманәт» иде, димәк — ата-бабалардан калган изге бурычны тою, шул олы вазифаны яшь йөрәкнең сизә башлавы дигән сүз. Икенче китап исеме «Гамь», димәк — әлеге яшь кешенең ныклап уйлана, фикер йөртә, дөнья, яшәү мәсьәләләрен хәл итә, аларга җаваплар эзли башлавы дигән сүз. Ә өченчесе инде «Авазлар», димәк — шагыйрь үз эчендәге, күңелендәге моңны, җырны, әйтер сүзен шигъри авазлар итеп кешеләргә җиткерә башлады дигән сүз. Бусы инде — укучының иң нык көткәне, шагыйрь яшәвенең нәтиҗәсе, аның гомер җимешләре...

«Авазлар». Шагыйрьнең өченче китабы... Юк, кайбер укучылар көткәнчә, баштанаяк тәнкыйтьләп ташлау өчен нигез юк анда. Чөнки китапта «Күңел», «Песнәк» «Шигырь», «Борчак ашы» шикелле бик уңышлы шигырьләр бар. Шагыйрьләрнең илаһи халәтен — илһам килгән чакны менә ничек оста итеп ачып бирәсең син:

**Һәр тарафтан җырлар, моңнар килә.**
**Барысы да якын, илһамлы.**

**Әллә дөнья,**
**әллә үзем сәер,**
**аңлап бетерә алмыйм бу хәлне.**

**Гадиерәк берәр нәрсә бармы!**
**Барысы да миңа илаһи.**
**Дөньяның бар ишекләрен ачып**
**алып керә шигырь,**
**и, даһи!**

Гап-гади дә, шул ук вакытта төгәл дә, тирән дә сүзләр — күренешне ап-ачык һәм тәэсирле итеп күз алдына китерә торган юллар болар. Алар, һичшиксез, синең уңышың, сәләт һәм тырышлык җимеше, Кадыйр.

Ләкин шулай да бу китабың без көткән өметләрне аклап ук җиткермәде сыман, Кадыйр... Нишләп икән? Әллә без, укучылар, үз өметләребезне әллә кая, артык югары үрләткәнбезме соң? Әллә соң без булмастай әйберләрне хыялыбызда тудырганбыз да, китапта аларны тапмагач, сиңа урынсыз үпкә белдерергә ашыгабызмы?

Юктыр, алай түгелдер...

Синең беренче китабың — бик матур һәм ышанычлы юлның башы иде. Шул юлда яуланган уңышларны син талантың һәм тырышлыгың белән тагын да үстерергә, күп санлы югары сәнгать әсәрләре итеп укучыга тәкъдим итәргә тиеш идең... Без әнә шуны көткән идек. Сине яратып, «сәләтле шагыйребез» диеп...

Ярый, конкрет шигырьләргә килик әле, әйтергә теләгән фикеребезне шулардан чыгып аңлатыйк. Эш нәрсәдә соң?

Менә китапны ачып җибәрүче өч зур шигырь. Аларның өчесе дә Чаллы тормышыннан алып язылган. Аерым-аерым алганда әйбәт кенә юллар да табарга мөмкин аларда. Ләкин тулаем алганда, бу өч шигырьгә образлылык, аныклык, көчле тәэсир булу җитми. Алар — газеталарда басыла торган күзәтүгә тартымрак язмалар гына. Өч шигырьдә дә сүз гомуми төстә генә бара. Шагыйрь, әйтерсең, Балык Бистәсеннән Чаллыга күчеп тә килмәгән һәм анда байтак кына яшәп тә өлгермәгән. Әйтерсең, аның әле Чаллыда бер генә танышы, дусты да юк, һәм ул шуңа күрә кая тукталырга белмичә, урамнар буйлап кына чаба. Өйләргә һәм кеше күңелләренә, язмышларына кереп тормыйча гына...

Икенче китапның уңышсыз килеп чыккан шигырьләре дип, юл язмасы характерындагы әсәрләр аталган иде, бусында да сиңа әнә шул нәрсә комачаулый. Ягъни, шигырь беренче туган тәэсирләр катламыннан үтеп китми, эчкәрәк, тирәнгәрәк керә алмый. Чаллы хакында без белгән мәгълүматка шигырь әллә ни яңалык өстәми. Чөнки, әлеге дә баягы — гомуми фонда гына сөйләү, укучының үзәгенә үтәрлек конкрет һәм көчле мәгънәле шигъри образлар яшәмәү, безне дулкынландыра алырлык кеше язмышы күренмәү зыян итә.

Аннан соң, синең соңгы китабыңда тагын бер күренеш игътибарны җәлеп итә: анда җиңел көйләр күбәеп, ишәеп киткән төсле. Алдагы китаплардагы шигырьләрдә һәр әсәрнең диярлек үзенә генә хас һәм дөрес эзләп табылган интонациясе, яңгырашы бар иде. Сүзләр генә түгел, хәтта сүз арасындагы һава да моңлы, тәэсирле тоела иде. Ә бу китапта нindидер җиңеллек белән йөгереп узасың шигырьләрне. Минемчә, бу — шагыйрь иҗаты өчен бик куркыныч күренеш. Ул — шәһәр тормышының барыбызны да туйдырган ыгы-зыгысын хәтерләтә, мәгънәсез кабалану, ашыгу сыман. Юк, дөрес аңла — шәһәр белән авыл арасына кытай стенасы корырга җыену түгел бу, бүген андый фикердә йөрү зур хата, ялгышу булыр иде. Бары тик шәһәрдә әле яңа гына яши башлаган кешегә хас кыланышлар: артык ыгы-зыгыга бирелү, кабалану, ашыгу турында әйтергә телим... Бәлки, син боларны үзең миннән яхшырак та беләсеңдер, Кадыйр. Әмма соңгы китабың ул начар шаукымга шактый бирешкән.

Ярар, шәһәр тормышы әлегә шагыйрь Кадыйр Сибгатуллин өчен «ватыласы чиклевек» булып та калсын, ди. Ә бүтән темага багышланган шигырьләрдә алга китеш, үсеш ни дәрәҗәдә нык сизелә соң? Әйтеп үтелгәнчә, икенче китаптан соң инде биш ел гомер үткән бит.

Ни җитми соң?

Иң башта, бүген без поэзиядән көткән һәм беренче китабың белән син үзең дә шуңа өметләндергән чын поэзия, сәнгатьчә тирәнлек җитми. Син үз күңелеңне бөтен көченә, бар тирәнлегенә эшләтмисең. Ә күбрәк беренче фикерләр, кичерешләр белән генә эш итәсең. Нәтиҗәдә, матур гына, тирән генә ачылып китәргә тиешле логик җепләр ачылып та бетмичә, сүтелеп тә җитмичә өзелеп калалар. Шигырьгә алынган күренешнең иң мөһим, иң кирәкле өлеше — сәнгатьчә фәлсәфилеге аста, караңгыда кала. Моңа мисал итеп бу китабыңдагы байтак шигырьләрне китереп булыр иде, ләкин андый мөмкинлек юк — шуңа күрә берсенә генә тукталыйк. «Эскәмиядәге карт» шигыренә.

**Йоклый алмый чыкты микән!**
**Чал сакалын бер сыпырды.**
**Түбәтәен кырынайтып,**
**моңсу гына уйлап торды.**

**Иреннәре көлеп куя.**
**Тере очкын карашында.**
**Бүлдермәгез!**
**Карт утырды**
**Яшьлегенең канатына.**
**Сәер генә карап алды**
**утыргычның уң ягына.**
**...Гаҗәпләнде табалмагач**
**сөйгән кызын үз янында.**

Шушының белән шигырь тәмамлана. Шагыйрь Кадыйр Сибгатуллин үз бурычын шушы җирдә тәмамлана дип саный. Ә укучы өчен шигырь ярты юлда бүленеп калды. Шагыйрь иң кирәкле катламга үтәргә иренде. Нәтиҗәдә әсәрнең яртысы гына килеп чыкты, аның тәэсире аз булды.

Бу урында заманыбызның олы шагыйре Мостай ага Кәримнең «Карусель» дигән шигыре искә төшә. Анда шундый күренеш сурәтләнә: егет белән кыз карусельдә әйләнәләр. Кыз алгарак утырган, егет аңа кагылмакчы, аның кулыннан тотмакчы булып үрелә, ләкин ара бик якын булса да — җитә алмый. Шигырь ахырында алар җиргә аяк басалар. Олы шагыйрь әнә шул әсәрен болай тәмамлый:

**Учларын җибәрмә учыңнан,**
**Адым да аерылма дусыңнан.**
**Чөнки бит җир шары әйләнә,**
**Җир шары корылган хәйләгә.**

Гади генә сыман тоелган тормыш күренешеннән нинди зур мәгънә, нинди тирән фәлсәфи фикер чыгарыла, чын тормыш өчен бик кирәкле сабак алына! Шигырьнең кешеләргә ни өчен кирәклеген дә менә шундый юлларны укыгач кына аңлыйсың шул аның.

Әйе, моңа якын әсәрләр синең иҗатыңда да бар, Кадыйр. Хатымның башында мин күбрәк әнә шундый шигырьләреңә тукталдым. Укучылар өчен бик кадерле шигырьләр алар. Синең күп кенә юлларыңны яшьләрнең куен дәфтәрләрендә дә күргәнем бар...

Әнә шуңа күрә дә — шигырь сөючеләрнең яраткан шагыйренә әверелеп килгән бер чорда синең иҗатыңда кайбер җиңелчә эчтәлекле язмалар очрый башлаганга языла бу хат. Әлбәттә, син үзең барысын да сизеп, аңлап, төшенеп торасың дип уйлыйм. Чөнки күңелеңнең үтә сизгер һәм нечкә икәнен беләм, бик күп катлаулы нәрсәләрне тоеп баруың беләм — аның чын шагыйрь күңеле икәнен беләм.

Ләкин... Ләкин син укучыларыңны да истән чыгарма әле. Без синнән зурны өмет итәбез, шуңа күрә зур таләпләр дә куябыз. Мөмкинлекләрең, табигый сәләтең булганга күрә... Ә сәләтне, талантны — халыкныкы диләр. Халыкның күңел бакчасындагы гөл бит ул. Үз бакчасында бик матур гөлләр күрәсе килә бит халкыбызның.

Кадыйр! Хатны тәмамлар алдыннан гына синең яңа әсәрең — журналыбызның менә шушы санында басыла торган «Хыялыбыз башкаласы» исемле поэмаң белән танышып чыктык. Ул мине чын күңелдән сөендерде — син олы төзелешнең кешелек моңына, поэзия өчен иң мөһим булган үзәгенә якынаеп киләсең. Синең күңелеңдә хәзер яңа җир, яңа төбәк моңы тулышуы сизелә. Әлбәттә, киләчәктә язылачак әсәрләреңдә алар тагын да калкурак чагылыр...

Үзең дә бик яхшы беләсең, соңгы елларда бик күп авыл егетләренең гомер юллары шәһәргә таба борылды. Әлбәттә, бу очраклы күренеш түгел, ә объектив чынбарлык. Тормыш таләбе, заман таләбе. Меңләгән авыл егетләре шәһәрләргә килеп, ерак төзелешләргә китеп, илебезгә матур-матур эшләр бүләк итәләр. Үз хезмәтләре белән гомер юлларын һәм халкыбызның тарихын бизиләр. Ләкин менә шушы гомер юлының кайбер уйланырлык урыннары булырга мөмкин. Мәсәлән, бүгенге шәһәр кешесендә шундый бер рухи ихтыяҗ ачык сизелә: ул үз тормышының, яшәешенең озын гомерле һәм тотрыклы матурлыгын, кешелекле матурлыгын табарга тели. Неон утлары сыман: бүген балкып, иртәгә сүнәчәк матурлык кына канәгатьләндерми аны.

Бүген шәһәр кешеләре тормышында килеп туган әнә шундый рухи ихтыяҗ карашларны, ирексездән, авылга һәм табигатькә юнәлтә. Авыл кешесенең меңләгән еллар дәвамында, табигать белән якыннан аралашып яшәү дәверендә туплаган гаять бай рухи тәҗрибәсе — күңел моңы безгә — шәһәр кешеләренә бик тә, бик тә кирәк. Бу безгә чын мәгънәсендә гармоник шәхес тәрбияләү өчен, бүгенге замандашыбызны тагын да матуррак итү өчен кирәк. Шуңа күрә, кая гына китсәк тә, авылыбыз моңын онытмасак, аны югалтмасак иде. Ул безнең ныклык тамырыбыз, чын матурлык чыганагыбыз. Ә тамырсыз, таянычсыз — үсемлек тә, таш та, кеше дә озакка чыдый алмый.

Тормыш та, шигърият тә безнең һәммәбезнең нык кешеләр, җитди кешеләр булуыбызны көтә...

Сиңа хөрмәт белән

**МАНСУР ВӘЛИЕВ**



Шагыйрь Сибгат Хәким — КамАЗда. Сулдан уңга: язучы Равил Вәлиев, СССР Верховный Советы депутаты Рәис Гаиев, Социалистик Хезмәт Герое Вазих Мәүликов, РСФСРның М. Горький исемендәге, ТАССРның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премияләре лауреаты Сибгат Хәким.

К. Ситдиков фотосы.

## КИТАП КҮЗӘТҮ

# СОКЛАНУ СӘЛӘТЕ

Кешеләр үзләренең гаҗәпләнү, соклану сәләтләрен беркайчан да җуймаска тиешләр. Язучы Эдуард Касыймов повестьлары[1], андагы геройлар, язмышлар турында уйланганда, күңел ирексездән әнә шул фикергә килә. Әйе, Э. Касыймов көчле кешеләр, соклангыч кешеләр турында күбрәк яза. Аның геройларының язмышы легендага тартымрак. Язучының үз геройларына мөнәсәбәтенә соклану, романтизм хас. Әсәрләрдә романтик кайнарлык, геройны бүтән персонажлар арасыннан аерыбрак, күтәребрәк куярга теләү сизелә.

Көчле кешеләр... Кемнәр соң алар? Нинди кешеләр? Табигать тарафыннан рәнҗетелгән Абдулламы? Әллә сабыйларча ышанучан һәм самими күңелле профессор Одинцовмы? Бәлки, «Ады-Ады» кушаматлы телсез Гыйлаҗдыр? Яисә алданган кыз Әлбинәме?.. Болар һич тә без күз алдына китергән һәм тормышта күреп күнеккән көчле кешеләргә охшамаган иң. Әмма повестьларны укып, алардагы вакыйгаларны күңелең аша кичергәннән соң, язучының үз геройларына карата булган җылы мөнәсәбәте әкренләп сиңа да күчә, уйларың үзгәрә. Әйе, алар көчле. Чөнки алар бервакытта да үзләрен ялгыз хис итмиләр. Юк, аларның авыр минутларда ярдәмгә килерлек күңелдәшләре, тугры дуслары булуда гына да түгел хикмәт. Авыр минутларда алар иң элек үз күңелләренә таяналар. Иң мөһиме — ул күңелләр өмет уты белән яктыртылганнар, кешегә, кешенең яхшылыгына ышаныч, бетмәс-төкәнмәс ышаныч белән сугарылганнар. Шул ышаныч аларны көчле итә.

Көчле кеше ул — җиңелүне белмәүче кеше дигән сүз түгел әле. Җиңелгәннән соң торып китә алган кеше көчле. Җиңелгәнне күтәреп торгызмыйлар, ул һәрвакыт үзе тора, үз күңеленә таянып тора. Менә шул вакытта сынала да инде. Аның әнә шул вакытта нинди көчкә ия булуы ачыклана... Әйдәгез, карыйк әле: Э. Касыймов геройлары мондый сынауларны ничек үтәләр соң?

«Кояш көн дә чыга» — язучының беренче повесте. Биредә кешене табигать сынный. Әсәр үзәгендә тумыштан сукыр Абдулла образы. Тормышның күп шатлыкларыннан, ләззәтләреннән мәхрүм ителгән бу геройның күңеле матурлыгына, байлыгына сокланмый мөмкин түгел. Ул — гадел, эчкерсез, матурлыкны, игелекне бик

---

[1] Эдуард Касыймов. Повестьлар. Татарстан китап нәшрияты. 1980.

сизгер тоючы кеше. Бик күп җырлар, әкиятләр, риваятьләр белүче, шулар кочагында матур бер тормыш белән яшәүче бу кеше халыкның җанлы күңеле булып күренә, шул күңелнең бүгенге көнгә килеп тоташкан нерв очы сыман тоела.

Дөнья яктысын аның бервакытта да күргәне юк. Әмма шуңа бәйле кыенлыкларны, түбәнсетүләрне ул үз гомерендә байтак кичергән. Ләкин моңа һич тә күнекмәгән — үз шәхесенә тиешле кадер, мөгамәлә өчен көрәшүдән туктамаган. Шул ук вакытта ул бүтәннәргә артык йөк булырга да теләми, кешеләргә файда китерергә тырыша. Ул — горур кеше.

Аянычлы язмышка дучар ителгән менә шул кешене тормыш икенче төрле шартларга куеп карарга уйлый. Эчкерсез дуслары булышлыгы белән аның күзләре ачыла. Дөньяның төсләрен, кешеләрнең йөзен, матурлыкны күрү мөмкинлегенә ия була ул. Язмыш аны бәхет белән сыный. Күз ачылу ул бит әле күрә башлау гына түгел. Ул бит тормышка, әйләнә-тирә мохитка карата мөнәсәбәтең дә үзгәрү дигән сүз. Мондый кискен үзгәреш шартларында кеше күңеленең ныклыгы сынала, асылы сынала. Ләкин бәхет Абдулланың башын әйләндерә алмый. Аның шадра йөзле, юантык хатынының «иремнең миннән күңеле кайтмаса ярар иде», дип пошынулары да юкка була. Сукыр вакытта Абдулла шадралар артында яшәүче матур күңелләрне күрергә өйрәнгән була инде, ә хәзер ул шома йөзләр һәм елдам карашлар артына яшеренгән кара җаннарны да тиз арада танып ала. Җәлүк карт, парторг Хәир һәм Якуб Сәйфи кебек яхшы күңелле кешеләрнең дөньяда күп икәнен аңлау, авылдашларының җылы игътибарын даими тою аңа эчке бер көч бирә, хисләрен төгәл, уйларын дөрес итә.

Бераз сузынкы булуга һәм урыны-урыны белән диалогларда табигыйлек, киеренкелек җитеп бетмәүгә дә карамастан, повесть җиңел укыла, гадәти булмаган язмыш, шәхес образы аны мавыктыргыч итә.

«Көмеш язулы кылыч» повестенда Гыйлаҗ исемле кеше турында сөйләнелә. Биредәге сынау — туры мәгънәсендәге сынау, җәза. Гражданнар сугышы. Дошман позицияләрен күзәтеп кайтырга дип киткән разведчик егет аклар кулына эләгә. Үзләренә кирәкле мәгълүматларны таләп итеп, аклар аңардан сорау алалар. Теләкләренә ирешү өчен аны төрлечә җәзалыйлар, кызган тимер белән көйдереп йолдыз ясыйлар, ахырда шашынган акгвардиячеләр разведчикның телен кисәләр, һушын югалткан һәм анадан тума ялангач гәүдәне салкын мунчага илтеп ташлыйлар. Шундый аяныч хәлдә дә егет әсирлектән һәм үлемнән котылу җаен таба, үзен атарга килгән акгвардиячене дөмектереп кача. Кайтып, командирларына дошман турындагы кирәкле мәгълүматлар тапшыра.

Әсәр менә шундый батырлык эшли алган кеше турында уйланулар, аны шушы батырлыкка илткән күңел сыйфатларын ачыклау рәвешендә язылган. Язучы стильләштерү алымын оста файдалана — әсәрнең сугышчы Гыйлаҗның батырлыгы сурәтләнгән өлеше риваять-дастаннарны хәтерләтә. Повесть яңа буын ирләрнең Бөек Ватан сугышына китүе белән тәмамлана. Көмеш язулы кылычына таянып баскан көенчә аларны озатып калган Гыйлаҗның мәһабәт сыны укучы күз алдыннан китми. Автор үз героена дастаннарга хас монументальлек бирә алган.

Халыкның иң күркәм сыйфатларын үз күңеленә туплый алган кеше язмыш алдында сынаты димени!

«Бир кулыңны, дустым» дигән повестьта язмыш яшьләрне, алар арасындагы мөнәсәбәтләрне хыянәт һәм мәкер белән сыный.

Институт тәмамлау көннәрендә яшь егетләр, яшь кызлар, соңыннан сагынып сөйләрлек булсын дип, Идел буенда төн үткәрәләр, ял итеп кайталар. Спортчы егет Әхсәннең матурлыгына һәм тасма телләнә алданып, шул төнне Әлбинә төзәтә алмаслык хата эшли. Соңыннан, авылга китеп эшли башлагач кына, ул үзенең балага узганлыгын аңлый. Әхсәннең никадәрле мәкерле кеше икәнлеге ачыла, аның мәхәббәт анты әчүләре ялган булып чыга. Авылга балалар укытырга килгән Әлбинә шулай бик катлаулы хәлдә кала. Әгәр шул вакытта аңа дуслары ярдәмгә килмәсә, нечкә, саф күңелле бу кызның киләчәген күз алдына китерү дә кыен булыр иде. Менә шушы вакытта чырагачтай ябык Роберт әзмәвердәй таза Әхсәннән көчлерәк булып чыга. Күңеле белән көчлерәк ул. Роберт Әхсән белән сөйләшкәннән соң, эчке икеләнүләрен җиңеп, электән үк күзе төшеп йөргән Әлбинә янына килә, аның баласына ата булырга теләвен әйтә... Кешелеклелек, игелеклелек тамыр

җибәргән күңелләрне мәкер дә, хыянәт тә җиңә алмый икән.

Нәфис лирик сурәтләүләр, нечкә психологик күзәтүләр повестьны бизәп тора. Язучы хикәяләүнең укучылар күңеленә таңгал килерлек хисле-йогынтылы дулкынын таба алган. Әсәр тәэсир итә, уйландыра.

«Сорбонна профессоры һәм без» исемле повестьтагы профессор Одинцов образы — һичшиксез Э. Касыймовның уңышы. Башка повестьларда үстерелеп килгән идея — кешенең үз-үзенә тугрылыгы, тормыш позициясенең ныклыгы турындагы фикер бу образда күпмедер дәрәҗәдә тәгәлләнеш таба.

Карт профессор үз гомеренең иң күтәренке, иҗади дәртле, бәхетле бер мизгелендә дөньядан китә. Әйләнә-тирәсендәгеләрнең күңелендә яктылык — кешегә, тормышка мәхәббәт дигән якты моң калдырып китә ул. Ак костюмы гына түгел, ак чәчләре генә түгел, аның күңеле дә актыр сыман тоела. Ак күңелле кеше ул. Ә бит язмыш аны пычратмакчы булып аз тырышмаган. Аның гомере тоташ көрәштән гыйбарәт. Бу көрәшнең формалары сәер генә була. Профессор башта тормыш шаулары-дауларыннан читтә торырга тырыша. «Революция культураны җимерә, Россияне упкынга тәгәрәтә» дигән уйдырмага ышанып, ул эмиграциягә китә. Әмма эмигрант булса да, политикага катнашырга теләми, бары үз эшен, үз фәнен генә белә. Ләкин көрәшнең пассив формасы аны уңышка китерми. Повестьтагы бер персонаж әйтмешли, «кеше политикадан читләшсә дә, политика кешедән читләшми... бөтерә дә, дулкыннарында тирбәлдереп агызып алып китә» ...Үзе дә сизмәстән профессор антифашистка әйләнә. Исеме дөньяга таралган галимне фашистлар үз максатларында файдаланмакчы булалар, ләкин аны буйсындыра алмыйлар, шуңа күрә концлагерьга ябалар. Одинцов фашист дәһшәтен кичерә, аңа каршы көрәшә. Рухи позицияләреннән бер карыш та читкә китми, киресенчә, ул үз позициянне, идеалыңны актив якларга кирәк дигән нәтиҗәгә килә. Һәм шунысы игътибарга лаек: дәһшәтле чорларны, фашизм фаҗигаләрен кичерүенә дә карамастан, ул һаман да үтә кече күңелле, нәфис җанлы булып кала. Кешегә, бәхетле киләчәккә булган якты ышанычын җуймый.

«Көчле кеше» дигәч, без, гадәттә, һичнинди җиңелү, түбәнлекләрне белмәүче кешеләрне күз алдына китерәбез. Ә андыйларны, бәлки, бөек дип әйтү дөресрәктер? Тормышның төрле сынауларын үтеп, күңел сафлыгыңны, хыялларның яктылыгын, максатың ачыклыгын җуймау да күп көч сорый ич әле. Үтә еш аякка уралучы вак киртәләр, сынаулар да безнең җаныбызның егәрен бик күп сарыф итәләр, кешене эчтән талкыйлар бит.

Табигать биргән рухи хасиятләреңне югалтмыйча олы бер гомерне кичү... Юк, яңаларын табып димим, ул турыда түгел әлегә сүз, ә булганны югалтмыйча яши алу. Яңа хасият табыла, вакыт белән килә ул. Ә менә югалтмыйча яши алу — җиңел түгелдер. Үзгә бер сәләт кирәктер моның өчен. Кешелеклелек сәләте, рухи куәт! Профессор Одинцов менә шундый куәткә ия.

Эдуард Касыймов геройлары нинди генә сынауларга юлыкмасыннар, аларны намус белән кичеп чыгалар, үзләренең әхлакый сафлыкларын саклый алалар. Алар үз күңелләренә тугры, көчле кешеләр.

Бирегә язучының үз-үзенә тугрылыгы турында да берничә сүз әйтергә мөмкин. Эдуард Касыймов тормыштан легендага тартым язмышлар, шәхесләр эзли. Көчле кешеләр, көчле кичерешләр тарта аны. Повестьларында ул шул көчнең чыганакларын ачыкларга омтыла, шәхесне төрле сынаулар аша уздыра. Кешенең мәгърур, олы җанлы икәненә ышандыра. Ул тормышчан, киң масштаблы, сокланырлык, гаҗәпкә калырлык күренешләр эзли. Язучының соңгы елларда Чаллыга күчүе, миңа калса, бүгенге көннең әнә шул легендасын эзләп килү ул. Көчле кешеләрне — образы китапларга кереп калырлык замандашыбызны эзләп килү. КамАЗ — үзе легенда, көч, куәт. Көчсез кешеләр аны сала алмас иде.

Эдуард Касыймов соклана, гаҗәпләнә белә. Тормышыбызның, замандашларыбызның соклангыч сыйфатларын күрсәтеп, ул укучының да әнә шул хисләрне кичерүенә ирешә.

**ФӘИЗ ЗӨЛКАРНӘЕВ.**

# БЕРЕНЧЕ ЗАТТАН

Берничә еллар элек, туган илебез юлларында «КамАЗ»лар әле яңа гына күренә башлаган чакларны, якын дустым белән аның «Жигули»ена утырдык та шәһәр читенә чыгып киттек. Күзләрнең явын алырдай төскә буялган житез «Жигули» алга ыргылучы машиналарның әле берсен, әле икенчесен куып уза. Аккош күле урманындагы төз буйлы озын наратлар йомылып кына артта кала, колак янында җил сызгыра...

Кинәт юлда шактый авыр йөк төягән «КамАЗ» автомобиле күренде. Дустым акселераторга басты, машинасын уңга да, сулга да борып карады. Әмма файдасыз. «Ярар,— дип куйды ул үҗәтләнеп һәм үзенен юатырга тырышып.— Хәзер юл үргә таба менәчәк, анда мин бу «КамАЗ»га сәлам биреп кенә утәрмен». Ләкин үргә күтәрелгәндә дә «КамАЗ» тизлеген киметмәде, моңа кадәр сәгатенә 80—90 километр белән ничек куырган булса, шул ук рухта юлын дәвам итте. Дустымның көнләшүдән янган күзләрендә гаҗәпләнү чаткылары кабынды. «Менә, ичмасам, җилдерә...— диде ул телен шартлатып, шаккатудан башларын селеккәләп.— Бер нәрсә дә әйтә алмассың, дизель — куәтле. Ай-һай, җен кебек тарта!»

Шундый сорау туа: «КамАЗ» белән чагыштырырдай тагын нинди йөк автомобильләре бар? КамАЗ төзелә башлауга бары тик дистә елдан артык вакыт узды, ә ул эшләгән йөк автомобильләре «крейсер тизлеге»н алдылар. «Правда» газетасында күптән түгел безнең өчен шатлыклы хәбәр басылган иде: «РСФСРдагы автомобиль паркының 13 процентын биләүче «КамАЗ» машиналары хәзер барлык йөкнең 40 процентын ташыйлар...» Арттырып әйтү түгел, КамАЗ комплекслары, тизлекне киметмәгән килеш, үр артыннан үргә күтәрелә бара: беренче һәм икенче чиратның сафка басуы, төп конвейерны эшкә җигү, ярдәмче цехларның ачылуы, һәм, гомумән, автозаводның тулысынча төзелеп бетүе. Болар гынамы соң! Карагыз сез офыктагы якты шәһәргә, таң шәһәренә... Илебездә иң яшь, иң матур шәһәр ул.

КамАЗга багышланган әсәрләр дә хәзер күпмилләтле совет әдәбиятында үзенең лаеклы урынын тота. Үзәк һәм республикабыз нәшриятларында дистәләгән роман һәм повестьлар, төзелеш романтикасын чагылдырган киң колачлы поэмалар, төрле характердагы очерк җыентыклары дөнья күрде. Илебез театрларында берничә пьеса куелды, документаль фильмнар төшереп алынды, популяр җырлар иҗат ителде, шигырьләр исә меңәрләгән юллар белән исәпләнә.

Әлбәттә, бу — куанычлы хәл, әмма икенче яктан караганда, әлеге муллык бераз уйландыра да. Чак кына күз ташлап алган очракта да, КамАЗ темасына өч төрле мөнәсәбәт сизелеп тора.

Беренчесе — публицистика. Бу төркемгә мин хисапсыз очерк, зарисовка, юльязмаларны гына түгел, ә бәлки зур төзелеш турындагы беренче тәэсирләр салынган шигъри авазларны, шигырь-репортажларны да кертер идем.

Икенчесе — эпик жанрлар. Әлеге омтылышлар — чынбарлыктагы вакыйгаларны фәлсәфи канунnarга буйсындырып, гомумиләштерү дәрәҗәсенә ирешә алган повесть-романнарда, пьесаларда. Р. Солнцевның «Яшел калкулыкта кызыл ат» повестенда, С. Хәкимнең «Дәверләр капкасы» поэмасында, Д. Вәлиевнең «Сиңа тормыш бүләк итәм» пьесасында тормышчан характерлар, кызыклы язмышлар, бүгенге көннең актуаль проблемалары күз алдына килеп баса. Авторлар тышкы яктан күренеп торган билгеләр белән генә мавыкмыйлар, алар кешеләрнең авырлыкларны җиңәҗиңә төзелешне җанландыруларын сурәтлиләр, шушы процесста төзелешнең дә кешегә тәэсир көчен, аннан ни рәвешле сынау алуын ачыклыйлар.

Өченчесе — лирика. Аның үзәгендә шагыйрьнең шәхси язмышын замандашлары башкарган зур эшләр белән чагыштырып карау ята. Күңел киңлекләре гигант төзелеш киңлекләре белән тәңгәлләшә. Бирегә гомуми төшенчәләр интим кичерешләр аша аңлашыла.

КамАЗ шагыйрьләренең 1981 елда Мәскәүдәге «Известия» нәшриятында басылып чыккан «Чаллы күгендә аккошлар» («Лебеди над Челнами») исемле җыентыгын нәкъ менә өченче төркемгә кертергә мөмкин[1].

Бу китапның «биографиясе» гадәти генә түгел. «Чаллы күгендә аккошлар»ның нәшрият планында булмавын һәм аның бары энтузиастлар тарафыннан гына эшләнүен

[1] Чаллы күгендә аккошлар. Шигырьләр. Рус телендә. М., «Известия», 1981.

әйтү дә моны ачык дәлиллиләр. Китап КамАЗны шефлыкка алган һәм төзелештә даими пост булдырган «Новый мир» журналы редакциясе хезмәткәрләре булышлыгы белән дөнья күрде. Җыентыкның редакторлары журналның җаваплы секретаре Феодосий Видрашку (укучыларыбыз аны «Новый мир» сериясендә чыккан күп санлы «Набережные Челны» китапларының даими авторы һәм редакторы буларак беләләр) һәм шул ук редакциянең әдәби хезмәткәре Арво Метс. «Известия» хезмәткәрләре китапны эш сәгатеннән тыш җәмәгатьчелек тәртибендә җыйганнар, версткa ясаганнар һәм бастырып чыгарганнар.

Ләкин китапның тарихы күп елларга алданрак — әле завод һәм шәһәр булачак урында экскаваторчылар беренче чүмеч балчыкны актартып ташлаган чаклардан ук башлана. Шул көннәрдә ВЛКСМ шәһәр комитетының элеккеге агач бинасына әдәби түгәрәк членнары җыйналалар. Аларны, монда әлбәттә, шигъриятькә мәхәббәт кенә түгел, КамАЗ шигырьсез төзелмәскә тиеш дигән инану да китергәндер. Иске Чаллы тирәсендә кар күмеп киткән басуларга беренче казыклар какканда, күккә ашачак йортларның нигезләренә беренче ташларны салганда геодезист Мәхмүт Газизовның (ул биредә КамАЗ төзелә башлаган көннән башлап), ремонт-инструмент заводы төзелешендә плитә җәюдә эшләүче Инна Лимонова, балта остасы Евгений Кувайцев, бетон-эремә заводы эшчесе Сәлимә Шәрипова һәм башка бик күпләр үзләренең КамАЗ турындагы тәүге шигъри юлларын иҗат иттеләр.

Ул — вагоннарда һәм палаткаларда төн уздырган чаклар, сазга-пычракка батып эшләгән даны көннәр иде. Юллар әлегә салынмаган, көзге пычракларда машиналар «муеннан» сазга чума, экскаватор казыган чокырларны яңгыр суы күмеп китә... Ә кыйммәтле материаллар илебезнең һәр тарафыннан һаман агыла тора, аларны кабул итәргә, бушатырга, урнаштырырга, гамәлгә кертергә кирәк.

«Чаллы күгендә аккошлар» китабындагы шигырьләр нәкъ менә брезент палаткаларда, вагоннарда яшәгән романтиклар тарафыннан язылган да инде. «Без үзебезне спецовка, сырма, резина итекләр киеп йөрергә хөкем иттек. Троллейбусларны вахта машиналарына алыштырдык».— КамАЗга Чиләбе шәһәреннән килгән Инна Лимонова бер шигырендә шундыйрак фикер әйтә. Аны бирегә нинди уй-хыяллар чакырган? Аның яшьтәшләрен нинди уй-теләкләр йөртсә, шагыйрә дә шул хисләр белән яши:

**Күңелемә бер таяныч эзләп,**
**Сиңа таба, Чаллы, йөгердем.**
**Кеше арасында «Мин — кеше!» дип**
**Расларлык көчләр бир идең![1]**

Хисләрнең кайнарлыгы соңрак та, «дала учында зәңгәрсу шәһәр» калкып чыккач та сүрелүне белми, ул һаман да «кояш керфекләре» иркәләгән, «алиһәләре иртүк уянып, асфальтны итекләре белән шакып йөргән» шәһәргә карап соклана (Вл. Потапов). Традицияләрнең дәвам итүе — җыентыктагы төп мотивларның берсе:

**Кем ялгыша: «Көрәш тынды...»— диеп!**
**Атоммашлар алда, алда — БАМ.**
**Якты ала БАМнар, Атоммашлар**
**КамАЗларда туган таңнардан.**

(М. Сафин)

Традицияләр дәвамы — намуслы хезмәтә. «Маңгай тирен чык тамчысы» итеп күргән тимерчелек цехы слесаре Ю. Малков хезмәткә дан җырлый («Гасырларны өя тупас куллар, кирпечләрне өя сак кына...»). Евг. Кувайцев та шул ук фикерне куәтли: «Чынбарлык итик хыялны,— кайда эшләр күбрәк, иңгә иң куеп басыгыз — фидакарьләр кирәк!» Җыентыкның тагын бер кыйммәтле ягы шунда: биредә әсәрләре белән катнашучы авторларның һәркайсы бөек төзелешкә азмы-күпме үзенең көчен куйган — кирпечләр тезгән, юллар салган, җир казыган, деталь кырган, тимер эреткән... Шигырьләр белән танышканда да шуны искәрергә мөмкин: әйтерсең, биредә төзелеш үзе шагыйрь булып сөйли, шагыйрь булып, һәм — беренче заттан.

Әлбәттә, КамАЗга килгән һәр кешенең юл чатларында эленеп торган плакат-щитларны күргәне бардыр, ул щитларда — КамАЗ шагыйрьләренең шигырьләре. Әлеге шигъри лозунглар үзләренең поэтик көче, ышанычлы булулары белән күңелне җәлеп итәләр.

Еллар үтү белән әдәби берләшмәдән мөстәкыйль ике түгәрәк аерылып чыкты: татар шагыйрьләренең «Ләйсән» һәм рус телендә язучыларның «Орфей» түгәрәкләре. Яшь шагыйрьләр тулай торакларда һәм клубларда, кызыл почмакларда һәм туры-

---

[1] Шигырьләр Хәйдәр тәрҗемәсендә бирелде.

дан-туры төзелеш мәйданнарында эшче яшьтәшләрен үз әсәрләре белән таныштыралар. Аларны һәрвакыт алкышлап каршылыйлар: чынлап та, төзелеш өчен чит-ят кешеләр түгел ич, үз кешеләр!

КамАЗга барган саен, мин «Ләйсән» һәм «Орфей» утырышларында булырга тырышам. Беренче карашка ук аларның кызу канлы һәм сүзне турыдан бәреп әйтергә яратуларын искәрергә мөмкин. Яшь шагыйрьләр төрле авторитетлардан куркып кала торганнардан түгел, кирәк икән, күңелләрендәге барлык уйларны сибеп ташларга да күп сорамыйлар. Алар белән сөйләшеп, бәхәсләшеп утыру кызык. Чак кына ясалма сүз дә яшь шагыйрьләрне чыгырыннан чыгара.

Җыентыкта катнашкан һәр шагыйрь профессиональ дәрәҗәгә ирешкән дип әйтергә җыенмыйм. Күбесе әйбәт журналистлар булып китте, кайберләре исә һаман да төзелештә һәм заводларда эшләрен дәвам итәләр. Лекин шигърият белән дуслашу һәммәсенең дә күңелендә тирән эз калдыргандыр дип уйлыйм. Һәрхәлдә, шигърият аларның күңелләрен рухи яктан баеткандыр, матурлыкны аңларга өйрәткәндер, тормышларына кызыклы вакыйгалар өстәгәндер.

Мактау сүзләренә генә бирешмичә, үзләренең көчләрен реаль мөмкинлекләр белән дә чагыштырып карау кирәктер, бәлки. Шуңа күрә җыентыктагы кайбер кимчелекләргә дә тукталып үтәсе килә.

«Чаллы күгендә аккошлар» җыентыгына тупланган шигырьләр һәммәсе дә бердәй дәрәҗәдә камил түгелләр әле. Кайберләре профессиональ яктан аксыйлар, коры сөйләп чыгу белән генә чикләнгәннәре дә очрый, күптән билгеле хакыйкатьне такъраплаучылар да бар, лозунг тәэсирен калдыручы шигырьләр дә шактый. Иң зур гөнаһ, минемчә, мөстәкыйльлек җитмәүдә, танылган шагыйрьләргә ияреп аларны кабатлауда. Әле Маяковскийның «баскычларын» хәтерләткән шигъри юлларга тап буласың, әле Есенинның моң-сагышлы авазы ишетелеп куя һ. б. Менә иң күзгә күренеп яткан кимчелек:

**Торналар да китте, тынды инде**
**Моңлы көйне уйнап торбалар.**
**Күтәрелә кебек төнге күккә**
**Рух булып кеше-торналар.**

Өлеге юлларны укыгач, Рәсүл Гамзатовның йөрәкне кысып алырдай шигыре искә төшә:

**Калмагандыр ятып ул солдатлар,**
**Калмагандыр канлы кырларда.**
**Очканнардыр алар зәңгәр күккә**
**Әверелеп ап-ак торнага!**

Аннары, кайбер яшь шагыйрьләрнең сүз белән сак эш итмәүләрен дә әйтеп үтәргә кирәктер. Кайчакта шундый гыйбарәләр күзгә чалына, аларның мәгънәсе елмаю уята. Мәсәлән, «чишмә улагында кер юалар кызлар» дигән юлларны укыгач, елмаймыйча ничек түзәрсең?! Чишмә улагында берәүнең дә кер юмаганын, бары тик керне чайкаганын гына һәммә кеше беләдер.

Мондый ялгышлар күп кенә авторларга хас булганга күрә, мин аларның исем-фамилияләрен бирәдә атап торуны кирәк санамыйм. Шулай да хәзер инде КамАЗ төзелешендә шагыйрьләрнең зур гына төркеме оешып килә дип ышанып әйтергә мөмкин. Чаллыда Язучылар союзының мөстәкыйль бүлеге ачылу да андагы яшь шагыйрьләрнең күпмилләтле совет әдәбияты мәйданына чыгуына булышлык итәр.

Татар шагыйрьләреннән Мәхмүт Газизов белән Хәниф Хөснуллин әсәрләрен аерып куярга теләр идем. Укучылар арасында исеме еш яңгырамаган Сәлимә Шәрипованың да каләменә өмет багларга кирәк. Рус телендә иҗат итүчеләрдән шагыйрә Инна Лимонованың уңышлары байтак. Күрәсең, җыентыкта иң күп урынның әлеге шагыйрәгә бирелүе дә юкка гына түгелдер. Әмма соңгы елларда Инна Лимонованың шигъри ачышлары шактый кимеде. Китапта Николай Алешков белән Павел Юлаев та күләмле генә шигъри цикллар белән катнашканнар. Аларның иң мөһим нәрсәне үзләштерүләре сизелә: дөньяга үзләренең карашлары бар, сүз белән эш итә беләләр.

КамАЗ шагыйрьләреннән күбесе яшь язучыларның VII Бөтенсоюз киңәшмәсенә барып кайттылар. Бишесе Мәскәүдәге М. Горький исемендәге әдәбият институтында укый. Белемгә омтылыш тагын шундый өмет уята: шагыйрьләрнең «беренче карлыгачлар»ыннан соң башка җыентыклары да дөнья күрер. Шикләнмичә әйтергә мөмкин, КамАЗ шагыйрьләргә мохтаҗ, әмма ул шагыйрьләрне үзе үстерә. Һәм алар, авыр йөк төялгән «КамАЗ»лар кебек, әдәбиятта үсеш тизлекләрен киметмәсләр.

**РАФАЭЛЬ МОСТАФИН.**

# КЕЧКЕНӘ РЕЦЕНЗИЯЛӘР

ХӘНИФ ХӨСНУЛЛИН. АЛТЫН ТОЯК. Шигырьләр. Татарстан китап нәшрияты, 1981.

Көтмәгәндә, уйламаганда үзем өчен яңа бер шагыйрь ачтым. Хәниф Хөснуллинның үзен күреп-очрашканда, аерым-аерым шигырьләрен укыганда һәм аның әлеге яңа җыентыгын кулга алгач та ул хакта уйламаган идем. Хәтта китапның беренче сәхифәсендәге шигырьне укып, ошатмыйча, аны байтак вакытлар кире кулга алмый йөрелгән. (Гомумән, китапны ничек төзү, нидән башлап, ничек тәмамлауга тиешле игътибар бирергә безнең күпчелек шагыйрьләр әлегә гадәтләнмәгән).

Чаллыда яшәп, Чаллыда эшләп иҗат итүче шагыйрьләр аз түгел. Арада кызыклылары һәм шактый танылганнары бар. Әмма алар башкалардан артык берни белән дә аерылып тормыйлар кебек. КамАЗ төзелешендә озак еллар дәвамында катнашып та, ни сәбәпледер, шул төзелешнең рухын, үзенчәлеген ачып бирә алмады кайберәүләр: туган авылларын сагындылар, котлованнарга төштеләр, биек йорт түбәләренә, краннарга күтәрелделәр. Әмма яңа төзелеш һәм яңа шәһәрнең кабатланмас шигъри үзенчәлеген таба алмадылар. КамАЗ хакындагы яңа сүзне анда вакытлыча гына командировкада булып киткән башка шагыйрьләр, беренче чиратта, С. Хәким һәм Р. Мингалимнәр әйтте. Һәм, ниһаять, көтмәгәндә, уйламаганда КамАЗ шагыйре Чаллының үзеннән калкып чыкты, ул — Х. Хөснуллин.

Х. Хөснуллинның үз биографиясе дә КамАЗны төзегән күп кенә башка замандашларныкы кебек.

**Без дә үстек авылларда,**
**Үстек атта чабышып.**
**Дәште булачак заводлар,**
**Дәште шәһәр тавышы.**

**Без барабыз урын карап**
**Заводлар каласына.**
**Куян куркып качты кинәт**
**Үләнлек арасына.**

Авыл егете Туган ил чакыруы белән гигант төзелешкә килгән, холык-фигыле, табигате белән авылныкы булса да, омтылышлары, хыял һәм максатлары белән ул КамАЗныкы. Һәр шигырьдән, Чаллы якларының рухын чагылдырган һәр строфадан әнә шундый хакыйкать күзгә карап тора. Юкса, зур төзелеш гөрелтесе башланган бер мизгелдә тынгысызланып чабулаган куянга игътибар итәр идеме, аның хәленә керер идеме башка берәү. Ташчы егетнең кирпечләргә суккалап алуына да «Каз томшыгын кага дисәм, шәһәрдә соң нинди каз?!» дип, соклана белмәс иде. Кыскасы, авыл кочагында формалашкан һәм тамыр җибәргән лирик җан һәр күренештән, колачлы индустрия картиналарыннан җылылык эзли, нәфислек һәм шигъри яңгыраш таба омтылып иҗат итә.

**Күгәрченнәр уйнап оча,**
**Тирбәлеп куя һава.**
**Кошлар юлына менгән дә**
**Йөкләр йөртә кыз бала.**

**. . . . . . . . .**

**Кранына тияр-тимәс**
**Очып үтә күгәрчен.**
**Кыз янында ак бәхете**
**Уйнап йөри, диярсең.**

Самими генә, гади генә юллар, чагыштырулар да табигый. Шул гадилек һәм табигыйлек артында чын шигъри штрихлар белән тудырылган гүзәл образлар тора. Яшьлек романтикасы һәм күңел җылылыгы белән өртелгән образлар. Аларга сокланмый карау мөмкин түгелдер кебек — танышлар да, бер үк вакытта, күпмедер дәрәҗәдә серлеләр дә. Шушы танышлык һәм бераз гына серлелек яшьлекнең, шигъри гәүдәләнеш тапкан яшьлекнең үзе була түгелме икән...

**Бер чибәр бүлмә акшарлый,**
**Җырлары чыңлап тора.**
**Кояш әллә эшен карый,**
**Әллә җыр тыңлап тора.**

**. . . . . . . . .**

**Шәфәкъ монда алсу-алсу,**
**Алма манып алырлык.**
**— Бу да синең эшме? —**
**диеп**
**Кыздан сорап калырлык.**

Кемгә ничек, белмим, әмма миндә Х. Хөснуллинның сүзләр белән шулай җинел, пөхтә эш итүе, гадилектән дә гүзәллек таба белүе чын-чынлап соклану тойгысы уятты. Аның наивлык чигендә генә булган ихласлыгы шигъри бер җылылык бөркеп тора, үзенә җәлеп итә.

Әмма шагыйрьне яңа төзелеш барган җирдәге каршылыкларны күрмәү, тоймауда да гаепләргә ашыкмыйк. Кубарылып атылган агачлар, хуҗасыз калган йорт һәм капкалар аның күңелен дә нечкәртеп алмый түгел. Күңелгә тия, ләкин чаң сугуны урынсыз дип саный, дөньяга аек акыл белән карый шагыйрь: «Үткәннәр якын күңелгә, Киләчәк — кадерлерәк». Тормышның, үсешнең үз закончалыклары бар. Шуны ачык тою, шагыйрьне урынсыз офтану, зарлануалардан азат итү, тормышка, үзгәрешләргә оптимистларча карый белергә өйрәтә. Нәтиҗәдә, шагыйрь иҗатында яңалык тойгысы бар нәрсәдән өстенрәк калкып чыга. Китапка оптимистик рух һәм якты нур чәчеп торган ул тойгы, бигрәк тә, «Безгә үз җырыбыз кирәк», «Яңа то-

елә» кебек шигырьләрдә шагыйранә чагылыш тапкан.

«Алтын тояк» дип исемләнгән китап аерым кимчелекләрдән дә азат түгел, әлбәттә. Әйтик, КамАЗ калар төзелешендә яшәгән шагыйрьнең ил масштабындагы борчу һәм уйлануларга килеп чыкмавы, үзен мәҗбүр итеп дигәндәй таррак рамкаларда чикләргә омтылуы, тормышыбызның табигый асылын характерлаучы халыклар дуслыгы, бердәмлек һәм туганлык төшенчәләрен искә алмавы җитди җитешсезлек булса кирәк. Китапның тышлыгын эшләгән художник та төсләр сайлауда зәвыксызлык күрсәткән — өр-яңа китап моннан илле-алтмыш еллар элек дөньяга чыгып таушалып беткән тузанлы кәгазь кисәген хәтерләтә. Бер жанр сыман, шигырьләрне юл саныннан чыгып бүлү принцибы да соңгы вакытта еш кабатлана торгач тәмам туйдыра башлады...

Кимчелекләр бәлки тагы да бардыр, әмма алар һич кенә дә күңелдәге матур тойгы һәм хисләрне капларлык түгел. Хәниф Хөснуллин — Чаллы шагыйре! «Без батырлык кылдык микәнни соң? КамАЗ гына салдык нибары...» — дип, тыйнак кына җырлаган шагыйрь күңел түрендә урын дәгъваларга сәләтле әсәрләр иҗат иткән. Бары тик шул ачыш, куаныч белән генә уртаклашу иде теләгем.

Ринат **МӨХӘММӘДИЕВ.**

●

---

РАЗИЛ ВӘЛИЕВ. БЕЗ — КОЯШ БАЛАЛАРЫ. Шигырьләр. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1981.

---

Балаларның киләчәге — һәрвакыт өлкәннәр кулында. Аларны шушы катлаулы тормышта гадел итеп, намус белән яшәргә өйрәтү — олыларның изге бурычы. Тәрбия бирүнең төрле чаралары бар. Шигърият — шуларның берсе.

Һич тә арттырып әйтү түгел: кечкенәләргә атап шигырь язу шактый ук катлаулы һәм җаваплы эш. Балалар белән уртак тел таба алу, беренчедән, шагыйрьнең дә сабый күңелле булуын, сабыйларны эчкерсез яратуын таләп итсә, икенчедән, ул — табигать күренешләренең, тормыш вакыйгаларының асылын гади итеп һәм бала үзе эшләгән яхшылыкларны хуплап яки хаталарын аның күңелен яраламыйча гына аңлата белү дә дигән сүз.

1981 елда Татарстан китап нәшрияты шагыйрь Разил Вәлиевнең «Без — кояш балалары» исемле шигырьләр җыентыгын бастырып чыгарды. Бу — авторның балаларга багышланган икенче китабы.

Р. Вәлиев озак еллар буе «Ялкын» журналы редакциясендә эшләде һәм шактый тәҗрибә туплап өлгерде. «Без — кояш балалары» исемле китабын шагыйрь иҗатының «Ялкын»да эшләү дәверенә үзенә күрә бер йомгагы дип карасак, һич тә ялгышмас идек. Җыентыкка тупланган шигырьләр әлеге фикернең дөреслеген раслый.

Шагыйрьнең балаларга сөйләр сүзе күп, ләкин сүз күплеге китапның эчтәлек сыйфатына зыян ясамаган. Р. Вәлиев балалар психологиясен ныклап үзләштергән, алар белән ничек һәм нәрсә хакында сөйләшергә кирәклеген ачык белә. Шигырьләр балалар шигърияте таләпләренә җавап бирерлек кызыклы вакыйгаларга, самими юморга, образлы сурәт-рәсемнәргә бай.

«Без — кояш балалары» китабы шул исемдәге шигырь белән башланып кита:

**Алсу битләр — ал кояштай,**
**Без — кояш балалары!**

Әлеге юллардан балаларча беркатлылык, күңел җылысы бөркелеп тора. Алсу битне ал кояш белән чагыштырып, шагыйрь сиздермичә генә «Без — кояш балалары!» дип зур гомумиләштерү ясап куя. Бу шигырьне кайда гына укысаң да — зәмһәрир кыш кенендәме, самолетта очканда яки поездда баргандамы — салкыннан күшегүләреңне оныттырып, шау-шуларны күмеп кинәт кенә иркен болында шатланып уйнап йөрүче балалар күз алдына килеп басалар. Ирексездән балачак елларына — балыклары йөзеп йөргән елга-күлләргә, кошлары сайрап торган урман-болыннарга әйләнеп кайтасың, күңелдә берәм-берәм якты хатирәләр калка... Һәм шушы хис укучыны китапның башыннан ахырынача озата бара.

**Җил шаяра, җил котыра,**
**Күгәрчен кебек гөрли.**
**Орчык алып утыра да**
**Көн буе җебен эрли.**
**Кабасына болыт элгән,**
**Эрли дә эрли шуны.**
**Ак булсын, ди, пакь**
**булсын, ди,**
**Кыш бабасының туны.**

Әлеге сурәт-рәсемне балалар яратып кабул итәрләр. Болыттан җеп эрләүче җил образы артык җете булмаган буяулар белән төгәл һәм уңышлы тасвирланган. Мондый шигырьләр баланың фантазиясен үстерергә ярдәм итә, табигатькә ихтирам белән карарга өйрәтә. Күктә болытлар пәйда булуын — «күкнең зәңгәр болынында казларның үсә агы», урманның юмартлыгын — «кызыл җиләк булып пешә урманның һәр шатлыгы», җемелдәп яуган карны — «бу карлар болыттан түгел, йолдыздан, ахры, яуган», кызарып кояш баюын — «күзе кызарган кояшның — йокысы килә бугай», суга иелеп үскән талларны — «тал кызлары, ярга ятып, юа яшел толымын», язын җирнең яшеллеккә күмелүен «җир әйләнә яшел кошка,— җир канатлана», дип тасвирлау, әлбәттә, бала күңеленә уелып кала һәм ул үзе дә һәр күренештән шундый матур сурәтләр эзли башлый.

Балалар холкындагы кимчелекләрне — ялкаулану, алдашу гадәтләрен, курку хисләрен, һичшиксез, аларның үз яшьтәшләре авызларыннан сөйләнгән көлкеле вакыйгалар белән

генә бетерергә мөмкин. Менә «Тәрбияле малай» шигыре. Урам буйлап көтүдән ашыга-ашыга сыер кайтып килә. Сыер үзе сөт-каймак белән сыйласа да, мөгезе Азатны азрак шөлләтә. Һәм Азат куркуыннан койма башына үрмәли.

**Кызлар көлде.**
**Ул кычкырды:**
**«Мин куркак түгел алай.**
**Мин бит сыерга юл бирдем,**
**Мин — тәрбияле малай».**

«Без — кояш балалары» китабында мондый гыйбрәтле шигырьләр байтак тупланган. Аларда без дәресен әти-әнисеннән, әбисеннән эшләтүче, «ике»ле алгач: «Әби «икеле алды...»— дип акланучы малай белән дә, «Шапшак булмам, гөрләвекне алсагыз әгәр юлдан»,—дип шарт куючы тәртипсез белән дә, кар яудырып кыярларны өшүдән саклап калырга теләүче ялкау белән дә очрашабыз.

«Мәңгелек ут», «Октябрь», «Май кояшы», «Ирек хакына», «Берлинда совет солдаты», «Мәңгелек яз» кебек патриотик хис белән сугарылган шигырьләр исә китап эчтәлегенең кыйммәтен бермә-бер арттыралар. Әлеге әсәрләр Туган илгә, бәхетле илебезгә мәхәббәт тәрбияли. «Җырлар җырга бәйләнсен» бүлегенә кертелгән җырлар да шул рухта үк иҗат ителгәннәр.

Әлбәттә, китапта урын алган шигырьләр бердәй дәрәҗәдә камиллеккә ирешкән дигән нәтиҗә ясау бигүк дөреслеккә туры килеп бетмәс иде. «Уенчыклар», «Җир буйлап барам», «Яңгырасын бөтен илгә», «Максат» кебек бер төркем шигырьләр сәнгатьчә эшләнеп җитмәгән, абстракт фикерләүгә корылган, шуңа күрә аларның мәгънәсе балалар күңеленә барып җитмәскә дә мөмкин. Ләкин китаптан алган гомуми тәэсирне болар гына үңдыра алмый. Шагыйрьнең балаларга әзерләнгән бүлэгенең адресы: «Сабыйлар иленә».

**Хәйдәр ГАЙНЕТДИНОВ**

---

РӘШИТ БӘШӘР. ЯШЕЛ ОКЕАН. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1981.

---

Олы кеше ничек итеп балалар өчен шигырь яза ала икән? Бу — һәркемнең кулыннан килә торган эшме? Мондый сорауларга җавап бирү өчен гомеребезнең «чишмә башы»на — балачакка караш ташламый мөмкин түгел. Балачак — даһи чор ул, гаҗәеп чор, бу хакта педагоглар һәм психологлар күп язды инде. Галимнәр аңлатуынча, тормыштагы һәм табигатьтәге һәр җисем, һәр күренеш сабый күңелендә фантастик буяулар белән баетыла, эмоциональ бизәкләр белән беркетелә. Әйе, гадәттән тыш кызыксыну, соклану, гаҗәпләнү хисе кебек сыйфатлар, үсә төшкәч, кем әйтмешли, «акыл теше» чыкканнан соң әкренләп кими, югала бара, җитдилек белән алмашына. Әмма балачак һәркемне дә бер үк дәрәҗәдә ташлап китми. Кайберәүләр сабыйчагы бүләк иткән сыйфатларның бөртеген дә югалтмый, гомере буе бала җанлы булып кала. Балалар шагыйренең рухи нигезен, талант дәрәҗәсен шушы җирлектә аңлатырга кирәктер дә.

Рәшит Бәшәрнең яңа китабы белән танышып чыкканнан соң әлеге фикергә тагын да ныграк ышанасың. Китап мәктәпкәчә яшьтәге балаларга, димәк, хәреф таный башлаучы нәни дусларыбызга дип адресланган. Әлбәттә, шартлы билгеләмә бу. Андагы шигырьләрне мәктәп яшендәге балалар да яратып укыячаклар. Чөнки тормыштагы сабый җанлы Рәшит үзенең шигырьләрендә дә бала булып кала, балаларча яза. Шагыйрьнең иң отышлы сыйфаты да шунда, минемчә. Ул ихлас сөйли, әйткән сүзе ышандыра. Нәни аю баласының хәрәкәтләрен, үз-үзен тотышын гына карагыз әле сез:

**Тиз-тиз атлап килде дә**
**Су салды юынгычка.**
**Сабын тотты кулына,**
**Булмый, ди, юынмыйча.**

Аю баласы черкиләр белән уйнап йөри, җиләк өзә, чигүле сөлгесенә битен сөртә, әнисенә чәй кайната... Кыскасы, кайсы шигырьдә нинди генә вакыйгалар турында сөйләнмәсен, алар бар да балалар психологиясенә, аларның фикер сөрешенә, кылган гамәлләренә тәңгәл килеп тора. Бу инде әдәби осталык, авторның яшь укучылар белән уртак тел таба белүе дигән сүз.

Балага «бала» дип кенә карарга ярамый. Ул — иң актив, иң хәрәкәтчән, фантазиягә иң бай шәхес. Әйе, шәхес дип әйтү гаҗәпләндермәсен. Корней Чуковский балаларны «бөек һәм эшчән» халыкка саный, «аларның 99 проценты — шагыйрьләр»,—дип тә өсти. Димәк, нәни укучыларга дөньяның катлаулылыгын күрсәтеп, аңлатып бирүдән, образларның шартлылыгыннан курыкмаска кирәк. Әйтик, нәни героебыз болытлы тауларны йөк төягән өркәчле дөягә охшата икән, яисә челләдә тирләгән талларга бит сөртергә кульяулык бирмәкче икән,— авторның мондый шигъри табышларын хупларга гына кала. Балаларның уйлау сәләтен, хыял тирәнлеген нәкъ менә шундыйрак әсәрләр үстерә дә инде.

«Тайгада» дигән шигырьдән бер мисал укып китәсе килә:

**Бөркү иде тайгада,**
**Ә биредә җил исә...**
**Лена ярына басып**
**Зәңгәр «КамАЗ» су эчә.**

Болан яисә поши су эчә дисәк, биредә тамчы да шигъри яңалык булмас иде, әлбәттә. Ә инде, «КамАЗ» су эчә» дигәндә, шушы гап-гади генә сүзләр кинәт очкынланып, балкып китә, әллә никадәрле яңалык төсмере белән яктыра. Шунысын да әйтеп үзу кирәк: тайга вакыйгалары килеп керү китапның тематик офыгын шактый киңәйткән. Ләкин, «яшел океан» вәгъдә итеп тә, тулаем алганда, автор тайга дип аталган әлеге океанның читендәрәк йөри, укучысын уртага алып керүдән читләшә.

Юкса тайга образын тулырак һәм эзлеклерәк бирү өчен әдәби материалга кытлык юк шикелле.

Хәрәкәт! Вакыйга! Драматургиядәге шикелле, балалар поэзиясенә дә шушы ике нәрсә зарури. Шигырьнең беренче юлларында ук хәрәкәт һәм вакыйга күренми икән, бу — су өстенә рәсем ясарга азаплану белән бер! Балалар өчен язылган күп кенә шигырьләребез, шул сыйфатлардан мәхрүм булу сәбәпле, ни нәниләргә, ни олыларга эстетик ләззәт бирә алмый. Рәшит Бәшәрне аерым пьедесталга бастырып куярга җыенмыйм, әмма шунысы хак: аның кечкенә генә шигырьләрендә дә хәрәкәт тыпырдап тора, вакыйгалар агышы өстенлек итә.

Китапта «Болан», «Июнь», «Болындагы ат» кебек йомшак шигырьләр дә урын алган. Бәшәр иҗатында күзгә ташланып торган кимчелекләрнең берсе — тормышны мажор авазлар белән генә аңлату, тыныч һәм гаугасыз дөнья белән чикләнеп калу. Ә бит баладан яшәү каршылыкларын, яхшылык янында явызлык, батырлык янында куркаклык кебек нәрсәләр барлыгын яшермәскә иде. Алар кечкенәдән үк күп нәрсәне аңлап, өйрәнеп үсеннәр.

Татар балалар шигърияте исемнәргә бай. Аларның һәркайсы үзенчә яза, тормыштагы матурлыкны үзенчә тоя. Әйтик, Шәүкәт Галиев иҗатына тапкырлык, шаянлык, көтелмәгән борылышлар хас булса, яшьрәк буын шагыйрьләрдән Роберт Миннуллин вакыйгаларны юмор белән сыгылмалырак итеп бирергә тырыша. Рәшит Бәшәр исә үзенең иҗат манерасы белән берсенә дә охшамаган. Әйткәнебезчә, аның шигырьләрендә балаларча сафлык, дөньяга гаҗәпләнеп һәм ратып карау хисе өстенлек итә. Үз йөзен киләчәктә дә саклый белсен, югалтмасын иде ул!

Рәшат **НИЗАМИЕВ**.




**Татарстан атоммашы шулай башланды.**

К. Ситдиков фотосы.

Гүзәл Вәлиева,
сәнгать фәннәре кандидаты

# ТЕРЕКЛЕК АГАЧЫ

## Чаллы һәм Түбән Кама шәһәрләрендә — декоратив сәнгатьнең яңа бизәкләре

Агачны сырлап нәкыш төшерү — татар халкы арасында борын-борыннан киң таралган һөнәр. Аның үзенчәлекле серләре, гасырлар тирәнлегеннән килүче ныклы традицияләре, остадан остага күчеп, бүгене сәнгатькәрләр иҗатында дәвам итә һәм үсеш ала. Республикабыз рәссамнары нәкыш сәнгатенең гадәти кысаларын киңәйтергә омтылалар, заманча биналарның интерьерын төзүдә, монументаль-декоратив композицияләр иҗат итүдә яңадан-яңа мөмкинлекләр табалар. Агачны кырып бизәк төшерү сәнгатенә мөрәҗәгать итү, үз чиратында, рәссамнарыбыз иҗатына халык иҗаты мотивлары һәм образларының килеп керүен дә көчәйтә.

Җәмәгать биналары интерьерында агач нәкышыннан киңрәк файдалана башлау 70 нче елларда төзү-бизәү эшләрендә табигый материалга игътибар арту белән бәйләнгән. Бүгенге декоратор-рәссамнар агач эшкәртүнең традицион алымнарына — яссы рельефны һәм өчкырлы уентылы нәкыш сәнгатенә йөз тоталар. Алар өчен нигездә юкә яисә зирек, ә сирәгрәк очракларда — нарат һәм каен төп материал булып хезмәт итә. Шушы рәвешле иҗат ителгән паннолар гадәттә бердәм композициягә буйсындырылган аерым кисәкләрдән төзелә.

Борынгы сәнгать традицияләренә, осталар туплаган тәҗрибәгә таяну Ә. Фәтхетдинов һәм Р. Круглякова кебек рәссамнарны яңа иҗади ачышларга рухландыра. Аларның әсәрләре Чаллыдагы һәм Түбән Камадагы күп кенә җәмәгать биналарының интерьерына ямь биреп тора.

Чаллы һәм Түбән Кама калаларында уку йортларын һәм культура учаклары биналарын бизәү эшенә аеруча зур игътибар бирелә. Нигездә типовой проектлар буенча салынган бу йортларга монументаль-декоратив сәнгать әсәрләре ярдәмендә башкалардан матур булып аерылып тору мөмкинлеге тудырыла. Балалар бакчаларында һәм мәктәпләрдә исә монументаль-декоратив сәнгать әсәрләре интерьерны художестволы оештыруның бердәнбер чарасы булып тора.

Чаллыда булган һәркем заманча төзелгән «Энергетик» Культура сараена игътибар итми калмый. Ә аның тамаша залына керү белән, балконнарны бизәп торучы декоратив панно үзенә җәлеп итә. Рәссам Р. Круглякова башкарган бу хезмәт — агачка сырлап бизәк ясау традицияләренә таянуның матур бер үрнәге. Балконнарның өчпочмаклы рәвеше панноның аерым кисәкләрен яктылык контрасты белән дә ассызыкларга мөмкинлек бирә. Өчкырлы уентылы нәкыш квадрат формасындагы тиң үлчәмле блокларга төшерелгән. Ритмик кабатланып килүче бизәкнең үзеген түгәрәк розетка хасил итә. Аның тирәсенә арадаш бизәкләр булып ваграк орнамент чалымнары тупланган. Нәкышның геометрик рәсеме интерьерның туры почмаклы архитектур формалары белән, аларның ритмы белән ярашып килә.


Халык нәкыш сәнгатендә чәчәк-үсемлек рәсемнәре һәм геометрик фигураларның даими бизәк булуы мәгълүм. Р. Круглякова иҗатында капка баганаларын, тәрәзә

бизәлекләрен, такта белән тышланган өй почмакларын бизәү өчен кулланыла торган формалар яңа төсмерләре белән ачылып киткәндәй була. Күп нурлы түгәрәкләр, балкышлар һәм ярымбалкышлар — бик борынгы заманнарда ук, Идел болгарлары сәнгатендә формалашкан, төбендә кояшка, утка табыну белән бәйле борынгы символика яткан формалар. Алар безнең халыкта күп очракта мөстәкыйль файдаланылсалар да, турыпочмаклы яисә квадрат яссылыкларга төшерелеп, артык зур булмаган композицияләр төшкил итәргә дә мөмкиннәр.

Рәссам халык иҗаты хәзинәсеннән белеп, кадерләп файдалана, аның аерым төрләренә яңа сыйфатлар өстәргә омтыла. Аерым алганда, ул туку сәнгатенә хас бизәк формаларындагы контрастлылык принцибын һәм композицион чишелешләрне уңышлы куллануга ирешә. Р. Круглякова һәр мотивның күпсанлы үзенчәлекле вариантларын иҗат итә. Иске мотивлар яңалары белән аралашып килә, алар, халык сәнгатендәге кебек үк, гомумиләштерелгән төстә, ерактанрак карауга исәпләп төзелгән. Ритм тигезлеге, композицион ачыклык һәм бөтенлек, халыкчан бизәк формаларыннан иҗади файдалану һәм масштаблылык интерьерның архитектур таләпләре үзенчәлекләренә туры килерлек, аңа тантаналы төс бирерлек итеп сайланган. Композицион бурычлар системасын хәл итүгә әсәрнең бөтен ритмик һәм пластик төзелеше буйсындырылган. Җиңелчә генә шомартып ялтыратылган агачның табигый төсе, күрер күзгә гади генә булып тоелган үзенчәлекле пластика залдагы гомуми җиһазланыш белән ачык контраст төзеп, интерьерның гадәти архитектурасына ямь бирә.

Агачка уеп ясалган композицияләрне интерьерда файдалануның башка алымы — аларны аерым декоратив паннолар рәвешендә стенаның төрле урыннарына элеп кую. Шул рәвешле, агач нәкышлы паннолар белән интерьер арасындагы сәнгатьчә бәйләнешларның яңа мөмкинлекләре ачыла. Бу бәйләнешләр сюжет композицияләре, орнамент үзенчәлекләре һәм халык иҗаты чалымнарын оста файдалану ярдәмендә көчәйтелә.

Халык иҗатына нигезләнгән сюжетлар бигрәк тә балалар учреждениеләре урнашкан биналар өчен бизәүдә киң кулланыла. Агачтан уеп эшләнгән «Шүрәле» исемле панно, мәсәлән, Түбән Кама шәһәрендәге 21 нче балалар бакчасының җанлы почмагын бизәп тора (рәссам Ә. Фәтхетдинов эше, 1974 ел). Үлчәмнәре белән артык зур булмаган бу әсәр күз биеклегендә генә урнаштырылган һәм ачык төстәге стена җирлегендә аерылып тора. Төп өлешен табигать элементлары (яшеллек, су һ. б.) алып торган интерьерга панно үзеннән-үзе кушылып китә, аны тулыландырып җибәрә.




Сюжет композициясенең үзәгендә — милли әкият герое Шүрәле образы. Ләкин, халык әкиятләрендәгечә усал һәм хәйләкәр җан иясе булудан бигрәк, ул биредә яхшы күңелле, юаш, хәтта бераз беркатлырак та «урман сарыгы» итеп сурәтләнә. Бары бер генә деталь — озын бармаклар гына Шүрәленең хәтәр шуклыгы турында искә төшереп тора. Шүрәле сурәте сырлап ясалган бизәкле композицияләр белән уратып алынган. Урман пейзажын хәтерләтүче бу бизәкләр уртасында — төп персонажның характерлы сыйфатлары ачылып китәрлек җанлы, төгәл сызыклар: озын сакал белән кушылып бер бөтен тәшкил итүче кул-аяклар... Гомумиләштерелгән эре формалар ерактанрак карауга исәп тотып кулланылган.

Панногa кертелгән мәче башлы ябалак сурәте композиция кисәкләрен сюжетлы итеп бергә бәйли. Мәче башлы ябалак сурәтен ясау халык сәнгатендә шулай ук киң таралган форма, ул башлыча чигешләрдә, тукып эшләнгән әйберләрдә, агачка сырлап бизәк төшерүдә еш очрый. Урман кошлары патшасы халыкның шигъри иҗатында акыллылык һәм хәерлек мәгънәсен гәүдәләндерә. Фольклор әсәрләрендәге кебек үк,

ул гомуми төстә, контурлар белән генә сурәтләнгән. Шүрәле образын тасвирлаганда исә, материал һәм техника мөмкинлекләрен исәпкә алып, нечкәрәк төсмерләргә игътибар бирелә төшә. Композицион-декоратив максатларны күздә тотып, чәчәк-үсемлек формалары, нигездә, шартлы бизәк итеп файдаланыла. Рәссам техника һәм материал белән иркен эш итә, агачның табигый сыйфатларына зур эстетик мәгънә йөкли.

Агачны сырлап эшләнгән бик үзенчәлекле композиция Чаллыдагы 5-08 нче балалар бакчасының музыка бүлмәсен дә бизәп тора. Биредә рәссам Р. Круглякова традицион сәнгать формасын иҗади куллана. Әсәрнең сюжет композициясе уңдырышлылык, тормышның яңаручы мәгънәсен аңлатучы «тереклек агачы» һәм аның ике ягындагы икешәр пар кош рәвешендә төзелгән. Бу борынгы форманың символик мәгънәсе бик күп халыклар өчен уртак булса да, Р. Круглякова тәкъдим иткән композицион сурәттә ул милли тамырларга барып тоташа. Билгеле булганча, «тереклек агачы» һәм пар кошлар болгар сәнгатендә үк киң таралган, татар халык чигүендә (алтын укалы калфакларда, сөлге очларында), агачка, металлга бизәк төшерүләрдә сакланып килгән.

Композиция гомумиләштерелгән символик мәгънәдә, шартлы формада бирелгән булса да, реалистик сурәтләргә нигезләнгән. Традицион форманы рәссам үз ачышлары белән баета алган. Ул композицион төзелеш принцибына да иҗади якын килгән. Борынгы мотивтан тышкы композицион схема гына сакланып калган. «Агач» өстән дә, астан да бизәк белән төгәлләнгән кәүсә рәвешендә тасвирланган. Ботаклар куе яфрак һәм эре җимешләр белән бизәлгән. Кәүсә өслегендә ритмик төстә кабатланып килүче кыр күбәләкләре игътибарны җәлеп итә. «Агач» ябалдашы астында ике рәт итеп гомумиләштерелгән күгәрчен сурәтләре урнаштырылган. Традицион кош мотивы рәссам иҗатында шулай ук яңа мәгънәсе белән ачыла: әсәрнең темасын билгеләүдә катнашучы бу кошлар кешенең күңел күгенә омтылучы музыкаль аһәңнәрне гәүдәләндерәләр.



Рәссам иҗатының үзенчәлеген татар халык сәнгатеннән аермалырак булган нәкыш төшерү техникасында да күрергә мөмкин. Композициядә күләмлелеккә, фактуралылыкка ирешергә омтылу сизелә. Ләкин бу әсәр, телгә алынган барлык матур сыйфатларына да карамастан, интерьерның гомуми структурасыннан беркадәр аерылып тора. Ул үзенең тәэсир көчен саклаган хәлдә бүтән архитектур җирлеккә дә күчерелә алыр иде. Биредә интерьерның архитектур-композицион үзенчәлекләрен һәм аның компонентларын исәпкә алуның никадәр мөһим булуын тагын бер кат искә төшерәсең. Әйе, әсәрдә иҗади файдаланыла торган традицион форма заманча архитектурага авазда булсын дисәң, бик күп таләпләрне үтәү зарури.

Бүгенге интерьер, аның таләпләре агачны сырлап эшләнгән сәнгать күренешләренең яңа жанрлары туугa сәбәпче була. Агач нәкышына нигезләнгән төрле конструкцияләрне бергә ябыштырып стенаны тоташтан каплау, мәсәлән — әнә шундый яңа җилләр исүнең бер нәтиҗәсе. Идәннән түшәмгә кадәр ябыштырылган рельеф куллану рәссамнар алдына әлегә кадәр чишәргә туры килмәгән бурычлар да куя. Җәмәгать биналарының эчке бизәлешендә идея эчтәлеген арттырырга омтылу сюжетлы тематик әсәрләр иҗат ителүгә җирлек әзерли. Бу яктан алганда, Чаллыдагы 3-13 нче мәктәп ашханәсенең интерьеры игътибарга лаек (рәссамнар Л. Владыкин, П. Ядрышников, 1975 ел). Унбиш квадрат метрлы панно бер як стенаны идәннән түшәмгә кадәр биләп, ашханә залын композицион берләштереп тора. Бизәкләр төрлелеге, нәкыш чалымнары интерьерга ачык һәм мәгънәле төс бирә.

Паннода тасвирланган сюжет нигезенә халык арасында киң таралган Сак белән Сок турындагы борынгы риваять мотивлары салынган. Билгеле булганча, ул риваятьтә әти-әниләре каргагач, имештер, кошка әверелеп нигезләреннән аерылган тыңлаусыз балалар турында сүз бара.

Рәссамнарның традицион композиция алымнарына таянулары күренеп тора: контрастлылык принцибына, орнаменталь җирлеккә мөрәҗәгать итү, халык иҗатында киң таралган роза, гөлҗимеш, төнбоек кебек чәчәкләргә өстенлек бирү дә әнә шуннан килә. Алар шулай ук халык иҗатына якын образларны, аерым алганда тавис кошын сурәтләгәндә традицион формаларны баетырга омтылалар. Шулай итеп, халыкчан традицияләргә һәм бер үк вакытта профессиональ сәнгать казанышларына таянучы рәссамнарыбыз иҗатында үзенең асылы белән халыкчан, заманча образлар мәйданга килә.

Халык иҗатында орнамент мотивлары еш кына очракларда билгеле бер символика белән бәйләнгән булса, бүгенге рәссамнар әсәрләрендә ул бизәкләр яңа мәгънә, яңа эчтәлек белән байый — тормыш матурлыгын, табигать хозурлыгын гәүдәләндерә.

Татарстан монументаль сәнгать әһелләренең югарыда карап үтелгән әсәрләре агачны сырлап бизәк төшерүдә халыкчан традицияләрнең үзләштерелүен бу юнәлештә яңа тенденцияләр билгеләнүен һәм художество чаралары үсешен күзәтергә мөмкинлек бирә. Агач нәкышлы паннолар иҗат итү тәҗрибәсе аларны интерьер белән бәйләү принципларын (пространствоны яссы һәм оптик сурәтләү) һәм архитектурада урнаштыруның төрле композицион алымнарын (пластик акцент, ябыштырылган рельеф белән тулысынча каплау) ачык күрсәтә. Архитектура белән рельефның бергә кушылып, бербөтен тәшкил итүендә фольклор традицияләренә, халык сәнгате мотивларына таяну да зур роль уйный.

Рәссамнарыбыз иҗатында халыкчан бизәкләрдән, аеруча чәчәк-үсемлек нәкышлары хәзинәсеннән, аларның бай символикасыннан файдалану зур урын тота. Халык орнаментлары белән эш итүдә һәр рәссамның үз алымы күзгә ташлана. Ә. Фәтхетдинов белән Р. Круглякова, мәсәлән, табигатьнең, әйләнә-тирә мохитның чынбарлыктагы формаларыннан гомумиләштерелгәнрәк, шартлырак формаларга таба йөз тоталар һәм бу юлда халык сәнгатенең традицион алымнарына таяналар. Сәнгатьчә формага җегәр, кискенрәк контраст кертергә омтылу бизәкләрнең төгәллегенә һәм җителәнүенә китерә.

Агачны сырлап эшләнгән әсәрләрдә яссы чишелешләрдән качу тенденциясе ачыграк сизелә бара. Рәссамнарыбыз тирән рельефтан файдаланырга, зуррак пластиклык тудырырга тырышалар. Шул ук вакытта сурәтләр реализмын көчәйтү, композицияләрнең мәгънәсен баету һәм тирәнәйтү юнәлешендә нәтиҗәле эзләнүләр алып барыла. Халык сәнгате казанышларын иҗади үзләштереп, Татарстан рәссамнары зур әһәмияткә ия булган әсәрләр иҗат итәләр. Ул әсәрләрнең Чаллы кебек яңа калаларда заманча биналарны бизәү өчен кулланылуы, бер яктан, халкыбызның сәнгать традицияләре уңышлы дәвам ителүе һәм үстерелүе, икенче яктан, аларың яңа төсмерләр белән баеп, замандашларыбызның зәвыгын үстерүдә катнашуы, тормышыбызны бизәве хакында сөйли. Бу «тереклек агачы» тамырлары белән халык сәнгате хәзинәсенә, ябалдашы белән киләчәгебез көгенә тоташкан.

## Рәшит Бәшәр

### Кызык булыр иде, ә?

Кызык булыр иде, ә!
Юлбарыслар урамда
Рәхәтләнеп йөрсәләр.
Печенье, конфет эзләп,
Кибетләргә керсәләр.

Кызык булыр иде, ә !
Маймылларым урамда
Атынсалар агачта.
Уйнарлар иде әле
Кешеләр йоклагач та.

Кызык булыр иде, ә!
Читлекләрнең һәммәсен
Ачтырыр идем дә мин,
Аю, тиен, куянны,
Тәңкәчуар боланны
Качырыр идем дә мин,
Зуп-зур зоопаркның
Хуҗасы булсам әгәр.

Кызык булыр иде, ә?!

### Чишмә

Йөз мең кояш бар монда,
Килегез дә санагыз,
Без аларны меңәрләп,
Чиләкләргә салабыз.

Зәңгәр күктән космонавт
Абый да төшәр әле.
Ул да безнең чишмәнең
Суын бер эчәр әле.

### Йокы килә

...Башта әтием китәр,
Әни белән без аннан
Җитәкләшеп бакчага
Ашыгырбыз урамнан.—

Аз гына йоклыйм әле
Эшкә китеп барганчы:
Хәл җыеп калыйм бераз...
Уйный-уйный арганчы.

●

Бакча. Кич.
Җил кагылды әз генә,
Утырып пәрәвезгә
Очты китте үрмәкүч.

# ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

## ЮЛБАШЧЫБЫЗ ИСТӘЛЕГЕНӘ

Казанда бөек юлбашчыбыз В. И. Ленинның тууына 112 ел тулуга багышланган сәнгатьләр фестивале үткәрелде. Һәр елны уздырыла торган традицион фестивальнең билгесе шул ягы белән үзенчәлекле: бу сәнгать бәйрәме СССРның төзелүенә 60 ел тулуга әзерләнгән көннәрдә узды.

Фестиваль Казан дәүләт консерваториясенең Актлар залында «Безнең дуслык — мәңгелек» дигән зур концерт белән башланып китте. Халыклар дуслыгын гәүдәләндергән бу концертта, рус, татар композиторлары, тугандаш Казагыстан, Грузия, Үзбәкстан, Тажикстан, Молдавия, Латвия, Каракалпакстан һәм башка республикалар композиторлары әсәрләре яңгырады.

Фестиваль көннәре республикабыз театрлары һәм Культура сарайларында үткәрелгән күпсанлы концертлар, спектакльләр, иҗади очрашулар, шулай ук үзешчән сәнгать көчләренең чыгышлары белән истә калды. Бөек юлбашчыбыз идеяләренең тантана итүе фестивальнең төп лейтмотивы булып яңгырады.

## ИҖАТ КОНФЕРЕНЦИЯСЕ

Казанның Актерлар йортында «Рус драматургиясе милли театрлар сәхнәләрендә» дигән темага зона иҗат конференциясе булды. Бөтенроссия театр җәмгыяте һәм аның Татарстан бүлеге оештырган әлеге конференциядә Мәскәүдән, Уфа, Йошкар-Ола, Чабаксардан килгән театр белгечләре, республикабызның театр эшлеклеләре катнашты. Аны кереш сүз белән Татарстан АССР культура министры И. Н. Алиев ачты. Конференциядә сәнгать фәннәре докторы М. Н. Строева, Бөтенроссия театр җәмгыятенең милли драматургия кабинеты мөдире А. Я. Вольфсон, театр белгечләре А. А. Якубовский, Е. А. Зубкова (Мәскәү), сәнгать фәннәре кандидаты И. И. Иляхова (Казан), Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының баш режиссеры М. Х. Сәлимҗанов чыгыш ясадылар.

Конференция эшендә КПСС өлкә комитетының культура бүлеге мөдире М. М. Мусин катнашты.

*

* *

12 мартта Мәскәүдә, СССР Язучылар союзы секретариатында, «Дружба народов» журналы буенча фикер алышу үткәрелде. Союздаш һәм автономияле республикалардан чакырылган язучылар журнал редакциясенең эшенә, анда соңгы елларда басылган әсәрләргә бәя бирделәр. СССР Язучылар союзы идарәсе секретаре Г. Ахунов утырышта чыгыш ясап, журналның эшен яхшырту буенча тәкъдимнәр кертте.

*

* *

17 мартта РСФСР Язучылар союзы идарәсе секретаре Г. Ахунов РСФСР Язучылар союзы секретариаты утырышында катнашты. Шагыйрьләр К. Латыйпов, Х. Әюпов, Р. Низамиев, драматург Ф. Садриев, прозаик Ү. Саттаров һәм тәнкыйтьче Р. Кукушкин СССР язучылар союзына кабул ителгән бу утырышта Г. Ахунов чыгыш ясады һәм әлеге әдипләр иҗатына бәя бирде.

*

* *

17 мартта ТАССР Язучылар союзы идарәсе председателе, «Современник» нәшриятының редакция советы члены Г. Ахунов нәшрият үткәргән киңәшмәдә катнашты һәм чыгыш ясады. Анда 1983 елга нәшриятның эш планы расланды. Планга татар язучыларының проза, поэзия әсәрләре кертелде.

*

* *

18 мартта РСФСР Язучылар союзының киңәйтелгән Пленумы булды. СССР төзелүгә 60 ел тулу уңае белән үткәрелгән бу Пленумда Татарстаннан Г. Ахунов, З. Нури, И. Юзиев, Т. Миңнуллин, Ф. Миңнуллин, М. Хәбибуллин, Г. Рәхим, Р. Хәмид һәм Р. Вәлиев катнаштылар. Пленумда ТАССР Язучылар союзы идарәсе председателе Г. Ахунов чыгыш ясады.

*

* *

СССР төзелүгә 60 ел тулу уңае белән, Мәскәү курчак театры өчен шагыйрь Р. Мингалим һәм Е. Крюков, татар фольклорына нигезләп, яшүсмерләр өчен махсус пьеса иҗат иттеләр.

Март аенда «Карурман» дип аталган әлеге пьеса буенча эшләнгән спектакльнең премьерасы булды. Спектакльдә күренекле татар композиторы Ф. Яруллин музыкасы файдаланылган, аны сәхнәгә режиссер Д. Плоткин куйган. Премьерага ТАССР Культура министры урынбасары Р. Харис та чакырылган иде. Ул спектакль иҗат итүчеләрне кайнар котлады, театр коллективына уңышлар теләде.

## ГАБИТ МӨСРЕПОВ ЮБИЛЕЕ

25 мартта Алма-Ата шәһәрендә Социалистик Хезмәт Герое Габит Мөсреповка 80 яшь тулуга багышланган тантаналы

җыелыш булды. Анда Советлар Союзының төрле өлкәләреннән кунаклар килгән иде. Күренекле казакъ язучысын тәбрикләргә безнең республикадан язучы Г. Ахунов барды. Казакъ дәүләт опера һәм балет театрында уздырылган әлеге җыелышта Г. Ахунов котлау сүзе белән чыкты, олы әдипкә Татарстан язучыларының сәламен һәм истәлек бүләкләрен тапшырды.

## БАЛАЛАР КИТАБЫ АТНАЛЫГЫ

Укучыларның язгы каникул чорында балалар китабы атналыгы үткәрелде. Бу — илебез күләмендә ел саен үткәрелә торган традицион бәйрәм. Бәйрәм 23 март көнне Казанның Пионерлар сараенда тантаналы төстә башланып китте. Атналык барышында ТАССР Язучылар союзының балалар әдәбияты секциясе актив катнашты. Язучыларыбыз Ш. Рәкыйпов, Ш. Галиев, Т. Миңнуллин, Р. Фәйзуллин, Р. Батулла, Н. Беляев, Р. Миңнуллин, Р. Хәлиуллина, К. Кәримов, Җ. Дәрзамановлар Казан шәһәренең күп кенә мәктәпләрендә, курчак театры бинасында һәм пионерлар йортларында чыгыш ясадылар. Каникул дәвамында язучылар Зеленодольск, Саба, Балтач, Әлмәт, Чаллы һәм башка район укучылары белән дә очраштылар.

Балалар китабы атналыгы СССР төзелүнең һәм В. И. Ленин исемендәге Бөтенсоюз пионер оешмасының төзелүенә 60 ел тулуга багышлап үткәрелде.

## КИНЕМАТОГРАФИСТЛАР ПЛЕНУМЫ

Татарстан Кинематографистлар союзы идарәсенең пленумы булды. 1981 елгы эш йомгаклары һәм КПССның XXVI съезды карарлары яктылыгында республикабыз кинематографистлары алдында торган бурычлар турында доклад белән иҗат союзы идарәсенең беренче секретаре И. Н. Алексеев чыкты. Пленумда ТАССР Кинематографистлар союзы идарәсенең 1982—1983 елларга иҗат һәм оештыру эше буенча чаралары тикшерелде. Пленумда Татарстан Язучылар союзы идарәсе председателе Г. Ахунов чыгыш ясады.

Пленум эшендә КПСС өлкә комитетының культура бүлеге мөдире М. М. Мусин катнашты.

## ОЧРАШУЛАР

*
* *

Тәнкыйтьче Ринат Мөхәммәдиев Мәскәү шагыйре Игорь Лапин белән Монголия Халык Республикасында булып кайтты. Ул Улан-Батор шәһәрендә узган «Шигърият тынычлык сагында һәм гражданлык» дип исемләнгән халыкара конференциягә чакырылган иде. Ул конференциядә радио һәм телевидение аша чыгышлар ясады, Монголиянең яшь шагыйрьләре иҗатын тикшерүдә катнашты, ил буйлап сәяхәт итте.

*
* *

1 мартта Казанда, сәүдә работникларының культура йортының китапханәсендә язучы Н. Дәүли белән очрашу булды. Әдип үзенең яңа шигырьләрен укыды, киләчәккә планнары белән уртаклашты.

*
* *

5 мартта «Ливадия» санаториясендә «Каһәрләнгән мәхәббәт» операсы турында сөйләшү үткәрелде. Санаториядә дәваланучылар янына операны иҗат итүчеләр композитор Б. Мулюков, шагыйрь Г. Рәхим һәм төп рольләрне башкаручыларның берсе Р. Дәминов белән концертмейстер Н. Гусева килгәннәр иде.

*
* *

5 мартта Куйбышев исемендәге «Тасма» производство берләшмәсенең культура йортында «Татар әдәбияты һәм сәнгатендә хатын-кыз образы» дигән темага әдәби-музыкаль кичә үткәрелде. Кичәдә язучылар Р. Фәйзуллин, Г. Рәхим, Р. Кәрами, Ф. Шәфигуллин, Ә. Гадел, композитор Б. Мулюков, җырчылар М. Галиев, З. Сәхәбиева, Р. Сәхәбиев, К. Хәйретдинова, музыкантлар Р. Халитов, А. Имаев һәм башкалар катнашты.

*
* *

11 март көнне Биектау районының «Алга» колхозына язучылар килде. Ш. Галиев, И. Юзеев, Т. Миңнуллин, А. Яхин колхозчылар белән очрашып, үз әсәрләре белән таныштырдылар, сорауларга җавап бирделәр. Әдәбият һәм тормыш турында кызыклы сөйләшү булды. Үзешчән сәнгать көче белән хәзерләнгән зур концертта шагыйрьләрнең җырлары, шигырь һәм поэмалары башкарылды.

Язучылар Зур Битаман урта мәктәбе укучылары белән дә очраштылар.

*
* *


12 мартта язучы М. Скороходов «Васильевский» ял йорты һәм санаториясендә чыгыш ясады. Илебезнең төрле почмакларыннан килгән ял итүчеләр һәм дәваланучылар аның чыгышын яратып тыңладылар.

*
* *

Язучы Ш. Рәкыйпов Казанның 80 нче мәктәбе укучылары алдында чыгыш ясап, «Кайдан син, Җан?» повестенең икенче кисәге турында сөйләде, укучыларны кызыксындырган сорауларга җавап бирде.

*
* *

13 мартта язучы һәм тәнкыйтьче Р. Мостафин Химиклар культура сараеның китапханәсендә VII—VIII класс укучылары белән очрашты. Казан шәһәре Мәскәү районының төрле мәктәпләреннән җыелган балалар аның патриот-шагыйрь Муса Җәлилгә багышланган чыгышын зур игътибар белән тыңладылар.



Түбән Кама пейзажы.

Н. Курамшин фотосы.

Бәясе 90 тиен.
Цена 90 коп.

Индекс 732

## КИЛӘСЕ САНДА:

*Проза*

М. Хәбибуллин. **Сулар үргә акса да.** Роман

М. Галиев. **Ерак урман авазы.** Повесть

*Поэзия*

Р. Харис, Г. Афзал, Х. Әюпов. Шигырьләр

*Очерк һәм публицистика*

М. Зарипов. **Сыеры барның сые бар.** Очерк

*Әдәби тәнкыйть*

Ф. Мусин. **Дуслык, туганлык җепләре.**

*Матбугат һәм культура*

Г. Шәрәфетдинов. **Китап — чорыбыз көзгесе**

**КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)** ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал, орган Союза писателей Татарии